

Данил Салихов



# Гыйләҗ тәрәзәләре

*Пьесалар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)–4
С 18

**Салихов Данил**

С 18 Гыйләҗ тәрәзәләре: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 286 б.

Драматургның бу китабына соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре тупланды. Автор пьесаларда бүгенге тормышыбыз турында уйлана. Ә яшәешебездә булган кайбер проблемалардан каһкаһәле көлә.

ISBN 5-298-01413-5 ©Татарстан китап нәшрияты, 2004

# Ак күгәрчен

*Драма ике пәрдәдә, унике күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Ибраһим.
Нәнкир.
Мөнкир.
Сәмигулла — Ибраһимның атасы.
Гөлсем — Ибраһимның анасы.
Җәмилә — Ибраһимның хәләл җефете.
Мәрфуга — Ибраһимның сөяркәсе.
Сирай — Ибраһимның сабый чак дусты (12 яшьтә).
Гыйләҗи — Ибраһимның күршесе.
Сәйфетдин — мәрткә киткән кеше.
Әгъләметдин Әһлетдинович — районның социаль-көнкүреш мәсьәләләре буенча хакимият башлыгы урынбасары.
Мулла.
I сабый.
II сабый.
III сабый.
I карт.
II карт.
III карт.
Хур кызлары, хур егетләре, тәмуг кисәүләре, район халкы.

Вакыйгалар Җирдә һәм Мәңгелектә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, сәхнәдә әйтеп аңлата алмаслык гүзәл әкияти табигать почмагы. Тау битләрендә, кыя башларында алма, хөрмә, әфлисун — җаның нәрсә тели, бар да бар. Кыя башларыннан алып тау итәгенә чаклы аллы-гөлле чәчәкләр белән үрмә гөлләр үсеп утыра. Бөтен тирә-якка ямь өстәп, оҗмах кошлары сайрый. Кыяның төрле урыннарында, төрле биеклектә ап-ак бәзгә төренгән берничә хур кызы арфада салмак кына көй башлыйлар. Җәннәт кошлары сайраудан тыналар. Аста, тигез үзәнлектә, шундый ук киемнәрдән хур кызлары һәм хур егетләре салмак кына бииләр. Аларның өслә-

рендәге киемнәрен җил уйната. Алар төрле төсләрдәге прожектор яктысында үзгәрәләр. Аста, алгы планда, кәфенлектә бер төркем халык утыра. Әкрен генә көй тына. Сәхнәне, аннары тамаша залын сихри тавыш баса. Сәхнәдәге барлык әрвахлар, урыннарында катып, тынып калалар. Ут сүнә. Алгы якны прожектор яктырта.

Өстән, югарыдан, алтыннан коелган кәрзингә утырып, Нәнкир белән Мөнкир төшәләр. Аларның кулларында сургуч мөһер сугылган, түгәрәкләп төрелгән боерык. Кулларын өскә күтәрәләр, буш кәрзин өскә менеп югала. Боерык кәгазьләрен сүтәләр.

Мөнкир (*тамашачыга*). Дөньялыкның Куян елында...
Нәнкир (*тамашачыга*). Арыслан йолдызлыгында...
Мөнкир. Унбишенче сәнәсендә...
Нәнкир. Ун сәгатьтә...
Мөнкир. Ундүрт минутта...
Нәнкир. Илле өч секундта...
Мөнкир. Җир йөзенә сынау шарты белән җибәрелгән...
Нәнкир. Гыйззәтулла углы Сәмигулла...
Мөнкир. Сираҗетдин кызы Гөлсемнең...
Нәнкир. Уртак никахы аша җан өрелгән...
Мөнкир. Сәмигулла углы Миңлеибраһим...
Нәнкир. Аллаһы Тәгаләнең боерыгы белән...
Мөнкир. Җир йөзендә кырык биш ел да унике көн, унбиш сәгать, унөч минут йөреп, Мәңгелек йортына кайтты.

Нәнкир, Мөнкир (*икесе бергә*). Хөрмәтлебез?! Гозерегезне үтәдек, хозурыгызга кабул итегез! (*Башларын түбән ияләр.*)

Сәхнәне томан баса, сихри көй башлана. Нәнкир белән Мөнкир, томанны ярып, кыялар артына кереп югалалар. Әрвахлар уяна.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Томан таралганда, сәхнәнең нәкъ уртасында кап-кара туфлидән, кәфеннән, кызыл галстуктан, тамашачыга карап, Ибраһим ята. Ул күзләрен ача. Күзе туфлиләренә төшә.

Ибраһим. Вот сволочь хатын!.. (*Ят җирен капшап карый.*) Анадан тума чишендергән, туфлиләремне салдырмаган. (*Туфлиләрен уйнатып.*) Һе, туфли! Нәрсә, ул мине теге йорттагы бозык кызлар дип уйлады микән әллә?! Яшь хатын яшь хатын инде. Үзенә кирәген салдырган, туфлиләрне калдырган. Уф, буылып, бастырылып үлә яздым. (*Күзе галстугына төшә.*) Галстугымны да салдырмаган бәреп үтерәсе нәрсә. (*Галстугын салмакчы була, янына салмак адымнар белән очкан халәт ясап, пышылдый-пышылдый кысрыклап килгән әрвахларны күреп, курка-курка алга үрмәли.*)

Гөлсем (*пышылдап*). Улым, балакаем, Миңлеибраһимым!..

С ә м и г у л л а *(пышылдап)*. Кайттыңмы, балакаем?

И б р а һ и м *(үз-үзенә)*. Мин кайда?.. *(Куркудан кычкырып.)* Хатын!.. Хатын, Айсылу, атаңның аты коргыры, син кая олактың?! Уяналмыйм. Бастырылам, чемет әле?!

Г ө л с е м. Улым, Миңлеибраһимым, тәүфыйклы бул.

И б р а һ и м *(курыккан хәлдә)*. Булырсың сезнең белән тәүфыйклы!

С ә м и г у л л а. Балакаем, син Ходай йортында.

Җ ә м и л ә. Бу дөньялык түгел, монда сүгенергә ярамый.

Г ы й л ә җ и. Ярамый...

С и р а й. Ярамый...

Җ ә м и л ә. Сүгенергә ярамый...

И б р а һ и м. Сүгенмәссең сезнең белән. Прямо бугаздан алдыгыз. Улым, улым, Илфак, Зөфәк, уятыгыз әле мине?! Айсылу, тип әле миңа, бастырылам.

Г ы й л ә җ и. Сал, сал муеныңдагы элмәгеңне! Элмәгеңне сал, Ибраһим. Элмәккә менгәннәрне, үз-үзенә кул салганнарны биредә кичермиләр. Элмәккә менгәннәргә биредә тәмуг!

Кыя башында тутый кош тоткан I с а б ы й пәйда була.

I с а б ы й. Әти, син мине таныйсыңмы?

М ә р ф у г а. Ибраһим, Ибраһимчик, таныйсыңмы, ул безнең улыбыз.

Кыяның икенче җиреннән II с а б ы й күтәрелә.

II с а б ы й. Син минем әти.

Кыяда III с а б ы й күренә.

III с а б ы й. Минем дә әти...

И б р а һ и м *(аягындагы ботинкасын кулына ала да сикереп тора. Ярсып)*. Анагызны! Бабагыз түгелме?! *(Үз-үзенә.)* Таптылар юаш кеше. Ярый әле, төш кенә. Өнеңдә бу кадәр балаң булса, алименттан башың чыкмас. Әле аның җир өстендә йөгереп йөргәннәре дә җитәрлектер. *(Маңгаен кулы белән сөртеп ала.)* Уф, бастырылып үлә яздым. Кая олаккан соң бу биләмче хатын? Айсылу! Илфагы белән Зөфәген дә әйтер идем инде, валлаһи, үлгәндә иреңнә су да тидермәсләр.

Җ ә м и л ә. Үзең гаепле. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр!

И б р а һ и м *(Җәмиләне күреп, сискәнеп)*. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, моннан унҗиде ел элек үлгән хатыным күземә күренә. *(Башын чайкап куя.)* Күпмеләр әйттем шул завхоз Галәветдингә: «Алма, алма шул Гыйләҗ кибетеннән аракы, аракы түгел, самапал сата ул»,— дип. Юк, тыңламады. Менә хәзер ят инде мәетләр белән саташып. Махмыры ничек булыр әле...

Күзне ачкач та, җен-пәриләр күренә. Шундый чакта юньлерәтле төше дә керми бит аның.

Җәмилә. Булды, Ибраһим, шаярма. Монда шаярырга ярамый.

Ибраһим. Кем шаярадыр әле...

Җәмилә. Биредә маймылланганны яратмыйлар.

Ибраһим. Ярый, мин маймыл. Ә син үзең кем?

Җәмилә. Җәмилә!

Ибраһим. Моннан унҗиде ел элек җир өстендә конькиларыңны ташлап качкан Җәмиләме?!

Җәмилә. Әйе, Җәмилә.

Ибраһим. Моннан унҗиде ел элек миңа ике ыштансыз малай калдырып качкан Җәмиләме?!

Җәмилә. Әйе. Синең никахлы хатының, Зөфәк белән Илфакның аналары — Җәмилә.

Ибраһим *(үз-үзенә)*. Хәзерге аракы нишләтми?! Ну боздылар, ну боздылар аракыны. Утырган җиремнән төш күреп утырам бит. *(Җәмиләгә.)* Бөкрең кая?

Җәмилә. Дөньялыктагы бөкреме?

Ибраһим. Әйе, дөньялыктагы бөкрең!

Җәмилә. Сине укытам, кеше итәм, диеп тормыш йөген тартканда чыккан бөкремне әйтәсеңме?! Ходай аны, миннән алып, хуҗасына тапшырам, диде.

Ибраһим. Кеше бөкресе кешегә ябышмый, сафсата! *(Тамашачыга.)* Бу похмельдән күзгә нәрсәләр генә күренми. Моннан бишбылтыр үлгән атаң белән култыклашып йөрсәң дә гаҗәпләнмәссең.

Сәмигулла. Мин монда, улым Миңлеибраһим.

Ибраһим. Әллә белогорячка башланды инде?..

Сирай. Мин дә монда, Ибрай...

Ибраһим. Ә син кем? Что за птичка?! Мин сине белмим.

Сирай. Беләсең. Мин бу, мин — Сирай... Синең сабый чак дустың, Сираҗетдин!

Ибраһим. Сираҗетдин?.. Мин сине хәтерләмим.

Сирай. Мишә буенда, таллар арасында уйнап үскән, каз оясы белән балык сөзгән...

Ибраһим. Тишек ыштанлы Сирай... Ышанмыйм! Тишек ыштаның кая, хәерче Сирай?! Кем сиңа бирде бу затлы киемнәрне?! Каян чәлдең?!

Сирай. Оҗмах!

Ибраһим. Оҗмах?! Сиңа тагын оҗмах! Күкәй карагы Сирай. Каракка оҗмах тәтеми. Хәмдүнә әбинең кетәклегеннән соңгы мая йомыркасына кадәр чәлдергән бәндә дә оҗмахка эләккәч, монда килүнең нинди кызыгы бар. Сирай икәнсең, Сирай бул, черт с тобой. Төшемә кергәнсең икән, файдаң тисен, чемет әле мине, Сирай! Уянасым килә.

С и р а й. Чеметсәм дә сизмәссең. Монда авыртканны сизмиләр.

И б р а һ и м. Сабый чак дустың, сабый чак дустың... Син Сирай түгел, син — җен! Сирай ул юмарт иде. Сирай ул, ач булса да, үз икмәген хайваннарга, судагы балыкларга бирә иде.

С и р а й. Телисеңме, исеңә төшерәм.

И б р а һ и м. Ничек итеп?

С и р а й. Икәү генә белә торган җырны җырлыйм.

И б р а һ и м. Икәү генә белә торган?..

С и р а й. Әйе. Теге чакта, таллыкта син мине тәмәке тартырга өйрәткәндә, икебез чыгарган җырны...

И б р а һ и м. Ну-ка, ну-ка?..

С и р а й *(җырлый)*.

Ак тавыгым бар иде,
Йомыркасы ак иде.

*(Ибраһимга.)* Йә, йә, дәвам ит.

И б р а һ и м *(кушылып җырлый башлый)*.

Безнең дә бит туып үскән
Туган җирләр бар иде.

*(Үз-үзен чеметә башлый.)* Авыртмый. Валлаһи, авыртмый. Тәнем берни дә сизми. *(Кычкырып елап җибәрә.)* Айсылу, Айсылу, кая олактың син, Айсылу, дим?! Айсылу, «скорый» чакырырга кирәк! Точно миндә белогорячка башланган. *(Янына салмак адымнар белән Мәрфуга килә.)*

М ә р ф у г а. Ибраһим, Ибраһимчик... Монда Айсылу юк. Син хәзер Мәңгелектә. Синең өчен җир өстендә калган Айсылу да, Гөлсылу да, Нәзирә дә, Сәлимә дә, Галимә дә юк. Синең өчен бу йортта бары тик мин генә бар.

И б р а һ и м. Син?!

М ә р ф у г а. Әйе, мин! Мин синең яраткан Мәрфугаң!

И б р а һ и м. Потың бер тиен! Исән чагында туйдырганың да бик җиткән, төшемә кереп азаплама.

М ә р ф у г а. Алай димә, Ибраһимчик. Миңа син җитмисең. Синең куеның җитми. Миңа — синсез, сиңа минсез салкын булыр бу тәмуг утларында. Кил, кил минем яныма.

И б р а һ и м *(куркып читкәрәк китә)*. Килгән диярләр. Читтәрәк торуың хәерлерәк.

М ә р ф у г а. Кил, кил, син минем куен җылысын беләсең.

И б р а һ и м. Рәхмәт инде, кыстама. Болай да шыбыр тирдә.

М ә р ф у г а. Синең урының безнең арада. Синең урының улыбыз Габдуллалар арасында түгел.

И б р а һ и м. Улыбыз, улыбыз... Нинди ул?! Минем синдә балам булмады.

М ә р ф у г а. Әнә, әнә ич... *(I сабыйга күрсәтеп.)* Карынымда килеш синең кушу, минем теләк белән дөньялыкны күрми Мәңгелеккә кайткан сабыебыз, Габдуллабыз. Андыйларга

Ходай үзе Габдулла дип исем куша. Әнә, әнә ул безнең ялгышыбыз Габдулла.

Ибраһим. Габдулла, Габдулла... *(Тамашачыга карап, ялварып.)* Чеметегез мине?! Уятыгыз мине?! Минем уянасым килә. *(Үз-үзенә.)* Сабыр, сабыр, сабыр, Ибраһим. Синдә белогорячка. Сине җеннәр котырта. Тәрәзәдән, тәрәзәдән сак бул, Ибраһим. Белогорячка тәрәзәдән сикертә, диләр. Кулыңа пычак ала күрмә, Ибраһим. Юри котырталар, җеннәр котырта. Җеннәргә кадыйм дип, хатыныңа, балаларыңа кадый күрмә. Нык бул. Үзеңне-үзең кулга ал, Ибраһим. *(Шаркылдап көлеп җибәрә.)* Ә мин сездән курыкмыйм! Ә мин кулыма балта алмыйм.

Гөлсем. Син авыру түгел, әрвахлар авыру булмый. Синең авыруларың, үткән юлың җир өстендә калдылар.

III сабый. Син авыру түгел, син...

I сабый. Син гөнаһлы, әти.

Сәмигулла. Озакламый Мөнкир килер...

Сирай. Нәнкир килер...

Сәмигулла. Ай, сорау алырлар...

Сирай. Ай, алырлар...

Гыйләҗи. Тизрәк муеныңдагы элмәгеңне салып ташла. Менә мин дә элмәккә менгән өчен гүр газапларында янам.

Ибраһим. Китегез, кит, күземә күренмәгез! Мин терелэм, мин бу газаплардан барыбер арынам.

Җәмилә. Соң инде.

Ибраһим. Соң инде?.. Нәрсә, минем җир өстендә эшләгән бер генә эшем дә саваплы булмаганмыни?! Нәрсә, миңа төшемдә генә булса да оҗмах күрергә Ходай насыйп итмәгәнмени?! *(Хур кызларын күреп.)* Менә сез!.. Сез, чибәркәйләр, керегез минем төшләремә. *(Хур кызына үрелә, куллары катып кала.)* Коткарыгыз, коткарыгыз! Кулларым күтәрелми!.. *(Икенче хур кызына.)* Нәрсә карап каттың. Кер, кер минем куеныма! Минем куен — серле урман. Җиләкле аланнары да, чәчәкле болыннары да бар. *(Өченче хур кызына үрелә.)* Син дә кер! Нәрсә, керсәм чыгалмам дисеңме?! *(Күкрәгендәге йонын сыйпап.)* Нәрсә, мондагы шүрәлеләр кытыклап үтерер дисеңме?! *(Дүртенче кызга.)* Син дә читтә калма. Минем куеным чибәркәйләр өчен иркен. Сездәй чибәрләр бу куенда күп эределәр. Әгәр куен җылым җитмәсә, байлыгым җылытыр. Мин бай! Мин бизнесмен! Эшкуар мин! Барысын да сатып алам. Оҗмахын да, кирәк икән, тәмугын да... Мин әле яшь. Уятыгыз, уятыгыз мине. Минем уянасым, кеше буласым килә.

Әрвахлар *(барысы бергә пышылдап)*. Соң, соң инде...

Әкрен генә сихри көй агыла башлый, сәхнәне томан баса. Әрвахлар томанга кереп югалалар. Сәхнәдә аптыраган хәлдә Ибраһим гына басып кала.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Томан таралганда, арткы якта, биеклектә, кыя башында, Нәнкир белән Мөнкир пәйда булалар. Сихри көй тына.

Мөнкир. Гыйззәтулла углы Сәмигулла...
Нәнкир. Сираҗетдин кызы Гөлсемнең...
Мөнкир. Уртак никахы аша...
Нәнкир. Җир йөзенә сынау шарты белән...
Мөнкир. Кырык биш елга...
Нәнкир. Унике көнгә...
Мөнкир. Унбиш сәгатькә...
Нәнкир. Унөч минутка җибәрелгән...
Мөнкир, Нәнкир *(икесе бергә)*. Сәмигулла углы Миңлеибраһим...

Нәнкир. Мәңгелек йортыңа, Ходай хозурына кайтканыңа инандыңмы инде?!

Ибраһим. Сез кемнәр?! Что за орлы?! Барыгыз, бар, юлыгызда булыгыз! Кеше куркытып, кызлар өркетеп йөрмәгез! Юньле-рәтле төш кенә күрә башлагач, козгын кебек кыя башына менеп, кызлар өркетү егетлек түгел.

Нәнкир. Сәмигулла углы Миңлеибраһим...

Ибраһим. Кырык биш ел Ибраһим.

Мөнкир. Син Мәңгелек йортыңа кайтуыңа инандыңмы?!

Ибраһим. Юк! Сез бигрәк кызык. Алдан чакыру юк. Барасыңмы, юкмы, дип сорау юк. Әштер-өштер иске ботинка кидерәләр дә, галстук тактырып, йокыдан да уятмыйча, алалар да китәләр. Җирдән адәм рәтле оркестр уйнатып, халык җылатып, машиналар туктатып озату юк. Без җирдә ни өчен яшибез?! Үз гомеребездә бер генә тапкыр булса да, үлгәч мактарлык өчен! Юньле-рәтле каршы алу юк, банкет юк, банкеттан соң кызлар юк та юк, что за бардак? Нинди оешма бу?! Нинди оешмаганлык?!

Нәнкир. Сәмигулла углы Миңлеибраһим...

Мөнкир. Җир йөзендә сиңа сәлам биргән, синнән сәлам алган таныш-белешләрең, туган-тумачаларың белән соңгы тапкыр хушлашу тантанасына чакырабыз.

Ибраһим. Рәхмәт инде, зурладыгыз, сарык кына суймадыгыз. Тантанага чакырдыгыз, чакыру билетын гына җибәрмәдегез!

Матәм маршы яңгырый, ут сүнә.

Ут янганда, сәхнәдә, кабер янында өч карт, мулла һәм Әгъләметдин Әһлетдинович басып тора.

Мулла. Җәмәгать, өстенә туфрак төшерә башласагыз да ярыйдыр.

Ибраһим *(үзе күренми, микрофоннан елабрак)*. Ташламагыз, районадашлар, ташламагыз! Зинһар, туганнар, ташламагыз! Минем күмеләсем, җирләнәсем килми.

Мулла. Җәмәгать, мәрхүмне соңгы юлга озату тантанасын башлыйбызмы?

Ибраһим. Нәрсә ди?! Тантана диме?! Вот карт ишәк. Шушы тинтәккә мәчет ачып бирдем бит.

I карт. Башлыйк, хәзрәт, башлыйк.

Ибраһим. Туктагыз әле, сабыр итик, халык аз бит.

II карт. Башлыйк, башлыйк, килмәгән халыкны эт өстереп кусаң да, килми инде ул.

Мулла. Әллә бераз көтикме? Малайлары килмәсме?

I карт. Юк, килмиләр. Байлык өчен канга батып сугышып яталар. Байлык бүләләр.

Ибраһим. Вот сволочьлар! Аталарына башы кәкрәйгән иске ботинка кидереп озаттылар да хәзер мал бүлешәләр диме?!

Мулла. Ярый, җәмәгать, бик ашыгам, вакытым юк, кичә көтүдә кәҗә тәкәмнең аягына сыер баскан, шуны кайтып бәйлисем бар.

Әгъләметдин Әһлетдинович. Дөрес, хәзрәт, дөрес, вакытны әрәм-шәрәм итеп булмый. Үземнең дә бакчамны каларада корты басты. Кайтып бәрәңгедән корт җыясым бар.

II карт. Аллага тапшырыйк, хәзрәт.

III карт. Ашыкмыйк әле. Әнә Түбән очтан өч кеше чыкты, монда килмиләр микән.

I карт. Юк, юк, монда килмиләр. Юньле-рәтле кешене җирләргә дә хәзер кеше табып булмый.

Ибраһим. Яхшылыкны оныткан карт иблис. Мунча директоры булып эшләгәндә, кылган яхшылыкларымны оныткан. Ялынып-ялынып сорагач, пиче сүтелгән мунчага кертеп, район тарихында калдырганымны оныткан. Шул мунча аркасында күпме популяр булып яшәде. Күпме үзе турында анекдотлар чыгардылар.

Мулла. Ходайга тапшырам.

II карт. Башла, хәзрәт.

Мулла. Җәмәгать, безнең арабыздан Мәңгелеккә киткән Сәмигулла улы Миңлеибраһим әйбәт кеше идеме?

Барысы бергә. Әйбәт кеше иде, әйбәт кеше.

Ибраһим. Әй сез, аты коргыры, кемнәр әле?.. Нәнкир бе-

лән Мөнкир, протоколыгызга язып куегыз, әнә әйбәт кеше иде, диләр.

Мулла. Җәмәгать, үзегез күрәсез, беребез дә бу якты дөньяга мәңгегә килмәгән. Кайчан да булса барыбыз да анда барасы. Гаделлек, дөреслек ул йортта. Адәм балаларының Мәңгелек йортында...

Ибраһим. Гаделлек, дөреслек... Сиксәнне куасың, бер дә анда барырга ашыкканың күренми. Мине, кырык биш яшьлек Ибраһимны җирләргә ашыгасың.

Мулла. Менә Сәмигулла абзыйның улы Миңлеибраһимны да җир куенына салдык. Мин инде сезнең вакытыгызны алып, Коръән, ясинны кабер өстендә укып тормам, дөресен генә әйткәндә, мәетне күтәреп алып чыгарга кеше булмау сәбәпле, мәет күтәргәндә, тәһарәтем бозылды. Кайтып тәһарәтемне яңарткач укырмын. Арагызда мәрхүмгә карата әйтәсе сүзләрегез юкмы?

Әгъләметдин Әһлетдинович. Бар, бар, хәзрәт. Минем әйтәсе сүзләрем бар.

Мулла. Сүз районыбызның социаль-көнкүреш мәсьәләләре буенча хакимият башлыгы урынбасары иптәш Әгъләметдин Әһлетдиновичка бирелә.

Ибраһим. Сволочь глава, үзе килмәгән, мин синең крышаң, дип күпме акчамны сауды.

Әгъләметдин Әһлетдинович (*кесәсеннән кәгазь чыгарып укый башлый*). Хөрмәтле иптәшләр, хөрмәтле районыбыз халкы. Арабызда кичә генә җир җимертеп йөргән, әле кырык биш яше дә тулмаган, эшкуар иптәшебез Сәмигулла улы... (*Пышылдап, янәшәсендә торган I карттан сорый.*) Исеме ничек әле?

I карт (*пышылдап*). Ибраһим...

Әгъләметдин Әһлетдинович. Ибраһим...

Мулла. Миңлеибраһим!

Әгъләметдин Әһлетдинович. Миңлеибраһим китеп барды. Безне, бөтен район халкын ятим итеп китеп барды.

Ибраһим. Акыртмагыз әле шул трубаларыгызны! Умарта күче җыярга тимер тас кагалармыни. Мөнкир белән Нәнкир иптәшләргә тыңларга комачаулыйсыз. (*Әгъләметдин Әһлетдинович кулын өскә күтәрә, оркестр тына.*) Нәнкир белән Мөнкир, сез тыңлыйсызмы? Бөтен район халкын ятим калдырып китеп барды, ди. Протоколыгызга язып куегыз!

Әгъләметдин Әһлетдинович. Аның Җир өстендә эшләгән эшләре, кылган гамәлләре халкыбыз күңеленнән беркайчан да чыкмас, онытылмас.

Ибраһим. Беркайчан да чыкмас, онытылмас дип язып куегыз!

Әгъләметдин Әһлетдинович. Сәмигулла улы Иб-

раһим партиябез кушуы буенча нинди генә җаваплы эшкә алынса да...

II карт *(пышылдап)*. Әгъләметдин иптәш, партия бетте бит инде.

Әгъләметдин Әһлетдинович. Бетсә соң. Ике көн саен үлеп торган һәр кешегә яңа нотык язып булмый инде. Кулга кайсы эләкте, шуны алып килдем. Тәртәсенә керсә ярамаган. Алла боерса, сине җирләгәндә, яңасын язарбыз. Министр күммибез ләбаса. Мәрхүмнең исемен дөрес әйткәнмендер бит?

I карт. Дөрес, дөрес, Сәмигулла улы Ибраһим!

Мулла. Җәмәгать, грамотный булыгыз инде. Миңлеибраһим... Миңлеибраһим!

Әгъләметдин Әһлетдинович. Исемен дөрес әйткәч булган инде. Тавыш, иптәшләр, тавыш! Ибраһим улы Миңлесәмигулла...

Мулла *(пышылдап)*. Сә-ми-гул-ла улы Миңлеибраһим, Миңлеибраһим!..

Әгъләметдин Әһлетдинович. Син нәрсә йомырка өстендә утырган каз кебек ысылдыйсың?! Әйтсәң, кычкырып әйт. Өч карт бар, аның да икесе юньле-рәтле ишетми, саңгырау! Мәрхүм, нинди генә җаваплы эшкә алынса да, үз эшен намус белән башкарып чыга иде.

Ибраһим. Ишетәсезме, намус белән диме?.. Протоколыгызга язып куегыз!

Әгъләметдин Әһлетдинович. Ул, шәһәрдә культура-агарту институтын тәмамлап кайту белән, мунча директоры вазифасын үз өстенә алды. Алынып кына калмады, ел ярым дигәндә, барлык район халкын чистартып, агартып, алюмин тасларын цветметаллга җибәреп, мунчаны япты.

Ибраһим. Монысын язмагыз! Алдый ул.

Әгъләметдин Әһлетдинович. Мунча урынына гөлбакча ясап, үзенең пивной барын ачып җибәрде. Бүгенгесе көндә районыбыз яшьләре, чит ил музыкасы тыңлап, анда культуралы ял итәләр, кул көрәше белән шөгыльләнәләр. Бу аның районыбыз тарихында беренчеләрдән булып демократик юлда тәүге адымы иде. Аның бу хезмәтен район администрациясендә дә олы бәяләделәр, әледән-әле барып, аның эшеннән ләззәт алып кайтучы җитәкчеләребез районыбызда җитәрлек. Яшьләр белән беррәттән картлар тормышында да социаль-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә дә үзенең көчен кызганмады. Районыбыз Мәдәният йортына директор вазифасына алынгач, ул Культура йортын тиз арада мәчеткә әйләндерде һәм аңа районыбызның иң мөхтәрәм, хөрмәтле кешесе, районыбыз хакимияте башлыгы Сираҗетдин Галәветдинович исемен мәңгеләштерү йөзеннән Сираҗетдин мәчете дигән исем кушты.

Ибраһим. Язып куегыз. Өтерен дә төшермичә, мәчет ачкан диеп язып куегыз.

Әгъләметдин Әһлетдинович. Сәмигулла улы Ибраһимның районыбыз өчен эшләгән эшләрен санап китсәң, ярты көн кирәк булыр иде. Иптәшләр! Вакытыгызның тар булуын истә тотып, мин аның иң соңгы эшен әйтми кала алмыйм. Ул үзе туган нигездән ерак түгел инеш буенда, чишмә буенда район халкы, килгән кунаклар өчен ял йорты ачты. Элек тимер кружка да тормаган чишмә буен чистартып, аны бикләп, районыбыз чишмәсенең данын бөтен тирә-якка, күрше һәм үзебезнең республикабызга, илебезнең төрле почмакларына яңгыратты. Нинди генә шәһәргә барып, нинди генә кибеткә керсәң дә, районыбыз суы, сигез сум да илле ике тиенлек мөһер тагып, кибет киштәләрендә горур басып тора. Шул чишмәбез суын сатып алып эчкәннән соң, күзгә яшь килә, туган районыбызга карата хозурлык хисләре арта. Ирексездән күз алдына районыбызның булдыклы, демократик егете Ибраһим килеп баса. Тыныч йокла, хөрмәтлебез Сәмигулла улы Миңлеибраһим иптәш. Авыр туфрагың җиңел булсын. Без ышанабыз, синең урының, һичшиксез, оҗмахның түрендә булыр.

Ибраһим *(елап җибәрә)*. Җитте, җитте, Әгъләметдин Әһлетдинович, җылатасыз. Болай икәнеңне белгән булсам, беркайчан да синең өстән шикаять язмаган булыр идем. Нишлисең, кеше китә, җыры кала.

Музыка. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, берничә хур кызы арфада уйнап утыра. Калганнары Ибраһимны әйләндереп алганнар да салмак кына әдәп белән бииләр.

Ибраһим *(шатланып)*. Эләктем! Алланың биргәненә шөкер, оҗмахның нәкъ үзәгенә эләктем! *(Кызларга күз ташлап.)* Болар Айсылу да, Гөлсылу да, Нәзирә, Сәлимә, Мәрфуга да түгелләр инде. Болар — сартавойлар! Билләре генә ни тора!.. Умарта кортларымыни!.. Наверно, миңа боларны сайларга җибәргәннәрдер. Кайсысы миңа булыр икән? Әллә барысы да миңа микән? *(Сикереп тора. Куллары белән ботинка табанына сугып ала.)* Аһ, мать якасы! *(«Цыганочка»га биеп китә. Кулларын җәйгәндә, кызларның арт санына үрелә. Арт санына үрелгән кыз, шырык-шырык көлеп, түгәрәктән чыгып кача.)* Монысы түгел икән. Ялгыштым. *(Икенче кызга үрелә, ул да түгәрәктән чыгып кача.)* Монысы да булмады. Зыян юк, монысы миңа картрак! *(Шул рәвешчә хур кызлары берәм-берәм түгәрәктән качып бетәләр. Бер генә кыз ка-*

*ла.)* Минә син нинди икән. Димәк, син минеке?! Кил, кил минем яныма! *(Колачын җәеп, хур кызына атлый.)*

Хур кызы *(бармагын иренена куеп)*. Чү, бу нишләвең?!

Ибраһим. Гашыйк булуым...

Хур кызы. Миңамы?

Ибраһим. Әйе, сиңа!

Хур кызы. Әбиеңәме?!

Ибраһим. Әби?..

Хур кызы. Әйе. Анаңның анасының анасының атасының анасынамы?! Бибисарамиңлебибикәримә әбиеңәме?! *(Шырык-шырык көлеп, Ибраһимның култык астыннан чыгып кача.)*

Ибраһим. Нәстә ди?.. Биби... Биби... Әбиең, диме? *(Баштагы көйне бию көе басып китә. Ибраһимны бии-бии кыямәт көнен көтеп яткан әрвахлар әйләндереп ала.)* Китегез, кит, бәдбәхетләр, тәмуг кисәүләре. Дөньялыкта да туйган сездән. *(Арадан, ярсып, Мәрфуга килеп чыга да, күкрәкләрен селкетеп, Ибраһимга килә башлый.)* Кит, кит, тәмуг кисәве Марфа! Дөньялыкта да гарык синнән.

Мәрфуга *(Ибраһимның каршында бии-бии)*. Нигә алай дисең, Ибраһимчик?! Күңелем сиңа тартылмаса да, күрмисеңмени, күкрәкләрем сиңа тартыла.

Ибраһим. Күкрәкләрең, арт саннарың, бөтен запчастьларың белән кадалып кит! Яныма гына килә күрмә.

Мәрфуга. Алай димә, синең урының минем янда.

Ибраһим. Булган диярләр!.. Әбиеңә кайтып сәлам әйт!

Мәрфуга *(биюеннән туктап, колачын җәеп, ямьсез итеп үкереп елап)*. Кил, кил, Ибраһимчик, кил яныма! Кил, кил, бер генә тапкыр үзеңне пәп итим әле?!

Ибраһим *(куркып)*. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, кыямәт! Пожар! Янам! Коткарыгыз! Көчлиләр!

Кинәт күк күкрәгән, яшен яшьнәгән тавышка сәхнәдә ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бераздан сихри көй яңгырый. Сәхнәнең арткы ягында, кыя башында, прожектор яктысында Нәнкир һәм Мөнкир басып торалар. Сәхнә уртасында, тезләнгән хәлдә кулларын аларга сузып, тамашачыга арты белән Ибраһим тора.

Ибраһим. Алыгыз, алыгыз ул Мәрфуганы минем яннан. Юкса бәреп үтерәм!

Нәнкир. Җир йөзендә Ибраһим аты белән йөргән Сәмигулла улы Ибраһим...

Мөнкир. Син хәзер Ходай хозурында җавап тотарга әзерләнәсең!

Нәнкир. Дөньялыктан үткән, узган вакытларың да...

Мөнкир. Авыр сынау вакытларың да...
Нәнкир. Җир йөзендә сиңа ярдәм кулы сузган...
Мөнкир. Ялгыш юлга җибәрмәгән...
Нәнкир. Хәзер Мәңгелек йортларына, Ходай хозурына кайткан...
Мөнкир. Туган-тумачаларың белән...
Нәнкир, Мөнкир (*икесе бергә*). Очрашырга телисеңме?
Ибраһим. Юк! Кирәкләре сукыр бер тиен!
Нәнкир, Мөнкир (*икесе бергә*). Җавап алдыннан соңгы гозерең!
Ибраһим. Кызлар! Күп-күп итеп хур кызлары!
Нәнкир. Мөмкин түгел!
Мөнкир. Кыяматтән соң!
Нәнкир, Мөнкир (*икесе бергә*). Үзе алдында җавап тотканнан соң!
Ибраһим. Жалко. (*Уйланып торганнан соң, үз-үзенә.*) Туган-тумача, дус-иш, дисез инде... Саескан Гыйләҗиеннән өч тәңкә акча аласым калган иде инде, шуны очратып җиденче бабасын исенә төшерсәм, ничегрәк булыр икән... (*Нәнкир белән Мөнкиргә.*) Мин риза!
Нәнкир, Мөнкир (*икесе бергә*). Рәхим ит!

Көй яңгырый. Сәхнәнең арткы ягын томан баса. Нәнкир белән Мөнкир томанда юкка чыгалар.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ибраһим яныннан, шаярып, ап-ак киемнән, бер үк буйда, бер үк төсле, өчесе дә бөдрә чәчле, ун-унике яшьләр тирәсендәге сабыйлар узалар.

Ибраһим. Әй, егетләр, туктагыз әле?!
I сабый (*II һәм III сабыйга*). Әнә теге әрвах безгә эндәште бугай...
II сабый. Безгә эндәштеңме, әрвахетдин?
Ибраһим. Нигә өлкән кеше белән исәнләшмисез?
III сабый. Исәннәр Мәңгелеккә килми.
Ибраһим. Сәламәтлегемне сорагыз!
I сабый. Мәңгелектә һәр барчабыз да сәламәт!
Ибраһим. Килегез әле минем янга! (*Сабыйлар аның янына киләләр. I сабыйга кулын suза.*) Бир бишне!
I сабый. Нәрсә соң ул биш?
Ибраһим. Биш ул... биш!.. Биш ул — санау берәмлеге. Әллә сез саный да белмисез?
Сабыйлар. Юк, белмибез!
Ибраһим (*бармакларын бөгеп саный башлый*). Берәү,

икәү, өчәү, дүртәү, бишәү. *(Сабыйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.)* Нигә көләсез?..

II сабый. Кызык ич.

Ибраһим. Нәрсәсе кызык?..

III сабый. Сан!

I сабый. Нигә кирәге бар?

Ибраһим. Акча санар өчен!

II сабый. Нәрсә соң ул акча?

Ибраһим. Акча... Акча акча инде ул... Акча ул — байлык!

III сабый. Байлык нәрсә?

Ибраһим. Байлык ул — власть!

I сабый. Мәңгелектә акча да, власть та юк!

II сабый. Шулай булгач, сан да юк!

III сабый. Сан ул — җирдәге хәким!

I сабый. Сан ул — куркыныч!

II сабый. Сан ул — рәхимсез!

III сабый. Сан ул — җирдәге адәм баласының үз-үзенә каршы уйлап чыгарган куркыныч коралы!

Ибраһим. Җирдәгеләр алай уйламый. *(I сабыйга эндәшә.)* Исемең ничек?

I сабый. Әрвахетдинчик!

Ибраһим *(II сабыйдан)*. Ә синең исемең?

II сабый. Әрвахетдинчик!

Ибраһим *(аптырап, III сабыйдан)*. Ә синеке?

III сабый. Әрвахетдинчик!

Ибраһим. Чик, чик!.. Алай икән, юкәдә икән чикләвек. Ә сез минем исемемне беләсезме?

Сабыйлар. Беләбез!

Ибраһим. Йә, ничек?

Сабыйлар. Әрвахетдин!

Ибраһим *(көлеп җибәрә)*. Әрвахетдин... Минем исемем Ибраһим!

III сабый. Дөньялыктагы исемегез Миңлеибраһим.

Ибраһим. Ә сезнең дөньялыктагы исемегез ничек?

II сабый. Без өчебез дә Габдулла!

Ибраһим. Әйтегез әле, егетләр, Җирдә рәхәтме, әллә Мәңгелектәме?

Сабыйлар. Белмибез! Без Җирдән узмадык!

Ибраһим. Зәңгәр күкне дә күрмәдегезме?

II сабый. Күрмәдек.

Ибраһим. Зәңгәр күлдә дә йөзмәдегезме?

III сабый. Йөзмәдек.

Ибраһим. Ни өчен?

Сабыйлар. Җир йөзеннән синең кебек куркаклар узган өчен!

Ибраһим. Кем куркак, минме?!

Сабыйлар. Син!

III с а б ы й. Безгә җан өреп тә, безнең дөньялыкка килүебездән курыккан...

II с а б ы й. Безгә зәңгәр күк...

I с а б ы й. Зәңгәр күлләр...

III с а б ы й. Яшел болыннар...

I с а б ы й. Чәчәкле аланнар күрсәтергә курыккан, әти булырга тиешле, гөнаһлы, куркак бәндә — син!

И б р а һ и м. Рәнҗемәгез миңа, зинһар, рәнҗемәгез!.. Мин генә гаепле түгел. *(I сабыйның башыннан сыйпап.)* Менә синең дөньяга килүеңә... *(III сабыйны кочаклап)* аның әнисе каршы булды. *(III сабыйга.)* Синең җиргә тууыңа *(II сабыйны кочагына алып)* менә аның әнисе каршы булды. *(II сабыйга.)* Ә менә синең тууыңа бүтән анаң каршы булды. Дөнья, кешелек куркыныч. Җир өстендә минеке генә дигән төшенчә яши.

II с а б ы й. Ә минем бик тә, бик тә туасым килгән иде, яланаяк Җирдән атлыйсым килгән иде...

I с а б ы й. Минем анда сөйгәнем калды, чәчәкле аланнан чәчәк җыеп, такыя кидертәсем калды...

III с а б ы й. Анда минем туганнарым калды...

I с а б ы й. Җирдә минем җырланмаган җырым калды... *(Сәхнәнең арткы ягыннан күк күкрәгән, яшен яшьнәгән тавышлар ишетелеп китә.)*

II с а б ы й. Егетләр, әйдәгез, әйдә, әнә күрәсезме Җир өстеннән Мәңгелеккә тагын бер әрвах кайтты.

С а б ы й л а р. Ур-ра!.. Кыямәт якынлаша. *(Өчесе дә йөгереп чыгып китәләр.)*

И б р а һ и м *(алар чыгып киткән якка кулларын сузып)*. Улларым!.. Балакайларым!.. Алыгыз, алыгыз мине дә үзегез белән, алыгыз?! *(Өметсезлектән башын түбән ия.)*

Музыка. Ут сүнә.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, И б р а һ и м шул ук урынында утыра. С и р а й чыга.

С и р а й. Нишләп утырасың, Ибраһим?

И б р а һ и м *(башын күтәреп)*. Сиңа рәнҗеп утырам, Сираҗетдин. Инешкә батканда, мин бит сиңа кулларымны суздым, Сирай... Нигә үз яныңа алмадың, Сирай. Бу кадәр, бәлкем, керләнмәгән булыр идем, Сирай.

С и р а й. Җирдән матур узарсың дип ышандым, Ибрай. Җирдә — син, Мәңгелектә мин оҗмах ясарбыз дип ышандым мин, Ибрай.

И б р а һ и м. Әгәр кире кайтыр юл булса, Җиргә кайтыр идеңме, Сирай?..

С и р а й. Кайтыр идем. Йөгереп кайтыр идем. Биш кенә минутка булса да, сабый чагыма, инеш буйларына, өянкеләрем янына кайтыр идем. Таудан, «уфалла»сын тартып, бер төркем кәҗәләрен иярткән, минем үлүем хәсрәтеннән акылдан шашкан газиз әнкәмнең каршына төшеп, арбасын тартышып менәр идем. Җир өстендә калган, иңнәренә кулларымны да салалмаган, алсу иреннәренең тәмен дә татымаган сөйгәнемне күреп, җырлар идем. *(Салмак кына җыр башлый.)*

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Кире кайта торган юл булса.

И б р а һ и м *(паузадан соң)*. Юләр син, Сирай. Җирдә чибәрләргә хуҗалар күп. Тапкандыр үз тиңен.

С и р а й. Адәм баласы Җиргә үз тиңе, үз пары белән килергә тиеш. Очар кошның пар канаты кебек, бер җан, бер тән булып. Җирдәгеләр генә шуны аңламый. Берсен атып, икенчесен яралаганнарын. Бер җан, бер тән булганда гына, парлар Җир өстеннән матур узалар. Барыйм әле. Бүген Мәңгелектә бәйрәм. Тагын бер җан Җирдән Мәңгелеккә кайткан, диләр.

И б р а һ и м. Җирдән кеше китү Мәңгелектә бәйрәммени?

С и р а й. Олуг бәйрәм! Әрвахлар өчен шатлыклы бәйрәм. Тиздән кыямәт туар. Изге җаннар — оҗмахка, гөнаһлылар тәмугка очар. Дөньялыкны күрмәгән сабыйлар сөйгәннәре белән кавышыр.

И б р а һ и м. Ә мин, мин кем белән кавышырмын соң, Сирай?!

С и р а й. Дөньялыкта мәхәббәтләрен саклый алмаганнар тәмугларда елап йөрерләр. Барыйм әле, күрим әле... Матур җанмы, изге җанмы, күрим әле. *(Чыгып китә.)*

И б р а һ и м. Матур җанмы, изге җанмы?.. Кызык. *(Артыннан кача-кача сәхнәнең икенче ягына чыгып барган Гыйләҗине күреп.)* Әй, Гыйләҗи, шыпырт-шыпырт кына миннән кая качасың?!

Г ы й л ә җ и. Тс!.. *(Пышылдап.)* Акырма инде. Пожар чыкмагандыр бит. Ботинкаңны биреп тор әле!

И б р а һ и м *(пышылдап)*. Нигә?

Г ы й л ә җ и. Өйгә кайтып килмәкче идем.

И б р а һ и м. Өйгә?..

Г ы й л ә җ и. Әйе, өйгә. Безнең районның юлларын үзең беләсең, катканаклы*. Синең кебек бәндәләр, асфальт сатып, үз-

* *Катканаклы* — каткан балчыклы.

ләренә хан сарайлары салдылар. Безнең баш булмады, аякны булса да сакларга кирәк, ахир, аякны...

Ибраһим *(көлемсерәп)*. Саташтыңмы әллә, Гыйләҗи. Кайтырсың моннан өйгә, бар.

Гыйләҗи. Мин елына бер, ике, өч тапкыр кайтып киткәлим. Әле менә синең өчеңне үткәрәләр, шуңа кайтып, Коръән укып китәргә чакырганнар.

Ибраһим *(ачуланып)*. Сиңа тагын Коръән уку, аңгыра. Әлифне таяктан аермаган башың белән сөйләшеп торган буласың. Бер класста биш ел утырганын оныткан.

Гыйләҗи. Кешесенә күрә укыйм мин.

Ибраһим. Коръән дигән була. Тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстә. *(Ачуы басыла төшкәч.)* Кайтулар бетте инде ул. Хуш, Аллаһ әкбәр! Якты дөньялар хыялда гына калдылар. Урыс әйтмешли, назад пути нет! Син миңа шуны әйт, кайчан теге өч тәңкәмне кире кайтарасың?!

Гыйләҗи. Кайсы?!

Ибраһим. Исән чагында дөньялыкта алган.

Гыйләҗи. Дөньялыкта алган дөньялыкта калган! Аллаһ әкбәр! *(Битен сыпырып куя.)* Оялмыйча шул өч тәңкәсен сорап утыра. Судка бирмәгәнгә рәхмәт әйт. Шул өч тәңкәләрегез, биш тәңкәләрегез аркасында бауга мендем дә. Сез, акча биреп торып, алкаш ясамасагыз, мин дә менә хәзер оҗмах турында уйлап яткан булыр идем.

Ибраһим. Менә сиңа мә! Ит яхшылык, көт яманлык! Әйттем исә кайттым.

Гыйләҗи. Әйтмә дә, кайтма да. Дөньялыкта кайсыбызның аласы да, кайсыбызның бирәсе калмаган!

Ибраһим. Аллага шөкер, бер кешегә дә бирәсем калмады.

Гыйләҗи. Беләм, сезнең кебекләрне бик яхшы беләм. Бергә үттек тормыш сукмагын. Сезнең кебекләрнең беркайчан да бирәсе булмый. Ә монда киресенчә. Шуңа да сездәйләргә авыр биредә.

Ибраһим. Нигә?

Гыйләҗи. Бирүче юк! Алалмыйсыз! Барыбыз да тигез.

Ибраһим. Алай димә, кемнәрдер, ягъни минем кебекләр, оҗмахка, кемнәрдер...

Гыйләҗи. Шаярма. Телисеңме, җырыңны өйрәтәм. *(Җырлый.)*

Эч аракы, тарт тәмәке,
Оҗмахларга керерсең.

*(Ибраһимга.)* Кушыл!

Ибраһим
Гыйләҗи *(икесе бергә җырлыйлар)*.

Оҗмахларга керерсең...
Оҗмахларга кералмасаң,

Ибраһим туктап кала.

Гыйләҗи (*үзе генә*).

Кругында йөрерсең.
Оҗмахларга кералмасаң,

(*Ибраһимга.*) Нигә кушылмыйсың?!

Ибраһим. Тфү, паразит!

Гыйләҗи. Кругында йөрерсең!

Сәхнә артыннан әрвахларның шаулашканнары ишетелә башлый.

Ибраһим. Нишлиләр анда?

Гыйләҗи. Ниндидер җанны зиратка алып баралар.

Ибраһим. Монда да зират бармыни?

Гыйләҗи. Булмыйча.

Ибраһим. Берни аңламыйм.

Гыйләҗи. Аның нәрсәсен аңлыйсың. Кайбер җаннар, адашып, дөньялыктагы сынауларын бетермичә, буталып, Мәңгелеккә кайталар.

Ибраһим. Карале, бәлки, мин дә буталып кына кайтканмындыр, ә? Үлгәнемә бер дә ышанасым килми.

Гыйләҗи. Кем кем, син, Ибраһим Сәмигуллович, бутала торганнардан түгел. Син инде нәкъ үзәгендә!

Ибраһим. Карале, Гыйләҗи, мине дә киредән җирләмәсләр микән?

Гыйләҗи. Белмим шул. Сорап кара, Җиргә синең кирәгең бар микән соң?

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәхнәгә «семейный» трусиктан, култык астына мендәр кыстырган Сәйфетдин, аның артыннан әрвахлар чыга.

Сәйфетдин. Ярар, җәмәгать, әйтермен, әйтермен. Дөньялыкта калган туганнарыгызга түкми-чәчми барыгызның да сәламнәрегезне җиткерермен.

II сабый. Сәйфетдин абзый, минем анда сөйгәнем калды. Исеме аның Гөлгенә, тирә-якка бер генә! Әйт шуңарга, тизрәк әйләнеп, Мәңгелеккә кайтсын. Сине анда Габдуллаң көтә, диген. Парсыз — дөньялыкта сансыз!

Сәйфетдин. Әйтермен. Әйтермен, балакаем.

Сирай. Минем әнкәй дөньялыктан арыгандыр. Улың, Сиражетдинең көтә, диген.

Сәйфетдин. Сиражетдинең көтә, диярмен.

Ибраһим (*Сәйфетдинне читкә алып китеп*). Туган, ал мине үзең белән!

Сәйфетдин. Кая?

Ибраһим. Җиргә. (*Аягындагы туфлиләрен салып, Сәйфетдингә суза.*) Ал үзең белән. Менә мин сиңа туфлиләремне бирәм.

Сәйфетдин. Син нәрсә, килешмәгәнне...

Ибраһим. Ал, башы кәкрелегенә карама, әле яңа алар. Моннан унбиш ел элек кенә кибеттән алдым мин аларны.

Сәйфетдин. Шулай дисеңме?..

Ибраһим. Шулай димен. Бакыслап, ялтыратып җибәрсәң, син әле боларны тагын унбиш ел кияләсең. Миңа әллә ни киң урын кирәкми.

Сәйфетдин. Җиргә кайтасың килә?!

Ибраһим. Үлеп!

Сәйфетдин. Взятка бирәсең?!

Ибраһим. Син нәрсә инде, туган...

Сәйфетдин. Мин көтүче, аңлыйсыңмы, көтүче, минем взятка алганым юк!

Ибраһим. Син нәрсә инде, мин чын күңелемнән...

Сәйфетдин. Шулаймы?! Чын күңелеңнәнме?!

Ибраһим. Валлаһи менә!

Сәйфетдин. Яхшы! (*Туфлине киеп куя.*) Килешәме?

Ибраһим. Үзеңә теккән кебек.

Сәйфетдин. Яхшы. Җидеңә киеп барырмын!

Ибраһим. Ал, ал үзең белән. Мин стенага сыланып кына ятармын. Синең гәүдәңә ялгыш та орынмам.

Сәйфетдин. Вот оятсыз, нахал! Гәүдәмә орынырга син минем хатыныммы әллә?! Ә хатынга орынырсыңмы?! Җир бит! Кабахәт!

Ибраһим. Туктале, кызма, хатының биредә юк бит.

Сәйфетдин. Булмаса! Минем гәүдәм янында, стена ягында, хатыным Мәймүнә җиңгәң йоклап калды бит, аңгыра! Минем гәүдәм авылда калды, түшәк өстендә йоклап. Мин бит мәрткә киткәнмен. (*Үз-үзенә.*) Кирәк бит, ә, кирәк бит... Гарифларга печән алып кайттык, шуны өйдек. Ну инде, икебезгә бер ярты салдык та, өйгә кайтып киттем. Кайтсам, Мәймүнә җиңгәгез мунча ягып куйган. Мунча кереп чыктык та Мәймүнә җиңгәгез белән йомшак ястыкка чумдык. Соң, ир белән хатын ястыкка чумгач, үзегез беләсез инде... Тирләп пешеп... Мендәремне менә шушылай култык астыма кыстырып, изрәп йоклап киткәнмен. Иртән уянып булмый. Таң атты, уянып булмый. Барысын күреп, белеп ятам, юк, уянып булмый. Мәймүнә җиңгәгез: «Сәйфетдин үлгән»,— дип, урамга чыгып йөгерде. Биш балам биш ягымда үкереп җылап утыралар. Үзләрен бик кызганам, ләкин уянып булмый. Бөтен авыл җыелды. Медсестра кыз килде. Арт саныма бер-бер артлы җиде укол сыламасынмы?! Авыртуына чыдап булмый, уянып та булмый. Кешеләр

иш чыгара алмады. Бертуктаусыз
керәп-чыгып йөргәләгәндә, авылның исерек Исрафилы кул сәгатемне, салдырып, кесәсенә дә тыкты. Алма дип әйтеп тә булмый, потому што, уянып булмый. Медсестра кыз: «Үлгән,— ди.— Тизрәк районда ярдырырга да исләнгәнче күмәргә кирәк»,— ди.

Ибраһим. Шуннан, шуннан...

Сәйфетдин. Чукынды, мин әйтәм, терелә̆й күмәләр икән.

Ибраһим. Элек болай булганың бар идеме?

Гыйләҗи. Әйе, элек?..

Сәйфетдин. Бар иде. Ну болай ук түгел иде.

Гыйләҗи. Ул чагында ничек уянган идең?

Сәйфетдин. Ул чагында мин исерек идем.

Ибраһим. Исерек идең?.. Дәвам ит.

Сәйфетдин. Өстәл артында пирәш* кабып утырган җиремнән өстәл астына егылып төшкәнмен дә йокыга киткәнмен. Берзаман төн уртасында тамагым кибеп уянып китсәм, бөтен дөнья караңгы. Йөрәгем жу итеп китте. Курка-курка гына уң кулым белән уң ягымны капшап карыйм — стена! Сул кулым белән өсне капшыйм — стена. Чукынды, мин әйтәм! Үлгән дип уйлап, гробка салганнар да күмгәннәр!

Сирай. Ничек гроб, ничек гроб... Син бит мөэмин-мөселман!

Сәйфетдин. Шаярма. Мин бывший коммунист!

Ибраһим (*Сираҗетдингә*). Бүлдермә әле! Сөйләгез, сөйләгез, иптәш.

Сәйфетдин. Куркуымнан кычкырып җибәрүем булды, йоклап яткан балалар да, хатын да, көчкә-көчкә таякка таянып йөргән туксан яшьлек әни дә, таягын ташлап, урамга чыгып атылмасыннармы. Ә бу юлы серьезно. Кычкырып карыйм, тавыш чыкмый.

Ибраһим (*бар тавышына кычкырып*). Коткарыгыз!

Сәхнәдәге барлык әрвахлар куркып качалар.

Сәйфетдин (*качкан җиреннән башын чыгарып*). Син нишлисең?!

Ибраһим. Минем тавыш чыга.

Сәйфетдин. Син чамалап! Йөрәкне яра яздың бит. Бөтенләйгә биредә калдырасың бит. Менә шул. Бу юлы район больницасына ярырга алып бармасалар, валлаһи, терелә̆й күмәләр иде. Ярый әле, яручы врач ушлый булды. «Бу үлмәгән. Моның йөрәге тибә. Бу мәрткә генә киткән»,— димәсә, тере Сәйфетдин абзагызны, таптый-таптый, авыллары белән күмәләр иде. Вәт медицина! Берсе үтерә, икенчесе терелтә! Берсе йөрәк туктата, икенчесе эшләтә. Сенсация! Әйдәгез, туганнар,

* *Пирәш* — исерткеч эчемлек.

тизрәк мине җирләгез! *(Җыелган халыкка.)* Татарның акылы төштән соң. Җаным кайтканчы, гәүдәмне күмеп куймасыннар. Йөрерсең аннан гәүдәңне эзләп. Моннан соң да Мәймүнә җиңгәгез кадеремне белмәсә, өченче тапкыр чынлап үләм!

Сәмигулла. Әйдәгез, әйдә, өйлә якынлаша, соңармыйк.

Ибраһим. Ал мине дә үзең белән. Минем дә җирләнәсем килә.

Гыйләҗи. Ярап булмый бу адәм баласына. Әле генә, мине җирләмәгез, дип кычкыра иде, хәзер, җирләгез, дип ялвара.

Сәйфетдин һәм аның артыннан, шау-гөр килеп, әрвахлар сәхнәдән чыгып китәләр. Сәхнә караңгылана.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәхнә уртасында утырган Ибраһимны прожектор яктырта. Кыя башында, арткы планда, ап-ак киемнән Ибраһимның анасы Гөлсем. Ул да прожектор яктысында.

Гөлсем. Улым, Ибраһимым... *(Кулларын Ибраһимга сузган халәттә иплəп кенә аска төшә.)*

Ибраһим *(сискәнеп китә)*. Әнкәй!.. Нигә сузасың кулларыңны, әнкәй?! Соңгы вакытларда төшләремә нигә кердең, әнкәй?! Нигә җитәкләп алып киттең, әнкәй?! Минем әле яшисем килә иде бит, әнкәй!

Гөлсем. Ходайның әмере җиткәнен аналар сизәләр, балам!

Ибраһим. Нигә ашыктыралар, әнкәй?!

Гөлсем. Ходайдан бирелгән вакытың узган, балам! Җир йөзенә берәү дә мәңгелеккә килми.

Ибраһим. Эшлисе эшләрем калды бит, әнкәй!

Гөлсем. Бер генә адәмнең дә җир йөзендә эшен эшләп бетерә алганы юк, балам! Җир йөзеннән адәми зат күз ачып йомганчы уза да китә. Син шул арада үзеңнән соң калганнарга изге эшләр эшли алдыңмы, балам!

Ибраһим. Белмим, әнкәй!

Гөлсем. Тәңре белә, балам! *(Әкренләп сәхнә яктыра, Гөлсем Ибраһим янына килеп җитә дә улы янына тезләнә. Ибраһимның маңгаеннан сыйпап.)* Әнә маңгаеңа сырлар кунган.

Ибраһим. Дөнья кудым бит, әнкәй!

Гөлсем. Кеше, адәм дөнья куалмый, балам! Дөнья адәмне куа.

Ибраһим. Маңгайдагы сырлар нәрсә соң ул, күңел сырланмасын, әнкәй! Күңел картаймый бит, әнкәй! Яшисе дә яшисе килә.

Гөлсем. Күңел картая ул, күңел тарая ул, күңел тупаслана, керләнә ул, балам! Дөньялыктан киң күңел белән киткәндә

генә, синнән соң калганнар алдында намусың саф, күңелең пакь була ул, балам!

Ибраһим. Күңелне күзгедән карап булмый шул, әнкәй!

Гөлсем. Тормыш — үзе көзге! Җир йөзеннән үткән һәр адәми зат янәшәсеннән узган адәмне үтәли күрә. Аның йөзендә синең күңел көзгең.

Ибраһим. Мин начар яшәмәдем. Мине җылап озаттылар.

Гөлсем. Күз яшьләренә ышанырга ярамый, балам! Күз яшьләрен Ходай кайгыдан да, шатлыктан да бирә. Күз яше — сынау шарты! Күз яше сынауларга яраклашу өчен ул, балам!

Ибраһим. Әйт әле, әнкәй! Мин... Мин дөрес яшәдемме? Сыналдыммы, әллә сынаттыммы?

Гөлсем. Ана баласына беркайчан да дөрес бәя бирә алмый, балам! Ананың баласына булган бәясен беләсең килсә, ананың җаны чykканда йөзеннән укырга кирәктер.

Ибраһим. Кичер, әнкәй! Сине дөньялыктан озатканда, янында булалмадым шул, кичер.

Гөлсем. Ә мин сине көткән идем. Менә-менә кайтып җитәрсең дип көткән идем.

Ибраһим. Яшәргә кирәк иде бит. Кеше төсле яшәргә, кеше булырга, кеше булу өчен укырга кирәк иде бит.

Гөлсем. Үзем гаепле. Ходайга барып ирешерлек бәхиллек биралмаганмын, ахрысы. Телем белән бәхиллек бирсәм дә, яшьле күзләремне ачып, синең күзләреңә карап, күңелем белән бәхиллек биралмаганмындыр, күрәсең. Кичер, балам! *(Ибраһимның аякларын кулына ала.)* Сабый чактагы чебиле, нәни аяклар... Җир өстеннән атлап, дөнья гизеп, дәү булганнар. Бу аяклардан Җир өстендә эзләр калдымы, балам?

Ибраһим. Белмим, әнкәй!

Гөлсем. Ул эзләрдә гөлләр үсәрме, балам?

Ибраһим. Белмим, әнкәй!

Гөлсем. Чебиле аяклар... Хәтерлисеңме, яз көне яланаяк йөреп аякларың чебили иде дә, мин аны җылы су белән юып, май сөртә идем. Ә син: «Кирәкми, әнкәй. Үссеннәр, үссеннәр дә бераздан чуар тавыкка кушарбыз»,— дия идең.

Ибраһим. Хәтерләмим, әнкәй!

Гөлсем *(Ибраһимның чалбар балакларын күтәреп, тез янындагы җөен күреп)*. Җөй! Өч яшьлек чагындагы җөең һаман да саклана икән.

Ибраһим *(аягына карап)*. Кая, нинди җөй? Күргәнем юк иде. Беренче тапкыр күрәм. Хикмәт. Валлаһи, беренче тапкыр күрәм.

Гөлсем. Әле менә монда да җөең булырга тиеш. Әйтәм бит, менә.

Ибраһим. Кызык син, әнкәй! Үзем дә белмәгән җөйләремне табасың.

Гөлсем. Сиңа ул чагында тугыз ай иде. Эссе җәй. Бүгенгедәй хәтеремдә. Борчак чабып кырдан кайтып киләм. Син «уфалла»да. Иңкү җирдән узган чакта, арбам авып китмәсенме? Син тәгәрәп җиргә төштең. Төшкәндә, аягың күчәр тимеренә сыдырылды. Үкси-үкси елыйсың, үзең ач, сөтем юк. Үзеңнән кан ага. Нишләргә дә белмим. Юл читендә үсеп утырган үги ана яфрагын телләрем белән яладым да синең яраңа капладым. Ә син һаман елыйсың. Басу кырыенда адашып чыккан өч-дүрт бөртек арыш башагын кулларымда удым да авызыма каптым. Чәйнәп, башымдагы яулыгыма төреп, имезлек ясап сиңа каптырдым. Син шуны имеп, изрәп йокыга киттең. *(Калтырап куя. Кулларын өскә күтәреп, тамашачыга карап тезләнә.)* Йа Рабби Тәңрем, үтенеп сорыйм, аз гына сабыр ит! *(Ибраһимга борыла. Башын куенына ала.)* Әй, бала, бала... Ходай тарафыннан миңа да ана булып торырга санаулы вакытлар гына калып бара. Озакламый син мине, мин сине белмәбез. Мәңгелектә ана һәм бала дигән төшенчә юк. Бу ике җанның мәңгегә аерылуыдыр. *(Кинәт Гөлсем чайкалып китә.)* Вакыт чыкты, балам! Тәңре вакыт чыкканны сиздерә. *(Ялварып.)* Тәңрем, йа Рабби бер Ходаем, тагын бераз гына балам белән бергә булырга вакыт бирсәңче? Соңгы очрашу, соңгы мизгел, йөрәгемнән өзелеп төшкән нарасыем белән мәңгегә хушлашу бит. Хуш, балам! Хуш, күз алмам, бавыр җимешем...

Сихри көй. Ут караңгылана. Гөлсем юкка чыга.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бераздан ут яктыра.

Ибраһим *(елый-елый)*. Әнием, әнкәй, китмә, зинһар, китмә?! Ал мине үз яныңа, ал?! Җир өстендә чылтырап аккан чишмәсе дә, чәчәкле аланнары да кирәкми миңа. Мин хәзер сабый хөкемендә. Миңа хәзер синең ярдәмең кирәк, әнкәй! Ал мине, ал үзең яныңа? *(Атасы Сәмигулланы күреп ала.)* Әткәй?! *(Тезләнгән килеш атасына килә.)*

Сәмигулла. Чү, бала... Мәңгелектә күз яше түгү чүлдә адашкан юлчының авызына бер тамчы су салу белән бер. Мәңгелек йорт күз яшьләренә ышанмый.

Ибраһим. Әнкәем белән соңгы тапкыр очраштым.

Сәмигулла. Адәм баласы, дөньялыктан Мәңгелеккә киткәндә, соңгы тапкыр сулыш, соңгы тапкыр күзен йомганда да өмет белән китә. Биредә өмет сүнә. Дөньялыкта сиңа җан өргән, Җир өстендә Ана ролен башкарган ул җан хәзер инде авыр йөгеннән азат.

Ибраһим. Нинди йөк?..

Сәмигулла. Уй! Уй, балам. Адәм баласына Ходай тарафыннан Җир өстенә биреп җибәрелә торган йөк — уй! Җир өстеннән узган, бер генә башка җан да күтәрә алмый торган авыр һәм газаплы йөк — уй! Ул йөктән Мәңгелеккә килгәч тә арына алмый, үз җилкәсендә күтәреп йөри. Җир йөзендә үзе җан өргән иң соңгы баласын Мәңгелектә каршы алгач кына, ул авыр йөктән арына. Менә минем дә ул йөктән арынырга санаулы гына вакытларым калып килә. Хушлашырга ашыгыйк, балам!

Ибраһим. Әйт әле, әткәй! Мин төш кенә күрәмме, әллә инде үлдемме?

Сәмигулла. Син туарга җыенасың!

Ибраһим. Мин бит инде бер тапкыр туган идем.

Сәмигулла. Нарасыйның елый-елый ана карыныннан төшүе әле ул туу түгел. Кеше, дөньялыктагы сынауларын җиренә җиткереп башкарып, Мәңгелекнең капкасын ачканда гына туарга мөмкин.

Ибраһим. Аңламыйм.

Сәмигулла. Җир өстендә син калдырган эзләрдә гөлләр шытып чыкса, шул гөлләргә су сибүчеләр табылса, димәк, син тугансың, димәк, син яшәгәнсең! Әгәр инде син дөньялыкта соңгы тапкыр күзеңне йомгач та, сине онытсалар, син тумагансың да, яшәмәгәнсең дә.

Ибраһим. Әйт әле, әткәй, синеңчә, мин тудыммы?

Сәмигулла. Атаның баласына булган бәясен Җир өстеннән узганда эзләргә кирәк, улым!

Ибраһим. Ничек итеп?

Сәмигулла. Капка шыгырдавыннан.

Ибраһим. Нинди капка, әткәй?

Сәмигулла. Нигез капкасыннан.

Ибраһим. Нәрсә сөйлисең син, әткәй?! Нинди нигез, нинди капка?.. Синең Мәңгелеккә киткәнеңә дә егерме биш ел! Синең ул нигез капкаң әллә кайчан череп ауды, әткәй!

Сәмигулла. Минем нигез, минем капкам син идең. Шул капка һәр кешегә елмаеп ачылып, тирә-юньгә нур чәчеп, Җирдәгеләргә яшәү яме биреп ачылып торса, шул кешеләрнең йөзеннән атаңның сиңа булган бәясен укырсың.

Ибраһим. Минем капкам биек. Келәсе бикле! Аның урынына мин сезнең икегезгә дә кешеләрнең күз явын алырлык һәйкәл, кабер ташлары куйдым. Көмешкә тиң чардуган койдым.

Сәмигулла. Сандугачлар кунып сайрыймы?!

Ибраһим. Сандугач тавышын танымыйм. Сандугач тавышы тыңларга минем вакытым булмады. Әнә көтүче Абдулладан сора, ул белә, ул сандугач тавышын аера.

Сәмигулла. Күңеле белән сандугач сайравын аңламаган кеше Җир өстендә якты эз калдыра алмый.

Ибраһим. Нәрсә?! Сандугач тавышын, сандугач сайравын аерган Абдулла Җир өстендә якты эз калдырганмыни?!

Сәмигулла. Аның атасы Галимулла, анасы Бибигайшә кабере өстендәге агач чардуганда сандугачлар оя кора, бала очырта. Ә син куйган мәрмәр таш — салкын таш!

Ибраһим. Ә мин аңа күңел җылымны салдым.

Сәмигулла. Ул ташларны синең күңел җылың гына җылыта алмый. Ул ташларны Җир өстендә икмәккә дә туймаган бәндәләр күңеле генә җылыта ала. Салкын ташлардан мәрхүмнәргә һәйкәл куеп булмый. Минем һәйкәл дәвамым булып дөньялыкта син калган идең. Синең һәйкәл — синең киләчәгең, синең дәвамың, балаларың. *(Чайкалып китә.)* Хәбәр килде, балам. Хушлашу вакыты җитте. *(Китә башлый.)*

Ибраһим. Ашыкма, әткәй, әйтеп кал. Минем дөньялыкта кылган яхшылыкларым юкмыни?

Сәмигулла *(улына борылып)*. Белмим, улым! Сират күперен ничек кичкәнсеңдер...

Ибраһим. Мин бит әле сират күперен кичмәдем...

Сәмигулла. Сират күпере дөньялыкта син узган юл ул, балам!

Ибраһим. Ә мин кайсы якта? Оҗмахтамы, әллә...

Сәмигулла. Анысы дөньялыкта кылган эшләреңдә.

Ибраһим *(пышылдап)*. Әткәй, оҗмахны сатып алып булмыймы?

Сәмигулла *(пышылдап)*. Була. Җир өстеннән узганда. Намус белән яшәп!

Музыка. Сәхнә караңгылана.
Сәмигулла юкка чыга, Ибраһим прожектор яктысында кала.

Ибраһим *(озак кына паузадан соң, үз-үзенә)*. Кылдан нечкә, кылычтан үткен... Дөньялыкта циркач булып яшисем калган.

## УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә яктыра. Сәхнәнең арткы ягында ап-ак киемнән яшь, чибәр Җәмилә басып тора. Шырык-шырык көлә.

Җәмилә. Тормыш — үзе цирк!

Ибраһим *(гаҗәпләнеп аңа карап)*. Ә ул циркта мин кем?

Җәмилә. Маймыл! Байлыкка алданган маймыл.

Ибраһим. Маймыл?! Юк, мин беркайчан да маймыл булмадым. Мин — дрессировщик! Күпләрне мин дрессировать иттем.

Җәмилә *(йөгереп килеп, Ибраһимның авызын каплый)*. Чү! Үзен рәнҗетәсең! *(Пышылдап.)* Ходай Тәгаләне рәнҗе-

тәсең! Җир йөзендәге барлык тереклек белән дә фәрештәләр идарә итә.

Ибраһим. Ә фәрештәләр кемнәр?

Җәмилә. Яхшылык һәм яманлык.

Ибраһим (*Җәмиләнең кулларын үз кулына ала*). Син кем, фәрештәме?

Җәмилә. Юк. Мин — Җәмилә.

Ибраһим. Син хур кызы...

Җәмилә. Юк. Мин — Җәмилә.

Ибраһим. Җәмилә?! Минем балаларымның...

Җәмилә. Әйе. Синең улларыңның Илфак белән Зөфәкнең аналары Җәмилә.

Ибраһим. Ышанмыйм. Синең белән танышкандагы минем беренче сүземне әйт.

Җәмилә. Күгәрченем!

Ибраһим. Ак күгәрченем! Җәмиләм, ак күгәрченем, сагынасыңмы без тәүге тапкыр очрашкан инеш буендагы карт өянкеләрне?

Җәмилә. Сагынам.

Ибраһим. Бер генә минутка, бер генә секундка гына булса да кайтып күрәсең киләме аларны, Җәмиләм?!

Җәмилә. Килә.

Ибраһим. Әйдә кайтабыз!

Җәмилә. Мәңгелектән качып булмый. Үткәннәргә кайтып булмый.

Ибраһим. Ул өянкеләр әле дә булса сине сагыналар бит, Җәмилә.

Җәмилә. Дөрес түгел!

Ибраһим. Дөрес, Җәмилә.

Җәмилә. Алар инде юк!

Ибраһим. Бар, бар, Җәмилә. Алар бит озын гомерле, алар бит икешәр йөз ел яшиләр.

Җәмилә. Кирәкми, Ибраһим, кирәкми, Мәңгелек ялганнарны кичерми. Инеш кипте, өянкеләр бетте, сукмакларга үләннәр үсте. Кире кайтыр юл бетте.

Ибраһим. Бар, алар бар, Җәмилә. Инеш тә бар, өянкеләр дә бар, сукмакларга гына үлән үскән, Җәмилә!

Җәмилә (*Ибраһимның кулларын үз кулына алып*). Ул өянкеләрне шушы куллар кисте.

Ибраһим (*ярсып*). Кем өчен кисте?! Кем өчен?! Үзем өченме?! Балаларыбыз өчен бетердем. Киләчәгебез өчен, Илфак белән Зөфәк өчен бетердем. Тамаклары тук, өсләре бөтен булсын өчен бетердем. Рәхәт яшәсеннәр өчен бетердем. Ул урынга ял йорты төзедем. Үзем өченме?! (*Тамашачыларга төртеп күрсәтеп.*) Алар өчен!

Җәмилә. Барысын да күреп ятам. Анда хәзер таллар инеш-

кә ятып иркәләнми, анда хәзер сандугачлар талга кунып сайрамый, анда хәзер сабыйларның шат авазлары ишетелми.

Ибраһим. Ташлап киткән сабыйларың турында сорашыр идең. Аларга бит нибары биш-алты яшь иде.

Җәмилә. Барысын да күреп ятам. Мәңгелектән бары да күренә. Сабый чакларын да, инеш буенда үскән карт өянкедәге таган атынганнарын да, инештән каз оясы белән балык сөзгәннәрен дә, хәзергесен дә.

Ибраһим. Мин аларны сасыган инештән тоткан балык ашатып үстермәдем.

Җәмилә. Алар таганда атынганда, мин аларга бар көчемне җыеп, күкрәгемнән чыккан назлы сулышымны җибәреп, таганнарын зәңгәр күктә тибрәлдерә идем. Аларның хыяллары ерак-еракларда, чиксез галәмнәрдә иде.

Ибраһим. Нәрсә, мин аларга үз җылымны бирмәдемме?!

Җәмилә. Син үз җылыңны башкаларга өләштең, син үз җылыңны кеше хатыннарына өләштең.

Ибраһим. Ялган! Сафсата!

Җәмилә. Тел сөйләсә дә, күңел алдый алмый. Үз-үзеңне алдап булмый, хәтерне алдап булмый.

Ибраһим. Мин аларга җил-давыл тидермәдем. Үз канатым астында үстердем.

Җәмилә. Кагынырга ирек бирмәдең. Очарга өйрәтә алмадың. Карт өянке төбендәге вәгъдәңне үти алмадың, Ибраһим. Нәфесле булдың, Ибраһим. Күпләрне җылытмакчы булдың, әмма берсен дә җылыта алмадың. Мәңгелеккә киткәннәрен дә, Җирдән узып баручыларын да. Юк шул, Ибраһим, юк, нигез капкаң елмаеп ачылмас, эзләреңә су сибүчеләр табылмас. Хуш, Ибраһим! *(Китә башлый.)*

Ибраһим. Җәмиләм, ак күгәрченем, ал мине, ал үзең белән! Минем дә синең кебек ак күлмәк киеп, ак хыялларга чумып, синең белән җитәкләшеп, ак кыялар арасында йөрисем килә.

Җәмилә. Ак күлмәктә — ак хыял, ак намус, Ибраһим... *(Китә башлый.)*

Ибраһим *(шашынып)*. Җәмилә... Җәмиләм! Ак күгәрченем! Калдырма, калдырма мине ялгызымны! Сал җилкәмә ак күлмәк!

Җәмилә *(туктап)*. Соң инде. Язмыш безгә туй көнебездә ак күлмәк бүләк итте. Саклый алмадың, пакьли алмадың. Минекен дә, үзеңнекен дә таптадың.

Ибраһим. Ә мин ул тапны бетерермен.

Җәмилә. Ул тап беркайчан да бетми. Ул тап балаларыбыз язмышына барып тоташа. Хуш! Әле минем улларымны көтәсем бар.

Ибраһим. Ашыкма. Алар әле тиз генә килмиләр. Алар әле яшь. Аларга җир җимертеп яшисе дә яшисе...

Җ ә м и л ә. Ә мин Ходайдан ялварып сорыйм. Дөньялыкта керләнеп беткәнче, тизрәк Мәңгелеккә килүләрен сорыйм. *(Чыгып китә.)*

И б р а һ и м. Ашыктырма, зинһар, ашыктырма аларны... Мин үз капкамның ябылуын теләмим, теләмим! *(Тезләнә. Чәчләрен куллары белән умырып тота.)* Ишетәсезме?! Мин капкамның ябылуын теләмим! *(Идәнгә каплана. Бераздан башын күтәреп, тамашачыга кулларын сузган хәлдә, елау катыш җырлый.)*

Ак күлмәгем, ак күлмәгем...
Бер киюдә каралттым...

*(Озак кына паузадан соң, ярым пышылдап.)* Җәмилә... Җәмиләм... Ак күгәрченем... *(Сузылган кулларына карап.)* Очты... Кулларымнан ак күгәрчен, ак күгәрчен очты!..

Музыка.

П ә р д ә

# Гыйләҗ тәрәзәләре

*Драма өч картинада, сигез күренештә*

(Аяз Гыйләҗевнең «Тәрәзәләр», «Өч тәгәрмәчле арба» хикәяләре һәм «Яра» повесте буенча эшләнгән инсценировка.)

КАТНАШАЛАР:

Габдулла.
Зәйтүнә — Габдулланың сөйгәне.
Сөләйман карт — Габдулланың атасы.
Зөләйха әби — Габдулланың анасы.
Кәримҗан — Зәйтүнәнең ире.
Мөхәммәт карт — Кәримҗанның атасы.
Сафура карчык — Кәримҗанның анасы.
Олы абый.
Кече абый.
Шәкүр.
Һадый — 12–14 яшьләр тирәсендәге малай.
I малай.
II малай.
Маһирә — Һадыйның анасы.
Рәшат (Сәләев).
Ханым — Рәшатның анасы.
Өммегөлсем — полковник хатыны.
Беренче хатын.
Икенче хатын.
Юан хатын.
Юка хатын.
Почтальон.
Бала-чагалар.

Вакыйга сугыштан соңгы елларда бара.

## БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, сәхнәнең уң як порталына арткы якка почмаклап, «П» хәрефе итеп салынган ике катлы йортның уннарча тәрәзәләре тамаша залына карап тора. Йортка терәп диярлек, озын утыргыч куелган. Ә сул якта Сөләйман картның өй почмагы белән җил капкасы күренә. Урамда малайлар пыр тузып туп тибәләр. 12–14 яшьләр тирәсендәге Һадый каты итеп тупка

тибеп җибәрә, туп порталга чыгып оча. Челтер-р иттереп тәрәзә пыяласы коелган тавышка тәрәзәләр ачыла, тузган чәчләр, бигудилы башлар, мендәр йонына манчылган сакал-мыеклар тәрәзәләргә үреләләр. Малайларның барысы да качалар.

Өммегөлсем *(черелдәвек тавыш белән)*. Тагын Мәһирә малаемы?..

Юан хатын *(икенче тәрәзәдән)*. Вәт шпана!

Юка хатын *(өченче тәрәзәдән)*. Төрмә көтә аны, төрмә!

Бераздан барак ишегеннән бер төркем халык чыга да малайлар качкан якка йөгерәләр. Сәхнәгә карана-карана Һадый йөгереп чыга да йортның икенче ягына үтмәкче була.

Аның каршысына әлеге дә баягы халык килеп чыга. Һадый кире якка йөгерә. Халык аның артыннан сәхнәдән йөгереп чыгып китә. Бераздан Һадыйны, колагыннан боргычлап, сәхнәгә алып чыгалар.

Өммегөлсем *(йодрыкларын йомарлап)*. Узган атнада син минем кер бавымны унсигез җирдән кистеңме, бәдбәхет?!

Юан хатын. Кичә минем галошларга су тутырып куйган.

Юка хатын. Галош нәрсә ул. Кичә кибеттән өч литрлы бидон белән сөт алып кайттым да, менә шушы баскыч тактасына куеп, керләремне җыйган арада, сөтемә тычкан салган.

Беренче хатын. Ятим бала бит, нинди тәрбия күрсен ул.

Өммегөлсем. Яшең генә керсен. Төрмә көтә сине, төрмә.

Авызына капкан икмәген дә йотып бетермичә, абына-сөртенә Мәһирә килеп чыга. Аны, иләмсез каргалар кебек, биш-алты хатын урап ала.

Юан хатын. Әнә! Күрә торып төрмә кошы үстерәбез!

Өммегөлсем. Башыбызга кара хәсрәт булды инде!

Юка хатын. Кая чабалардыр?!

Юан хатын. Тәрәзә ваталар!

Өммегөлсем. Керләрне пычраталар!

Юка хатын. Йокыдан уяталар!

Юан хатын. Тузан туздыру турында әйтәсе дә юк.

Мәһирә. Болай кыланмыйлар бит инде, улым. *(Халыкка.)* Гафу итегез инде. Хәзер, хәзер пыялачы алып килеп куйдырырмын. Син ваттыңмы, Һадый?..

Һадый *(пышылдап)*. Алмаз, Алмаз!

Җыелган халык янына берән-сәрән малайлар җыела башлый.

Мәһирә *(малайлардан)*. Кайсыгыз ватты?

I малай *(иң алга чыгып)*. Ул, ул ватты.

II малай. Һадый ватты.

Мәһирә *(Һадыйны беләгеннән тотып)*. Әйдә. Әй бала, бала, гел кирәкмәгәнне эшлисең. *(Сөләйман картның җил капкасыннан алып кереп китә.)*

Ө м м е г ө л с е м (*җыелган малайларга*). Барыгыз, күземә күренмәгез!

Ю а н   х а т ы н. Сезгә ишегалдыннан башка урын беткәнме?

Ю к а   х а т ы н. Җыен шпана безнең баракка җыелган инде.

Б е р е н ч е   х а т ы н. Ятимлек. Сугыш шулай итте аларны.

И к е н ч е   х а т ы н. Ата тәрбиясе җитми аларга, ата...

Малайлар, шау-гөр килеп, сәхнәдән чыгып китәләр. Хатыннар утыргычка тезелешеп утыралар.

Ө м м е г ө л с е м. Бу баланың атасы бар идеме соң? Бер дә күзгә-башка күренгәне булмады. Әллә...

Ю к а   х а т ы н. Булмыйча. Һадый куйган да каплаган атасы инде. Зур күз дисеңме, ул авыз дисеңме...

Ю а н   х а т ы н (*симәнке чиртеп*). Кырык дүртнең көзендә, госпитальдән фронтка үтеп барышлый, өенә сугылган иде. Шул китүдән башка күзгә-санга күренмәде.

Ю к а   х а т ы н. Әхтәриме?

Ю а н   х а т ы н. Исемен кем хәтерләгән.

Ю к а   х а т ы н. Әхтәри ул, Әхтәри. Маһирәнең әйтүенә караганда, Берлин янында җирләнгән, ди ул.

Бераздан җил капкадан иңбашына зур агач тартма күтәргән С ө л ә й м а н   к а р т, М а һ и р ә, аның артыннан Һ а д ы й чыгалар да барак ишегеннән кереп югалалар.

Ю а н   х а т ы н. Бу Сөләйман карт та акчага туясы булмады.

Ю к а   х а т ы н. Сөйлисе юк. Ике җанга нигә кирәктер шулкадәр акча.

Ө м м е г ө л с е м. Бала-чагалары бармы?

Б е р е н ч е   х а т ы н. Төпчекләре 44 тә үк хәбәрсез югалды бугай.

Ю к а   х а т ы н. Кызлары да бар иде түгелме?..

Ю а н   х а т ы н. Беренче балаларымы? Разияләреме?!

Ю к а   х а т ы н. Әйе. Гәүдәгә дә кәй, аяк-куллары да нәзек, муены да нечкә кызлары бар иде шул.

Б е р е н ч е   х а т ы н. Минем белән укыды. Беренче классның беренче көнендә үк без аңа Кәтүк кушаматы тактык. Җылап атна буе сабакка йөрмәде. Юмалап, китап, каләмнәр тоттырып, укытучы гына барып алды. Бүгенгедәй хәтерлим букчасының почмагын чәйни-чәйни класска килеп кергәнен.

И к е н ч е   х а т ы н. ТБУМны бетергәч, бер ел яшелчәдә бергә эшләдек. Улмы, ул Разия, ызгышканда, берәүгә дә авыз ачтырмый, оятсыз сүзләр белән олысын-кечесен тигезли иде. Яшелчәдә эленке-салынкы йөрде дә, ата-анасына, күрше-күләнгә ләгънәт укып, яман сүз белән каргап, Ярославлга торф эшенә китте. Ата-анасы хәер-фатыйхасын да бирмәгән икән, дип сөйләделәр.

Беренче хатын. Шул кичне Сөләйман карт, аулаграк чакны сагалап алып, үз гомерендә беренче тапкыр Йомры таш эргәсенә менеп, кесәсеннән ак намазлык чыгарып, чирәмгә җәеп, кыйблага карап, Тәңресенә баш орган. «Бердәнбер кызымны харап итмә берүк. Түбән оч Ибраһим көненә калдырма,— Ибраһим кызы урман кисәргә Марига барган җирендә куенына акча, бүксәсенә бәбәй тутырып кайткан иде,— кызыма зиһен бир, түземлек өстә, ярдәмеңнән ташлама!» — дип, ихлас ялварган икән, дип сөйләделәр бит.

Икенче хатын. Әйе, әйе. Чишмә анасының хәтерен саклап, тиле Баһавига, аксак Ситдыйкка садака...

Беренче хатын. Тирә-якның диванасы Гыйльванны атна дәвамында, ашатып-эчертеп, өендә асраган, дип сөйләделәр.

Икенче хатын. Озак кайтмады бугай ул Разия.

Беренче хатын. Шул китүеннән үзе шикелле үк тәбәнәк, дәү чуен башлы, муенсыз рус егетенә кияүгә чыгып, бергә җайсыз кысылышып төшкән сап-сары фотоларын аналары Зөләйха күрсәтеп йөргән шул.

Икенче хатын. Нишләп кайтмасын? Кайтты. Сугыш беткән көзне кайтты, җирән кыл чәчле, сипкелле почык борынлы, муенсыз ике малаен ияртеп кайтты бит әле ул. Малайлар татарча бер авыз сүз белмиләр иде.

Өммегөлсем. Нады же! Татар имие имгәннәрен оныткannар, диген. Боже упаси!

Икенче хатын. Бабаларының, Сөләйман картның, түбәтәенә төртеп күрсәтеп, «чаплашка, чаплашка!» дип көлгәннәрен үзем күрдем.

Беренче хатын. Разия белән бергә укыгач, мин аларга гел кереп йөри идем. Икенче балалары Йосыфҗан иде. Таза иде. Ашарга утырса, һич туюны белмәс иде. Бер утырганда, унике бәрәңге дурычмагын күз ачып йомганчы бөкләп куя иде.

Өммегөлсем. Боже упаси. Унике дисеңме?!

Беренче хатын. Ярма ташы хәтле бәлешнең йогын да калдырмый иде.

Өммегөлсем. Боже упаси.

Беренче хатын. Ояга менеп, сигез җылы күкәй, олы бер чүлмәк сөтне тын тартмыйча чөмереп бетерә иде.

Икенче хатын. Арттырасың, су кушасың бугай.

Беренче хатын. Бер ялгансыз. Ипи телемен кул яссуы калынлыгы кисә, вак бәлешләрне бер кабуда йота, ашны, ботканы чүмеч хәтле агач кашык белән соса иде.

Өммегөлсем. Боже упаси.

Беренче хатын. Упасимы, не упасимы, пилмән бөгә башласа, аналары Зөләйха түти кулсыз калам, дип сөйли иде. Йосыфҗан бер утыруда ике йөз пилмәнне сыпырып бетерә, дия иде. Нигә, тирә-якта Сөләйманның Йосыфҗанына бирән бул-

ган, гуҗ кебек тыгына икән, һич туйдырыр әмәлләре калмаган дигән яман сүзләр йөрде бит.

Өммегөлсем. Гуҗ диген, ә?

Беренче хатын. Мәктәпкә озатканда, ярты бөтен ипигә ярты кадак май ягып тамагын ныгыталар иде. Букчасына вак-төяк ризык — дүрт-биш катлама, мичтә тәгәрәткән ике кило бәрәңге, киндер, мәк түбе өше туклыклы ризыкларны төяп җибәрәләр иде.

Өммегөлсем. Әйтәм җирле, ул карт, Сөләйманны әйтәм, тел-тешсез калган, дөнья мәшәкате баскан икән. Боже упаси. Дию пәрие ашатып кара әле.

Беренче хатын. Тутырып җибәрәләр, кайтканда, букчада бер бөртек ризык калмый. Йосыфҗан мәктәптән өйләренә кадәр разбой салып, «Әнә-әй, карыным ачты!» дип үкереп кайта иде. Мескен Зөләйха апа, капка төбенә чыгып йә күпер өстенә үк менеп, малаен каршы ала, кулында әрчелгән күкәй, карабодай табикмәге яки бер кыерчык ипи иде.

Юан хатын. Әй бичара ана.

Юка хатын. Кирәк бит, ә?

Өммегөлсем. Боже упаси!

Беренче хатын. Көтү каршына төшкән Йосыфҗан әнкәсе кулындагы сарыкларга дигән каткан икмәкне чәйнәмичә генә йотып җибәрә иде. Сабый чагында, тавыкларга сипкән ярманы чүпләп, ярма ташы ялап үскән малай ул Йосыфҗан.

Юан хатын. Кая китеп олакты соң ул бахыр?

Беренче хатын. Йосыфҗан кырык бернең июнендә үк сугышка китте. Сөләйман абзый Чишмә анасының рухына багышлап, икенче тапкыр сукыр Миңлебикәгә тавык суеп илтсә дә (*тиле Баһави ул чакта үлгән иде инде*), теләкләре изге, сүзләре хак булса да, теләге кабул булмады, Тәңресе чарасыз калган атаны тыңламады, бик күп адашкан күңелләргә юл табышкан, ятимнәрне иркәләгән, толларны юаткан Чишмә анасы аның гозерен ишетмәде. Йосыфҗан сугышка да барып җитә алмады. Казаннан ерак та түгел, Суслонгер дигән каһәрләнгән урында, запас полкта торганда, эче китеп, дизентерия дигән афәттән җан тәслим кылды, дип сөйләделәр бит.

Өммегөлсем. Оятыннан телсез калган инде алайса, бабаң.

Юан хатын. Кызың — кыз, улың ул булмасын. Бөкрәерсең дә.

Өммегөлсем. Тамак тәмугка кертә, тамак эш белән бер сукмактан йөртә, ашагандыр шунда бер-бер ярамаган ризык, бирән корсак!..

Ишектән Сөләйман карт, аның артыннан, сулы чиләк күтәреп, Маһирә чыга.

М а һ и р ә. Абзый... *(алъяпкыч кесәсеннән унлык акча чыгарып)* алыгыз! Рәхмәт сезгә.

Маһирә өй артына китеп югала. Сөләйман карт үз капкасына атлый. Икенче катның тәрәзәсеннән карап торган Һ а д ы й н ы күреп, бармагы белән ымлый.

С ө л ә й м а н к а р т. Әй, малай! Монда кил әле!

Һ а д ы й *(сәерсенеп, як-ягына каранып)*. Минме?

С ө л ә й м а н к а р т. Син инде, син! *(Һадый ишектән очып диярлек чыга да Сөләйман карт янына килә.)*

Ө м м е г ө л с е м *(Һадый артыннан)*. Әнә сугыш чукмары чыгып бара. *(Кереп китә.)*

Ю а н х а т ы н. Тәрәзә ватучы. *(Утыргычтагылар өйләренә таралалар.)*

Һ а д ы й. Нәрсә, бабай?

С ө л ә й м а н к а р т *(унлыкны Һадыйга сузып)*. Бар, әниеңә кертеп бир.

Һ а д ы й. Кирәкми, бабай.

С ө л ә й м а н к а р т. Ал инде, ал!

Һ а д ы й. Алмыйм. Мин озакламый үзем эшли башлыйм.

Сөләйман карт көчләп диярлек малайга унлыкны тоттыра да капкасыннан кереп югала. Һадыйны м а л а й л а р әйләндереп ала.

I м а л а й. Йә, ничек, куйдымы?

Һ а д ы й. Ну мастер да икән үзе. Сул кулы белән пыялага басты да уң кулындагы алмазы белән чыж-ж иттереп йөртеп алды. Күз дә иярмәде аның хәрәкәтенә. Пыяла келт кенә итеп сынып төшмәсенме?!

II м а л а й. Алмаз белән?

Һ а д ы й. Алмаз белән дигән була, үләксә. Синең алмаз күргәнең бармы соң, аңгыра.

I м а л а й. Их, карап торсаң иде аны. Алмаз белән диген, ә?

Өй артыннан, буш чиләк күтәреп, М а һ и р ә килеп чыга.

М а һ и р ә. Улым, Һадый, әйдә өйгә керәбез.

Һ а д ы й. Бераз гына торыйм инде, әни.

М а һ и р ә. Кер, дим мин сиңа. *(Малайлар, шау-гөр килеп, сәхнәдән кайсы кая чыгып китәләр, Һадый әнисе янына килә.)* Нәрсә ул кулында?

Һ а д ы й *(учындагы унлыкны күрсәтеп)*. Теге бабай бирде.

М а һ и р ә *(унлыкка карап)*. Шул унлык икән шул. *(Һадыйны кочаклап, утыргычка барып утыра.)* Алай шукланырга ярамый бит, улым... Ярамый. Әтиең дә яратмас! *(Һадый җирдә яткан зәңгәр сәдәп күреп кулына ала.)* Тагын нәрсә алдың инде? Кешенеке булып, үзеңә урлагансың дип бәла ягарлар.

Һ а д ы й (*сәдәпне бармак очларында тотып, әнисенә күрсәтеп*). Сәдәп!

М а һ и р ә. Сәдәп?

Һ а д ы й. Әйе, зәңгәр сәдәп! Бәләкәй сәдәп!

М а һ и р ә (*Һадыйның кулындагы сәдәпне үзенә ала да озак кына карап торганнан соң*). Өйләнешкән елны әтиең, Сигезенче мартка дип, үземә зәңгәр күлмәк бүләк иткән иде. Шул күлмәкнең җиң очында иде ул сәдәп. «Бигрәк яратам, Маһирә, шушы күлмәгеңне!» дия торган иде атаң Әхтәри. Ел саен яз да, көз дә җилләтеп, кимичә сакласам да, тузды шул. Күлмәк белән бергә өч почмаклы хатлар да саргайды. Күлмәк тузып, итәкләре, җиңнәре сизери* башлагач, мин аңардан вак-вак капчыклар тектем. Әхтәрием, атаң ранный булып ятмыймы, берәр җирдән хәбәре килмәсме дип, соңгы акчаларыма сатып алып, шул капчыкларга кипкән өрекләр, урман чикләвекләре тутырып тоттым. Өрекләр ашалды, чикләвекләрнең истәлеге булып, урындык башларында бәләкәй чокырлар гына калды. Чикләвекләр белән тәгәрәп син үстең. Зәңгәр капчыклар тузып, өстәл сөрткеч тастымалларга әйләнсәләр дә, җиң очындагы зәңгәр сәдәпләрне саклый идем. Син үсә төшкәч, күз алдымда истәлеге булсын дип, синең күлмәк изүеңә таккан идем мин аларны. Ярый, улым, караңгы төшә. Миңа төнге сменага эшкә барырга кирәк. Арлы-бирле сугылма, тамагыңа аша да ятып йокла.

Һ а д ы й. Әни, бүген ишекне бикләмә инде. Мин ишегалдында аз гына уйныйм да керәм.

М а һ и р ә. Ярамый, улым.

Һ а д ы й. Әни...

М а һ и р ә. Ярамый, улым.

Һ а д ы й. Печтек кенә, нәни генә уйныйм.

М а һ и р ә. Аз гына түз инде. Менә ике көннән көндезге сменага күчәм. Туйганчы уйнарсың.

Һ а д ы й. Әй, ике көннән бит ул. Бүген уйныйсы иде.

М а һ и р ә. Улым, әйбәт кенә бул. (*Ишектән кереп китәләр.*)

Музыка. Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнәдә төнге караңгылык. Һ а д ы й икенче катка урнашкан фатирларының тәрәзә төбендә утыра. Подъезд төбенә п о ч т а л ь о н килә.

Һ а д ы й (*өстән, почтальон хатынга*). Апа-у!

П о ч т а л ь о н. Нәрсә бар?

Һ а д ы й. Почмакта примус астындагы ярыкта ачкыч бар. Ишекне генә ач әле, апа.

---

* *Сизери* — туза.

Почтальон. Кая барасың?

Һадый. Монда гына, монда гына, апа!

Почтальон. Өеңдә генә утыр! Сәләев кайда икән, белмисеңме?

Һадый. Рәшат абыйммы? Ишекне ачсаң, әйтәм.

Почтальон. Әйт инде, кайда?

Һадый. Өйдә юк ул.

Почтальон. Вәт сантый. Өйдә юклыгын үзем дә беләм!

Һадый. Ишекне ачсаң, эзләп табам мин аны.

Почтальон. Рәхмәт, каян килгән сыщик!

Һадый. Нәрсә, әллә хат бармы? Аның бит хат язар кешесе юк.

Почтальон. Телеграмма бар.

Һадый. Бир миңа, апа. Үзем бирермен.

Почтальон. Бирерсеңме? Онытмассыңмы?!

Һадый. Онытыр, бар.

Почтальон. Ә ничек бирим?

Һадый. Примус астыннан ачкыч алып, ишекне ач та бир.

Почтальон. Акылың котмы?!

Һадый. Алайса, әнә утыргыч янында полковник хатыны Өммегөлсемнең таягы онытылып калган. Шул таякның кадагына телеграмманы када да миңа суз.

Почтальон. Онытa күрмә. (*Таякка телеграмманы кадый да Һадыйга суза.*)

Һадый. Рәхмәт, апа. Юлыңда бул. Синең кирәгең калмады. Болай булгач, ишек ачыла.

Почтальон. Ишетсен колагың, чыгып йөрмә. Ул-бу хәл булса, әниең миннән күрер.

Һадый. Рәхмәт, почтальон апа.

Почтальон. Нәрсә өчен?

Һадый. Өммегөлсемнең шоп-шома таягы өчен. Бүген төнлә мин аннан тәрәзә рамы ясыйм.

Почтальон. Олы кешенең таягын боза күрмә, ишетсен колагың. Рәнҗер үзеңә. (*Почтальон чыгып китә.*)

Һадый. Их, апа. Бу тәрәзәләр белән чуарланган ишегалдыннан читкә, еракка китәсе, теләгәнчә уйныйсы, чабасы, йөгерәсе килә.

Рәшат кайта да подъезд ишеге төбенә якыная.

Һадый. Рәшат абый!..

Рәшат (*сискәнеп, куркып*). Уф, котны алдың. Нәрсә бар, Һадый.

Һадый. Сүзем бар.

Рәшат. Сөйләп кара.

Һадый. Примус төбеннән ачкычны ал да, ишекне ачып, мине урамга чыгар әле?

Рәшат. Йокла, Һадый, йокла. Балалар вакыты чыкты.

Һадый. Юк. Башта мин сине биетәм әле.

Рәшат. Биегән диярләр.

Һадый. Алайса, мин сиңа менә бу телеграмманы бирмим.

Рәшат. Миңа?.. Телеграмма?.. Алдашма. Мин беркемнән дә телеграмма көтмим.

Һадый. Укыйммы?..

Рәшат. Укы.

Һадый. Ишекне ач.

Рәшат. Шаярма, Маһирә апа белсә, нәрсә дияр?

Һадый. Алайса бие!

Рәшат. Ярар инде, Һадый. Миңа да, үз гомеремдә бер генә тапкыр булса да, телеграмма тотып карарга ярыйдыр бит.

Һадый. Икесенең берсе: йә биисең, йә ишекне ачасың!..

Рәшат. Ярый. Синеңчә булсын.

Һадый тәрәзә төбенә аякларын бөкләп менеп утыра да кул чаба-чаба бию көе такмаклый. Рәшат ишегалды буйлап биеп китә.

Һадый. Бие, бие, биесәнә
Шушы такмак көенә.
Тыпыр-тыпыр бер биесәң,
Күңел генә сөенә.
Һоп, һоп, һопа-һоп,
Биючегә рәхәт.
Биемәгән туташларның
Йөрәгенә җәрәхәт.

Тәрәзәләр ачыла, башлар күренә.

Юан хатын. Айт, эттәгенәсе!.. *(Рәшат, тәрәзәдәгеләрне күреп, оялып биюеннән туктый.)* Нәрсә?.. Һадый «Әпипә»гә биетәме?.. *(Тәрәзәсен яба.)*

Өммегөлсем. Озакламый әле ул безне бөтен ишегалдыбыз белән биетәчәк!.. *(Тәрәзәсен яба.)*

Юка хатын *(Рәшатка)*. Йокла, дивана. Сәгать төнге унике! Кешеләрдән оял! *(Тәрәзәсен яба.)*

Һадый. Бию — гайбәт сату түгел, ояты юк!

Рәшат *(үпкәләп)*. Әй синең белән. *(Кереп китмәкче була.)*

Һадый. Тукта, укыйм. *(Телеграмманы укый.)* «Уналтынчы майда синең янында булам. Өйдәрәк торырга тырыш. Сине күрәсем бар. Әниең».

Рәшат *(сискәнеп китә)*. Кем?..

Һадый. Әниең! *(Телеграмманы җиргә ыргыта да тәрәзәсен яба.)*

Рәшат *(телеграмманы алып укый, гаҗәпләнеп)*. Әниең... әниең... *(Утыргычка барып утыра да озак кына паузадан соң.)* Әниең... *(Кабат Һадыйның тәрәзәсе ачыла. Тәрәзәдән йомычкалар очып төшә.)*

Музыка. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, яңа көн туган. Тәрәзә төбенә төшкән йомычкалар янында хатыннар җыелышкан, алар пыр тузып гәпләшә.

Өммегөлсем (*йомычкаларны кулына алып*). Менә күрегез инде. Шул малай актыгы алгандыр, дип әйттемме мин сезгә? (*Маһирә кайтып керә дә ашыга-ашыга җыелган халык янына килә.*)

Маһирә. Нәрсә булды тагын?

Юан хатын. Нәрсә булсын. Менә Өммегөлсем ханым таягын ишегалдында онытып калдырган. Синең малаең шуны урлаган һәм тураган.

Һадый (*башын тәрәзәдән чыгарып*). Мин тәрәзә ясыйм.

Өммегөлсем (*черелдәп*). Ясый, һе, кара әле берәүләрне.

Юка хатын. Син тәрәзәләрне вата гына беләсең!

Юан хатын. Синең ишеләрдән гомергә игелек буласы юк!

Һадый. Мин, чыннан да, тәрәзә ясыйм, әни. Менә, менә, ышанмасагыз, йомычкалары. (*Тәрәзәдән йомычкалар ыргыта. Астагы халык як-якка таралыша.*)

Өммегөлсем. Бандит!

Юан хатын. Эгоист!

Маһирә. Алай ярамый бит инде, улым.

Һадый. Мин үскәч, тәрәзәче булам, әни. (*Ул ишегалдыннан үтүче Сөләйман картны күреп ала.*) Бабай, пыялачы бабай...

Сөләйман карт (*туктап кала*). Нәрсә бар, улым?

Һадый. Бабай, күрәсеңме безнең йортта күпме тәрәзәләр.

Өммегөлсем (*сукранып*). Бандит! Ват, ват, сиңа җитәрлек. Син ватырсың, анаң түләр.

Һадый. Син нәрсә аңлыйсың. Әнә бабайның алмазын күрәсе иде сиңа. Пыялага бер генә сыза, шунда ук пыяла келт итеп кителә дә төшә.

Юан хатын. Бу безгә алдагы тормышта нәрсәләр генә күрсәтмәс әле... (*Керен китә.*)

Юка хатын. Үги бала үстерсәң, авызың-борының кан булыр, үги бозау үстерсәң, авызың-борының май булыр, дип тәккә әйтмәгәннәр. (*Кереп китә.*)

Ишектән, атылып, Һадый килеп чыга да кереп баручы Өммегөлсемне бәреп ега.

Өммегөлсем. Нишлисең, бандит. Таяк белән башыңны сугып ярам бит. (*Егылган урыныннан торып, сукрана-сукрана өенә кереп китә.*)

Һадый. Аяк астында уралмале! Күрмисеңмени, пыялачы бабай килгән. (*Сөләйман карт янына килә.*)

Маһирә. Чү, бала, олы кешене имгәтәсең бит. Хәзер үк өйгә кер. Ишетәсеңме, өйгә кер.

Һ а д ы й. Хәзер, әни. Күрче, бабай, ничаклы тәрәзәләр!

С ө л ә й м а н к а р т. Тәрәзәләргә көндез түгел, төнлә караңгыда карарга кирәк. Кичләрен җан керә аларга! Тәрәзәдә нур бар икән, тормыш бар, тереклек бар дигән сүз.

Һ а д ы й. Ә синең зур тәрәзәләр куйганың бармы?

С ө л ә й м а н к а р т *(Һадыйның башыннан сыйпап)*. Зур?.. Сиңа ошыймы әллә? Яратмыйсыңмы?

Һ а д ы й *(яратмавын раслап, башын чайкап)*. Безнең ишегалдында зур тәрәзәләр булса, бөтенләй аптыраш булыр иде. Болай да уч төбе кадәр ишегалдында тегеләр борылырга да ирек бирмиләр. *(Утыргычка килеп утыралар.)*

С ө л ә й м а н к а р т. Әйбәт ул зур тәрәзәләр. Бүлмәләр якты була. Аннары тыш та ап-ачык күренеп тора. Тәрәзә каршында бакча да булса, ә, Һадый?.. Кешене тышкы дөнья белән бәйли ул тәрәзә... Шуның өчен зур булсыннар алар. Тәрәзә алларында бакчалар, гөлләр булсын.

Һ а д ы й. Минем синең белән эшлисем килә, пыялачы бабай. Зур тәрәзәләр куясым, ерак-еракка карыйсым килә.

С ө л ә й м а н к а р т. Безгә, күпләргә, язмыш тар тәрәзәләрдән карарга насыйп итте. Сезнең буын зур тәрәзәләр ясасын.

Һ а д ы й. Күп итеп акча эшлисем килә минем, пыялачы бабай.

С ө л ә й м а н к а р т. Акча белән нишләр идең?

Һ а д ы й. Әнигә зәңгәр күлмәк алыр идем.

Иплэп кенә як-ягына карана-карана, шомлы адымнар белән Ш ә к ү р солдат килә.

С ө л ә й м а н к а р т *(Шәкүрне күреп сискәнеп китә, пышылдап)*. Улым, Һадый, син мине калдырып тор әле. Мин сиңа тәрәзәләр турында күп сөйләрмен. Әнә минем янга яңа гына тар тәрәзә артыннан чыккан Шәкүр солдат килә.

Һ а д ы й. Кем ул Шәкүр солдат, пыялачы бабай?

С ө л ә й м а н к а р т. Улмы? Ул минем төпчегем, сугышка китеп югалган Габдулламның яшьтәше. Сугышка бергә чыгып киткәннәр иде.

Һ а д ы й. Сугыш беткәнгә дә күпме үтте.

С ө л ә й м а н к а р т. Ә шулай да тереләр кайтып тора. Кем белә, бәлки, минем дә төпчегем сугыш исереклеге белән кайдадыр адашып йөридер.

Һ а д ы й. Минем әткәй Әптери белән бергә кайтып керсеннәр иде, ә, пыялачы бабай?!

С ө л ә й м а н к а р т. Көтәргә кирәк, олан, көтәргә. Хәбәрсез югалганнарны көтәргә кирәк. Минем тәрәзәләремә кем ут салыр да, миннән соң минем капкамны кем ачар?!

Һ а д ы й. Мин синең яныңа гел килермен, яме, пыялачы бабай.

С ө л ә й м а н к а р т. Килерсең, улым. Килерсең.

Һадый кереп югала. Аксаклый-аксаклый Шәкүр килә дә, исәнлек-саулык сорашмыйча гына, Сөләйман карт янына килеп утыра. Тырнаклары ярылып, сынып беткән бармаклары белән тезләрен уып ала.

Сөләйман карт (*моң тулы күзләре, көйгән керфекләре арасына югалып торганнан соң, кыяр-кыймас кына*). Бәлки, Шәкүр энем, өйгә керербез?

Баганалары бер турга ава төшкән капка. Сөйрәлеп кенә ачыла торган ишектән авыз читен яулык белән каплаган Зөләйха әбинең башы күренә.

Шәкүр (*өзек-өзек тавыш белән*). Рәхмәт, Сөләйман абзый. Кереп тормам инде. (*Озак кына паузадан соң.*) Сугыш нәрсә... Нәрсәкәй дисеңме? Кулга корал кергәч, сугышасың аны-сы. Плен яман! Плен! Берзаман командирлар качып бетте, припаслар юк. Кергәндә үк өч кешегә бер мылтык, бер мылтыкка дистә ярым патрон биргәннәр иде... Плен әшәке! Качтык без аннан, Сөләйман абзый, пленнан, дим. Ике түгел, өч качтым. Икесендә дә тотылдым. Эт итеп кыйнап, сул аяктан баганага асып куйдылар... Явыз ул немец, вәхшидән дә явыз... Әнекәчкәем, ник тудырдың бу дөньяга, дип кычкырасы килгән чаклар булды... Кычкырыр иден дә, кем ишетә аны?! Өченче качуымда француз макилары арасына барып эләктем. Француз партизаннарын шулай дип атыйлар. Тел белмибез, кием — адәм страмы. Башта ышанмадылар, ябып асрадылар. Вчүтеки ашарга бирделәр. (*Кесәсеннән ак чүпрәккә, аннары кургаш кәгазьгә төрелгән төргәк чыгарып, ашыкмыйча сүтеп, урталайга бөкләнгән катыргыны күрсәтеп.*) Шушы документ булмаса әгәренки, Сөләйман абый, кайту тәтеми иде. Да, дөнья бездән кәмит ясады, икмәктер! Чуалды инде хөлаеклар сугыш елларында. Яхшылары да бар адәм балаларының, мәгәр арада эт-кош та җитәрлек икән.

Сөләйман карт (*катыргыны алып, укымакчы булып карый да, укый алмагач, хатынына суза*). Мәле, сиңа әйтәм, карачы.

Шәкүр (*куркып катыргыны тартып ала*). Макиларда булуымны раслаучы документ. (*Кадерләп төреп, кесәсенә сала*). Франциядән инглизләр йолып алды безне. Коткардылар да, әсир итеп прахутка төяп, илләренә алып бардылар. Өч-дүрт көн баргач ук, Англиядә калырга кыстарга тотындылар. Көн саен үгетлиләр. Чәтердәп торган бер марҗа теттерә урысча сөйләп. Без әз-мәз французча да сукалый башлаган идек. Әллә русчаны аңламыйлармы дип, французча да үгетләп карыйлар, инглизчә дә кыстыралар. Ә без татарлардан ике егет идек, «кайтабыз!» дигәнне русча да, татарча да җибәрәбез димчеләргә. Терәлеп катты тегеләр: «Рәчәйгә кайтсагыз, башыгыз Себердә чериячәк»,— диләр. Күрәбез, жәлләп сөйлиләр!

Сөләйман карт (*ашыгып-каушап*). Калучылар булдымы?

Ш ә к ү р. Эт-кош булмаган җир бармы, кемдер калгандыр, мәгәр минем сүзем гел бер иде: «Кайтам и все!» И-и, анда күргәннәрне сөйләсәң, Сөләйман абзыкаем, баш китәчәк.

С ө л ә й м а н   к а р т. Англичанда да безнекеләр күпме?

Ш ә к ү р. И-и, кым-кырыч. Аларда күргәннәр инде актыккы дисәк, мин әйткәнгә син ышанмассың, Сөләйман абзый... Кызыл әләм селкеп озатып калдылар, яр буена җыелган халык юлга ризыгын-мазарын бирде, «илебезгә кайткач, кирәге чыгар» дип, кием-салым тоттырдылар... Союзниклар! Кызыл әләм селкеп каршы да алдылар. Прахуттан төшкәч, җирне кочаклап җылашабыз, «котылдык!» дип, бер-беребезне үбеп тә алабыз... Бер баракка илтеп яптылар да сәгать ярым үтте микән, ишегалды сыман җиргә чыгарып тезделәр. Чишендерделәр. Авызларны ачып карыйлар. «Кәгазь-мазар, акча эзлиләр!» дип пышылдаша иптәшләр. Шәп-шәрә торабыз шулай, актык чиктә, әйберләремне аралап, шушы документны саклап алып калдым. Аны да алмакчы булалар!.. Бирмәдем, артка лык-лык тибәләр, әле генә үпкән туган ил җирен тырмый-тырмый җыладым. Фильтрация пунктында ярты ел яттык. Немец хәтәр иде, болар алардан да хәтәррәк булып чыкты. Чакыралар да мылтык түтәсе белән төяләр, таяк белән каезлыйлар... «Англиядән нинди задание белән кайттың, син кайсы ил шпионы?» дип теңкәне корыттылар. Тикшергәндә, ялгышлык белән, француз телен әзмәз беләм, дип ычкындырганмын... Рәчәй җирендә авызың биктә торсын икән ул, агай, ачылмасын да, ябылмасын да! Чәчләрем картаеп коелмады, учма-учма йолкый торгач, сирәкләнде... Шушы документ булмаса, исән калулар юк иде... *(Озак кына паузадан соң.)* Кайтыр, Габдулла да кайтыр. Ул югала торган егет түгел. *(Авырлык белән урыннан торып.)* Үлеменә дә бирешмәс, сугышта, пример, башлап куркак үлә... *(Пышылдап, иелә төшеп.)* Алай да, Сөләйман абзыкаем, мин сөйләгәннәрне берәүгә дә тишмә. Җаның тиз генә чыкмаганлыгын әйтергә теләп, примерга гына сүләдем боларны. Кайттык менә, ахыры хәерлегә булсын! Кайтыр Габдулла, кайтыр, Зөләйха түти. *(Аксаклап китеп бара.)*

С ө л ә й м а н   к а р т *(озаклап бер ноктага карап торганнан соң)*. Сиңа әйтәм, яныма утыр әле. *(Зөләйха әби Сөләйман карт янына килеп утыра.)* Егетнең соңгы сүзләре төче. Егет нәрсәдер белә. Шәкүр нәрсәдер яшерә.

З ө л ә й х а   ә б и. Тәкъдирдә язганыдыр. Кайтасылар кайтып бетте, югалып торганнар табылды.

С ө л ә й м а н   к а р т. Тәкъдирдә язган икән, кайтыр.

З ө л ә й х а   ә б и. Дөреш күрәзәчесе Түбән очка төшкән икән. Әллә булмаса, берәр дистә күкәй күтәреп барып кайтыйммы?

С ө л ә й м а н   к а р т. Утыр! Дистә күкәеңне әнә Бибиҗа-

малларга керт. Биш баласы белән ятим калды, савап булыр! *(Мөхәммәт карт күренә.)* Әйдә, сиңа әйтәм, өйгә керәбез. *(Урыннарыннан тора башлыйлар.)*

Мөхәммәт карт. Ерагайдың, кордаш, ерагайдың. *(Сөләйман карт ирексездән урынына утыра.)*

Сөләйман карт *(Зөләйха әбигә)*. Сиңа әйтәм.

Зөләйха әби. Ярый, атасы, ярый. *(Урыныннан тора да Мөхәммәт картка башы белән ым салып, исәнләшеп, капкадан кереп китә.)*

Мөхәммәт карт *(кул сузып күрешә дә Сөләйман карт янына утыра)*. Ераклаштың, Сөләйман кордаш, ераклаштың. Бала чакта җан дуслар булмасак та, бергә тәгәрәп үстек. Исәйгәч, кичке уеннарга, аулак өйләргә бергә йөрдек. Олыгайгач та читләшмәгән кебек идек, мәгәр сугыштан соң аралар ерагайды. Минем улларым, ике киявем исән-аман әйләнеп кайтканны әллә кичералмадың инде?

Сөләйман карт. Кайтсыннар берүк, бөтен киткән кеше үлеп калырга димәгән, дөнья бетмәгән, дөнья авырлык белән булса да яши. Югары авылда да аны кемдер яшәтергә, алга таба илтергә тиештер ләбаса, берүк кайтсыннар гына! Толларны юатырга, үксезләрнең күз яшен сөртергә җылы куллар кирәк. Синекеләр гомер буе инсафлы, кешелекле, гадел яшәделәр, исән кайтканнар икән, ишле бала-чагалары куанычын күреп, хатыннарын сөендереп яшәсеннәр.

Мөхәммәт карт. Яшь чагында без синең белән мәчет юлын таптамасак та, укыган догаларыбыз гап-гади такмазадан узмаса да, инде сугыш ачылып, илдә хәвеф башлангач, Аллаһы Тәгаләне ешрак искә төшердем шул мин, кем, Сөләйман яшьти. Тәңредән ерагайдың, кордаш. Менә мин сугыш елларында биш вакыт намазымның берсен дә калдырмадым. Намаз арты саен улларыма, кияүләремә исән-иминлек сорап, бер Ходама ялвардым. Теләгәннәрем кабул булды, иншалла, ялваруларым барып иреште, балаларым тезелеп исән кайтты, мең шөкерләр Ходама!

Сөләйман карт. Бик изге җан икәнсең, кордаш, Тәңре белән турыдан-туры алыш-бирешкә дә керер чамаң бар икән, нигә шунда, бер тапкыр булса да, минем улым өчен дога кылмадың? Нигә аның исемен дә Ходайга ирештермәдең?

Мөхәммәт карт *(озак кына тынлыктан соң)*. Йомыш кисәге дә бар иде, Сөләйман кордаш, әйтим микән, юк микән, дип утырам.

Сөләйман карт. Сезнекеләр йомышсыз йөрмәс.

Мөхәммәт карт. Йомыш бар анысы. Күрәм, синең капка да нужарган икән, баганалары бөтенләй черегән... Без бит төпчек малайга ихата, нигез алырга йөрибез. Яше дә шактый. Өйләнәм, дисә дә, күптән вакыт җиткән. Көзгә өйләнеп тә куй-

масмы. Җамал карчыкны беләсең, йорт җире ару гына, үзе тол, ире сугыштан кайтмады, ерак булса да, безгә кодача тиешле кеше, моңарчы бер-беребезне какмадык, шул Җамал кодачаның йортын Кәримҗанга килешендек.

Сөләйман карт. Җамал кая бара?

Мөхәммәт карт. Бибигайшә белән өйдәш булмакчылар. Ике тол, ике карчык.

Сөләйман карт. Гайшәнең кызы, кияве бар.

Мөхәммәт карт. Калага сеңгән ич алар! Калач ашап яталар. Ә монда икесе тиң алабутага калган. Әз-мәз онын бирербез, мал суйганда да буш итмәбез.

Сөләйман карт. Алай икән.

Мөхәммәт карт. Шуннан искә төште...

Сөләйман карт. Ачыграк әйт, бутама башны.

Мөхәммәт карт. Хан заманыннан бирле капка баганалары ята ич синдә.

Сөләйман карт. Ятса?

Мөхәммәт карт. Барыбер муртаеп яталар. Биш багана. Сиңа җил капкаңны элеп куярга ике багана җитеп ашкан. Бишесен дә сорармын дип менгән идем, күрәм, үзеңнекеләр дә тузган. Минем малайлар җыйнаулашып менеп икесен замат* арада сиңа көйләп бирерләр. Калган өч баганаңны миңа сатасың. Хәзер имән багана табу бик читен икән. Башыңа төшмичә белмисең. Малайлар лесничествога барып кайттылар, районга кагылганнар — юк, имәннәрне кисеп, буй-буй турап, Донбасска җибәрергә дигән фәрман бар, дигәннәр. Безгә тиз генә чират тимәс! Ә Җамалның капкасы, ташка үлчим... Яшьләр керергә оялырлык. Капка бит ул — йортның, хуҗаның йөзе...

Сөләйман карт (*озак кына бүртенеп утырганнан соң*). Мине күмәргә булдыгыз алайса?

Мөхәммәт карт. Нишләп алай дим? Муртаеп яталар, диюем... Беләм ич, заем акчаң да түләнеп бетмәгән...

Сөләйман карт (*мыскыллап*). Күпме бирергә чамагыз бар?

Мөхәммәт карт (*сүрән генә*). Хакын үзең әйтерсең.

Сөләйман карт. Бай булсаң да, як-ягыңда терәкләрең ишле булса да, мин куйган бәһане түләрлек чамаң юк синең, кордаш. Күмәргә булдыгыз алайса? Бала-чагасыз яши, үзенең дә көне санаулы калды дип беләсез. Үзегез генә уйлаштыгызмы, әллә Җамал карчык белән киңәштегезме? Баш очымда кара козгын булып каркылдыйсың! Габдулла кайтмас дип беләсеңме? Капка — хуҗаның йөзе, дисең дә, минем чыраемны, йөземне умырып алмакчы буласың инде.

---

* *Замат* — тиз.

Мөхәммәт карт (*урыныннан торып*). Бушка сорап килмәдем, сатып алырга. Әйттем исә кайттым. (*Ачулы адымнар белән китеп бара.*)

Зөләйха әби (*капканы әз генә ачып, йомшак кына итеп*). Сиңа әйтәм!..

Сөләйман карт (*ачуын баса алмыйча*). Капка... Күпме еллар ачылып-ябылып, ничәмә-ничә еллар кешеләрне, малтуарларны үткәреп, ихатаның тынычлыгын саклаган тугры капка хәзер, хәле бетеп, коймага сөялеп ял иткәч тә, Сөләйман карт белән Зөләйха карчык мәңгегә ул капкадан чыгарга ашыкмыйлар әле. Аларның әле төпчекләрен, Габдуллаларын, шул капканы ачып каршы аласылары бар. Габдулла кайтыр. Һәм бер көн килер, мине дә шушы капкадан алып чыгарлар. (*Зөләйха әбигә.*) Минем арттан син дә чыгарсың. Икәүләшеп, бер-бер артлы шушы капка аша еракка, томанлы һәм серле Мәңгелеккә, караңгы һәм шомлы ләхеткә чыгып китәрбез. Капка безне шыгырдап озатып калыр, саубуллашыр.

Зөләйха әби. Сиңа әйтәм, әллә артыгын бирәсеңме? Бездән соң бу йортка керүче, аларны сагынып яшь коючы булырмы?..

Сөләйман карт. Әнкәмә әҗәл чире килеп җиткәч, күзен шушы капкадан алмады. Бер иртәдә ярты чынаяк чәй эчкәч, чынаягын каплады, озак итеп амин тотты, кинәт: «Өч көннән мин үләм, улым, капканы ачыбрак тотыгыз, мин аның килгәнен күрергә телим!» — диде. Өч көн якты күздә, кат-кат өелгән мендәргә арык гәүдәсен терәп ятып, капкадан күзен алмады. Өченче көнне, өйләдән соң, кояшлы яңгыр явып торганда, ул миңа дәште: «Килде, улым, мин аны күрәм»,— диде. Мин тәрәзәгә ташландым, ишегалдында беркем дә юк, хәтта җил дә юк иде. Ә ачык капка нигәдер бер яктан икенче якка тирбәлә иде. Каян белгән ул үзенең үләр сәгатен? Капкадан кемнең керүен көтеп торган? Кем кергән? Мин шул көннән башлап капкага колак сала башладым. Юкмы шунда берәр ым?.. Җил капка үзе бер ым, ишарә түгел микән? Кемнең соңы хакында хәбәр итте соң әле ул капка?.. Ничә тапкыр капка баганаларын, такталарын алыштырдык, тимер биге шул килеш калды, берсеннән икенчесенә күчә-күчә бүгенгәчә килеп җитте. Дөнья ага, нидер үзгәрә, нидер алмашына, нәрсәдер яши, кулдан кулга, буыннан буынга күчә... Сөләйман да китәр, Зөләйха китәр, ризыгыбыз киселгән көннәребезнең берсендә кем безнең арттан капкабызны ябар? Кем?

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, шул ук картина. Барак карчыклары утыргычта. Кайсы йон эрли, кайсы бәйләм бәйли, кайсыларыдыр симәнке чиртеп гайбәт саталар.

Өммегөлсем. Ишеттегезме әле, Шәкүр солдатны районнан килеп алып киткәннәр ди.

Юан хатын. Чит ил шпионы булып чыккан ди түгелме соң ул?

Беренче хатын. Сөйлиләр инде. Шәкүрне белмибез. Бергә шәпи сугып үстек. Сугышка кадәр физкультура укытты.

Юка хатын. Алай димә, ахир. Җае бардыр. Гаепсез кешене алып китмиләр аны.

Өммегөлсем. Киткәненә атнадан артты, кайтканы күренми.

Юан хатын. Маһирәнең шпанасы кайтканмы соң әле?

Өммегөлсем. Һадыймы? Ә кая олаккан? Әйтәм җирле, күзгә-башка күренми.

Юан хатын. Шәкүр солдаттан соң Сөләй картны да районга чакыртып алганнар бит.

Өммегөлсем. Кит аннан.

Юан хатын. Әйе, теге стекларез шуңа ияреп киткән ди.

Юка хатын. Капка тәләкәсе! Анасы башына бер кайгы.

Икенче хатын. Нәрсә сөйлисез. Әле моннан биш кенә минут элек *(Өммегөлсемгә)* синең әтәчеңне арбага җигеп маташа иде.

Өммегөлсем. Арбага җигеп?! Әтәчем белән ул-бу хәл булса, районга милициягә барам. Ул шпанага права табармын мин.

Беренче хатын. Әнә ич Сөләйман абзый шакылдый. Димәк, кайткан инде.

Өммегөлсем. Аның теге сугышта югалган малае белән Шәкүр солдат пленда бергә булганнар ди.

Юан хатын. Кит аннан.

Өммегөлсем. Мин бывший полковник хатыны. Минем район белән связь бетмәгән.

Юка хатын. Тагын нинди малае бар соң ул картның?

Беренче хатын. Соң, Габдулла соң, төпчекләре. Җырчы Габдулла. Югары авыллар Моңлы Габдулла дип йөртәләр иде. Минем мәрхүм ирем Исрафилнең анасы, каенанам Бибигөлсем шул Габдулланың кендек әбисе иде. Бик яратып, үз баласы кебек итеп сөйли иде. Дүрт сыны төгәл туды, алты айдан ике ирен арасында тешләр җемелдәде, унбер айда тәпи басып китте, яшь ярым дигәндә, теле тәмам ачылды. Башлап әйткәне «әт-тә» булды, тиз-тиз үсте, җитез булды, яшьтәшлә-

реннән бер ягы белән дә калышмады, зиһене нык, кулы егәрле, нәфесе җыенкы, тамакка ашавы да ипле, килешле, һәр яктан камил бала тудырттым Сөләйман Зөләйхасыннан, дип сөйли иде, мәрхүм. Сөләйманның олан диярлеге дә бар, дия иде. Габдулла, туу белән, Йомры таш янындагы чишмә суында чыныгу алды. Без аны Зөләйха белән Чишмә анасына алып бардык, дип кабатлый иде.

Юка хатын. Гаиләсе, бала-чагасы бар идеме соң ул Габдулланың?

Беренче хатын. Кырык бернең июнендә Габдулла Йосыфҗан абыйсыннан өч көнгә соңга калып сугышка китте, Сөләйман картның иң соңгы, актыккы өмете дә киселде, төпчеге Габдулласы да сугыштан кайтмады. Кырык дүртнең көзендә үк өзелгән иде Габдулланың хәбәре. Җан кинәт икегә ярылды. Габдулла китте, Зәйтүнә калды.

Юан хатын. Зәйтүнә, дисеңме? Тукта, тукта теге Хәлилен көткән Галиябану-Зәйтүнә түгелме ул?

Беренче хатын. Суң... Нәкъ үзе. Түбән оч Зәйтүнә.

Өммегөлсем. Хәтерлим. Исемә төште. Ул вакытта без мәрхүм ирем белән Зәйдә яши идек. Югары авыллар театр уйный, дигәч, театрга бардык. Театр беткәч, еламаган халык калмады. Бүгенгедәй хәтерлим: халык бу ике яшь йөрәкне театрдан соң, толыпка төреп, атка утыртып, хәерле юл, бәхет теләп озатып калды.

Икенче хатын. Хәерле юл, бәхет теләгәннәр, озын гомерле булсыннар, дияргә онытканнар, күрәсең.

Беренче хатын. Шулай. Алар театрда гына түгел, тормышта да Галиябану белән Хәлил булдылар. Сугыш алды елларында тирә-як халкы елый-елый аһ итте, сакаллары чаларган ил агалары Габдулла белән Зәйтүнәне очратканда, беренче булып бөгелеп сәлам бирәләр иде. Моңлы бала кыска гомерле була, диләр. Сөләйман картның ярты җан ярчыгы — Зәйтүнә калды.

Ишегалдына кулына җыйнак кына чемодан тоткан, кара-кучкыл битле, озынча ханым килеп керә дә игътибар белән тирә-юньне күзәтә. Аннары утыргычтагылар янына килә.

Ханым. Исәнмесез.

Юан хатын. Сезнең хәер-фатыйхада.

Өммегөлсем. Ходайның биргәненә шөкер.

Ханым. Рәшат биредә яшиме?

Өммегөлсем. Сәләевме?

Ханым. Әйе, Сәләев.

Икенче хатын. Әйе, әйе, биредә.

Беренче хатын *(башы белән ымлап)*. Әнә теге ишек янындагы ике тәрәзә Рәшатныкы.

Ханым. Өйдә микән?

Ю к а  х а т ы н. Юк, юк, өйдә түгел. Бу вакытта эштә була ул.
Ө м м е г ө л с е м. Ә сез анык кеме буласыз?

Ишектән, пыр тузып, Һ а д ы й очып чыга да урамга атыла.

Б е р е н ч е  х а т ы н. Һадый!..

Һ а д ы й *(туктап)*. Нәрсә?! Кайсыгызның тәрәзәсен куясы бар?

И к е н ч е  х а т ы н. Син Рәшат абыеңны күрмәдеңме?

Һ а д ы й. Юк. Аның әнисе килергә тиеш, шуны каршы алырга киткәндер. *(Пыр тузып, урамга чыгып йөгерә.)*

Ө м м е г ө л с е м. Таптыгыз сорар кеше. Нәрсә ди?..

Ю а н  х а т ы н *(шаркылдап көлеп)*. Анасын каршы алырга китте, ди.

Ө м м е г ө л с е м. Бу Маһирәнең малае акылга тулы микән?

Һ а д ы й *(өй артыннан саклык белән чыга да әкренләп кенә утыргычка килә)*. Синең чама, Өммегөлсем түти, капкорсак!

Ө м м е г ө л с е м. Күрсәтермен мин сиңа Өммегөлсемеңне!.. Аһ, бандит. *(Таягын болгый-болгый Һадый артыннан куып, өй артына кереп китә.)*

Ю а н  х а т ы н. Нәрсә ди?.. Кап корсак, диме?.. Балалы өйдә карак ятмас, ди. Һи... һи... һи... Керим әле.

Ю к а  х а т ы н. Безгә дә вакыттыр.

И к е н ч е  х а т ы н. Кызлар, тагын кайчан чыгасыз?

Ю а н  х а т ы н. Көтү кайткан вакытта чыгарбыз әле.

Берәм-берәм кереп китәләр. Йорт артыннан, тирләп-пешеп, Ө м м е г ө л с е м килеп чыга.

Ө м м е г ө л с е м *(Һадыйларның тәрәзәсенә бармагы белән янап)*. Мин әле сезнең нәселегезне корытмасам, 35 ел бывший полковник хатыны булмыйм! *(Кереп китә башлый. Ханымга сүз әйтмәкче булып туктап кала.)* Мин сезне таныдым. Улыгыз Рәшат суйган да каплаган сез. Ташлап бик дөрес эшләгәнсез. Менә бу Маһирә кебек бандит бала үстергәнче, балаң булмавы яхшырак. *(Өске тәрәзәгә бармагы белән янап, сикерә-сикерә.)* Мин әле сезнеме?.. Мин сезне!.. *(Кереп китә.)*

Ханым утыргычка утыра. Өй артыннан кача-поса чыгып барган Һ а д ы й н ы күрә.

Х а н ы м. Энем, Рәшат абыеңны күрмәдеңме?

Һ а д ы й *(тәрәзәгә карап кычкыра)*. Рәшат абый, Рәшат абый! *(Ике бармагын авызына тыгып, әче итеп сызгырып җибәрә. Бераздан.)* Юк, кайтып җитмәгән. Әнисен каршы алырга киткәндер ул. *(Йөгереп ишектән кереп китә. Тавышка тәрәзәләр ачыла, башлар күренә.)*

Өммегөлсем *(тәрәзәгә карап торган ханымны күреп)*. Юньсез, хатын-кыз башың белән нигә акырасың?! *(Шап итеп тәрәзәсен яба.)*

Һадый *(тәрәзәдән башын чыгарып, Өммегөлсем булып)*. Боже упаси!..

Юан хатын. Нәрсә, әллә урманда адаштыңмы? Тәрбиясез!.. Урам шпаналары кебек сызгырмасаң... *(Тәрәзәсен яба.)*

Юка хатын. Абау, хәерсез. Жуликлар да болай сызгырмас! Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла. *(Тәрәзәсен яба.)*

Маһирә *(тәрәзәләреннән башын тыгып)*. Ханым, Рәшат өйдә юк әле ул. Озакламый кайтып җитәр. Безгә кереп торыгыз.

Ханым. Рәхмәт, биредә генә көтәм. Сез Рәшатның кеме буласыз, хатыны түгелдер бит?..

Маһирә. Юк. Күршесе. Рәшат үзе генә яши. Сез үзегез кем буласыз?

Ханым. Мин, мин... танышы.

Маһирә *(сумка күтәреп кайтып килүче Рәшатны күреп)*. Әнә үзе кайтып килә. Рәшат, сиңа кунак бар. Каршы ал. *(Тәрәзәсен яба.)*

Рәшат, анасын күреп, башта туктап кала, аннары әкрен генә аның янына килә. Алар баш селкеп кенә исәнләшәләр.

Ханым. Ничек яшисең, Рәшат?

Рәшат. Әйбәт.

Ханым. Мин сине озак эзләдем. Ничек син бу аулак авылга килеп эләктең?

Рәшат. Абый калдырып китте. Сугышка киткәндә калдырыр кешесе булмагач, шушы баракта яшәүче бер дустына калдырып китте.

Ханым. Тазалыгың?

Рәшат. Әйбәт.

Ханым. Әтиең турында хәбәрне укыдыңмы?

Рәшат. Укыдым.

Ханым. Әйбәт тә язганнар инде! Йа Хода, нинди изге күңелле кешеләр була бит. Менә мин дә япа-ялгыз яшәп ятам. Былтыр пенсиягә чыктым.

Рәшат. Ялгыз? Ә ирегез?

Ханым. Ирем юк. Үлде. Рәшат... Мин синең янга зур йомыш белән килдем.

Рәшат. Нинди йомышыгыз булыр икән?

Ханым. Рәшат, син күп нәрсәләрне белеп тә бетермисеңдер. Белгәннәрең онытылгандыр. Яшь идең шул әле син. Без әтиең белән бик матур еллар үткәрдек.

Рәшат. Әти исемен телгә алмагыз.

Ханым. Гомеремнең иң матур чакларын мин аның белән

үткәрдем. Яратып чыктым, яратып яшәдем. Әгәр дөньялар үзгәрмәгән булса... *(Сумкасыннан кулъяулыгын чыгарып, күз яшьләрен сөртә.)* Хәерле булсын алайса! Усаллангансың син, бала...

Р ә ш а т. Бала...

Х а н ы м. Ана йөрәген аңлый торган бала булмадың шул син!

Р ә ш а т. Минме? Мин шундый баламы?

Х а н ы м. Атаң мәрхүм дә шундый каты бәгырьле иде!

Р ә ш а т. Сез әтинең кем икәнен беркайчан да белмәдегез, бервакытта да аңламадыгыз! Хәтерегездәме, әтине төрмәгә алып китәргә килгән кешеләр, бусага төбенә килеп җиткәч, нәрсә диделәр? «Атла, атла, халык дошманы!» Уникe яшьлек сабый идем мин ул чагында. Сез аларның сүзләренә шундук ышандыгыз. «Чыннан да дошманмы ул?» дип сорадыгыз. Нигә шулай дип сорадыгыз алардан? Әгәр сез әтине белсәгез, үзегез хәзер раслаганча, аны яратсагыз, аңа ышансагыз, гомерлек юлдашыгызны шулай ансат кына биреп җибәрер идегезме?.. Иң беренче итеп үз тынычлыгыгызны саклар өчен, телефон шнурын өзеп ташлар идегезме?.. Йоп-йомшак күңелле, шат әтинең дошман булуын мин, сабый, һич тә аңламый идем. Нинди дошман булсын ди ул?! Кичтән генә мин аның тезенә утырып торган идем. Ул, бик тырышып, миңа уенчык арба ясаган иде. Шул чагында бик җитди итеп: «Улым, гомер менә шулай уза, иң элек син менә шушы уенчык арбага утырып юлга чыгарсың, аннан машиналарга күчеп, язмыш капкаңны кагарсың, поезд-самолетларда илләр гизәрсең, күп кешеләр белән аралашырсың, берәүләр белән дуслашырсың, икенчеләреннән читтәрәк йөрергә тырышырсың. Һәрчак гадел, саф күңелле, чиста булып кал!» — дигән иде... Сүзләре бүтән булгандыр, әмма әтинең уе әнә шундый иде. Арбага өч тәгәрмәч куйгач, без йокларга яттык. Мин шунда әтигә: «Тәгәрмәче өч кенә булгач, мин ничек юлга чыгыйм соң?» — дидем. Ул мине кочаклады да: «Юк, улым! Юк, балам, сине өч тәгәрмәчле арбага утыртып чыгараммы соң?! Сине өч тәгәрмәчле генә арбага утыртырга һич ярамый, дөнья хәтәр, тормыш давыллы, малай кешеләр нык булырга, нык утырырга тиешләр!» — дигән иде... Төрмәчеләр, төрткәләп, әтине ишек катына алып килеп җиткергәч, чыдамадым: «Әти! Ә арба! Аның тәгәрмәче җитми бит!» — дип үксеп-үксеп җыладым. *(Ханымга.)* Хәтерегездәме, ул миңа таба борылып көлде дә болай диде: «Улым, балам! Кайтам әле мин, арбаңа дүртенче тәгәрмәчне куяр өчен кайтам!» — диде. *(Сумкасын ачып, аннан өч тәгәрмәчле арба чыгара.)* Менә ул арба. Исән. Өч тәгәрмәчле агач арба! Шушы арба — әтинең миндә сакланган бердәнбер истәлеге.

Х а н ы м *(өзгәләнеп)*. Рәшат улым!

Р ә ш а т. Әйе, еллар үтәр, без, өч тәгәрмәчле арбаларда утырып калган дошман балалары, мең афәтләр татып, әтиләребезне эзләп табарбыз. Күпләренең исән гәүдәләрен кайтаралмасак та, тугры исемнәрен кайтарырбыз.

Х а н ы м. Рәшат, кирәкми андый сүзләр! Ул чагында мин берни дә белми идем бит.

Р ә ш а т. Белмәгәч, нигә белергә тырышмадыгыз?! Нигә читләр сүзенә шулай ансат ышандыгыз? Үз балагызның әткәсе кыенлыкка төшүгә, нигә шулай ашыгып аны оныттыгыз?!

Х а н ы м. Мин йөрсәм, ни файда булыр иде икән? Барыбер йолып ала торган түгел иде бит!

Р ә ш а т. Сезнең әтине юллап йөрүегез миңа кирәк иде, ахыр чиктә миңа кирәк иде! Мин бит — өч тәгәрмәчле ярык арба янында утырып калган унике яшьлек сабый! Сезнең аңа ышануыгыз миңа кирәк иде. Ул көннәрдә ни уйлап яшәвегезне мин үсә төшкәч кенә аңладым. Хәтерегездәме, сез бервакыт соң гына кайтып кердегез. Өй салкын, ягылмаган, тәрәзә пыялалары шыкыраеп каткан. Мин юрганга аякларымны ныгытып төрәм дә тәрәзә бозын ялыйм, нәни генә күз ясап, сезнең кайтканны көтәм! Куркуданмы, суыктанмы бөтен тәнем дер-дер килә. Тешләр тешкә тия! Сез лап-лоп атлап кайтып кердегез, ут кабыздыгыз, минем йокламыйча сезне сагынып көтүемне күргәч: «У-у, бәләкәй ерткыч, тач халык дошманы инде!» — дидегез. Бу сүзләрнең мәгънәсен ул чакта ук яхшы белә идем мин!

Х а н ы м. Рәшат, җитте!..

Р ә ш а т. Хәтерегездәме, сез әтинең истәлекләрен ничек юкка чыгардыгыз?!

Х а н ы м *(ачынып)*. Рәшат!..

Р ә ш а т. Иң элек альбом битләреннән аның фотолары югалды. Бергәләп төшкәннәрдән сез аның башын кисеп алдыгыз. Җыйдыгыз, җыйдыгыз да мичкә илтеп яктыгыз! Аннары әтинең кием-салымнарын чыгарып саттыгыз. Ул укыган китапларга чират җитте. Мин үземнең өч тәгәрмәчле арбамны чормага менгереп яшердем. Әти көннәрдән бер көнне кайтып керер дә аңа дүртенче тәгәрмәчне ясап бирер кебек иде... Сугыш башланды. Күп әтиләр фронтларга киттеләр. Бик күп малайлар ясап бетермәгән өч тәгәрмәчле арбалар янында утырып калды. Минем дә абый сугышка китте. Мин, өч тәгәрмәчле арбамны кочаклап, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән менә шушы авылга артык кашык булып килеп төштем. Байтак әтиләр әйләнеп кайтмады, алар белән минем Нурулла абый да мәңгелектә ятып калды. Хәтерлисезме? Сез мине көзге салкын төндә, өстемә сүсәргән иске бишмәт кидереп, аларның биш баласы арасына илтеп ташлаганыгызны?.. Хәтерлисезме, сез минем култык астыма кыстырган өч тәгәрмәчле арбамны таш-

латырга теләгәнегезне? Хәтерлисезме, шул вакытта мин сезнең кулыгызны тешләгәнемне?

Ханым (*уң кулын артына яшереп*). Рәшат, шәфкатьлерәк бул! Мин бит синең анаң. Ул вакыттагы хәлләрне уйлап кара: мин бит, чыннан да, этиең халык дошманы дип ышанган идем. Мин аннан баш тартмыйча булдыра алмадым, коммунист ич мин!

Рәшат. Ярый, ул — дошман, син — коммунист! Мин, мин кем дошманы идем?! Мин! Шул кышны сез кияүгә чыктыгыз... Ирегезне күрсәттегез! Мин аны таныдым! Этине алып киткән өч кешенең берсе иде ул! Нурулла абый сугышка китте дә югалды. Гөлсем апа, биш баласын калдырып, сирәк кенә булса да, минем янга килә иде. Ә сез минем хәлне белергә теләмәдегез.

Ханым. Улым, кызган, кичер мине. Мин бит сине тудырган ана.

Рәшат. Тудырганыңны кичерә алмыйм.

Ханым, чемоданны кулына алып, урамга чыгып китә. Рәшат бер ноктага карап кала. Аның янына Һадый керә.

Һадый. Нәрсә булды, Рәшат абый?

Рәшат (*утыргычка утыра да кулындагы өч тәгәрмәчле арбаны әйләндереп*). Тудырганыңны кичерә алмыйм! Этиең үлемен кичерә алмыйм!

Һадый (*арбаны күреп*). Рәшат абый, бу нәрсә?

Рәшат (*уянып китеп, кулындагы арбага карап*). Арба! Өч тәгәрмәчле арба!

Һадый. Өч тәгәрмәчле арба булмый.

Рәшат. Безнең буын өч тәгәрмәчле арбада уйнап үсте. Мә ал, сиңа бирәм.

Һадый. Өч тәгәрмәчле арба белән мин нишләрмен?

Рәшат. Ә без аңа дүртенче тәгәрмәчне куябыз. (*Сумкасыннан үзе ясаган дүртенче тәгәрмәчне чыгара да малайга суза.*) Ал! Дүртенче тәгәрмәч!.. Энем, гомер менә шулай уза, иң элек син менә шушы уенчык арбага утырып юлга чыгарсың. Аннары, машиналарга күчеп, язмыш капкаңны кагарсың, поезд-самолетларда илләр гизәрсең, күп кешеләр белән аралашырсың, берәүләр белән дуслашырсың, икенчеләреннән читтәрәк йөрергә тырышырсың. Һәрчак гадел, саф күңелле (*аның тавышы, ераклашып барган поезд тавышын хәтерләткәндәй, кайтавазлар булып ерагайганнан-ерагая*), чиста булып кал! (*Аның күмелеп барган тавышына музыка килеп кушыла.*)

Ут сүнә.

Ут янганда, Сөләйман картның иске капкасы сүтелеп ташланган. Капка төбендә юнылган ике имән багана, агач кайрылары ята. Сөләйман карт, өченче бүрәнәгә аркан тагып, аны иңсәсенә куеп, бүрәнә сөйри. Бауның башыннан
Һадый тоткан. Утыргычта бер төркем әбиләр утыра.

Өммегөлсем *(Һадыйга күрсәтеп)*. Карагыз әле теге капка тәләкәсен. Ишегалдын тәки ташлады. Сөләйман картны үз итте. *(Ишек төбендә, билләренә таянып, горур кыяфәттә Маһирә басып тора.)*

Икенче хатын *(Маһирәгә)*. Күрәсең, улың дөнья көтә.

Мөхәммәт карт күренә. Сөләйман карт, каш астыннан гына сөзеп, Мөхәммәт картка карый да бүрәнәгә утыра. Кул арты белән маңгаен сөртеп ала. Ике бияләен бүрәнә өстенә таслап җәя.

Сөләйман карт. Һадый улым, әйдә, утыр, ял итәбез. *(Һадый бияләй өстенә утыра.)* Сиңа әйтәм, әйрән чыгар әле. Һадыйның тамагы кипкән бугай.

Һадый *(олыларча кыяфәт ясап)*. Мин, Сөләйман бабай, ашаганда һәм эшләгәндә тирлим инде. Шуңа тамак янадыр.

Зөләйха әби *(әйрән алып чыга да Һадыйга суза)*. Мә, улым, эч!

Һадый. Әнә олы кешегә бир. Өлкән кешедән башлыйк. *(Зөләйха әйрәнне Сөләйман картка суза. Сөләйман карт әйрәнне кулына ала.)*

Мөхәммәт карт *(килеп утыра)*. Ай рәхмәт, улым. Олы кешедән башлыйк, диме? *(Сөләйман карт эчеп туйгач, Мөхәммәт карт әйрәнгә сузыла.)*

Һадый. Сабыр, абзый кеше. Эшләгәч эчәрсең. Башта осталар эчсен әле. *(Әйрәнне алып чөмерә башлый.)*

Мөхәммәт карт *(Сөләйман карттан көлеп)*. Каян таптың бу останы? Әллә Зәйдән алып кайттыңмы?

Һадый. Телеңә салынма! Әйрән җылына. Эч тә әби базга төшереп куйсын. *(Әйрәнне Мөхәммәт картка бирә.)*

Мөхәммәт карт. Рәхмәт, улым, рәхмәт. *(Әйрәнне эчә дә Зөләйха әбигә бирә. Зөләйха әби әйрәнне күтәреп кереп китә.)* Яңартабыз диген, ә?

Сөләйман карт. Бакчага, түргә керик булмаса. Олы кешене капка төбендә утырту килешми.

Һадый. Капкасы булмагач, түре булмыйдыр аның, Сөләйман бабай.

Мөхәммәт карт. Бу балада адәм акыллары бар. Бик җайлап утырдым әле. Болайрак бит әле, кордаш. Син минем төпчек Кәримҗанны беләсең инде.

Сөләйман карт. Беләм, белмичә. Бригадир улыңны әйтәсеңме?

Мөхәммәт карт. Шуңа Зәйтүнәне киленлеккә сорап барган идек тә, ике як та ризалашты. Үзең күреп торасың, кызның да яше бара. Күңеленә авыр алма, Габдулла әллә кайта, әллә юк. Әнә Шәкүр шикелле гарипләнеп кайтып керсә, Зәйтүнәнең күңеле ятармы, анысын да белгән юк. Күрәләтә кызны ялгыз калдырып булмый, кордаш. Үзең беләсең, көтмәде түгел, көтте Габдулланы. Вәли Мөҗәһитен Зәйтүнә кире борган, дип сөйләделәр. Мөгаен, Габдулланың кайтмавыдыр!..

Зөләйха әби *(кысып ачылган өйалды ишеге ярыгыннан)*. Сиңа әйтәм!..

Сөләйман карт. Нигә миңа киләсе иттең?

Мөхәммәт карт. Кыз шулай сораган.

Сөләйман карт. Ул әйтер дә... Кыз бала. Менә сез нишләп миннән кыз сорыйсыз? Аның язмышында минем дәхелем юк.

Мөхәммәт карт *(ачуы чыгып)*. Син, кордаш, ачык итеп аңлат: ризамы син, рәнҗемисеңме? Кыз тәгаен шуны белергә теләгән.

Зөләйха әби. Сиңа әйтәм!..

Сөләйман карт. Йа Рабби, ни булган бу кадәр? Берәү өйләнә, берәү кияүгә чыга, нигә шулай кара көеп утырырга? Олан кайтмады, югалды, кайтмас та... Чыннан уйлаганда, кыз бала күпме көтә ала? Тере кеше яшәргә тиеш. Тере җан — ишен, иш кушын эзли. Малай кайтмады. Югалды. Улыма ярәшелгән кыз түгел, яшь чакта дуслашып йөргәннәр икән, кем белән кем дус булмаган? Бүгенгә улым хәбәрсез югалган. Кыз, безне шулай олылап, эш башлардан әүвәл киңәшергә уйлаган икән, аңа рәхмәттән бүтән сүз булмас. Риза булмыйча нишлисең?

Зөләйха әби *(кысып ачылган өйалды ишеге ярыгыннан)*. Сиңа әйтәм!..

Мөхәммәт карт. Ярый, кордаш. Әманәтеңне кызга җиткерермен. Килен буласы кеше «туйлап тормыйк» ди. Каршы килмәдек инде. Ярый, кордаш, исән-сау тор. *(Китеп бара.)*

Зөләйха әби *(өйалды ишеген ачып)*. Сиңа әйтәм!.. *(Сөләйман карт урыныннан тора да Түбән очка атлый. Зөләйха әби аның каршына төшә.)* Сиңа әйтәм! Кая китеп барышың болай?

Сөләйман карт. Барыйм әле.

Зөләйха әби. Нинди хәбәр җиткерде тагын Мөхәммәт? Шуның белән күрешәсең дә, тәмам акылыңны җуясың. Дөньяда мин барын онытып бетерәсең. Син теләгән җиреңә барырсың, ә мин монда, берни белмичә, дивана булып калам. Йомры ташка барам, дисәң, ике балаңа җиңеллек сорап барып карадың лабаса... Ни файдасын таптың? Мөхәммәт хәбәрен нигә миңа ачмыйсың?

Сөләйман карт. Сиңа әйтәм... Аптыратма әле! Аптыраганга юл кайда? Озакламам, кайтырмын. *(Китеп бара.)*

Зөләйха әби җирдә яткан имән баганага утыра да, ире киткән якка карап, тирән уйга бата.

Һ а д ы й (*аның янына килеп утыра*). Зөләйха әби, Зөләйха әби, ни өчен картлар, гарип-горабалар гел Йомры таш янына баралар. Нинди сере бер аның?

З ө л ә й х а  ә б и (*кулы белән күрсәтеп*). Әнә кыйбланы күрәсеңме?

Һ а д ы й. Күрәм.

З ө л ә й х а  ә б и. Нәкъ кыйблага карап, мул сулы чишмә агып чыга.

Һ а д ы й. Аның суы салкын, эчкәндә, тешне сындыра.

З ө л ә й х а  ә б и. Изге чишмә дип йөртәләр аны тирә-якта. Чишмә анасы төннәрен утырып ял итсен өчен, чишмә башында ук, әнә күрәсеңме, кәп-кәкре, тубырлы кабыклы, тармаклы ботаклы тал агачы үсә.

Һ а д ы й. Күрәм.

З ө л ә й х а  ә б и. Айлы төннәрдә, Чишмә анасы талда утырганда, су агышы әкренәя, кайсыбер төннәрдә бөтенләй туктый, тына, диләр.

Һ а д ы й. Туктый, тына, дисең, ә?

З ө л ә й х а  ә б и. Таң яралганда ыргылып тагын килеп чыга, бөркелеп-бөркелеп ага, имеш... Талдан сулдарак, әнә тегендә, шарлавык читендә, үләннәр бетеп, ташлы калкулыкларны күрәсеңме?

Һ а д ы й. Күрәм, Зөләйха әби. Әнә йоп-йомры дәү ташны да күрәм.

З ө л ә й х а  ә б и. Дәү таш! Аркылысы метрдан аша. Ничәмә-ничә еллардан бирле ник бер кыйпылчыгы кубып төшсен. Яңгыр-җилләр дә имгәтә алмый аны, кар-бураннарга да бирешми. Изге таш — Йомры таш ул! Аны борын заманнардан изге санаганнар, олылап, бәет тә чыгарганнар.

Һ а д ы й (*урыныннан сикереп тора да бүрәнә өстенә менеп басып*).

Әй Йомры таш, Йомры таш!
Татар башы кебек таш,
Татар ашы кебек таш,
Татар яше кебек таш.
Әй Йомры таш, Йомры таш!
Күпне күрде безнең баш,
Күпне күргән башлар гына
Бу дөньяда түгә яшь.
Әй Йомры таш, Йомры таш!
Йомарлан да тәгәрә —
Кайгы-хәсрәт күргәннәрдән
Шәфкатеңне җәлләмә.

Утыргычта утырганнар кул чабалар.

Беренче хатын. Үскәч, әртист булыр бу.

Өммегөлсем. Фокусник! Кер бавын турарга ярата ул.

Юан хатын. Сөйлисе юк. Настоящий фокусник! Кул таягыннан рам ясап кара әле син.

Һадый. Син үзең фокусник! Мин үскәч, пыялачы булам!

Зөләйха әби. Олы кешегә каты бәрелмә, улым. Үзең дә Йомры таш хакында беләсең икән ләбаса.

Һадый. Беләм. Янына йөз тапкыр, мең тапкыр, миллион тапкыр барганым бар. Бәет борынгы түгел, диләр, тегe герман сугышы беткәндә, Австриядән әсирлектән кайткан солдатлар гына чыгарган, дип бәхәсләшәләр. Монысын Йомры таш белми, Чишмә анасын саклап утыра да утыра. Зәй юлында, уңда, шул төбәкнең иң биек ноктасы Кашка тауда, таш кыяларның берсендә, нәкъ Йомры таш сыярлык кына бер тишек бар, аны Изгеләр куышы дип йөртәләр. Имеш, Югары авылларның изге Чишмә анасы, үзенә иптәш итеп, Йомры ташны шул кыядан китереп утырткан... Чирләп киткән, тазалыкка туймый башлаган карчык-корчыклар айның ундүртенче кичәсендә тауга менәләр дә, кыйблага багып, Йомры ташка кулларын куеп торалар, белгән догаларын укып, теләк телиләр.

Зөләйха әби. Белмәгәнең юк тагын үзеңнең.

Һадый. Мин бит күп йөрим. Мин бит сукбай. Әнә тегe әбиләр мине Сукбай дип йөртәләр. Яшь чагымда йөреп калыйм әле. Үскәч йөреп булмас.

Зөләйха әби. Минем төпчегем Габдулла да нәкъ синең төсле иде. Көненә өчәр тапкыр Йомры таш янына барып кайта иде. Үскәч тә ташламады. Әнә сукмакны күрәсеңме?

Һадый. Күрәм, әби.

Зөләйха әби. Әнә күрәсеңме, көянтә-чиләк асып, Изге чишмәгә бер кыз суга төшеп бара.

Һадый. Ә мин аны беләм. Изге чишмәгә ул гына суга йөри. Зәйтүнә апа ул. Бүген ул яшь килен чәенә суга төшә.

Зөләйха әби. Ни сөйлисең син, хәерсез бала. Нинди килен чәе?

Һадый. Ул бүген Мөхәммәт картның кәкре чәкәнле төпчек улы Кәримҗанга кияүгә чыга.

Зөләйха әби *(сискәнеп китә)*. Ни сөйлисең син, ул бит минем төпчегем Габдулламның...

Һадый. Юк шул, Сөләйман бабай бүген ризалыгын бирде.

Зөләйха әби утырган урыныннан җиргә шуып төшә. Утыргычта утырганнар, шау-гөр килеп: «Әй Ходаем, нәрсә булды?», «Әллә Ходаем, йөрәге туктадымы?» — дигән кызганычлы сүзләр белән ашыга-ашыга Зөләйха әби янына киләләр.

Музыка. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, сәхнә уртасында Йомры таш. Бераз вакыт үткән. Һ а д ы й, Сөләйман картның алагаем зур түбәтәен күзләренә кадәр батырып кигән дә, уң кулын ташка куеп, тамашачыга карап.

Һ а д ы й. Әй Йомры таш, Йомры таш!
Татар башы кебек таш,
Татар ашы кебек таш,
Татар яше кебек таш.
Әй Йомры таш, Йомры таш!
Күпне күрде безнең баш,
Күпне күргән башлар гына
Бу дөньяда түгә яшь.
Әй Йомры таш, Йомры таш!
Йомарлан да тәгәрә —
Кайгы-хәсрәт күргәннәрдән
Шәфкатеңне жәлләмә.

*(Бәетнең ахырында кыштырдаган тавышка сискәнеп борылып карый да куркып читкәрәк китә.)* Сез кем?

Утта янган шома битенә бер бөртек сакал да чыкмаган, аксак-туксак, култык таягына таянган, кыршылып, тузып беткән солдат гимнастеркасы кигән Г а б д у л л а күренә.

Г а б д у л л а. Курыкма, курыкма, энем. Мин тыштан гына шулай. Мин куркыныч кеше түгел. Мосафир мин. Солдат.

Һ а д ы й. Нишләп йөрисең?

Г а б д у л л а. Дөнья белән хушлашып. Ә син үзең нишлисең?

Һ а д ы й *(курка-курка гына Габдуллага якынлаша)*. Минме, мин теләк телим.

Г а б д у л л а *(авырлык белән генә чирәмгә утыра)*. Кемгә?

Һ а д ы й. Сөләйман абзый карчыгы Зөләйха әбигә.

Г а б д у л л а *(сискәнеп китә)*. Зөләйха әбигә?.. Әллә... *(Урыныннан тормакчы була, торалмый.)* Аның белән ул-бу булмагандыр бит?!

Һ а д ы й. Ярты ел инде урында ята. Мин бирегә кичә дә килгән идем, теләкләр теләгән идем. Бүген әби аягына басты да: «Бүген кайтып кермәсме?» — дип, он иләп, коймак изеп калды. Балаларын көтә ул. Бигрәк тә төпчеген, сугышта югалган Габдулласын көтә. Иртә таңнан тора да гөбедә май яза, табага коймак сала.

Г а б д у л л а *(яшьле күзләрен яшереп, урыныннан тора башлый)*. Китим әле, барасы юлым ерак.

Һ а д ы й. Ай-һай, йончыгансың, абзый, карт кешегә инә буе җир дә авыр, әллә авылга илтеп куйыйммы? Ял итеп китәрсең.

Г а б д у л л а. Юк, юк, кирәкми. Минем ашыгыр җирем юк. Йөргән аякка йөрем иярә, бер кузгалсам, барасы җиремә барып

житәрмен. *(Торып баса да авыл өстенә карый. Бераздан бармагы белән төртеп.)* Әнә тегендә тап-таза имән баганаларга эленгән, әле тактасы да каралып өлгермәгән яп-яңа урыс капкасы кемнеке ул? Өйдә әллә яңа хуҗалар яшиме?

Һ а д ы й. Юк. Капкасы яңа, хуҗалары иске. Минем ахир Сөләйман карт йорты ул.

Сәхнә кырыеннан Зәйтүнәнең «Галиябану» җыры яңгырый. Габдулла сискәнеп артка чигенә, чак кына егылмый кала.

Г а б д у л л а *(озак кына җыр килгән якка карап торганнан соң)*. Кем ул? Кем анда кер чайкый?

Һ а д ы й. Мөхәммәт карт килене Зәйтүнә апа. Мөхәммәт картның кәкре чәкәнле төпчек улы Кәримҗанның хәләл җефете. Көн дә чишмәгә төшеп керләр чайкый ул. Җырлаганын беренче ишетәм. Яшь чагында аның үзенең Хәлиле булган, сугышка китеп югалган, диләр. Мөхәммәт малаена яратып кияүгә чыкмаган, диләр. Хәзер инде балалары бар. Кечкенә Хәлилләре... Дөньяның бер елагы. Имчегә алып барып өшкертеп тә карадылар, фельдшер Хафаза апага да күрсәттеләр, эссе мунчага алып кереп, ачы катык, көнбагыш мае белән кәчеркәсен дә чыгарып карадылар, күз тигәндер дип, иске-москыдан теккән күлмәк тә кидерделәр, маңгаена корым да сөртеп карадылар, юк. Ике борын тишегеннән куык кабарта да бөтен авылга сөрән сала. Әнә, көянтәсен иңбашына асып, җитез-җитез генә Зәйтүнә апа да менеп килә.

Г а б д у л л а *(каударланып)*. Мин китим әле. Ашыгам. Кичкә калмагаем. *(Ашыга-ашыга китеп бара.)*

Һ а д ы й *(аның артыннан карап)*. Бу да мин кеше дип йөри инде. Төнлә сукмагыңа каршы төшсә... Мосафир! Бәлки, минем атам да күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларда мосафир булып йөридер. *(Уң кулын таш өстенә куя.)*

Әй Йомры таш, Йомры таш,
Татар башы кебек таш!

З ә й т ү н ә *(Һадыйның артына килеп баса)*. Энем...

Һ а д ы й. Бүлдермә! Күрмисеңмени, теләк телим. Фикеремне чуалтасың.

Татар ашы кебек таш,
Татар яше кебек таш.

З ә й т ү н ә *(сабырсызланып)*. Энем, Һадый?..

Һ а д ы й. Нәрсә инде, нәрсә?

З ә й т ү н ә. Синең янга туктаган юлчы кем иде ул?

Һ а д ы й. Мосафир.

Әй Йомры таш, Йомры таш!
Күпне күрде безнең баш.

З ә й т ү н ә *(Габдулла киткән якка карап)*. Кем дисең?..

Һ а д ы й. Солдат.

Күпне күргән башлар гына

Бу дөньяда түгә яшь.

Зәйтүнә. Нишләп йөри ул бу якларда?

Һадый. Дөнья белән хушлашып.

Әй Йомры таш, Йомры таш!
Йомарлан да тәгәрә —
Кайгы-хәсрәт күргәннәрдән
Шәфкатеңне жәлләмә.

Зәйтүнә. Кара, кара, инеш өстендәге басмадан чыга түгелме?

Һадый (*таш өстенә менеп баса*). Әйе, әнә Сөләйман бабайлар тыкрыгына борылды, үргә менеп бара.

Зәйтүнә (*бар көченә һаваны ярып*). Габдулла!!!

Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

### ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Сөләйман картның яңа капкасы пәйда була. Габдулла көч-хәл белән капкага якынаеп килә. Житез адымнар белән, көянтә-чиләк асып, Зәйтүнә аны куып тота. Сәхнәнең икенче ягыннан, елаган сабый бала күтәреп, Кәримҗан чыга. Габдулла яңа капкага килә дә капка тоткасына үрелә.

Зәйтүнә (*катып кала, әче итеп*). Габдулла!.. (*Барак тәрәзәләре ачыла, башлар күренә. Сәхнә кырыена Кәримҗанның анасы Сафура карчык, атасы Мөхәммәт карт һәм йодрыкларын йомарлаган абыйлары чыга. Капкадан Сөләйман карт һәм Зөләйха карчык күренә.*) Габдулла!.. (*Габдулланың муенына килеп сарыла.*) Габдулла, бу син бит, бәгырем? Син бит, илаһым! Ходавәндәм!

Габдулла. Зәйтүнә!

Зәйтүнә. Кайттың бит, кайтып җиттең! Габдулла, Габдулла, ник дәшмисең? Син бит бу, бәгырем! Кайттыңмы? Кайтып җиттеңме?

Габдулла. Миңа сөенергә ярамый, Зәйтүнә.

Сафура карчык. Илдә булмаганны... Адәм рисвае итте.

Мөхәммәт карт. Җитәр сиңа, мырлама. Болай да баш каткан!

Олы абый (*кан йөгергән күзләре белән*). Йә, Кәримҗан, хатын синеке, син ни дисең?

Кече абый (*йодрыкларын уйнатып алып*). Ие, ие, Кәримҗан, әйт, эш синнән тора.

Мөхәммәт карт. Әйт, улым.

Кәримҗан. Зәйтүнә, безнең хәлне аңлыйсыңмы, юкмы?

Зәйтүнә. Әти, Кәримҗан, абыйлар, җизниләр... Сез минем хәлгә дә керегез. Кәримҗан, син акылсыз түгел, кемгә өйләнгәнеңне белеп өйләндең. Сугышка озатканда, Габдуллага вәгъ-

дәм барын белә идегез. Кәримҗан, рәнҗемә, син бик әйбәт егет идең, тугры ир булдың, гаиләгез мине иш итте, мин сиңа әнкәй сүзен сүз итебрәк чыктым. Хак, гомерлек ишем син дип белдем, бусын да беләсең, риясыз, саф күңелем белән синеке булдым. Гаепләмә, мин бүгеннән Габдулла янына китәргә тиешмен. Аның хәле барыбызныкыннан да читенрәк, язмыш безгә караганда яманрак! Аны бүгеннән ялгыз калдырырга ярамый дип исәплим. Сез ничек уйларсыз тагын. Кәримҗанга үз ихтыярым белән чыктым, мине беркем көчләп китермәде. Әмма, киткәндә, сезнең тулы ризалыкны алып, хәер-фатыйхагызны ишетәсем килә. Яшермим, әгәр ул сау-сәламәт кайткан булса, мин бүтәнчә уйлар идем.

Кече абый. Ә бала?!

Олы абый (*атасы Мөхәммәт картка карап*). Нәсел!..

Мөхәммәт карт (*уртагарак чыга*). Җиргә зур афәт килде. Җир өстен ятимнәр басты. Күпләрнең капкаларында аркылы такта. Мин Сөләйман кордашның капкасы ябылуын теләмим. Син дә теләмисеңдер, улым Кәримҗан. Син әле яшь, таза, сау-сәламәт. Үзеңә тиңне табарсың. Бәхетле дә булырсыз, алып кайткан хатының сине бәбисез калдырмас. (*Кәримҗан кулындагы баланы ала да аңа карап.*) Син, олан, безгә рәнҗемәссең дип уйлыйм. Мин синең дәү бабаң, ә бу Сөләйман бабаң, кече бабаң булыр. Бәхетле бул, олан. (*Баланы Сөләйман картка тоттыра да аңа чыгып китә.*)

Кәримҗан (*озак кына паузадан соң*). Язмыштан узмыш юк. Баланы миннән читләштермәгез, Зәйтүнә. Бәхетле бул, Зәйтүнә.

Көчле музыка. Ут сүнә.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Сөләйман карт капка төпләрендәге утыргычта бала арбасы селкетеп утыра. Аның янына Һадый килә.

Һадый (*арбадагы балага карап*). Нихәл, елак, киртек колак?.. Тындыңмы?.. Мә! Безнең буын өч тәгәрмәчле арбада уйнап үсте. (*Куеныннан дүрт тәгәрмәчле арба чыгарып.*) Сезнең буын дүрт тәгәрмәчле арбада уйнап үссен. Энем, гомер әнә шулай уза, иң элек син шушы уенчык арбага утырып юлга чыгарсың, машиналарга күчеп, язмыш капкаңны кагарсың, аннан поезд-самолетларда илләр гизәрсең, күп кешеләр белән очрашырсың, берәүләр белән дуслашырсың, икенчеләреннән читтәрәк йөрергә тырышырсың. Һәрчак гадел, саф күңелле (*аның тавышы, ераклашып барган поезд тавышын хәтерләткәндәй, кайтавазлар булып ерагайганнан-ерагая*), чиста булып кал!.. (*Аның күмелеп барган тавышына музыка килеп кушыла.*)

Пәрдә

Бөек Ватан сугышында җиңүнең
60 еллыгына багышлана.

# Өзелгән йөзем

*Драма ике пәрдәдә, ун күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Сәлимгәрәй — элеккеге колхоз рәисе, Тәуфыйкның әтисе.
Мәмдүдә — Сәлимгәрәйнең хәләл җефете.
Сәүбән — Тәуфыйкны тәрбияләп үстерүче.
Мәрьям — Сәүбәннең хәләл җефете.
Тәуфыйк — колхоз рәисе.
Саҗидә — күрше карчыгы.

Вакыйга сугыштан соңгы илленче елларда һәм бүгенге көндә авыл җирендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, Сәлимгәрәй картның алтмышынчы елларда салынган йортының бер бүлмәсе. Уң порталда икенче бүлмәгә чыгучы, икегә ачыла торган иске генә игезәк ишекләр. Сул порталда шул елларга аһәңле иске диван. Бүлмә уртасында имән өстәл, дүрт урындык, түрдә матур бизәкләр белән эшләнгән шкаф. Сәхнәнең арткы өлешендә урамга чыга торган ишек. Ишек шакыган тавышка Сәлимгәрәй карт көч-хәл белән диваннан тора да, таягына таянып, ишек катына китә.

Сәлимгәрәй карт. Керегез, кер. Ишек ачык. *(Бүлмәгә Тәуфыйк килеп керә.)* Аяклар тыңламый хәзер, энем. Картайгач, гәүдәнең бөтен органнары да демократия сорый икән ул. Берсен дә тыңлатып булмый.

Тәуфыйк. Күрәм, Сәлимгәрәй абзый, күрәм. Нихәл? *(Кулын суза.)* Әйбәт кенәме?

---

Искәрмә: Сәлимгәрәй, Сәүбән, Мәрьямнең яшьлек һәм картлык көннәре уйнала.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Карт ишәкнеке кебек. Далага карап, и-а, и-а дип кычкырасы килә.

Т ә ү ф ы й к. Терәлеп яшәп, хәлеңне дә белгән юк.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Авылда бер мин генә түгел бит. Күпмерәк әле без — мич башында җилкә җылытып, хөкүмәт икмәген сыпыртучылар?.. Пинсиәнирләрне әйтүем, Тәүфыйк улым.

Т ә ү ф ы й к. Йөз унике кеше, Сәлимгәрәй абзый.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Авылда йөз сиксән хуҗалык. Димәк, почти һәр йортта минем кебекләр бар диген. Ә шулар арасында иң өлкәннәренең берсе — мин. Вакыт, вакыт, энем. Газраил бабаңа килергә вакыт.

Т ә ү ф ы й к. Бик каты авырып алдың бугай.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Авылга грипп дигән хөрәсән керде бит. Үзе белән сөйләшеп тә караган идем: «Ялгыз башым, өем иркен, мешать итүче юк, үземдә генә кунак бул да, сабыйларны, эш кешеләрен борчуга салмыйча гына, вакытың җиткәч, үз юлың белән китәрсең»,— дип. Тыңламады, киребеткән грипп.

Т ә ү ф ы й к. Сәлимгәрәй абзый, мин сиңа бер киңәш белән кердем.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Тыңлап карыйк яшьләр киңәшен.

Т ә ү ф ы й к. Үзең күреп торасың: ялгыз башка гомер итүләре авыр. Мәмдүдә әбинең үлгәненә дә шактый булды бугай инде.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Дөнья куйганына кичә унбиш ел тулды. Беренче тапкыр каберенә баралмадым. Рәнҗегәндер инде. Көткәндер инде ул мине. Баралмадым.

Т ә ү ф ы й к. Иртәгә барырбыз.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Кеше белән килгәнне яратмый. Аннары үзем дә яратмыйм. Иркенләп сөйләшеп, күңелне бушатып булмый. Рәтләнеп, аякка бассам, аяк асты җайга салынгач, үзем генә барырмын әле. Бу юлга кичерер.

Т ә ү ф ы й к. Өеңдә салкын.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Бер атна инде якканым юк. Кергән утын бетте. Мин үзем туңмыйм туңуын. Мәмдүдәмнең гөлләре генә харап булмасын дип куркам.

Т ә ү ф ы й к. Сәлимгәрәй абзый, болай яшәп булмый. Әллә соң районндагы картлар йортына күчәсеңме?

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Шулай дисеңме?

Т ә ү ф ы й к. Дөрес булыр, димен. Җылы, чиста урын, тәмле ашаталар. Сөйләшергә дә кешеләр бар.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Картлар йорты, дисең инде. Авылдан кит, дисең. Ничек ташлап китим? Кендегем белән береккән бит мин бу җиргә. Атам-анам нигезе. Аларның, туганнарымның кабере. Тегендә баргач, атама нәрсә дип җавап бирермен? «Мәңгелеккә килергә өч көн калгач, нигә нигезне ятим иттең, нигә ташлап киттең?» дисә, нәрсә дип җавап бирермен?

Тәүфыйк. Болай да яшәп булмый. Җылы аш, чиста постель күргәнең юк.

Сәлимгәрәй карт. Чиста булмаса да, үз постелем, үз ятагым, үз нигезем. Булдыралмыйм, энем. Рәнҗемә. Мин, тыныч кына сиңа да, авыл халкына да читенлек китермичә, соңгы минутымны үз почмагымда күтәрмен инде.

Тәүфыйк. Син мине борчымыйсың, Сәлимгәрәй абзый. Авылның кайбер кешеләрен, район хуҗаларын борчыйсың. Алар, алар кыса мине.

Сәлимгәрәй карт. Кысалар, дисең инде. Син аларга әйт: «Риза түгел ул, карт тәре, киребеткән, минем сүзне тыңламый»,— диген.

Тәүфыйк. Әйтерсең, бар. Авыл халкы күнаралаш районга жалоба язып тора. Менә соңгысы. Укыйм. Тыңла.

Сәлимгәрәй карт. Берсенә дә зыян кылганым булмады, шәй. Нигә мине күпсенәләр икән?

Тәүфыйк (*куен кесәсеннән хат чыгарып укый*). Хөрмәтле Мәрдән Хөҗиәхмәтович! Сезгә мәгълүм булганча, Саз Тирәк авылында күп еллар колхоз рәисе булып эшләгән орденлы Сәлимгәрәй абый Гыйлемханов яши. Хәләл җефете Мәмдүдә апаның үлгәненә дә унбиш ел тулып килә. Аның балалары юклыгын, хәер, сез беләсездер. Аның күршесендә яшәүче хәзерге колхоз рәисе Тәүфыйк Сәләхов, аңа ярдәм итү урынына, бакчасын тартып алып, үзенә бәрәңге утыртты.

Сәлимгәрәй карт. Бакчаны бит мин үзем сиңа бирдем.

Тәүфыйк. Тыңлап бетер. (*Укый.*) Сәлимгәрәй абзыйның ягарына юк, газ кертелмәгән.

Сәлимгәрәй карт. Газын мин үзем керттермәдем. Хәтерем алама, шартлармын дип курыктым.

Тәүфыйк (*укуын дәвам итеп*). Өсте-башы керләнеп беткән, үз-үзенә ашарга пешерә алмый. Өстәвенә аяклары йөрми. Әмма ләкин клуб кадәрле алты почмаклы, юан нарат бүрәнәле, калай түбәле йорты бар. Бу йорт безнең хәзерге рәискә тыныч кына яшәргә ирек бирми, аңа Сәлимгәрәй абыйның тизрәк бу якты дөньядан китүе, йортның бушавы мөһимрәк. Чөнки Сәлимгәрәй абыйның йортын калдырырга бер кешесе дә юк. Тиз арада Сәлимгәрәй абзыйга ярдәм кулы сузарсыз дип ышанып калабыз.

Сәлимгәрәй карт. Кем кулы тора?

Тәүфыйк. Кулын куймаган. Бер төркем авылдашлары, дигән.

Сәлимгәрәй карт. Син, Тәүфыйк улым, Мәрдән Хөҗиәхмәтовка барып әйт: «Йорт аныкы түгел, колхозныкы»,— диген. Үзең беләсең. Йортны мин приватизация ясатудан баш тарттым. Ә бу хатны язган авылдаш, миңа атна саен кереп,

йортны сатуымны сорап, туйдырып бетерде инде. Мәрдән иптәшкә минем сүзне җиткер. «Ул карт районга картлар йортына барудан баш тарта, бер төркем авылдашлары ярдәм итәргә булдылар»,— диген. «Соңгы сулышымны үз нигеземдә, күземне соңгы тапкыр үз түшәмемә карап йомасым килә»,— диде диген.

Т ә ү ф ы й к. Сәлимгәрәй абзый, болай яшәп булмый бит. Китик районга.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Молокосос! Ничек яшәп булганын мин үзем беләм. *(Йомшый төшеп.)* Тирәгемнән аермагыз, тирәгеннән аерылган кош озак яши алмый. Минем бөтен гомерем шушы җирдә, шушы авылда, шушы болыннарда үтте. Сабыр итегез, күп калмады. Китәм. Озакламый бөтенләйгә китәм.

Т ә ү ф ы й к. Шунда бала табып, берәр бала үстергән булсагыз.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Язмыш бездән сорамый. Шулай язгандыр. Мәмдүдә апаң яшьли сулды шул, яшьли... Син миңа бүтән бу йомыш белән кермә. Синнән бу сүзне ишетү авыр миңа, ай, авыр. Исән бул.

Борылып китеп бара. Ишектән С ә ү б ә н  к а р т күренә.

С ә ү б ә н  к а р т *(Тәуфыйкка)*. Нишләп йөрисең эш вакытында? Бар, юлыңда бул!

Т ә ү ф ы й к. Наконец, бүген көн кояшлы булыр. Минем газиз эткәм дә үз гомерендә беренче тапкыр айнык. Уйла әле, Сәлимгәрәй абзый, уйла.

С ә ү б ә н  к а р т. Икәүләп уйларбыз. *(Тәуфыйк чыгып китә.)* Нихәл, күрше Сәлимгәрәй.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Ярый. Селкенәм. Рәхәтлеккә чыдап булмый.

С ә ү б ә н  к а р т *(ишеккә карап)*. Кодалыймы?

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Кем?

С ә ү б ә н  к а р т. Үзе!

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Ә, аны әйтәсең. Ындыр табагына эшкә барасыңмы дип кергән.

С ә ү б ә н  к а р т. Нәрсә, икмәк урынына кар көрәргәме?! Кодалый, дисең, ә? Районга, диме? Картлар йортына, диме?

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Төшереп кергәнсең, ахры.

С ә ү б ә н  к а р т. Барма. Пычагым калганмы...

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Күрше, нинди йомышың бар?

С ә ү б ә н  к а р т. Кума. Кырык ел күрше булып яшәп, бусаганы беренче тапкыр атлап кердем.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Керергә иде, Сәүбән туган, керергә... Караңгы чырай катканым булмады бугай.

С ә ү б ә н  к а р т. Юк, булмады. Гел яхшылык кына эшләдең.

С ә л и м г ә р ә й  к а р т. Мәмдүдәнең дә караңгы чырай катканын хәтерләмим.

Сәүбән карт. Мәмдүдә әүлия иде. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмәнең. Гел ярдәм итеп тордыгыз.

Сәлимгәрәй карт. Артыграк эчтең шул, күрше, артыграк җибәрдең.

Сәүбән карт. Эчсә, синекен эчмәдем, үз тапканымны эчтем. Синнән бер дә ким яшәмәдем. Син колхоз барагында яшисең, ә мин үзем төзедем. Үзем, менә шушы кулларым белән.

Сәлимгәрәй карт. Мин колхоз аякка бассын дип йөгердем.

Сәүбән карт. Шуннан нинди файда? Син бастырдың, синнән соң килгәннәр колхозны күтәрәмгә калдырдылар.

Сәлимгәрәй карт. Менә синең улың эшли бит. Ул күтәрсен.

Сәүбән карт. Улың... Ул күтәрер... Сиңа охшаса, күтәрер. Үҗәт ул. Сиңа охшаган. Артык төшердең... Минем урында булсаң, син нишләр идең?! Куеп кара үзеңне минем урынга.

Сәлимгәрәй карт. Куйсам, шуннан ни булыр иде?

Сәүбән карт. Шартлар идең. Мәрьям гомер буе сезнең яктан күзен алмады. Сине күзләп сукыр калды ул.

Сәлимгәрәй карт. Юкны бушка әйләндереп утырма. Салгансың икән, буеңа сеңдер.

Сәүбән карт. Юк, Сәлимгәрәй туган, Сәлимгәрәй күрше, мин бүген аек...

Сәлимгәрәй карт. Нәрсә, мине картлар йортына озаталар дип, шатлыгыңнан айныдыңмы әллә?

Сәүбән карт. Юк. Кайгыдан айныдым. Югалтасым килми сине.

Сәлимгәрәй карт. Әгәр болай айныганыңны белгән булсам, кырык ел элек, үзем теләп, картлар йортына киткән булыр идем.

Сәүбән карт. Ә шулай да Тәүфыйк сиңа охшаган. Улы Илшат суйган да каплаган син инде.

Сәлимгәрәй карт. Тузга язмаганнарны уйлап чыгарма әле. Нәрсә?! Минем белән илле өч ел сөйләшмәгәнеңне бүген сөйләшеп бетерим дип кердеңмени?

Сәүбән карт. Берне ясагансың, берәгәйле ясагансың. Тик күршегә кереп ясап ялгышкансың. Бүген Тәүфыйкка илле өч яшь. Туган көнендә атасына бүләк — картлар йорты.

Сәлимгәрәй карт. Уйлап табасың да инде.

Сәүбән карт. Ә мин ике малай ясадым. Икесе дә барып чыкмады. Берсе — бандит, икенчесе — җилкуар. Мин аларны шулай булсыннар дип үстердеммени?!

Сәлимгәрәй карт. Холыксыз булдың шул син, Сәүбән, холыксыз. Алар бит юньле-рәтле өйдә дә йоклый алмадылар. Карлыган куагы арасында, минем лапас түбәсендә үстеләр.

Сәүбән карт. Синең аркада. Гомер буе синнән шикклә-

неп яшәдем. Синекеләр түгел микән дигән уй белән яшәдем. Уй кимерде мине, уй! Ярый әле, алары сиңа охшамаганнар. Гәүдә, йөз, кыяфәт — минеке. Ә шулай да синең орлык үндырышлырак булып чыкты. Тәүфыйкны әйтәм. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, диләр. Укыды... Ничек итсә итте, мунчада укып булса да, кеше булды.

Сәлимгәрәй карт. Кара әле, күрше, мине ялгызымны гына калдыр әле. Хәлем дә, сәламәтлегем дә яхшы түгел. Аннары...

Сәүбән карт. Син түгел, мин бүген картлар йортына китәргә тиеш.

Сәлимгәрәй карт. Мин дә китмим, син дә китмисең. Яшә. Балаларың бар ич синең. Әгәр мин сиңа комачаулыйм икән, иртәгә үк картлар йортына китәргә ризалыгымны бирәм.

Сәүбән карт. Юк, яшә. Син биредә яшәргә тиеш. Син бирedән беркая да китәргә тиеш түгел. Кичә кич Тәүфыйк сине картлар йортына җибәрү хәбәрен әйткәч, Мәрьям аяктан егылды. Һәм минем синең янга керүемне үтенде. Ул миңа барысын да түкми-чәчми, кайда, кайчан, ничек булганын — бөтенесен дә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Сәлимгәрәй карт (*башын түбән иеп, урындыкка барып утыра. Озак кына паузадан соң*). Ниятем сиңа начарлык эшләүдә түгел иде. Мәрьям үтенеп сорады. «Синеке була алмадым. Балаңны булса да калдыр, балаңны сөеп булса да юанырмын»,— диде. Карышып карадым, әмма каршы килә алмадым. Ул бала сөеп, мин авыру хатын карап, ә син аракы эчеп юандың. Кайсыбыз бәхетледер, белмим. Кичерә алсаң, кичер.

Сәүбән карт. Син минем беренче тапкыр бу авылга, Саз Тирәккә кайтканымны хәтерлисеңме?

Сәлимгәрәй карт. Бүгенгедәй хәтерлим. Кулында чемодан, култык астында гармун, өстеңдә матрос киеме.

Сәүбән карт. Ә син гимнастерка, галифедан өстәл артында утыра идең.

Сәлимгәрәй карт. «Нихәл, иптәш председатель? Эшче көчләр кирәкме?» — дип, кулыңны суздың.

Сәүбән карт. Ә син кирәк, дидең. Нигә син шул чагында кирәк, дидең? Нигә син шул чагында кирәк, дидең, нигә?!

Сәлимгәрәй карт. Ялгышасың, Сәүбән туган, ялгышасың. Хәтерең бик алама икән. Син ул вакытта безнең колхозда бер генә минут та эшләмәдең. Мәрьямне күрдең дә мөкиббән киттең. Аның итәгенә тагылып, шул ук көнне авылдан чыгып югалдың. Ә инде өч елдан соң, Тәүфыйкны ияртеп, Мәрьям белән кире безнең авылга, Саз Тирәккә әйләнеп кайттыгыз. Нигә кайттың, нигә кирәк иде, нигә?!

Сәүбән карт. Гомерем буе шул кайткан көнемне каһәрләп яшәдем. (*Акрын гына имән шкаф янына барып, гар-*

*мун ала.)* Синең белән очрашканда уйнап җырлаган җырымны хәтерлисеңме?

Сәлимгәрәй карт. Хәтерлим, Сәүбән, хәтерлим.

Сәүбән карт. Җырның сүзләренә игътибар иттеңме?

Сәлимгәрәй карт. Сагынам туган илкәйне,
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән иркәмне.

Сәүбән карт *(гармунын тартып җырлап җибәрә).*
Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам туган илкәйне, шул,
Сагынам туган илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән иркәмне.

Җырның икенче куплеты сүзсез генә фонограммада яңгырый, ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук бүлмә. Өстәл урыныннан сулга күчкән, ә уң якта карават пәйда булган. Караватта Мәмдүдә авырып ята. Бүлмәгә алтмышның теге ягына чыккан Саҗидә килеп керә.

Саҗидә. Нихәл, сеңлем Мәмдүдә?

Мәмдүдә. Яхшы. Рәхмәт, Саҗидә апа. Минем, үзең беләсең, аш беткән инде. Түшәм саныйсым гына калган. Шул түшәм такталарына карыйм да, их, мин әйтәм, шушы түшәм такталары ләхет такталарым булсын иде, дим.

Саҗидә. Ашыкма кара җир асларына керергә, ашыкма. Терелерсең. Йөреп тә китәрсең әле.

Мәмдүдә. Йөрүләр миңа тәтемәс инде, Саҗидә апа. Озак кына хаста булып ятмасам иде. Сәлимгәрәемне кызганам. Иртәнге дүрттән чыгып китә дә сигезләрдә йөгереп кайта. Мине ашата да тагын чыгып чаба. Төннәрен кер уа, ашарга пешерә. Көн эшли, төн эшли, белмим, күпме түзәр.

Саҗидә. Алай димә әле, Мәмдүдә. Кайтса, юанырга кешесе бар. Син дип йөгереп кайта. Ә менә мин, төннәрен капкама җил килеп какса, утымны яндырам. Сугышта югалган улларым, ирем Фатыйх абзаң кайтмады микән дип, тәрәзәгә капланам. Ә урамда эт җаны да күренми. Җилләр генә бер капкадан кереп, икенче капкадан чыгып, минем кебек ятимнәрне үртәп, авыл буйлап хуҗа булып йөриләр. Төпчегемә китмәскә була иде бит. Кала ала иде. Унсигезе тулар тулмас фронтка китеп, бер ай да сугышмыйча, хәбәрсез югалды. Каберен генә күрсәм дә, тыныч күңел белән китәр идем бу дөньядан. Һаман көтәм. Кайтып, төнлә тәрәзәмне кагар кебек. Әй бала, бала, кай җирләрдә ятасың икән?! Бармы ул синең каберең? Әллә исәнме син?

Мәмдүдә. Минем әткәй дә хәбәрсез югалды. Ә абыем кайтты. Ярым мәет булып. Әни белән яшәп яткан булалар. Икесенә бер кешелек сәламәтлекләре юк. Азапланалар.

Саҗидә. Кайтсыннар иде әле. Нинди генә булсалар да кайтсыннар иде. Үземнекеләр бит. Ишегемне ачып кергәндә, юанычларым булырлар иде. *(Паузадан соң.)* Карале, сеңлем Мәмдүдә, калага бүлнискә барырга уйламыйсыңмы? Файдасы тимәс микән?

Мәмдүдә. Юк, Саҗидә апа, бармыйм. Бармадык түгел, Сәлимгәрәйнең йөртмәгән бүлнисе, йөртмәгән ымчысы калмады. Җен сукканны брачлар гына төзәтә алмый.

Саҗидә. Алай димә әле. Өметсез — шайтан гына, дигәннәр. Әнә фрунтта кырык яра алган Ифратны да аякка бастырдылар. Әнә кичә өч өй аркылы ләфкәгә кадәр килеп җиткән. Шатлыгыннан авызын җыеп алалмый, мескенем.

Мәмдүдә. Ярага ямау салып була, ә менә үлгән тәнне терелтеп булмый. Сәлимгәрәемне кызганам.

Саҗидә. Күз тиде сезгә, күз... Авылда, сез урамнан үткәндә, кешеләр борылып карап кала иде сезгә.

Мәмдүдә. Сәлимгәрәйдән берәр генә айга булса да әниләргә кайтарып тор, тын алырсың, дип әйтеп карыйм да, риза түгел.

Саҗидә. Әй сеңлем, ялгыз өйгә кайтудан да авыр нәрсә бар бу дөньяда? Әле телең бар, сөйләшер кешең бар. Аннары әниләреңнең дә үз хәлләре хәл, дисең. Ул ягын да уйлыйдыр.

Мәмдүдә. Аны җәллим. Аягыңа басып, элмәккә менәрлек тә хәлең, көчең булмагач...

Саҗидә. Авызыңнан җил алсын. Булмаганны. Андый ямьсез уйны ялгышып та башыңа алма.

Мәмдүдә. Башка әллә нинди уйлар килә. Мин мин инде, бер йомырка маяда да чери, Сәлимгәрәй...

Саҗидә. Мин юасы чүпрәк-чапракларыгызны алырга дип кергән идем. Кайдарак икән алар?

Мәмдүдә. Кирәкми, Саҗидә апа. Әнә беркөнне күрше Хәлимә апа алып чыгып киткән иде, Сәлимгәрәй сүкте үземне. «Безнең шакшыны кеше юарга тиеш түгел»,— ди.

Саҗидә. Аның нәрсәсе бар. Ир-атка кер юу бик авыр бит ул. Керне дә бозалар алар.

Мәмдүдә. Ярар, үзебезнеке үзебезгә ярар әле. Бер генә йомышым бар. Күптән мунча кергәнем юк. Дөнья хәлен белеп булмый. Ходайдан вакыт җитеп, китеп тә бармаммы.

Саҗидә. Иртәгә ягарга җыенам. Чакырырмын.

Мәмдүдә. Утынын бездән ал.

Саҗидә. Мунчам искергән. Искерсә дә, кererлек әле. Гаеп итмәссез. Пары бик йомшак. Себерке парында да ятарсың. Үләнле су да ясап куярмын. Ярый, Мәмдүдә сеңлем, мин чы-

гыйм әле. Иртәгә чакырырмын. Озакламый гает. Бәйрәм мунчасы ягарбыз. Алайса, юасы керләреңне бирмисең инде.

Мәмдүдә. Юк, Сажидә апа. Рәхмәт. Үпкәләп чыкма.

Сажидә. Нинди булмаган үпкәләү ди ул. Кергәләрмен әле.

Мәмдүдә. Рәхмәт, ташламыйсың.

Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, колхозның илленче еллар башындагы иске генә идарә бүлмәсе. Утыз яшьләр тирәсендәге Сәлимгәрәй гимнастерка, галифе чалбардан өстәл артында счет төймәсе тартып, санап утыра. Бүлмәгә өстенә плащ кигән, кулына чемодан тоткан егерме биш яшьләр тирәсендәге Мәрьям килеп керә.

Мәрьям. Исәнмесез!

Сәлимгәрәй (*күтәрелеп карый да сискәнеп китә*). И-сән-ме-сез!

Мәрьям. Әллә танымыйсыңмы, иптәш сержант?

Сәлимгәрәй (*урыныннан торып*). Тукта, тукта әле... Син бит Мәрьям.

Мәрьям. Таныдың.

Сәлимгәрәй. Ничек танымыйм. Син бит мине...

Мәрьям. Суга төшеп югалгандай булдың бит, иптәш сержант.

Сәлимгәрәй (*Мәрьям янына килә, плащын салдыра*). Әйдә, түргә уз. (*Урындык бирә.*) Йә, сөйлә, сестричка, нинди җилләр сине бирегә ташлады?

Мәрьям. Үзең эзләмәгәч, үзем эзләп кайттым. Да, сержант Вәлиәхмәтов, сүзегездә тормыйсыз икән.

Сәлимгәрәй. Менә авылга кайттым да эшкә чумдым. Артка борылып карарга да вакыт юк.

Мәрьям. Артка борылып карарга кирәк. Үткәннәрне онытырга ярамый.

Сәлимгәрәй. Бик шулай да. Тормыш баса икән шул.

Мәрьям. Вәгъдәгездә торалмыйсыз икән.

Сәлимгәрәй. Мин сине онытмадым. Гел искә төшереп яшәдем. Ачуланма. Шулай килеп чыкты.

Мәрьям. Вәгъдәләрне онытырга ярамый. Вәгъдә тота ул.

Сәлимгәрәй. Да... Вәгъдә?! Тотты бугай инде ул безне.

Мәрьям. Беләм. Барысын да беләм, барысын да ишеттем.

Сәлимгәрәй (*ярсып*). Нәрсә беләсең?! Нәрсә ишеттең?! Нигә кайттың?!

Мәрьям. Сине сагынып кайттым.

Сәлимгәрәй. Нәрсә кирәк миннән сиңа?

М ә р ь я м. Йөрәгемә дәва кирәк!

С ә л и м г ә р ә й. Ә мин сине көтмәдем.

М ә р ь я м. Ә мин бу очрашуны сигез ел көттем.

С ә л и м г ә р ә й. Кит син, кит. Авылда берәүнең дә күзенә күренмә. Миңа болай да бик авыр, аңлыйсыңмы, авыр!

М ә р ь я м. Беләм. Мин синең хатыныңны дәваларга дип кайттым.

С ә л и м г ә р ә й. Бу күзләрең белән син аны дәвалый алмыйсың. Бу күзләрең белән син аны да, мине дә харап кына итәсең.

М ә р ь я м. Мине сезнең авылга медсестра итеп җибәрделәр.

С ә л и м г ә р ә й. Бирегә фронт түгел, медичкалар кирәкми.

М ә р ь я м. Кем белә бит. Ә вдруг күкрәгеңдәге осколкаң кузгалыр.

С ә л и м г ә р ә й. Аңа тыныч кына яту өчен синең китүең кирәк.

М ә р ь я м. Хатыныңа тыныч кына ятмас өчен, бәлки, мин кирәктер.

С ә л и м г ә р ә й. Юк, ул синең ярдәмгә мохтаҗ түгел. Аңа Ходай Тәгалә бер үзе генә ярдәмче.

М ә р ь я м. Бәлкем. Син хаклы. Мин ул чирне беләм.

С ә л и м г ә р ә й. Белгәч, нигә белә торып кайттың? Аның канына тоз салыргамы?

М ә р ь я м. Ә минем каныма салынган тозны кем юар да, йөрәгемдәге бозны кем эретер?

С ә л и м г ә р ә й. Вакыт.

М ә р ь я м. Вакыт. Мин сине сигез ел көттем. Тәрәзәмнән күземне алмыйча, сигез ел көттем. Син бит миңа вәгъдә бирдең. Сугыш кына бетсен, эзләп табармын да үземнеке итәрмен, дидең. Ә мин сиңа ышанган идем.

С ә л и м г ә р ә й. Кичер. Тормыш без уйлаганча гына бармый икән шул.

М ә р ь я м. Син бит мине яраттың, беләм, яраттың!

С ә л и м г ә р ә й. Ә хәзер яратмыйм.

М ә р ь я м. Яратасың. Күзләреңнән күрәм. Яратасың. Мин бит сине госпитальдә ятканыңнан бирле беләм. Син авырлыкларга сызлана торганнардан түгел. Ә син бүген сызланмыйсың, син бүген елыйсың.

С ә л и м г ә р ә й. Мин дә таш түгел.

М ә р ь я м. Чын дөресен яшермичә әйт. Син мине яраттыңмы?

С ә л и м г ә р ә й. Яраттым, яратам, әмма онытырга телим.

М ә р ь я м. Ә мин оныта алмыйм.

С ә л и м г ә р ә й. Ә син, госпитальдә врач, полковник Сергей Петрович Зыкин бүлмәсенә кергәндә, мине оныткан идең бугай.

М ә р ь я м. Менә нәрсә... Үзгәргәнсең син, иптәш сержант.

Сәлимгәрәй. Дөнья үзгәртте.

Мәрьям. Чупрәккә әйләнгәнсең.

Сәлимгәрәй. Нәрсә, минем сүзләремдә хаклык юкмыни?

Мәрьям. Бар. Әйе, полковник белән булган хәлләр дә хак. Мин боларын сиңа үзем сөйләгән идем кебек.

Сәлимгәрәй. Сөйләү — бер, үз күзең белән күрү — икенче.

Мәрьям. Син шуңа госпитальдән дезертирларча качтыңмыни?!

Сәлимгәрәй. Полковник сөяркәсенә плен төшкәнче, дезертир булуны кулайрак күрдем. Нәрсә! Синең сүзеңне тыңлап, фронтка китмичә, синең белән госпитальдә утын кисеп йөрергә тиеш идеммени?! Мин синең иртәнге дүрттә полковник бүлмәсеннән чыкканыңны күргәч, шул ук таңда фронтка китүче солдатлар утырган машинага утырдым да фронтка тайдым.

Мәрьям. Полковник, дисең инде. Полковник. Кем өчен кердем, кем өчен яшьлегемне бирдем?! Синең өчен! Синең гомереңне саклар өчен, үз-үземне корбан иттем. Яшәтәсем килде. Саклап каласым килде. Сине тилереп яратканга, аның куенына кердем.

Сәлимгәрәй. Булды, Мәрьям! Җитте! Бер-беребезне шашып яратсак та, без бергә була алмыйбыз. Соң инде.

Мәрьям. Исеме ничек?

Сәлимгәрәй. Мәмдүдә.

Мәрьям. Шушы авыл кызымы?

Сәлимгәрәй. Юк. Күрше авылдан. Укытучы булып безнең авылга килгән иде. Әйдә, безгә кайтыйк, таныштырырмын.

Мәрьям. Юк. Мин сезгә бармам инде.

Сәлимгәрәй. Син нәрсә?! Мин сине биредә калдыралмыйм. Ерак юл килгәнсең. Ял итәрсең, капкалап алырбыз.

Мәрьям. Хатыныңнан яхшы түгел. Мин аның бәгыренә, ул минем бәгырьгә кереп утыралмас. Авыру кеше кимсенүчән була. Минем килүне күтәрә алмас.

Сәлимгәрәй. Менә духтыр алып кайттым, диярмен. Күңеле булыр. Адәм баласы өмет белән яши.

Мәрьям. Син мине берәр ялгыз карчыкка урнаштыр.

Сәлимгәрәй *(Мәрьямнең плащын кидерергә булышып)*. Борчылма. Авылда ирләрен фронтта югалткан ялгызлар ике йортның берсендә. Күңеләңә ошаганына урнаштырырмын.

Мәрьям. Ярый. Безнең арадагы мөнәсәбәтне хатының белергә тиеш түгел.

Сәлимгәрәй. Яхшы. *(Кулына чемоданны ала да ишекне ачып җибәрә.)* Рәхим итегез, иптәш сестра!

Мәрьям *(честь биреп)*. Есть, иптәш сержант!

Музыка. Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Сәлимгәрәйләрнең өй эче. Ишек ачылып китә.

Сәлимгәрәй (*кулын алга сузып*). Рәхим итегез, иптәш сестра, в мою хату!

Мәрьям. Исәнмесез!

Мәмдүдә. Исәнмесез!

Сәлимгәрәй. Мәмдүдә, таныш бул. Безнең авылга килгән яңа медсестра Мәрьям.

Мәмдүдә. Ярый. Сәлимгәрәй, өстен ал, өстен. (*Сәлимгәрәй Мәрьямнең плащын салдыра.*) Түргә узыгыз, Мәрьям, түргә. Гаепләмәгез инде, бераз өйдә тәртипсезлек булса.

Мәрьям. Зыян юк. (*Мәмдүдә янына килә.*) Нәрсә булды?

Сәлимгәрәй (*шаяртып*). Кылтаеп, иркәләнеп ята.

Мәмдүдә. Картларча әйтсәк, җен зәхмәте. Сезнеңчә — паралич.

Мәрьям. Күптән булдымы инсульт?

Сәлимгәрәй. Өч елдан артты инде. (*Урындык китереп куя.*) Утыр, Мәрьям. Үз өеңдәге кебек хис ит үзеңне. Менә, Мәмдүдә, тау белән тау гына очрашмый, диләр. Сиңа үземнең...

Мәрьям. Сәлимгәрәй?!

Сәлимгәрәй. Борчылма. Безнең Мәмдүдә белән секретларыбыз юк. Шулай бит, Мәмдүдә?

Мәмдүдә. Күпме яшәп беренче тапкыр исемем белән эндәштең, Сәлимгәрәй. Рәхмәт. Алайса, әнисе дә әнисе... Балабыз булмагач, әнисе дигән сүзне ишетүе авыр.

Сәлимгәрәй. Хәтерлисеңме, мин сиңа, Курский дугасында яралангач, госпитальгә китерделәр дә урамга тезеп салдылар, дип сөйләгән идем? Яралылар, госпитальгә керер өчен чират көтеп, атналар буе ачык һавада яталар иде, дигән идем.

Мәмдүдә. Сөйләгән идең шул.

Сәлимгәрәй. Минем бәхетемнән, бер татар кызы очрап, ул мине көнендә үк эчкә кертеп салды, ул аның үз койкасы булган икән. Миңа гомер бүләк иткән туташ менә үзе була инде.

Мәмдүдә (*шатланып, көлемсерәп*). Хәзер миңа ярдәмгә килгәнме? Хәтерлим. Нишләп хәтерләмим? Исеменә кадәр хәтерлим.

Сәлимгәрәй. Мәмдүдәнең хәтере аның! Исеменә кадәр хәтерли.

Мәмдүдә. Хәтерләмичә. Кызыбыз туса, Мәрьям исеме кушам, дип шатланып йөргәнеңне дә хәтерлим. Тик балабыз гына булмады. Ходай үзе белгәндер. Ярый әле бирмәгән. Сәлимгәрәйнең бер башына авыр булыр иде.

Сәлимгәрәй. Ярый, әнисе, мин өстәл әзерлим. Ә сез сөйләшә торыгыз.

Икенче бүлмәгә чыгып китә.

Мәрьям. Кан басымыгыз ничек?

Мәмдүдә. Кем белгән аны, кем үлчәгән. Авылда брач юк.

Мәрьям. Үлчәрбез. Дарулар да эчкәнең юктыр инде?

Мәмдүдә. Юк.

Мәрьям. Сиңа хәрәкәтләнергә кирәк. Яткан таш мүкләнә, диләр.

Мәмдүдә. Мин күрәсен кеше күрмәс. Тәкъдирдә шулай язылгандыр. Аркамның сызлавына чыдый алмыйм.

Мәрьям. Арканны удырасыңмы соң?

Мәмдүдә. Юк.

Мәрьям. Ну инде, Сәлимгәрәй. Нигә иреңә удырмыйсың? Үпкәләреңә зыян килүе бар. Ярар, бүгеннән башлап үзем уармын.

Мәмдүдә. Кирәкмәс. Авылда бер мин генә хаста түгел. Сугыш күпләрне имгәтте. Аяксыз, кулсызлар авылда да җитәрлек. Сиңа болай да эш күп булыр.

Мәрьям. Өлгерермен. Белеп килдем.

Мәмдүдә. Авырулардан болай да туйгансыңдыр. Ничек килеп җиттең? Сөйлә. Юл бик авыр булмадымы?

Мәрьям. Бик җиңел генә булмады.

Мәмдүдә. Хәзер Сәлимгәрәй белән чәйләп алырсыз. Ятып ял итәрсең. Сәлимгәрәй ашарга тәмле пешерә ул.

Мәрьям. Рәхмәт.

Мәмдүдә. Җәмәгатең бармы?

Мәрьям. Юк.

Мәмдүдә. Сугыш алгандыр инде?

Мәрьям. Юк.

Мәмдүдә. Сөйгәнең бармы?

Мәрьям. Бар иде.

Мәмдүдә. Кавыша алмадыгызмы?

Мәрьям. Кавыша алмадык.

Мәмдүдә. Бүтәнне яр иттеме, әллә башка сәбәп бар идеме?

Мәрьям. Бүтәннеке булды.

Мәмдүдә. Борчылма. Чибәрлегең бар, тазалыгың җитәрлек, үз тиңеңне табарсың әле.

Мәрьям. Үзем дә шундыйрак фикердә.

Мәмдүдә. Менә Сәлимгәрәй генә үз тиңе белән яши алмады.

Мәрьям. Ә сез? Сез бар бит.

Мәмдүдә. Мин? Мин тере мәет. Өрлектәй ир, типсә, тимер өзәрдәй чагында берьялгызы, төннәр буе уңнан сулга, сулдан уңга боргаланып, төн уздыра. Авыр аңа. Аны күреп миңа авыр. Нинди хатын инде мин.

Мәрьям. Терелерсең әле. Мин дә ярдәм итәрмен.

Мәмдүдә. Бирсен Ходай. Рәхмәтеннән ташламасын.

Бүлмәгә Сәлимгәрәй килеп керә.

Сәлимгәрәй. Хәзер өстәлне генә Мәмдүдә янына тартабыз да мин ризыкларны ташый башлыйм.

Мәрьям. Сәлимгәрәй, син мине берәр фатирга урнаштырсаң иде. Көн дә кичкә авышып бара. Караңгы төшкәч, кешегә ишек шакып керүе уңайсыз.

Мәмдүдә. Мәрьям, әллә берәр сүзем авыр тоелдымы? Нигә бик тиз китәргә булдың? Чит кешеләр түгел ләбаса. Сәлимгәрәй, нигә авызыңа су кабып торасың? Үзең гомер буе Мәрьям, Мәрьям, дидең, ә үзең...

Сәлимгәрәй. Бәлки, бүген бездә генә калырсың?

Мәрьям. Юк, син нәрсә?!

Мәмдүдә. Мәрьям, кун бездә. Сәлимгәрәй белән сөйләшәсе сүзләрегез дә күптер, мин комачауламамын. Кал бездә.

Мәрьям. Юк, калмыйм.

Мәмдүдә. Кал, Мәрьям. Куәтемнән килсә, гелгә калдырыр идем дә, чирле кеше белән яшисең килмәс шул. Аллага шөкер, баз тулы бәрәңгебез, икмәк тә җитәрлек. Бергә-бергә күңелле булыр. Сәлимгәрәйне кызганам. Иптәш булыр идең.

Мәрьям. Ярый, бүген сездә, иртәгә фатир табарбыз.

Мәмдүдә. Бар. Күрше бүлмәгә, кухняга кереп юынып ал да аннары ашарсыз.

Мәрьям. Рәхмәт. (*Икенче бүлмәгә кереп китә. Сәлимгәрәй өстәл өстендәге әйберләрне бушата башлый.*)

Мәмдүдә. Сәлимгәрәй, син нишлисең?

Сәлимгәрәй. Өстәлне синең яныңа тартам.

Мәмдүдә. Кирәкми. Зинһар, кирәкми. Минем кеше янында ашарлыгым юк.

Сәлимгәрәй. Булмаганны сөйләмә әле, әнисе.

Мәмдүдә. Зинһар, мине читен хәлгә куйма. Кулыңа кашык тота алма, коеп-чәчеп, кеше җирәндереп утырыр хәлем юк.

Бүлмәгә Мәрьям чыга.

Мәрьям. Булышыйммы?

Сәлимгәрәй. Әйдә алайса, Мәмдүдә янына өстәлне илтик.

Мәмдүдә. Сәлимгәрәй, әйттем бит. Минем кабар җирем юк. Әле генә Саҗидә апа бәрәңге күзикмәге кертkән иде, шуны бик тәмләп ашадым. Үзегез генә утырып ашагыз.

Сәлимгәрәй. Ярый алайса. Мәрьям каршы килмәсә, без кухняда гына ашарбыз. Ничек уйлыйсың, Мәрьям?

Мәрьям. Шатланып. Киттек, иптәш сержант.

Икенче бүлмәгә кереп китәләр, алар кереп киткән бүлмәдән шатлыклы көлү авазлары ишетелә.
Ут сүнә.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, яңа көн туган. Эчтәге бүлмәдән Мәрьям чыга.

Мәрьям. Хәерле көн.

Мәмдүдә. Хәерле көн, Мәрьям. Тыныч йокладыңмы?

Мәрьям. Яшермим. Төн буе уйлар дәрьясында йөрдем. Таң сызылып килгәндә генә йокыга киткәнмен.

Мәмдүдә. Урын алмаштырсам, мин үзем дә йоклый алмыйм. Урын алмаштыру килешмәгәндер.

Мәрьям. Үзең ничек йокладың, Мәмдүдә?

Мәмдүдә. Төш күрдем. Бәбкәләр саклыйм икән. Бер тилгән килеп чыкты да бер бәбкәмне алмакчы була...

Мәрьям. Алдымы соң?

Мәмдүдә. Бер билгесез егет килеп чыкты да тилгәнне атып алды.

Мәрьям. Билгесез егет?

Мәмдүдә. Әйе. Бер дә күзгә-башка күренмәгән егет.

Мәрьям. Тилгән, дисең инде... Алалмады, дисең... Сәлимгәрәй кая соң әле?

Мәмдүдә. Ул иртәнге дүрттә үк китә. Иртә таңнан наряд аларның. Ә син, Мәрьям, тартынып торма, үзеңне-үзең кара. Ашап ал.

Мәрьям. Хәзер бергә ашыйбыз.

Мәмдүдә. Рәхмәт, мине Сәлимгәрәй ашатып китте.

Мәрьям. Мин иртә белән ашарга күнекмәгән. Ярый, мин җыеныйм да Сәлимгәрәй янына барыйм әле. Ул миңа бер ташландык йортны күрсәтермен, шунда медпункт ясарбыз, дигән иде. Ошап китсә, үзем дә шунда яшәрмен.

Мәмдүдә. Мәрьям, син миңа ачуланма. Авыру яткан өйдә яшәү читенен читен дә, әмма минем сиңа бер үтенечем бар. Мөмкин булса, минем хакка, Сәлимгәрәй хакына кал бездә бөтенләйгә. Үтенеп сорыйм. Кал. Сәлимгәрәйгә иптәш булырсың.

Мәрьям. Мәмдүдә, булдыралмыйм. Бик теләсәм дә, булдыралмыйм. Зинһар, дөрес аңла мине.

Мәмдүдә. Ул бит сине хөрмәт итә. Сине сөйләмәгән көне юк иде аның. Син бит аңа гомер бүләк иткән кеше.

Мәрьям. Юк, булмый. Мин әҗәт алырга кайтмадым.

Мәмдүдә. Ярый алайса. Башка кыстый алмыйм. Соңгы үтенечемне үтә.

Мәрьям. Нинди үтенеч?

Мәмдүдә. Минем болай булганыма өч елдан артты. Сә-

лимгәрәйгә ял кирәк. Үзеннән күпме ялынып сорадым, әниләргә берәр атнага гына булса да кайтарып куюын. Мине тыңламый. Арыды, бәгырь, талчыкты. Аңа ял кирәк. Мөмкин булса, күндер шуны.

Мәрьям. Яхшы. Ничек тә күндерермен.

Мәмдүдә. Минем хакка тырыш.

Мәрьям. Тыныч бул. Тырышырмын. Бер генә атнага түгел, берәр айга, кирәк исә, елга тырышырмын синең хакка.

Мәмдүдә. Рәхмәт.

Мәрьям. Үзеңә рәхмәт.

Мәмдүдә. Ни өчен?

Мәрьям. Аны, Сәлимгәрәйне аңлавың өчен. Син акыллы хатын. Ярый, мин киттем.

Чыгып китә. Бераздан бүлмәгә Саҗидә килеп керә.

Саҗидә. Кем ул? Маңгайга-маңгай бәрелә яздык, кош тоткандай чыгып китте.

Мәмдүдә. Авылга медсестра булып килгән. Сәлимгәрәйнең танышы. Сугышта, госпитальдә танышканнар. Медсестралары булган.

Саҗидә. Бик әйбәт булган. Күптән авылга брач-духтыр кирәк иде инде. Ялгызмы?

Мәмдүдә. Тормышка чыкмаган. Медпункт карарга китте. Узган ел үлгән Рәшидә әбинең өен медпункт итмәкче булалар бугай. Торуын да шунда тормакчы була.

Саҗидә. Рәшидә чордыйның өендә торалмас ул. Аның стеналарыннан буран уйный бит.

Мәмдүдә. Үзебездә генә тор, дигән идем дә, авыру кеше белән яшисе килмидер инде, риза булмады.

Саҗидә. Авыру, дип, авыру күрмәгән кеше түгелдер инде. Брач, дисең бит. Бик чибәр нәрсә күренә.

Мәмдүдә. Ходай матурлыкны җәлләмәгән. Өстәвенә сөйкемле. Их, үзебездә генә калмады бит.

Саҗидә. Калмый торсын әле. Кәҗә янына кәбестә куймыйлар. Хәзер ир табулары, ай-һай. Бик яләштермә. Аң бул! Менә нәрсә, Мәмдүдә, озакламый мунча ягып җибәрәм. Кич мунчага керерсез.

Мәмдүдә. Рәхмәт, Саҗидә апа. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый дигәндәй, Саҗидә апа, суы калырдай булса, кунакка да әйтеп булмасмы, юл килгән бит.

Саҗидә. Нишләп булмасын. Керер. Ул да керер. Аллага шөкер, күңелем киң. Барыбызга да җитә. Ярый, мунча өлгергәч, кереп әйтермен.

Мәмдүдә. Саҗидә апа, әнкәйне бик сагындым. Сәлимгә-

рәй белән сөйләшеп кара әле. Берәр генә атнага авылга кайтарып куймасмы?

Саҗидә. Юк инде. Яткан җирең корымы, коры! Анаңның күкрәгенә сөт төшмәгәндер. Тыныч кына ят! Ир-атны ялгыз калдырырга ярамый ул. Җеннәр ияләшә. Синең җен күргәнең бармы?

Мәмдүдә. Юк. Күргәнем юк. Әмма берсе үземне алмаштырып китте, сизми дә калдым.

Саҗидә. Анаң янында күп йөрсәң, өеңә үк кереп утырыр. Тамагыңа ашадыңмы?

Мәмдүдә. Ашадым. Рәхмәт.

Саҗидә. Тагын керермен әле.

Чыгып китә. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, колхоз идарәсе. Сәлимгәрәй тәрәзәгә карап тора. Әкрен генә ишек ачыла. Аяк очарына гына басып, иплəп кенә Мәрьям керә дә Сәлимгәрәйнең күзләрен каплый.

Сәлимгәрәй (*Мәрьямнең кулларын үз куллары белән тотып*). Мәрьям...

Мәрьям (*кулларын ала. Шатланып*). Таныдың.

Сәлимгәрәй. Синең кулларны башка куллар белән бутап булмый, Мәрьям.

Мәрьям. Әллә катымы?

Сәлимгәрәй. Юк...

Мәрьям. Әллә кытыршымы?

Сәлимгәрәй. Синең куллар нәфис һәм йомшак...

Мәрьям. Ә синекеләр? (*Сәлимгәрәйнең кулларын үз битенә куя.*)

Сәлимгәрәй. Крестьян куллары. Җилдә ашалып, яргаланган тупас куллар.

Мәрьям. Бу куллар минем бит алмаларымны гына түгел, йөрәгемне назлыйлар.

Сәлимгәрәй (*кулларын алып*). Кирәкми, Мәрьям, кирәкми.

Мәрьям. Синең бу бармакларың гармун төймәләрендә шундый җитез бииләр иде. Хәтерлисеңме? Госпитальдә син безгә гармун тартып җырлый идең. Ничек җырлый идең әле син?

Сәлимгәрәй. Хәзер җырлап булмый инде. Уйнап та булмый. Бармаклар каткан.

Мәрьям. Бармаклар түгел, күңелең каткан. Бугазда төер,

кулларда сөял. Ә мин синең яраларыңны төзәтергә дип кайткан идем.

Сәлимгәрәй. Соң инде. Сугыш яраларын төзәтеп була, күңел ярасын төзәтеп булмый.

Мәрьям. Шулай шул. Миңа нишләргә, миңа? Бир бер киңәш.

Сәлимгәрәй. Кит син, кит. Үз тиңеңне табарсың. Син чибәр, өстәвенә сөйкемле.

Мәрьям. Ә син?

Сәлимгәрәй. Мәмдүдә әйтмешли, бер йомырка маяда да чери. Үзем сайлаган язмыш. Язмышлардан узмыш юк, диләр. Бәхетле бул. Синең бәхетле булырга хакың бар.

Мәрьям. Сиңа минем соңгы үтенечем: җибәр син аны берәр атнага әниләренә, җибәр.

Сәлимгәрәй. Нигә?

Мәрьям. Минем хакка. Минем сиңа булган керсез мәхәббәтем хакына. Мин биредән буш китәргә кайтмадым. Мин биредән синең дәвамыңны алып китәргә дип кайттым. Җибәр. Минем хакка, сөюем хакына.

Сәлимгәрәй *(озак кына уйланып торганнан соң)*. Яхшы.

Мәрьям. Рәхмәт сиңа.

Сәлимгәрәй. Әйдә кайтабыз.

Мәрьям. Юк, мин сезгә кайталмыйм. Авыру хатының мөлдерәмә күзләрен тутырып миңа карап ятканда, мин сезнең бусагагызны кабат атлап керә алмыйм.

Сәлимгәрәй. Ә син Мәмдүдә хакына кайт. Ә син минем авыру хатыным хакына кайт. Күңелендә авыр төер калдырма. Әниләренә тыныч күңел белән китсен.

Мәрьям. Яхшы. Син кайта тор. Мин бераздан кайтырмын.

Сәлимгәрәй. Озаклама. *(Чыгып китә. Мәрьям тәрәзә янына килә, тәрәзәне ачып җибәрә.)*

Музыка. Ут сүнә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, кабат Сәлимгәрәйләрнең йорты. Сәлимгәрәй тәрәзәдән карап тора.

Мәмдүдә. Сәлимгәрәй, тәрәзәдән нәрсә карыйсың?

Сәлимгәрәй. Юк, болай гына. *(Тәрәзә пәрдәсен ябып куя.)*

Мәмдүдә. Син мине әниләргә кайтарсаң иде, Сәлимгәрәй.

Сәлимгәрәй. Синсез нишләрмен соң мин? Кем янына кайтырмын? Кем мине елмаеп каршы алыр?

Мәмдүдә. Мин озакка түгел. Бер генә атнага.

Сәлимгәрәй. Синең тамагың ачмы? Сиңа минем караңгы чырай катканым бармы?

Мәмдүдә. Соңгы вакытта начар төшләр күрәм. Бәлки, авылым белән дә соңгы тапкыр саубуллашуымдыр. Аннары әнине дә сагындым, абыйны да күрәсем килә. *(Сәлимгәрәй тагын тәрәзә янына бара, тәрәзәдән карый.)* Озакламас, кайтыр, кайтыр ул, Сәлимгәрәй, борчылма.

Сәлимгәрәй. Кем?

Мәмдүдә. Мәрьям.

Сәлимгәрәй. Мин бит аны көтмим. Кайтыр. Авыл адашырлык түгел. Мөстәкыйм малае тик торганда урам буйлап ат куалап йөри. Шуңа ачуым чыгып карап торам.

Мәмдүдә. Ул сине ярата.

Сәлимгәрәй. Баш катырма әле. Каян беләсең?

Мәмдүдә. Күзләреннән.

Сәлимгәрәй. Менә ни өчен авылга да авылга, дисең икән. Нәрсә, безгә аулак өй калдырмакчы буласыңмыни? Хәзер үк мин аны Сажидә апага урнаштырам. Ә юк, ул бит иртәгә бөтенләйгә китә.

Мәмдүдә. Яратуның нинди начарлыгы бар?

Сәлимгәрәй. Әнисе, ваклана башладың. Нишлим? Өлгерә алмыйм бит. Бәлки, сиңа игътибар җитмидер, бәлки, бүлнискә йөртә алмыймдыр.

Мәмдүдә. Җитә, Сәлимгәрәй, җитә. Бүлнисенә дә йөртмәдең түгел, йөрттең. Мин үләрмен дә котылырмын. Синең өчен борчылам. Картлык көнеңдә нишләрсең? Ярый да син мине карыйсың. Сине кем карар?

Сәлимгәрәй. Авылдашлар ташламас әле, авылдашлар ташламас.

Мәмдүдә. Син әле яшь. Сиңа бала кирәк. Миннән фатиха. Кушыл син аның белән. Мин сиңа мәңге бәхил. Минем яшәгән кадәр гомерем калмагандыр. Калган гомеремне үз авылымда, әни белән абый янында яшәп бетерермен. Әгәр инде алар алданрак китсәләр, кардәшләрем авылда күп бит минем.

Сәлимгәрәй. Сиңа нәрсә җитми? Нигә мине телгәлисең? Эштә булса — эштә, өйгә кайтсам — өйдә, миннән нәрсә кирәк соң сезгә? Асылына алмыйм бит инде, син бар. Син бер яклап, Сажидә апа икенче яклап, Мәрьям өченче яктан... Ярар, илтеп ташлармын авылыңа. Кара аны, сагынырсың, барып алмам.

Мәрьям кайтып керә.

М ә р ь я м. Нигә тавышланасыз?

С ә л и м г ә р ә й. Өч яктан атаковать итәсез! Тәмам өнемне алдыгыз. Сугышта чолганышта калганда да бу кадәр борчылмаган идем. Булды бу турыда сөйләшү, бетте. Иртәгә иртә белән берәр атнага авылыңа кайтарып куярмын.

М ә р ь я м. Менә монысы ирләрчә, иптәш сержант.

М ә м д ү д ә. Рәнҗемә инде, Сәлимгәрәй. Бүтән сорамам. Соңгы тапкыр. Мунчага чакырып Саҗидә апа кергән иде.

С ә л и м г ә р ә й. Башта әллә, Мәрьям, син барасыңмы? Без соңыннан барырбыз. Мәмдүдәгә эссе мунча ярамый.

М ә р ь я м. Юк, Сәлимгәрәй, син бар. Син ир кеше, иркенләп чабын. Аннары Мәмдүдәне үзем алып барырмын. Әйбәтләп чабармын, тәннәрен сыларм ын, шулай бит, Мәмдүдә?

М ә м д ү д ә. Шулаен шулай да, Сәлимгәрәйнең бер генә тапкыр да кеше рәтле мунча кергәне юк. Миңа көчең җитмәс шул синең. Мин имгәк бит.

М ә р ь я м. Госпитальдә йөзләгән гарип-горабаны караган кеше әле мин. Бар, Сәлимгәрәй.

С ә л и м г ә р ә й. Әнисе, нәрсә әйтәсең?

М ә м д ү д ә. Бар, бар, Сәлимгәрәй. Иркенләп чабынып, бер кешечә мунча кереп кайт әле.

С ә л и м г ә р ә й. Ярый алайса.

М ә р ь я м. Безнең өчен дә эссе салырга онытма. Җиңел пар сиңа!

С ә л и м г ә р ә й. Рәхмәт. *(Чыгып китә башлый.)*

М ә р ь я м. Ә, тукта әле, Сәлимгәрәй. *(Чемоданыннан күлмәк алып, Сәлимгәрәйгә бирә.)* Миннән сиңа бүләк.

С ә л и м г ә р ә й. Юк, кирәкми. Минем күлмәкләрем җитәрлек.

М ә м д ү д ә. Ал, Сәлимгәрәй, ал. Бүләктән олы булырга ярамый.

С ә л и м г ә р ә й. Рәхмәт, Мәрьям. Син үзең безгә бүләк. Шулай бит, әнисе. *(Күлмәкне ала да чыгып китә.)*

М ә р ь я м. Сиңа да, Мәмдүдә, бүләгем бар. Кара әле, нинди матур яулык. Ал.

М ә м д ү д ә. Рәхмәт, Мәрьям, бүләгең өчен. Мин бу бүләкне ала алмыйм. Безнең якта шундый йола бар. Чит мунчага беренче тапкыр кергәндә, хуҗаларга бүләк калдыралар. Бу яулыгыңны Саҗидә апага калдырсаң, дөресрәк булыр.

М ә р ь я м. Ал инде, ал. Аңа мин оек бүләк итәрмен.

М ә м д ү д ә. Юк, рәхмәт. Ала алмыйм. Болай да бик күп бүләк алып кайткансың, рәхмәт. Бүләккә бүләк бирергә кирәк.

М ә р ь я м. Иртәгә авылга җыенасың. Әниеңә бүләк итеп алып кайтырсың.

Мәмдүдә. Бүләккә каршы бүләк итәрлек бер генә нәрсәм бар минем, Мәрьям.

Мәрьям. Миңа бүләк кирәкми.

Мәмдүдә. Кирәк. Сиңа Сәлимгәрәйнең мәхәббәте кирәк. Мәрьям, син аны ташлама. Ялгызын калдырма. Минем авылга китүем дә шуның өчен. Ятим итмә аны. Беләм. Ул мине ташламаячак. Сизәм. Минем гомерем озак калмады. Син аңа бала алып кайт. Мине җирләгәч, ул сезне эзләп табар.

Мәрьям. Син нәрсә, үз акылыңдамы, Мәмдүдә?

Мәмдүдә. Син аны яратасыңмы?

Мәрьям. Яшермим, яратам. Яратмасам, эзләп кайтыр идемме?! Мин аның өйләнгәнен белмәдем. Мин аның хәтта исән икәнен белмәдем. Мин сезнең тормышыгызны җимерергә дип кайтмадым. Дөрес аңла мине, Мәмдүдә. Исән булса, соңгы тапкыр күрергә, үлгән булса, каберенә чәчәк салырга дип кайткан идем мин. Аны күргәч, мәхәббәтем тагын да яңарды. Син миңа рәнҗемә. Син киң күңелле, сабыр һәм саф хатын. Рәнҗемә. Мин Сәлимгәрәйдән үземнекен алып китәм. Мин Сәлимгәрәйдән нәсел җебен алып китәм. Рәнҗемәссеңме син миңа, Мәмдүдә?

Мәмдүдә. Рәхмәтемнән гайре башка сүзем юк сиңа, Мәрьям. Бәхил бул!

Музыка. Ут сүнә.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, кабат шул ук колхоз идарәсе. Мәрьям урындык аркасына куйган кулларына ияген куйган да тирән уйга баткан. Тәрәзәгә карап, Сәлимгәрәй баскан.

Мәрьям *(озак кына паузадан соң)*. Мәмдүдә үзеңне сагынганмы?

Сәлимгәрәй. Мине күрүгә елап җибәрде. *(Паузадан соң.)* Китәм, дисең инде.

Мәрьям. Китәм.

Сәлимгәрәй. Бөтенләйгә.

Мәрьям. Бу юлы бөтенләйгә. Башка күрешмәбез инде.

Сәлимгәрәй. Бәлки, китмәссең?

Мәрьям. Кеше бәхетен урлап бәхетле булмам.

Сәлимгәрәй. Рәнҗеп китмә. Балабыз туса...

Мәрьям. Кайчан булса да ул сине эзләп табар. Бәхил бул, Сәлимгәрәй!

Сәлимгәрәй. Хуш, Мәрьям!

Кулына чемодан, култык астына гармун кыстырган, матрос киеменнән бүлмәгә Сәүбән килеп керә. Чемоданын куя да кулын Сәлимгәрәйгә суза.

Сәүбән. Нихәл, иптәш председатель? Эшче көчләр кирәкме?

Сәлимгәрәй (*кулын биреп*). Кирәк.

Сәүбән. Ә бу чибәр туташ кем була?

Мәрьям. Юлчы.

Сәүбән. Кучерыгыз бармы?

Сәлимгәрәй. Әлегә юк.

Сәүбән. Үзем булам.

Сәлимгәрәй. Ат идарә каршына бәйләнгән. Станция бездән ун чакрым.

Сәүбән. Есть, иптәш председатель. Ай момент. (*Гармун каешларын кия башлый.*)

Мәрьям. Мин хәзер Мәмдүдә белән генә саубуллашам да чемоданымны алып чыгам. (*Озак кына Сәлимгәрәйнең күзләренә карап тора да, кинәт башын түбән иеп, тиз генә чыгып китә.*)

Сәүбән (*Сәлимгәрәйгә*). С музыкой. (*Гармунын тартып җырлап җибәрә.*)

Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам туган илкәйне, шул,
Сагынам туган илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән иркәмне.

Җырның икенче куплеты башланганда, ут сүнә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Сәлимгәрәйләрнең өй эче. Мәрьям караватта ярым яткан, ярым утырган Мәмдүдәнең битенә битен терәгән дә яшьле күзләрен еракка-еракка төбәгән. Мәмдүдә дә тирән уйга чумган.

Мәмдүдә, Мәрьям (*икесе бергә өзек-өзек тавыш белән җырлыйлар*).

Ай ю-га-ры, ай ю-га-ры,
Ай-га ме-нә-сем килә,
Ай-га ме-неп, тү-бән ка-рап,
Сез-не кү-рә-сем ки-лә...

Бер-берсенә капланып елыйлар.

Мәрьям (*бераздан башын күтәреп, күз яшьләрен сөртә-сөртә*). Акыллым, рәнҗемә миңа, рәнҗемә. Син бәхетле... Авыру булсаң да, урында ятсаң да, син миннән бәхетлерәк. Синең янында сине яратучы кеше булуың белән бәхетле син.

Мәмдүдә. Мәрьям, кал, кал, биредә кал!

Мәрьям. Юк. Синнән качып китәм. Синең керсез намусыңнан качып китәм. Бәхетле бул. (*Мәмдүдәнең башын күкрәгенә кыса.*) Бәхетле бул, алтыным. (*Өзек-өзек җырлый.*)

Ак-лы-чук-лы ал тас-мам-ны
Та-гып җи-бәр тәң-кә-ңә.
Шул е-гет-не я-ра-там, дип
Әйт, Мәм-дү-дә, ән-кә-ңә.

Шул...

Ут сүнә. Җыр дәвам итә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, беренче күренешнең дәвамы. Сәүбән карт кулына гармун алган да урындыкта утыра. Янында Сәлимгәрәй карт.

Сәүбән карт. Хәтерлисеңме ул җырны?

Сәлимгәрәй карт. Хәтерлим, Сәүбән, хәтерлим.

Сәүбән карт. Җырның сүзләренә игътибар иттеңме?

Сәлимгәрәй карт. Сагынам туган илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьли сөйгән иркәмне.

Сәүбән карт (*гармунына таяна да озак кына уйланып торганнан соң*). Илкәй дә калды, яшьли сөйгән иркәм дә калды...

Сәлимгәрәй карт. Нигә кайттың? Кайтмаска иде сиңа, кайтмаска иде.

Бүлмәгә көчкә-көчкә атлап, капшана-капшана, ярым сукыр Мәрьям килеп керә. Ул инде әби.

Мәрьям. Мин, мин алып кайттым аны, мин... Мәмдүдә алдындагы антымны саклап, картлык көнеңдә сине ялгыз калдырмыйм дип, улыңны да, аны да мин алып кайттым.

Сәүбән карт (*гармунын әкрен генә тартып, салмак кына җырлап җибәрә.*)

Өй артындагы бакчадан
Өзеп алдым бер йөзем, шул,
Өзеп алдым бер йөзем.
Өзеп алган йөзем кебек,
Чит илләрдә берүзем.

*(Паузадан соң.)* Шулай, күрше. Өзеп алган йөзем кебек яшәмик чит җирдә. Кал, кал син үз нигезеңдә. Синең тамырың, дәвамың бу җирдә.

Музыка.

П ә р д ә

# Рәзмыш

*Драма ике пәрдәдә, җиде күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Н ә с и м — Әфганстанда сукыраеп кайткан ир.
З ә м з ә м и я — Нәсимнең хатыны.
Г ө л г е н ә — аларның кызлары.
Н а и л ә  ә б и — Нәсимнең әнисе.
С ө л ә й м а н  к а р т.
И л д у с — Нәсим белән Зәмзәмиянең классташы.
Р ә м и л ә — Нәсим һәм Зәмзәмиянең күршесе.
С ә е р  к е ш е.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, Нәсимнәр яши торган фатирның залы. Арткы планда, уң якта, урамга чыга торган, сул якта кухняга керә торган ишекләр. Арткы планда, уртада, киң зур тәрәзә. Аңа пәрдә корылган. Сул як стенага терәтеп, диван куелган. Бүлмәнең уртасында өстәл. Өстәл янында берничә урындык. Җайлы гына бер урында стенага телефон эленгән. Өстәл артында, тирән уйга батып, Н ә с и м утыра. Тәрәзә кырыенда С ә е р  к е ш е басып тора. Ара-тирә ул урамга карап ала.

С ә е р  к е ш е. Качмакчы булдыгыз?! Якты дөньядан туйдыгыз?! Бауга мендегез?! Үз-үзегезгә кул салдыгыз?!

Н ә с и м. Минем өчен бары тик бер генә юл калды.

С ә е р  к е ш е. Хатыныңны, кызыңны калдырып?! Син үлгәч, алар белән нәрсә буласын уйладыңмы?

Н ә с и м. Алар өчен тырыштым. Минсез аларга җиңелрәк булыр дип уйладым.

С ә е р  к е ш е *(ирония белән көлеп)*. Ул уйлаган, җиңелрәк булыр дип уйлаган. Юк, син алар турында уйламагансың, син үзең турында, үз шкураң турында уйлагансың. Үлә дә котыла. Ансат. Ә аннан соң калган кешеләр газап чигәргә тиеш.

Нәсим. Миңа нишләргә иде соң?

Сәер кеше. Уйларга!

Нәсим. Уйларга... Минем төннәр буе күз йомганым юк.

Сәер кеше. Сиңа күз йомуның кирәге юк. Син болай да сукыр! Ә син уйла, уйла. Минем әле көтәргә вакытым бар.

Нәсим. Яхшы.

Сәер кеше. Пока. Мин сезгә шалтыратырмын.

Нәсим. Мин сездән үтенеп сорыйм. Гаиләм өйдә чагында шалтыратмагыз.

Сәер кеше. Яхшы. *(Чыгып китә.)*

Нәсим, урындыкларны капшый-капшый, тәрәзә янына килә, пәрдәне ачып, урамга карый. Шат күңел белән Гөлгенә кайтып керә дә сумкасын диванга ыргыта. Барып әтисен кочаклый.

Гөлгенә. Әтием, син нишлисең?

Нәсим. Урамга карыйм.

Гөлгенә. Син бит барыбер күрмисең.

Нәсим. Күрмим шул.

Гөлгенә. Әтием, әнә теге абый кем ул?

Нәсим. Кайсы? Мин күрмим.

Гөлгенә. Бездән чыгып киткән абый. Әнә, әнә машинасына утыра.

Нәсим. Бездә бернинди дә абый булмады.

Гөлгенә. Алдашма. Ул, минем башымнан сыйпап: «Син Нәсим кызымы, син Гөлгенәме?» — дип сорады.

Нәсим. Ул хәтта синең исемеңне дә белә... Сәер кеше ул.

Гөлгенә. Безнең йортта аңа ни калган?

Нәсим *(сүзне икенчегә борып)*. Әйдәле, кызым, диванга утырыйк. *(Гөлгенә Нәсимне, култыклап, диванга алып килеп утырта да әтисенең куенына керә.)* Йә, сөйлә, кызым, мәктәптә нәрсәләр җимердең?

Гөлгенә. Математикадан олимпиада да катнаштым.

Нәсим. Уңышлымы соң?

Гөлгенә. Нәтиҗәсе бер атнадан билгеле була.

Нәсим. Әй, кызым, кызым, син дә үсеп буйга җиттең... *(Кызының башыннан сыйпый.)*

Гөлгенә. Әтием, әйдә качышлы уйныйбыз?

Нәсим. Кияүгә чыгар вакытың җитеп бара, ә син һаман да минем белән качышлы уйныйсың. Бар. Синеңчә булсын. Кач.

Гөлгенә *(урыныннан сикереп тора)*. Сана!

Нәсим. Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты... *(Гөлгенә өстәл астына кереп кача.)* Җиде, сигез, тугыз, ун! Эзли башлыйм. *(Диванда утырган килеш.)* Әй, кызый, син кая? Барыбер табам. Әһә, син анда, өстәл астында утырасың?!

Гөлгенә *(өстәл астыннан)*. Дөрес түгел!

Нәсим. Ничек дөрес түгел?
Гөлгенә. Син хәрәмләштең!
Нәсим. Менә сиңа мә! Әллә үпкәләде инде.
Гөлгенә. Үпкәләдем шул.
Нәсим. Чык аннан, өстәл астыннан.
Гөлгенә. Чыкмыйм! *(Паузадан соң, өстәл астында килеш.)* Әйт әле, әтием, син күрмисең дә, ничек бик тиз мине эзләп табасың?
Нәсим. Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер, дигәннәр. Яраткан кешене югалтып булмый ул, кызым. Күзләрем күрмәсә дә, күңелем күрә. Күңел ул шундый — күңел ул яраткан кешене күздән югалтмый, кызым. Мин Ходайдан күпне сорамыйм. Күкрәгемдәге йөрәгем тибүдән туктагач, сезне — әниеңне, сине ярдәменнән ташламасын иде.
Гөлгенә *(әтисе янына килә)*. Теге абый кем ул, әтием?
Нәсим. Күптәнге танышым.
Гөлгенә. Әллә бергә хезмәт иттегез?
Нәсим. Әйе, Әфганда.
Гөлгенә. Хәзер мин яулык алып киләм. Син минем күзләремне бәйләрсең дә качарсың.
Нәсим. Кирәкми, кирәкми, кызым. Яныма утыр. Гомер ул бик кыска, ә дөнья гаҗәеп матур. Анда нинди генә төсләр юк. Адәм-кеше шул төсләрне күрүе белән бәхетле дә. Ә син күзләреңне бәйләргә кушасың. Адәм баласы күз ачып йомган арада да күпме матурлыкны күрми кала. *(Гөлгенәнең чәченнән үбеп.)* Чәчләрең нәкъ әниеңнеке төсле.
Гөлгенә. Син минем чәчемнең төсен каян беләсең? Син бит күрмисең.
Нәсим. Төсләрнең дә исе була, кызым. Менә чәчләреңнең очларын агарткансың.
Гөлгенә. Гаҗәп син, әтием. Син боларны каян беләсең?
Нәсим. Төсләрнең дә исе, авырлыгы, кешеләр кебек үз парлары була ул, кызым. Ак төс — пакь төс. Әмма салкын төс. Кар исе килә. Яшел төс — авыр төс. Җәй исе килә. Кызыл төс — күңелгә авыр төс. Кан исе килә. Зәңгәр төс — җиңел төс. Салкынча төс. Сары төс — ачык төс. Әмма сагышлы төс. Көз исе килә. Ак төс — караны, кара төс акны ярата. Дөньяда акны карадан аера алган кеше генә бәхетле була, кызым.
Гөлгенә. Син бигрәк инде, әтием. Дөньяны сукырлар басмаган лабаса. Акны карадан аермас өчен, дөм сукыр булырга кирәк.
Нәсим. Сак бул. Акны — кара, караны ак, дип әйттерергә теләүчеләр бик күп, кызым. Менә син дә быел мәктәбеңне тәмамлыйсың, уйлаганың бармы, кем булырга җыенасың?
Гөлгенә. Табиб! Күз врачы. Сукырларга дөньяның матурлыгын күрсәтергә телим.

Н ә с и м. Син бәхетле. Синең алда — өмет! Өмете, хыялы булган кеше — бәхетле кеше!

Г ө л г е н ә. Кешенең иң-иң бәхетле көне буламы?

Н ә с и м. Була.

Г ө л г е н ә. Ул көнне кеше үзе беләме?

Н ә с и м. Белә.

Г ө л г е н ә. Кайчан?

Н ә с и м. Башына кайгы төшкәч.

Г ө л г е н ә. Синең иң бәхетле көнең?

Н ә с и м. Сукыр лампа яктысында әниемә беренче тапкыр инә саплап биргән көнем.

З ә м з ә м и я кайтып керә.

З ә м з ә м и я. Кара боларны, эшләре беткән. Әтиле-кызлы, дөньяларын онытып, кочаклашып утыралар.

Г ө л г е н ә *(сикереп тора да диванга менеп баса)*. Ура... Әни кайтты. *(Йөгереп барып әнисен үбә.)* Әни, әнием, синең тормышыңдагы иң бәхетле көнең?

З ә м з ә м и я. Синең сукыр атаңа кияүгә чыккан көнем.

Г ө л г е н ә *(ярсып)*. Әни!!!

З ә м з ә м и я. Нәрсә әни, нәрсә?! Дәресеңне әзерләдеңме?

Г ө л г е н ә. Өлгерәм!

З ә м з ә м и я. Кайчан өлгерәсең? Быел мәктәбеңне бетерәсең. Кая бармакчы буласың?! Институтка кертергә минем акчам юк! Диванда атаңның сукыр күзләренә карап утырганга акча китереп тоттырмыйлар.

Г ө л г е н ә *(ачынып)*. Әни!!!

З ә м з ә м и я. Мин сиңа унҗиде ел инде әни!

Нәсим урыныннан тора да капшана-капшана кухняга кереп китә.

З ә м з ә м и я. Бар әнә кухняга! Суыткычтан итне алып куй. Авылдан әбиең киләм дип шалтыратты. Минем бер башыма шул гына җитмәгән иде.

Г ө л г е н ә *(зәһәрләнеп)*. Ну, әни!.. *(Кухняга кереп китә.)*

З ә м з ә м и я. Нәрсә әни, нәрсә әни!.. Бүлмәгезне кара, свинарник! Мин җыештырмасам, аркылысын буйга да салмыйсыз! *(Кухняга ишетелерлек итеп.)* Син ашадыңмы? *(Паузадан соң.)* Сиңа әйтәм, Нәсим, син ашадыңмы?

Н ә с и м *(тавышы кухнядан ишетелә)*. Минем ашыйсым килми.

З ә м з ә м и я *(үз-үзенә ишетелерлек, мыгырданып)*. Үпкәли тагын...

Р ә м и л ә килеп керә.

Р ә м и л ә. Нихәл, күрше? Нигә сафура бураннары чыгарасың?

З ә м з ә м и я. Чыгармассың болар белән. Бөтен тирә-якка хур итте. Бауга менгән, имеш! Асылынган! Харап иткән, дөньядан туйган! Ашарына пешерәм, керен уам, чиста постельдә йоклатам, җылы фатирда яши, сабый бала тәрбияләгәндәй тәрбиялим, тагын нәрсә җитми?! Мин бит эштә дә, сигез сәгать буе станок янында, аның янына тизрәк кайтырга дип, җан атып торам. Ә ул?! *(Елап җибәрә.)* Килсен әле әнисе, килсен...

Р ә м и л ә. Наилә апа киләмени?

З ә м з ә м и я. Шалтыратты. Киләм, ди. Ишеткән! Мине гаепләр әле.

Р ә м и л ә. Зәмзәмия, син Нәсимдә берәр үзгәреш сизәсеңме?

З ә м з ә м и я. Сизмичә. Көннән-көн үз-үзенә бикләнә. Һәр сүзе саен үлем.

Р ә м и л ә. Кеше гаиләсенә тыкшыну минем эш түгел, шулай да әйтми калдыралмыйм. Сезнең юклыктан файдаланып, сезнең бусаганы көнаралаш ниндидер сәер кеше таптый.

З ә м з ә м и я. Сәер кеше?..

Р ә м и л ә. Әйе. Юан гына, кара күзлекле бер ир кеше. Капкара «джип»тан төшә дә сезгә кереп китә. Бүген дә ул сездә булды. Ләкин ул бүген машинасыз иде.

З ә м з ә м и я. Кара «джип», дисезме?

Р ә м и л ә. Әйе, кап-кара чит ил машинасы, иномарка. «Джип»!

З ә м з ә м и я. Кичә мине проходнойдан мәктәпне бетергәннән бирле күрешмәгән яшьлек дустым, беренче мәхәббәтем, Нәсимнең җан дусты, отставкадагы милиция полковнигы Илдус кап-кара «джип» белән каршы алды.

Р ә м и л ә. Белмим. Полковникмы, юкмы, ләкин ул гражданский киемнән иде.

З ә м з ә м и я *(үз-үзенә)*. Кызык... Ә ул миңа: «Кичә генә Себердән кайттым»,— диде.

Р ә м и л ә. Күрше, минем Нәсимгә йомышым бар иде. Нигәдер тышкы ишегем бик авырлык белән ачыла башлады.

З ә м з ә м и я. Нәсим, Нәсим, чык әле. Күрше Рәмилә кергән.

Н ә с и м *(тавышы кухнядан ишетелә)*. Хәзер.

З ә м з ә м и я. Утырып тор, Рәмилә.

Р ә м и л ә. Рәхмәт! Башка вакытта.

Н ә с и м *(чыга)*. Нинди йомыш, Рәмилә?

Р ә м и л ә. Тышкы ишегем авыр ачыла. Карап бирмәссең микән, күрше?

Н ә с и м. Хәзер керәм. Инструментларымны гына алам да керәм.

З ә м з ә м и я *(шаяртып)*. Карагыз аны, эчтә икәүләп бикләнеп кала күрмәгез.

Р ә м и л ә. Мастеры ничегрәк була инде. *(Чыгып китә.)*

З ә м з ә м и я. Нәсим, бүген бездә кем булды?

Н ә с и м. Беркем дә булмады.

Г ө л г е н ә *(чыга)*. Булды, булды, кара күзлекле, юан гына бер абый булды.

Н ә с и м. Бездә бүген беркем дә булмады!

Г ө л г е н ә. Ул гел безнең йорт тирәсендә йөри. Мин аны инде күп мәртәбәләр күрдем. Ниндидер сәер кеше.

Н ә с и м *(инструментларын ала да)*. Ярый, мин кереп чыгыйм әле. *(Чыгып китә.)*

З ә м з ә м и я *(Нәсимнең артыннан кычкырып)*. Карап, чамалап эшлә. *(Гөлгенәгә.)* Ниндирәк кеше иде ул?

Г ө л г е н ә. Кем?

З ә м з ә м и я. Безгә килгән кеше.

Г ө л г е н ә. Таза гына гәүдәле, кара күзлектән. Ниндидер сәер ул. Әллә инде парик та кигән...

З ә м з ә м и я. Кулына игътибар итмәдеңме?

Г ө л г е н ә. Әйе, әйе, кулында зур алтын печатка.

З ә м з ә м и я. Кайсы кулында?

Г ө л г е н ә. Уң кулында! Точно, уң кулында, урта бармагында. Бүген ул кара тәрәзәле «джип» белән килгән иде.

З ә м з ә м и я. Милиция киеменнән түгел идеме?

Г ө л г е н ә. Юк. Шикарный костюмнан иде. Әтием миңа аны, служагым, Әфганда бергә булдык, диде.

З ә м з ә м и я. Әтиеңнең андый служагы юк. Бар, бәлешкә ит тура.

Г ө л г е н ә. Ярый, әнием. *(Кереп китә.)*

З ә м з ә м и я *(озак кына уйланып торганнан соң)*. Урта бармагында зур печатка... «Джип»... Полковник... Шул, шул, үзе, полковник! Нәрсә кирәк аңа?.. Минме? Оныталмый... Беренче мәхәббәтен оныталмый. Беренче мәхәббәт?!

Музыка. Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, өстәл артында Н ә с и м, З ә м з ә м и я, Н а и л ә  ә б и, Г ө л г е н ә ашап утыралар.

З ә м з ә м и я. Әнкәй, бәлешенә җитеш әле, җитеш. Бер дә ашамыйсың.

Н а и л ә  ә б и. Рәхмәт, кызым Зәмзәмия, рәхмәт. Җитешәм, җитешәм. *(Нәсимнең аркасыннан сөеп.)* Әй, улым, улым, уң кулым.

Н ә с и м. Уң кулың булалмадым шул, имгәгең булдым.

З ә м з ә м и я. Нәсим, җитте. Әллә нигә бер килгән әнкәйнең нервысында уйнап утырма.

Н ә с и м. Авылда ничек, әнкәй?

Н а и л ә  ә б и. Авыл картая, улым. Авылда минем кебек карт-корылар гына калып бара. Авыл урамын элеккечә чирәм баса. Трактор, машина тавышлары сирәгәя.

Н ә с и м. Авылдашлар исән-саулармы?

Н а и л ә  ә б и. Синең хәер-фатыйхаңда, улым. Исән-саулар. Читтән Илдус кайтты.

Н ә с и м *(сискәнеп)*. Илдус?! Үзен күрдеңме? Нәрсәләр сөйли?

Н а и л ә  ә б и. Полковник булган.

Н ә с и м. Полковник булган?!

З ә м з ә м и я. Как будто белми?!

Н ә с и м. Каян белим. Аның белән күрешмәгәнгә ничә еллар.

Н а и л ә  ә б и. Күчтәнәч кертте. Дуслар идегез бит.

З ә м з ә м и я. Аерылмас җан дуслар...

Н а и л ә  ә б и. Ун ел бергә укыдыгыз.

З ә м з ә м и я. Бер партада утырдыгыз...

Н а и л ә  ә б и. Башлангычта өчегезне дә үзем укыттым бит.

З ә м з ә м и я. Бергә кызлар артыннан йөрдегез...

Н ә с и м. Син нәрсә, сүз саен комментария биреп барасың.

Н а и л ә  ә б и. Отставкага чыккан.

З ә м з ә м и я. Марҗасын алып кайтканмы соң?

Н а и л ә  ә б и. Юк. Кызганычка каршы, быел җәмәгате үлеп киткән.

З ә м з ә м и я *(кулындагы кашыгын төшереп җибәрә)*. Хатыны үлгән?!

Н а и л ә  ә б и. Әйе. Яман шеш авыруыннан.

З ә м з ә м и я *(урыныннан торып, төшеп киткән кашыгына үрелеп )* . Бала-чагалары бар иде микән?

Н а и л ә  ә б и. Малайлары бар икән. Өйләнгән, үз тормышы белән яши, ди.

З ә м з ә м и я. Анысы әйбәт. Аякка баскан икән. Бөтенләйгә күчеп кайтмагандыр бит.

Н а и л ә  ә б и. Шәһәрдән фатир эзлим, ди. Бик баеган. Утырып йөргән машинасы да бик кыйммәтле, әллә миллион, диде. Менә җәмәгате үлү генә яхшы булмаган.

З ә м з ә м и я. Беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Ярый әле гарип булып урын өстендә калмаган.

Н а и л ә  ә б и. Адресыгызны алды. Килеп чыгар әле.

Н ә с и м. Полковник?!

Н а и л ә  ә б и. Ә син минем — майор!

Н ә с и м. Таяклы сукыр — майор!

З ә м з ә м и я. Утырма әле эч пошырып. Милиция полковнигы белән хәрби майор арасында әллә ни аерма юк!

Н а и л ә  ә б и. Улым, нигә өстеңә матуррак күлмәк кимисең?! Кайчан килсәм дә, өстеңдә шушы уңган күлмәк.

З ә м з ә м и я. Нәрсә сөйлисең син, әнкәй?! Уңса! Туйга барасы юк. Мин аңа керле күлмәк кидергәнем юк. Ул барыбер төсләрне аермый.

Н ә с и м *(йодрыгы белән өстәлгә китереп суга, ярсып).* Мин төсләрне аерам! Мин төсләрне аерам!

Н а и л ә ә б и. Чү, чү, улым, тәртипле бул. Кулыңны авырттырасың бит.

Н ә с и м *(урыныннан торып).* Мин акны — карадан, кешене кешедән аерам! Менә син майорны полковниктан аерырсың микән?!

З ә м з ә м и я. Нишли ул?! *(Елый башлый. Урыныннан тора да күрше бүлмәгә кереп китә. Бераздан җилкәлеккә эленгән бер көлтә күлмәк күтәреп чыга да күлмәкләрне селкеп.)* Менә, менә мин аңа, зарплатымны алган саен, күлмәк алам!

Н а и л ә ә б и. Мин бит сине гаепләмим, Зәмзәмия. Ул бит сабый бала түгел, күлмәген генә алыштыра ала.

З ә м з ә м и я. Шулай, әнкәй, шулай... Хәзер ул элеккеге Нәсим түгел. Соңгы вакытта мин аны аңламыйм. Аңа хәзер син дә, мин дә, кызы да кирәкми. Аңа бау кадерлерәк.

Н а и л ә ә б и. Мин килгәч кенә ямьсезләнешмәгез инде, балалар.

Телефон шалтырый. Нәсим сискәнеп китә. Зәмзәмия телефон трубкасын ала.

З ә м з ә м и я. Алло. Алло, ишетмим?! Алло, дим?! Сезгә кем кирәк? *(Трубкасын колагыннан алып.)* Эндәшми. *(Нәсимгә трубканы суза.)* Мә, кара күзлекледер! Минем белән сөйләшәсе килми. Тавышымны таныр дип куркадыр.

Н ә с и м *(пышылдап).* Мин юк! Мин өйдә юк! Мин, мин авылга киттем. Әнисе үлгән, диген... Әнисен җирләргә китте, диген!..

З ә м з ә м и я *(бөтен тавышка әрнеп).* Нәсим! Син үз акылыңдамы?! *(Трубканы урынына куя.)*

Тавышка Г ө л г е н ә йөгереп чыга да ишек яңагына сөялә.

Н ә с и м *(башын өстәлгә куя, озак кына паузадан соң).* Кичер мине, әнкәй. Кичер.

Н а и л ә ә б и. Зыян юк. Ашасын ашадым, яшәсен яшәдем, анда китәргә дә вакыт җиткәндер.

Н ә с и м *(йодрыклары белән өстәлгә сугып).* Мин бит аңа бу вакытта шалтыратма, дидем, шалтыратма, дидем!!!

Музыка. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Г ө л г е н ә диванда йоклап ята. Телефон шалтырый. Кухнядан кабалана-кабалана Н ә с и м йөгереп чыга да, урындыкка сөрлегеп, урындыкны аудара. Гөлгенә күзләрен ача. Тавышка Н а и л ә  ә б и чыга.

Н ә с и м *(телефон трубкасына пышылдап)*. Алло, алло?! Бу синме?! Синме бу?! Син нәрсә?! Мин сиңа нәрсә дидем?! Мин сиңа, кич шалтыратма, дидем, сукин сын! Әгәр тагын гаиләм өйдә чагында шалтыратсаң, аң бул! Син миннән бөртек тә алалмаячаксың! Әйе, әйе, бер бөртек тә! *(Шап итеп трубканы куя.)*

Г ө л г е н ә. Әтием, кем ул? Теге абыймы?

Н ә с и м. Йокла, йокла, кызым.

Г ө л г е н ә. Әтием, милициягә хәбәр итәргә кирәк.

Н ә с и м. Юк, ул начар кеше түгел, кызым. Ул әниең өчен, синең бәхетең өчен тырыша.

Н а и л ә  ә б и. Нәрсә тели ул? Нәрсә тели ул синнән, балакаем? Кем ул?

Н ә с и м. Син сорама, әнкәй, мин әйтмим.

Г ө л г е н ә *(торып утыра)*. Дәү әнием, ул әтиемнең Әфганстанда бергә хезмәт иткән служагы.

Н а и л ә  ә б и. Әфган өчен күзләреңне бирдең... Тагын нәрсә кирәк аларга?!

Н ә с и м *(әнисен күкрәгенә кыса)*. Борчылма, әнкәй. Бар да тәртиптә. Күп калмады. Ул минем служагым түгел. Ул бары тик «Сәер кеше». Ул безнең гаиләгә бәхет тели.

Н а и л ә  ә б и. Бәхет теләгәнгәмени, аның тавышын ишетүгә, коелып төшәсең.

Н ә с и м. Кызык икән ул дөнья. Кайвакытта бәхет алдында да коелып төшәсең.

Н а и л ә  ә б и. Бар, кызым Гөлгенә, кухня өстәлендә ашың суына.

Г ө л г е н ә. Хәзер, дәү әни. *(Кухняга кереп китә.)*

Н а и л ә  ә б и. Кеше хакына кергән булсаң, үземә генә әйт, балам. Мин бит синең анаң. Мин сине аңлармын.

Н ә с и м. Син нәрсә инде, әнкәй. Минем кешенең инәсенә дә тигәнем юк.

Н а и л ә  ә б и. Курыкма, яшермә, балам. Йортымны сатып булса да түләрмен.

Н ә с и м. Минем бу җир йөзендә хатыным Зәмзәмия белән кызым Гөлгенәдән гайре беркемгә дә бурычым юк. Ә син мине кичерерсең дип уйлыйм. Гомер бүләк итсәң дә, мин ул гомернең яртысын да рәхәт яшәмәдем.

Н а и л ә  ә б и. Бәлки, синең Илдус алдында бурычың бардыр?

Н ә с и м. Нәрсә, урлаган мәхәббәтем өченме?! Ул үзе миңа

риза булып кияүгә чыкты. Мәхәббәтне урлап булмый, әнкәй. Иртәме, соңмы ул барыбер үзенекен итә. Минем бит яшисем килә, әнкәй. Яшисем килә. Сукыр булсам да, күзләремне мәңгелеккә йомасым килми.

Наилә әби. Син хәзер үзең өчен генә түгел, дөньяга тудырган балаң, кызың хакына яшәргә тиеш.

Нәсим. Аларга ярдәм италмыйм бит, әнкәй.

Наилә әби. Хөкүмәт биргән фатирың бар, пенсияң бар. Сиңа тагын нәрсә җитми?

Нәсим. Зәмзәмияне кызганам. Миңа кияүгә чыгып нинди бәхет тапты соң ул?! Аның өчен җан атып торучылар, аның өчен бар байлыгын бирергә әзер торучылар барда, нигә ул мин имгәкне карап ятарга тиеш соң?!

Наилә әби. Язмыштан узмыш юк! Үзең сорап алган гариплек түгел. Туган ил өчен, туган җир өчен биргән күзләр!

Нәсим. Туган ил, туган җир, туган туфрак... Минем өчен туган ил дә, туган җир дә куе томан булып артта калдылар. Минем өчен хәзер иң кадерле нәрсә — тирә-яктагыларга комачау ясамыйча, тыныч кына сукыр күзләремне тизрәк йомып, теге дөньяга китеп бару.

Наилә әби. Ялгышасың, балам! Син яшәргә хаклы, син бу җирнең герое!

Нәсим. Кем өчен герой?! Синең өченме? Әллә әфган халкы өченме?

Наилә әби. Сине шунда җибәргән туган җир өчен!

Нәсим. Кая ул туган җир?! Шушы егерме сигез квадрат метрлы фатирмы?! Кем өчен көрәштем? Нәрсә майтардым?! Басып кереп, пистон атып, кеше үтереп, күз чыгардыммы?! Нинди герой... Кем өчен?

Наилә әби. Ходай барысын да күрә.

Нәсим. Дөрес, Ходай күрә... Кемнәрнеңдер җирләренә басып кереп, газиз балаларына автомат көпшәсе төзәгәнгә, бәлки, күземнән яздыргандыр. Хәзер менә туган ил биргән садакамны да вакытында бирмиләр. Гөлгенә дә үсеп буйга җитте. Укырга кирәк. Ул кемнән ким? Мәктәптә гел бишлегә генә укый. Әйт әле, әнкәй, ул кемнән ким? Аның да бай балалары кебек укыйсы, югары белемле буласы килә.

Наилә әби. Башында зиһене булса, укыр! Ходай ярдәменнән ташламас.

Нәсим (*урыныннан торып*). Зиһен?! Нәрсә соң ул зиһен? Хәзер андый төшенчә юк! (*Чалбарының ике кесәсен тартып чыгара.*) Кесә бит — тишек! Акча юк! Димәк, зиһен дә юк! Тегендәгеләр, институттагылар, кесәгә карыйлар. Кесә буш, димәк, институт ишекләре дә безнең кебекләргә хуш!

Урам ишектән Зәмзәмия кайтып керә.

З ә м з ә м и я. Нигә дулыйсың, Нәсим! Тавышың урамга ишетелә.

Н а и л ә  ә б и. Нервалары беткән, нервалары тузган. Таушалган ул.

З ә м з ә м и я. Хәзер кемнең нервалары бетмәгән дә, кем таушалмаган. Нәрсә хәзер, нерва беткән дип, тәрәзә ачып, урамга акырыйкмыни?!

Н а и л ә  ә б и. Нишләп син, кызым Зәмзәмия,囲 эштә түгел?

З ә м з ә м и я. Сине озатырга сорап кайттым.

Н а и л ә  ә б и. Кирәкмәс иде инде, кирәкмәс иде, борчыласың калмаган, үзем киткән булыр идем әле. Улым, Нәсим, бәлки, минем белән бераз авылга кайтып торырсың?

Н ә с и м. Булмый. Кайтмыйм. Берсен дә күрәсем килми.

Н а и л ә  ә б и. Нигә алай дисең? Дусларың, авылдашларың бит.

Н ә с и м. Мин аларның кызгануларына мохтаҗ түгел.

З ә м з ә м и я. Кыстама, әнкәй. Үзе беләдер. Ансыз безгә дә күңелсез.

Н а и л ә  ә б и. Балалар, мин сезгә күп булмаса да, бераз акча алып килгән идем... *(Кесәсеннән акча чыгарып, өстәлгә куя.)*

Н ә с и м. Әнкәй, син нәрсә?! Күземә күрсәтмә!

З ә м з ә м и я. Нигә алай дисең, Нәсим? Авыр елыбыз бит. Гөлгенәне укырга кертәсе бар.

Н ә с и м. Әгәр син ул акчаларны аласың икән, мин өстәлдәге пычакны йөрәгемә алам! Сайла! Икесенең берсе!

Н а и л ә  ә б и. Улым, нигә син гел киреңә катасың? Минем бер башым. Пенсиям җитәрлек. Кем өчен яшим?! Син бит минем балам. Мин бит сезгә артканын гына бирәм.

Н ә с и м. Артык булгангамыни ел саен ярты гектар чөгендер утыйсың?! Артык булгангамыни арба тартып сыер асрыйсың?!

Н а и л ә  ә б и. Гөлгенәне укытырга кирәк, улым.

Н ә с и м. Үзем укытам.

З ә м з ә м и я. Фатирыңны сатыпмы?!

Булмәдән, ярсып, Г ө л г е н ә килеп чыга.

Г ө л г е н ә *(Зәмзәмиягә)*. Фатирыңда үзең калырсың! *(Әтисенең муеныннан кочып.)* Әтием, мин барыбер врач булам. Мин барыбер сиңа якты дөньяны күрсәтәчәкмен!

З ә м з ә м и я. Күз сатып алыпмы?

Г ө л г е н ә. Маңгайдагы күзләр алар әле күз түгел. *(Йөрәгенә төртеп күрсәтеп.)* Күз ул менә монда. Күз ул — күңел түрендә!

Музыка. Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Н ә с и м телефон трубкасыннан сөйләшеп тора.

Н ә с и м. Алло? Алло, дим! Кем әле бу? *(Сөләйман карт керә дә сөйләшкәнне тыңлап тора.)* Ә сез... Күзлегегезне салыгыз. Телефон аша сезне барыбер беркем дә танымый... Борчылмагыз. Куйган срогыгызга җавабымны әйтермен... Бик сабырсыз икәнсез. Нәрсә? Нәрсә дидегез? Сезне срок кыса. Түзегез, түз, озакламый, бәлки, мин сезне бәхетле итәрмен. Тагын өч тәүлек. Бары җитмеш ике сәгать! Яхшы. Сау булыгыз! *(Трубканы куя да өстәл артына кереп утыра. Озак кына уйланып торганнан соң.)* Бары өч тәүлек! Өч тәүлек — җитмеш ике сәгать! Үләргәме, әллә яшәргәме?!

С ө л ә й м а н к а р т *(җырлап җибәрә)*.

Эх, Сөләй, Сөләй, Сөләй,
Эх, Сөләйман балдагы.
Вәгъдәләрең кай дөньяда —
Монсындамы, андамы?

Н ә с и м. О, Сөләйман абзый. Нихәл, күрше?

С ө л ә й м а н к а р т. Әбиеңнеке кебек. Гәрючи күтәрелгән.

Н ә с и м. Күтәрелсә, синең барыбер машинаң юк.

С ө л ә й м а н к а р т. Булмаса, ягулык күтәрелсә, Сөләй абзаңның да топливасы күтәрелә. Аракы күтәрелә.

Н ә с и м *(өстәлдән консерва калае ала да сувенир ясыйясый)*. Аракы күтәрелгәч, пиво да күтәрелә. Пиво күтәрелгәч, консервасы да күтәрелә.

С ө л ә й м а н к а р т. Иренә диген, ә?

Н ә с и м. Кем?

С ө л ә й м а н к а р т. Теге, кара күзлекле, кара «джип»лы бәндә.

Н ә с и м. Нигә?

С ө л ә й м а н к а р т. Стена аркылы бүре куа. Кереп сөйләшми. Подъезд янына килеп җиткәч, машинасыннан төшәргә иренә. Машинасыннан гына сөйләшә.

Н ә с и м. Нигә, ул бирердәмени?

С ө л ә й м а н к а р т. Тәрәзәңә терәлеп туктаган бит.

Н ә с и м *(ашыга-ашыга тәрәзә янына бара да саклык белән әз генә пәрдәне ача)*. Кая?

С ө л ә й м а н к а р т. Нигә куркасың?! Син — аны, ул сине күрми. Машинасының тәрәзәсе кап-кара аның. Бәлки инде киткәндер дә. Кем ул?

Н ә с и м. Ә, улмы, ул... дустым!

С ө л ә й м а н к а р т. Шәп дус! Вәгъдәләшкән дус! Үләргәме, әллә яшәргәме?! Нигә куркасың?

Н ә с и м. Кемнән?

Сөләйман карт. Кара күзлекле, уң кулының урта бармагында йодрык кадәрле «сөләйман» балдаклы ул кешедән.

Нәсим. Мин беркемнән дә курыкмыйм. Җитешмәгән җирең юк.

Сөләйман карт. Сөләй бабаң сугышка кадәр чекист булган кеше. Ике япун, бер немеч шпионын тоткан кеше. Күзлеген салдырам әле мин аның. Күзлеген салдырып, ике күз арасына шундый итеп тамызам, җилеге атылып чыкканын да сизми калачак ул.

Нәсим. Эшләмәгән эшең калмаган. Әле кая югалып тордың? Өч-дүрт көн күренмәдең!

Сөләйман карт. Мәскәүгә, Кремльгә барып кайттым.

Нәсим. Бер тик торалмыйсың. Әллә инде Мәскәүгә атнасына өч тапкыр барып кайтасың?!

Сөләйман карт. Чакыралар бит.

Нәсим. Мәскәү юлын таптап, ничә пар ботинка туздырдың инде?

Сөләйман карт. Санаганым юк!

Нәсим. Тагын нәрсәгә чакырганнар?

Сөләйман карт. Мин бит правительствода эшләгән кеше.

Нәсим. Кит аннан?!

Сөләйман карт. Әйе, сугыштан соң сиксәненче елларда мин бит Никитаны машинада йөрттем.

Нәсим. Хручевнымы?

Сөләйман карт. Бәй, соң.

Нәсим. Сиксәненче елларда ил белән Брежнев идарә итте түгелме соң? Нинди машинада йөрттең, Сөләйман абзый?

Сөләйман карт. Карт кешенең хәтереннән көлеп утырма. «Девятка»да йөрттем!

Нәсим. Йә, ярый, үпкәләмә, Сөләйман абзый. Нигә чакырганнар?

Сөләйман карт *(онытып)*. Кая?

Нәсим. Мәскәүгә, Кремльгә.

Сөләйман карт. Орден бирергә. Сугышта Самара янындагы немечләр белән каты бәрелештә югалткан орденымны тапканнар.

Нәсим. Кемнәр?

Сөләйман карт. Авыл көтүчеләре.

Нәсим. Немец Самарага килеп җиттемени ул, Сөләйман абзый?

Сөләйман карт. Җитмичә.

Нәсим. Тарихта нигәдер бер дә алай язмыйлар.

Сөләйман карт. Синең гәҗит укыганың бармы соң?! Гәҗит укы! Элек язмыйлар иде, секрет иде. Менә хәзер, син сукырайгач, яза башладылар.

Нәсим. Ярый әле мин сукырайганмын. Дөреслекне белмичә яшәгән булыр идек.

Сөләйман карт. Немечләр инде алар Казан урамында йөри башлаганнар иде.

Нәсим. Кит аннан?!

Сөләйман карт. Соң, Опера театрын Гитлер төзетте бит.

Нәсим. Син Кремльдә йөргәч беләсең инде.

Сөләйман карт. Белмичә. Муса Җәлилне шул театрдан кулга алдылар бит.

Нәсим. Немецлармы?

Сөләйман карт. Соң...

Нәсим. Ул театрга шуңа Җәлил исеме кушканнар инде.

Сөләйман карт. Билгеле шуңа.

Нәсим. Белмәгәнең юк.

Сөләйман карт. Шәләпин дә әләгәсе булган, алданрак чыгып качкан.

Нәсим. Да...

Сөләйман карт. Да шул менә.

Нәсим. Кая, күрсәт инде орденыңны?

Сөләйман карт. Кәчтүм киеп бармаган идем, плащка такмадылар. Икенче юлы килерсең, диделәр.

Нәсим. Яңа костюм киеп барасың бар икән әле!

Сөләйман карт. Бармыйм. Яңа кәчтүмемне, орден тактырам дип, тиштерәсем юк әле. Ул орденнарның файдасы кәчтүм тишеге кадәр дә юк. Кая, стаканыңны бир әле? Бер чүлем бар иде.

Нәсим. Рәхәт яшисең син, Сөләйман абзый.

Сөләйман карт. Соң, орденны юарга кирәк бит инде.

Нәсим. Орден юып гомерең үтә.

Сөләйман карт. Гел биреп торалар бит.

Нәсим. Көнаралаш диген. Минем медальләрне дә күршеләргә кереп юдың бугай инде син.

Сөләйман карт. Һадыйларга керепме?! Күрсеннәр, янәшәләрендә кемнәр яшәгәннәрен белсеннәр. Ялганчы Һадый ышанмаган була. «Бу медальләр синеке түгел, бу медальләр Нәсимнеке» ди. Аңгыра, ялкау Һадый. Әйтеп торам мин аңа, минем Украина фронтында югалткан орденнарым да нәкъ менә шушындый иде, дип. Юк, ышанмый. Эшлә, мин әйтәм. Сиңа да бирерләр. Гарьләнмәсә гарьләнми. Бер көн эшкә чыгып карамый, исерек баш! Кая, стаканыңны бир әле, бер чүлем бар иде.

Нәсим. Әнә кухнядан кереп ал. *(Сөләйман карт кухнядан стакан алып чыга.)* Таптыңмы, Сөләйман абзый.

Сөләйман карт. Көлмә авыру кешедән. Алкаш булсам да, стакан күрерлек кенә күзем бар әле. *(Куеныннан ярты чыгарып, калтырый-калтырый стаканга аракы сала.)* Каһәр төшкере кул!

Н ә с и м. Әллә калтырыймы?

С ө л ә й м а н  к а р т. Бетәбез! Дихлофуз сибеп үтергән чебеннәр кебек бетәбез. Ялганчы Һадый да бетә, шадра Ибрай да бетә, барыбыз да эчеп бетәбез. Син бәхетле, син каласың, потому что син таза! Күз ул чепуха! Син тотмыйсың инде.

Н ә с и м. Тотмыйм, Сөләйман абзый.

С ө л ә й м а н  к а р т. Дөрес эшлисең! Бик кыстасам да тотмыйсың!

Н ә с и м. Бик кыстасаң да тотмыйм.

С ө л ә й м а н  к а р т. Бик кыстарга җыенып та тормыйм әле. Үземә дә чүл генә.

Н ә с и м. Чүл түгел, ярты, Сөләйман абзый.

С ө л ә й м а н  к а р т. Менә син дә күрә башладың.

Н ә с и м. Күрмим, ишетәм, Сөләйман абзый.

С ө л ә й м а н  к а р т. Ничек?

Н ә с и м. Күзеңне йом да башта чүлдән стаканга аракы салып кара, аннан бер яртыдан салып карарсың.

С ө л ә й м а н  к а р т. Шуннан...

Н ә с и м. Бульт-бульт иткәненнән белеп була аны.

С ө л ә й м а н  к а р т. Ә мин аракы урынына су салып утырсам...

Н ә с и м. Ә син шулай эшлисең дә.

С ө л ә й м а н  к а р т. Кеше түгел, әүлиядыр син. Су икәнен каян белдең?

Н ә с и м. Анысын музыкантлар, сукырлар гына ишетә. Шешәдән аккан су белән спирт тавышын да аермасам, стажлы сукыр булмыйм да мин.

С ө л ә й м а н  к а р т. Вот черт! Эт икәнсең. Ходай белеп синнән күзне алган. Әгәр синең күзләрең исән булса, син минем янда утырасы кеше түгел. Синең урын ученыйлар, галимнәр арасында. Кирәк бит, ә? Вот сиңа мә! Вот талант! Кая, нәрсә ясыйсың?

Н ә с и м. Юкны бушка әйләндереп утырам.

С ө л ә й м а н  к а р т (*бер сувенирны кулына алып әйләндереп карый да сызгырып куя*). Да, малай. Настоящий ювелир! Күзле кеше дә болай ясый алмый. Коеп куйгансың. Адәм баласына Ходай талантны бирсә дә бирә инде. Минем үземнең мондыйга кул ятмый. Мин бит телевизор мастеры.

Н ә с и м. Шулаймыни?

С ө л ә й м а н  к а р т. Шулай булмыйча. Березовскийның алты каналлы телевизорын унике каналга эшләп биргән кеше бит мин. Кара әле, энем, миңа да берәр миниатюрный гына йозак ясап бир әле?

Н ә с и м. Нигә?

С ө л ә й м а н  к а р т. Сәрвәр әбиеңнең авызын бикләп куярга.

Нәсим. Әллә сүгәме?

Сөләйман карт. Юк, йоклаганда гырылдый. Сиңа мин, энем, бер яңалык сөйләрмен дип кергән идем.

Нәсим. Нәрсә, әллә тагын искусственный күз уйлап тапканнармы?

Сөләйман карт. Каян белдең?

Нәсим. Егерме ел сөйлисең түгелме соң инде син аны.

Сөләйман карт. Бу юлы үзем, үз күзләрем белән күреп кайттым, эшләтеп тә күрсәттеләр.

Нәсим. Ничегрәк эшли соң?

Сөләйман карт. Эшләү тәртибе болайрак. Менә минем күзләремә кара әле!

Нәсим. Синең күзләреңне күрсәм, син миңа бу турыда егерме ел сөйләмәс тә идең.

Сөләйман карт. Уңга караганда, уң күз уңга борыла.

Нәсим. Ә сул күз?

Сөләйман карт. Сул күз урынында тора.

Нәсим. Нигә?

Сөләйман карт. Бәтәрәе утырмаска. Сулга караганда, сул күз сулга борыла, ә уң күз урынында тора.

Нәсим. Ә турыга караганда?

Сөләйман карт. Турыга караганда, сул күз сулга, ә уң күз уңга борыла. Юк, мин буталып беттем. Так значит, турыга караганда, сул күз сулга, уң күз уңга борылса, барып чыкмый бит әле бу. Ә менә күрше Һадый бер стакан эчкәч, ике күзе ике якка карый. Гаҗәп. Ә син, күзләрем күрми, дип, үз-үзеңне каһәрлисең. Җир өстендә Һадый кебек күзле бүкәннәр дә җитәрлек. Күкрәгеңдә йөрәгең типкәндә, яшә. Синең яшәргә хакың бар. Үләргә әле сиңа иртәрәк. *(Ишектә звонок шалтырый.)*

Нәсим. Да, да, керегез! Ишек ачык!

Сөләйман карт *(кычкырып)*. Нельзя! Занято! *(Тиз генә шешәсен куенына тыга.)* Вот сейчас можно, даже нужно!

Бүлмәгә милиция киеменнән Илдус килеп керә.

Илдус. Мөмкинме?

Нәсим *(сискәнеп китә, урыныннан торып)*. Да, да, мөмкин.

Сөләйман карт *(үз-үзенә сөйләнеп, урыныннан тора-тора)*. Нужносын нужно да, такой важный не нужно! Белер-белмәс акырып утырсаң, машинасына утыртып алып та китәр. Бывшый чекист дип тормас. *(Илдус янына килеп җиткәч, башын иеп.)* Здрасте? *(Илдусның күкрәгендәге бер значокка төртеп.)* Миндә дә мондый орден бар иде. Белоруссия фронтында каты бәрелештә югалттым. *(Нәсимгә Илдусның бармагындагы йөзеген ымлап күрсәтеп җырлап җибәрә.)*

Эх, Сөләй, Сөләй, Сөләй,
Эх, Сөләйман балдагы.
Вәгъдәләрең кай дөньяда —
Монсындамы, андамы?

Илдус. Исәнме, дустым Нәсим? *(Ашыгып, Нәсимгә атлый.)*

Көчле музыка.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Пәрдә ачылганда, Нәсим белән Илдус кочаклашып торалар.

Нәсим *(Илдусның җилкәсеннән тотып)*. Илдус, дускаем, возмужал, как возмужал! Иңсәләр киңәйгән. Әйдә, утыр. *(Утыралар.)* Кайчан кайттың?

Илдус. Бер атна элек.

Нәсим. Другом считается. Кайтканына бер атна, күзгә башка күренми.

Илдус. Ачуланма. Мин синең исән икәнлегеңне белмәдем.

Нәсим. Ничек исән икәнлегемне белмәдең?

Илдус. Озын гомерле булырсың. Син минем өчен бу якты дөньяда күптән юк идең инде. Күптән мин сине җирләгән идем.

Нәсим. Ничек? Ничек мине җирләгән идең, Илдус?

Илдус. Мин Зәмзәмияне эзләп кайткан идем.

Нәсим. Зәмзәмияне эзләп?..

Илдус. Әйе, Зәмзәмияне эзләп. Ул ялгыз, мин ялгыз, бергә тормыш корырбыз дип кайткан идем.

Нәсим. Ишеттем. Хатының үлгән. Кайгылы булгансың икән.

Илдус. Әйе, мин ялгыз. Синең исәнлегеңне Зәмзәмия белән очрашкач кына белдем.

Нәсим. Зәмзәмия белән очрашкач?..

Илдус. Әйе, Зәмзәмия белән очрашкач.

Нәсим. Сез очраштыгыз?

Илдус. Әйе, Нәсим, очраштык.

Нәсим. Үлеп булмады шул, Илдус.

Илдус. Йә, сөйлә, ничек булды?

Нәсим. Военный училищены бетергәч, Германиягә киттем.

Илдус. Беләм. Мин ул вакытта, армиядән кайтып, Алабуга милиция мәктәбендә укый идем.

Нәсим. Ике елдан соң Союзга кайтардылар. Озак та үтмәде, Әфганда сугыш, каты бәрелешләр башланды. Беренчеләр-

дән булып безне шунда ыргыттылар. Зәмзәмия Термез шәһәрендә калды. Семьяны алып керергә ярамый иде.

Илдус. Беләм. Миңа Зәмзәмия Термездан хат язды.

Нәсим. Башта штабта хезмәт иттем. Аннары передовойга җибәрделәр. Бер каты бәрелештә янымда снаряд шартлады.

Илдус. Аннары Зәмзәмия синең үле хәбәреңне алды.

Нәсим. Каян беләсең?

Илдус. Әйтәм бит, ул миңа хат язды. Укыйсың киләме? Ул хат исән. Ул хатны мин ничә еллар инде куен кесәмдә саклыйм. *(Куен кесәсеннән дүрткә бөкләнгән хатны чыгара да Нәсимгә суза. Нәсимнең сукыр икәне исенә төшеп.)* Гафу, зинһар, гафу ит, Нәсим. Мин сине рәнҗетергә теләмәдем. Юк, юк, теләмәдем.

Нәсим. Зыян юк. Үзең укы.

Илдус *(хатны укый башлый)*. Сәлам Термез шәһәреннән.

Хатның дәвамы микрофон аша Зәмзәмия тавышы белән дәвам ителә.

Зәмзәмия. Исәнме, Илдус. Бу хатны сиңа Зәмзәмия яза. Синең теләгең тормышка ашты, әтиләргә, минсез бәхетле булмый ул, дигән сүзләрең чынга әверелде. Нәсимне мин мәңгегә, гомерлеккә әфган җирендә югалттым. Бер атна элек штабыннан, батырларча һәлак булды, дигән кәгазь алдым. Кичә каралай янган гәүдәсен, цинковый гробка салып, шушы Термез шәһәренең зиратына, җир куенына салдык. Әнисенә хәбәр итмәдем. Ялгыз ана бердәнбер улының үле хәбәрен ишетеп, авыр кайгысын күтәралмас, дип уйладым, шуңа күрә хәбәрсез югалды, дидем. Калган гомеремдә өмет чаткысы калдырдым. Дөрес эшләмәгән булсам, Ходай кичерер. Без өч классташ, өч дус идек. Өчебез дә өч якка китеп югалдык. Бәлки инде мин сине дә югалтканмындыр. Син башканыкыдыр. Синең белән соңгы тапкыр очрашкандагы дорфа сүзләрем өчен кичер, гафу ит. Мин Казанга юл тотам. Исәбем — шунда кайтып урнашу. Кайда да булса, кайчан да булса юлларыбыз кисешсә, мине эзләп тап. Адресым әниләрдә булыр. Кабат сәлам белән...

Нәсим. Кабат сәлам белән беренче мәхәббәтең Зәмзәмия.

Илдус. Юк, Зәмзәмия генә. Биш елдан соң мин синең кабереңне эзләп бардым. Зират хуҗаларын аякка бастырдым. Кабереңне тапмадым. Синең кабереңне казып, мәетне туган ягына алып киттеләр, диделәр.

Нәсим. Шартлаудан соң носилкага салып мине госпитальгә озатканда, ярты үле гәүдәм өстенә ялгыш янәшәмдә үлеп яткан бер солдатның документлары белән шинелен сал-

ганнар. Аңыма килгәндә, мин инде майор Фәхрисламов Нәсим түгел, ә сержант Воронцов Геннадий идем. Ярты ел үземнең кем икәнемне яшердем. Мин үземнең бу дөньяга кирәкмәс имгәк икәнемне белеп яшердем. Барыннан да элек Зәмзәмия эзләп тапмасын дип яшердем. Аңа сукыр абуза буласым килмәде.

Илдус. Шуннан?..

Нәсим. Шуннан шул. Минем янга госпитальгә улларын күрергә Воронцовның әти-әнисе килде. Барысы да ачыкланды. Ярты ел мин кеше гомере белән яшәдем. Шул ярты ел гомер миңа бүген дә тынгы бирми. Йә, үзең турында сөйлә.

Илдус. Өйләндем. Гомер буе Себердә яшәдем. Быел хатыным үлде. Малаем бар. Хәзер инде үз гаиләсе белән яши. Кызы туды. Зәмзәмия дип куштык. Зәмзәмия кая соң әле?

Нәсим. Эштә. Озакламый кайтып җитәр. Син утырып тор. Мин хәзер. *(Кухняга кермәкче була.)*

Илдус. Кирәкми! Бернәрсә дә кирәкми! Янымда утыр. Үзеңне күрәсем килә. Ничә еллар бит, ничә еллар... Дуслар идек бит. Игезәкләр дип йөртәләр иде. Мин һәрвакыт сиңа охшарга тырыша идем. Кайчакларда синнән көнләшеп тә куя идем. Сиңа ошаган кызлар миңа ошый иде.

Нәсим. Зәмзәмия генә нәрсә тора?

Илдус. Да, мин йөрдем, син урладың. *(Көлемсерәп.)* Герман җиреннән кайтып урладың. Ә мин Себердә авыз ачып калдым.

Нәсим. Юк, Илдус, урламадым. Үзе чакырды. Хат аша чакырды. Үз теләге белән алып киттем. «Нәсим,— дип язган иде ул хатында,— үзең безнең төшкә дә кермәгән чит илдә, чит җирдә, герман җирендә йөрисең. Ә мин монда, тездән пычрак ерып, авылда ятам. Кая синең дуслык хисләрең? Мин синеке булырга телим, бары тик синеке. Мине бәхетсез итәсең килмәсә, уйла. Мине кайтып алмасаң, тотам да беренче очраган кешегә кияүгә чыгам. Туема да чакырмыйм»,— дип язган иде ул.

Илдус. Ә мин аның өчен көзге яңгырлы төндә Себердән авылга, ашкына-ашкына атлап түгел, очып кайттым. Ун чакрым араны саз ерып, көзге караңгы төндә җәяү кайттым. Кайтсам, ул киткән. *(Зәмзәмия кайтып керә дә, Илдусны күреп, ишек яңагына сөялеп өнсез кала. Нәсим белән Илдус аны күрмиләр.)* Шул вакытта чыккан ачуымны белсәң?.. Ну, мин әйтәм, кайчан да булса ул егеттән үземнең үчемне алмасам, исемем Илдус булмасын.

Нәсим. Вакыт җитте. Күрәсең, мин хәзер көчсез!

Музыка. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шактый көннәр узган. Тәрәзәдән эңгер-меңгер караңгы төшкәне сизелә. Гөлгенә өстәлдә дәрес хәзерли. Зәмзәмия затлы күлмәген кигән дә көзге алдында бизәнә. Нәсим урындыкта утырып тора.

Зәмзәмия. Димәк, син бармыйсың?

Нәсим. Зәмзәмия, аңла, анда барып нишлим?

Зәмзәмия. Егерме елга бер тапкыр театрга чакырдылар, шунда да бармыйсың.

Нәсим. Сиңа ял кирәк. Мин сиңа йөк кенә булам.

Зәмзәмия. Йөк?.. Нәрсә, мин ирсез хатынмыни?!

Нәсим. Чит кеше чакырмады лабаса. Дустыбыз, классташыбыз.

Зәмзәмия. Беренче мәхәббәтең, дип тә өстә.

Нәсим. Яшьлек. Кем кем белән йөрмәгән дә, кем кемне кочмаган.

Зәмзәмия. Спектакльдән соң ул мине ресторанга чакырса?..

Нәсим. Ресторанда да булмаганыңа ярты гасыр.

Зәмзәмия. Рестораннан соң кайтасым килмәсә?..

Нәсим. Унсигез яшь түгел. Үз акылың үзеңдә.

Зәмзәмия. Минем яшьтә дә гашыйк булалар.

Нәсим. Берәүне дә бәйләп тотып булмый.

Зәмзәмия. Бармыйм дисең инде? Үз гомереңдә бер генә тапкыр булса да чит ил машинасына, «джип»ка утырып карар идең.

Нәсим. Миңа хәзер машина кирәкми. Сукырлар таягы да бик җиткән.

Гөлгенә. Әни, мине алып бар?

Зәмзәмия. Дәресеңне хәзерлә. *(Машина кычкырткан тавыш ишетелә.)* Ай-яй, килеп җитте. *(Тәрәзәгә барып кул болгый.)* Кызым, туфлиемне бир әле?

Гөлгенә *(коры гына)*. Үзең алырсың әле. Дәрес хәзерлисем бар.

Нәсим. Кызым, әниеңә булыш.

Зәмзәмия. Кара бу кызыйны!.. Сөт теше коелып бетмәгән, теле авызына сыймый башлаган. Харап булган, әнисе үз гомерендә театрга җыенган икән. *(Туфлиен кия дә бүлмә уртасында бөтерелә.)* Йә, ничек, Нәсимчик?

Нәсим. Әйбәт, әнисе, бик күркәм.

Зәмзәмия. Әй, кемнән сорыйм бит, кемнән сорыйм... Кызым, мин ничегрәк?

Гөлгенә. Мактанырлык түгел. Аякларың нечкә.

Зәмзәмия. Юаны синдә! Ярый, әтисе, пока! *(Барып, Нәсимне үбә.)* Не скучайте. *(Чыгып китә.)*

Нәсим тәрәзә янына бара, саклык белән пәрдәне ачып, урамга карый. Янына кызы килә.

Гөлгенә (*әтисен кочаклап*). Әтием, беренче тапкыр күзләреңдә яшь күрәм.

Нәсим. Юк, юк, кызым, ул яшь түгел.

Гөлгенә. Яшь, яшь, әтием. Күзләреңдә беренче тапкыр яшь күрәм.

Нәсим. Тәрәзәдән сирпелгән яңгыр тамчысы ул, кызым.

Гөлгенә. Көн аяз. Тәрәзәдә яңгыр тамчылары юк. Мин беләм, әйе, әйе, мин беләм. Күз чишмәсе кипмәсә, ул күрә. Сукыр күздә яшь булмый. Иртәме-соңмы син барыбер күрәчәксең!

Музыка. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Гөлгенә бүлмә җыештырып йөри. Нәсим өстәл артында сувенир ясап утыра. Икенче бүлмәдән, киерелә-киерелә, йокысыннан торып Зәмзәмия килеп чыга.

Зәмзәмия. Хәерле көн!

Нәсим. Хәерле көн, Зәмзәмия!

Гөлгенә. Хәерле көндез.

Зәмзәмия. Күпсенмә. Мин атнага бер генә көн кеше төсле йоклыйм. (*Звонок шалтырый. Барып телефон трубкасын ала.*)

Гөлгенә. Саташа башладыңмы әллә?! Ишектә кеше бар! Төне буе театрда йөрсәң, телефон шалтыравын көтә башлыйсың ул.

Нәсим. Кызым, җитте! Күпне белә башладың.

Зәмзәмия. Булса, бар, ишекне ач!

Гөлгенә ишекне ача. Наилә әби килеп керә.

Наилә әби. Әйдә, җыен, Нәсим. Мин сине алырга килдем.

Зәмзәмия. Тукта әле, әнкәй, берәр нәрсә булмагандыр бит?

Наилә әби. Минем белән нәрсә булсын. Менә сездә нәрсә булды?!

Нәсим. Бездә тынычлык.

Наилә әби. Әйдә, җыен, улым, авылга кайтабыз.

Нәсим. Мин беркая да кайтмыйм, әнкәй.

Наилә әби. Кайтасың! Мин әйткәч, кайтасың! Ходай күпме гомер биргәндер, исәнлегем барда, артык кашык булмассың.

Зәмзәмия. Тукта әле, әнкәй, нәрсә булды соң?

Наилә әби. Белми, имеш?! Нәрсә булганын белми. Үзе сорап алган бәхетсезлек түгел. Гариплек сорап килми. Сукыр өстеннән көлеп, ерак китә алмассың. Байлык ул — бер көн-

лек. Чит ил машиналарына утырып йөрмәсәк тә яшәдек әле, бер җиребез дә кимемәде.

Н ә с и м *(ярсып)*. Әнкәй!!!

Н а и л ә  ә б и. Иптәшенең хатынына үрелеп, сукырның таягын сындырып рәхәт күрмәс, ерак китә алмас әле.

З ә м з ә м и я. Менә эш нәрсәдә...

Н ә с и м. Әнкәй!!!

Н а и л ә  ә б и. Нәрсә әнкәй, нәрсә?! Бәхетле булсаң, җиде яшеңнән ятим калып, атасыз үсмәс идең син! Бәхетле булсаң, шушы яшеңнән кеше күзенә карап, кояш нуры күрергә тилмереп яшәмәс идең син! Әйдә, җыен. Мин синсез авылга кайтмыйм.

З ә м з ә м и я. Боларны кем җиткерде инде?

Н а и л ә  ә б и. Сүз иясе белән йөрми. Күршеләрегезгә кадәр аның ничек җәфа чиккәнен белгәннәр инде. Тик торганда кеше бауга менми.

З ә м з ә м и я. Әй күршеләр, күршеләр... Әй Сөләйман абзый... Ярый, нишлисең, Ходай шулай кушкандыр. Мин күрәсен кеше күрмәс. Юлга чыгар алдыннан утырып алыйк. *(Урындыкка барып утыра.)*

Г ө л г е н ә. Мин дә этидән калмыйм.

З ә м з ә м и я. Калмассың, кызым, син дә китәрсең. Инде син дә үсеп буйга җиттең... Бар, соңгы тапкыр әниеңнең үтенечен үтә. Күршеләрне чакыр. Рәмилә апаң да, Сөләйман бабаң да керсен. Бергәләп озатыйк. *(Гөлгенә чыгып китә.)*

Н ә с и м. Мин беркая да китмим! Мин Зәмзәмия яныннан беркая да китмим!

Н а и л ә  ә б и. Сине ул бер тапкыр җирләде инде. Тагын җирләгәнен көтәсеңме?! Хатыннар бетмәгән. Үз тиңеңне табарбыз!

Н ә с и м. Чыгып кит, әнкәй!

Р ә м и л ә килеп керә.

Р ә м и л ә. Нәрсә булды, күршеләр?

З ә м з ә м и я. Рәмилә, сиңа ир кирәкме?

Р ә м и л ә. Нигә алай дисең, күрше?

З ә м з ә м и я. Менә мин сиңа үземнең иремне бирәм.

Р ә м и л ә. Нәсимнеме?! Шәп булыр иде дә, ул синсез өч минут та торалмый шул. Күршеләргә керсәң дә, артыңнан керәп җитә. Юк, Зәмзәмия, аны бәхетсез итәсем килми. Шул ук вакытта сине дә. Миңа кеше пары, кеше яры кирәкми. *(Шигырь укый башлый.)*

Өсләремдә мамык юрган,
Күңелемдә кышның салкыны.
Шул салкынны эретердәй
Үзем кебек ялгыз җан кирәк.

Кичә кич син машинага утырып киткәч, күңелем тулды. Уңга сугылдым, сулга сугылдым, тәрәзә янына бардым. Аска, ишегалдына карасам, боек кына Сөләйман абзый басып тора. Янына төштем. Картның яшьле күзләре сез киткән якта иде. «Мин карт инде. Күп яшисем калмагандыр. Ул бит әле яшь. Аңа әле яшәргә дә яшәргә... Күзләремне бирер идем, мөмкин түгел. Ярдәм итәргә юк чарам. Ә син әле яшь. Ул бала ялгыз калса, зинһар, ташлама аны. Үзең беләсең, анасы карт. Зинһар, ташлама»,— диде дә җылап җибәрде.

Зәмзәмия. Сез минем турыда нәрсә беләсез?! Нигә сез безнең тормышыбызга керәсез? Сезнең нинди хакыгыз бар? Минем йөрәгемдә нәрсәләр ятканын сез каян беләсез?

Гөлгенә килеп керә.

Гөлгенә. Сөләйман бабайны кичә төнлә «скорый» белән больницага алып киткәннәр.

Музыка. Ут сүнә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Нәсим тәрәзәдән карап тора. Телефон шалтырый. Нәсим ашыгып барып телефон трубкасын ала.

Нәсим. Алло, алло... Бу синме?! Сөйлә! Үзем генә. Беләм. *(Әкрен генә сиздермичә кухнядан Гөлгенә чыга да тыңлап тора.)* Бүген мин җавабымны әйтергә тиеш. Кайчан киләсең? Кич?! Юк, хәзер кил! Минем күршем үлгән. Әйе, әйе, күршем Сөләйман абзый, инфарктган. Гаиләм шуны озата. Озаклама, тиз килеп җит. Пока! *(Утыра. Озак кына уйланып торганнан соң.)* Гөлгенә, Гөлгенә кызым, син өйдәме?

Гөлгенә *(ишекне ачып япкан булып)*. Нәрсә булды, әтием?

Нәсим. Бар, кызым, Сөләйман бабаңны озатырга кер. Күрше бабай бит. Сине бакчага йөрткән бабай.

Гөлгенә. Дөрес әйтәсең, әтием. Яхшы, мин керим әле!

Нәсим. Чыгып киткәнче яныма кил әле!

Гөлгенә *(янына килә)*. Нигә, әтием?

Нәсим *(кызын куенына ала)*. Кызым Гөлгенә, бер генәм, син әниеңне яратасыңмы?

Гөлгенә. Яратам, әтием.

Нәсим. Ташламассыңмы аны?

Гөлгенә. Ташламам, әтием.

Нәсим. Дәү әниеңне, минем әниемне яратасыңмы?

Г ө л г е н ә. Яратам, әтием.

Н ә с и м. Син аның янына кайтып йөрерсеңме?

Г ө л г е н ә. Йөрермен, әтием.

Н ә с и м. Рәхмәт, кызым. Мин ышанам сиңа, мин ышанам сиңа, кызым. Ә хәзер бар, Сөләйман бабаңны озат. *(Гөлгенә ашыга-ашыга чыгып китә. Озак кына паузадан соң.)*

Эх, Сөләй, Сөләй, Сөләй,
Эх, Сөләйман балдагы.
Бәхетемне көтәрлек тә
Сабырлыгым калмады.

Әй Сөләйман абзый, Сөләйман абзый, син дә мине ташлап киттең. Буш шешәңә су тутырып керә идең дә, миңа канат куеп чыгып китә идең. *(Тәрәзә янына килә. Пәрдәләрне киң итеп тартып, тәрәзәләрне ача. Ачык тәрәзәдән озак кына карап торганнан соң.)* Яшәргәме, әллә үләргәме?..

И л д у с килеп керә.

И л д у с. Яшәргәме, әллә үләргәме?.. Минем тәкъдимне үтәсәң, яшисең, әлбәттә. Йә, җавабың әзерме? *(Урамга чыга торган ишек әкрен генә яртылаш ачыла.)*

Н ә с и м. Әзер. Бу турыда ялгыш кына да минем гаиләм белергә тиеш түгел.

И л д у с. Зәмзәмияме?!

Н ә с и м. Әйе, Зәмзәмия.

И л д у с. Җүләр син! Ул шатланып риза булачак. Син, син үзең ризамы?

Бүлмәгә З ә м з ә м и я, Н а и л ә  ә б и, Г ө л г е н ә, Р ә м и л ә килеп керәләр.

З ә м з ә м и я *(ярсып)*. Мин риза түгел! *(Нәсимнең күкрәгенә куллары белән сугып.)* Аңлыйсыңмы, мин риза түгел!

И л д у с *(аптырап)*. Аңламыйм?!

З ә м з ә м и я. Кабатлап әйтәм. Мин риза түгел. Мин бары тик Нәсимнеке! Җаным, тәнем, бөтен барлыгым белән бары тик аныкы, Нәсимнеке!

Н ә с и м. Зәмзәмия, син үз акылыңдамы?!

Г ө л г е н ә *(йөгереп барып әнисен кочаклый)*. Әнием!

З ә м з ә м и я. Әй, син, классташ, сиңа нәрсә кирәк?! Беренче мәхәббәтме?!

Н ә с и м. Зәмзәмия!

З ә м з ә м и я. Шушы сукырның гомер иткән хатынымы?

Н ә с и м. Җитте, Зәмзәмия!

З ә м з ә м и я *(Гөлгенәне кочагына алып)*. Шушы сабыйның анасымы?

Н ә с и м. Зәмзәмия, дим, Зәмзәмия, акылыңа кил!

Илдус. Их, Зәмзәмия, Зәмзәмия... Мин бит сине...
Наилә әби. Әй бала, бала... Мин бит сине гомерем буе үз балам кебек күрә идем.
Нәсим. Әнкәй!
Илдус. Мин бит Нәсим бәхете өчен!..
Зәмзәмия. Рәхмәт инде...
Илдус. Синең бәхетең, кызыгыз бәхете өчен!
Наилә әби. Рәхмәт. Мондый ук бәхет көтмәгән идек...
Илдус. Их, сез... Сез мине кемгә саныйсыз?! Мин, мин шушы кешенең — дустымның шушы хәлендә гомер иткән хатынына үреләмме?! Мин, мин шушы баланың анасына үреләмме?! Их, сез... *(Эре-эре атлап чыгып китә.)*
Нәсим. Их, сез... Кешемени сез... Рәнҗеттегез, ай, рәнҗеттегез! Минем иң якын дустымны, дөнья бәясе кешене рәнҗеттегез! Ул бит җан атып, минем өчен машинасын сатып, миңа күз куйдырырга йөргән кеше! Их, сез... *(Арткы планга китә.)*

Калганнар уйга батып катып калалар. Бераз паузадан соң.

Гөлгенә. Мин аны алып кайтам. *(Чыгып йөгерә.)*
Зәмзәмия. Рәмилә, ул ялгыз. Аның барыр җире юк. Бар, зинһар, син дә бар!
Рәмилә. Яхшы. *(Чыгып китә.)*

Бераздан бүлмәгә дипломат күтәреп, кара күзлекле Сәер кеше килеп керә.

Сәер кеше. Мөмкинме?

Зәмзәмия белән Наилә әби аны күреп сискәнеп китәләр.

Нәсим. Ә хәзер икегез дә чыгып китегез! Минем бу кеше белән аерым гына сөйләшәсем килә.
Сәер кеше. Кирәкми, чыкмагыз! Сез барын да белеп, ишетеп торырга тиеш.
Нәсим. Мин сезгә, безне калдырыгыз, дидем түгелме?!
Сәер кеше. Кирәкми! Иртәме-соңмы алар барысын да белергә тиеш. Калыгыз! *(Нәсимгә.)* Мин сөйләшкән срокка килдем. Менә сезгә мин тәкъдим иткән сумма! *(Өстәлгә дипломат куя.)*
Наилә әби. Сезгә нәрсә кирәк?! Минем киленем түгелдер бит?
Сәер кеше. Юк. Минем үз хатыным бар.
Наилә әби. Аллага шөкер! Рәхмәт!
Сәер кеше. Миңа йөрәк кирәк! Сезнең үләргә җыенган улыгызның күкрәгендә типкән йөрәге кирәк!
Зәмзәмия. Аңа йөрәк кирәк. Сәер...

С ә е р к е ш е. Юк, мин сәер түгел. Мин бауга менгән, үзүзенә кул салган кешенең йөрәген сатып алырга килдем.

З ә м з ә м и я. Димәк, маньяк!

С ә е р к е ш е. Ялгышасыз! Мин маньяк түгел. Маньяк кеше гомеренең бәясен белми. Ә мин үләргә җыенган кешенең йөрәген сатып алып, сезне дә, кызыгызны да, үземне дә, гаиләмне дә бәхетле итмәкче булам.

Н а и л ә ә б и. Гафу итегез, мин сезне бәхетле итә алмыйм! Кешегә гомер бер генә бирелә. Шул гомерне санар өчен йөрәк бирелә. Ул гомерне аңа мин, анасы бирдем. Ул йөрәкне аңа мин, анасы бүләк иттем. Бүләк сатылмый! Йөрәк сатылмый!

Музыка.

П ә р д ә

# Узып барышлый

*Моңсу драма ике пәрдәдә, өч күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Ш ә й х у л л а — авыл карты, фронтовик.
Ф л о р и д - Ф р е д.
Ф ә н и я - Ф е н а.
Г а р ә п ш и н — милиция капитаны.
Ф р о л о в — милиция сержанты.
М а р и я  П а в л о в н а — фатир хуҗасы.
Я ш ь  е г е т.
Я ш ь  к ы з.
Х а н ы м.
О л ы  я ш ь т ә г е  и р.
И н т е л л и г е н т  и р.
У р а м  м а л а е — ун-унике яшьләр тирәсендә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кечкенә генә урыс шәһәренең тимер юл вокзалы. Вокзал тәрәзәләрендә төнге караңгылык хөкем сөрә. Бу караңгылыкта каланчадагы прожекторлар, алар яктысында бөтерелгән кар бөртекләре генә балкып-яктырып ала. Ара-тирә дикторның поездларның килүен-китүен хәбәр иткән тавышы ишетелә. Вокзал бинасы эчендә аркалы агач эскәмияләр тезелеп киткән. Кайбер юлчылар, үзләренең чемодан, сумка ише әйберләреннән мендәр ясап, эскәмияләргә бөгәрләнеп яткан. Кайсылары газета укый, кайсылары, эскәмиянең аркасына башларын салып, азапланып булса да, йокымсырап утыра. Янә дикторның тавышы ишетелүгә, кемнәрдер перронга ашыга, алар урынына икенчеләре керә. Кыскасы, вокзал уянып киткәндәй, сулыш алгандай була. Сәхнәнең алгы планындагы сул порталда, шундый ук эскәмияләрнең берсендә аягына чүчинкә, өстенә каракүл якалы пальто кигән, бүрегенең колакларын төшергән бер карт утыра. Ул — Ш ә й х у л л а  к а р т. Башындагы бүреген салып, бүрек эченнән түбәтәен алып кия. Бүрек колакларын артка кайтарып бәйли дә яңадан башына кия. Кыршылып беткән зур агач чемоданын үз янына эскәмиягә яткырып куя. Ике аягы арасындагы төенчеген алдына алып, аның бавын чишә. Янчык эченнән ризыклар чыгарып, чемодан өстенә тезә. Ике кулын йөзенә китереп, бисмилла укый. Шәйхулла карттан ерак түгел, шунда ук, ун-унике яшьләр тирәсендәге йорт-җирсез у р а м  м а л а е буш консерва банкасы тибеп йөри. Елгыр күзләре белән вокзал эчен күзәтә. Шәйхулла картны да күздән югалтмый.

Шәйхулла карт. Бисмиллаһир-рахманир-рахим.

Ашый башлый. Алгы планның уң як порталындагы эскәмиядә 30—35 яшьләр тирәсендәге, уртача гына киенгән, салкыннан бөрешеп үз-үзен кочаклаган Фәния утыра. Күп тә үтми, аның янәшәсенә күн куртка, джинсы, башына спорт башлыгы кигән Флорид килеп утыра.

Флорид. Сукыр тычкан юлга чыкса, тез биеклеге кар ява, дигәнне ишеткәнең бармы синең?

Фәния. Өметле адәмнәр күренмиме?

Флорид. Илдә хәерчелек хөкем сөрә. Атлаган саен, килде-китте юлга чыгалмый. Булыр-булмас — анасын күмәргә дә кайталмый.

Фәния. Бүгенге охота уңышсыз чыгар дип уйлыйсыңмы?

Флорид. Күреп торасың. Җыен ыбыр-чыбыр, әтрәк-әләм, бетле хәерче!

Фәния. Ә син тирә-якны игътибар белән күзәт. Горизонтта яктылык күренә. Объект бар.

Флорид (*як-ягына карана*). Мин юньле бәндә күрмим.

Фәния. Әнә теге, авызындагы ризыгын сулдан уңга, уңнан сулга әвәләп ризык интектереп утырган кәҗә сакалга кара. Ничегрәк?

Флорид. Кайсы?.. Теге бетәшкән картмы?

Фәния. Бетәшкән булса да, Татариядән монда кадәр килеп җиткән әле.

Флорид. Түшенә таккан металлоломыннан башка шымытыры да юк аның.

Фәния. Безнең халык. Татар карты. Башындагы чаплашкасын күрдем.

Флорид. Каешланган чаплашка белән нишләмәкче буласың?

Фәния. Бабаң иртәгә шушы вакытта юлын Смоленскига дәвам итә. Пересадка көтә картлач. Ашаган ризыгын кара. Син төшеңдә дә күрмәгән осетрина балыгы кимерә.

Флорид. Смоленск поезды иртәгә төнге 12 дә генә китә түгелме соң?!

Фәния. Китсә соң. Аның янчыгы калын. Аягында киез итек. Шелләми дә ул. Син утыр, ачка койрык чәнчеп. Өтәләнгән бүре кебек, койрыгы бозга каткан.

Флорид. Ул картның рәте бардыр дип уйлыйсыңмы?

Фәния. Рәте бардырмы, юктырмы — анысын белмим, йоклап карамадым, но, акчасы барына шигем юк.

Флорид. Не знай... Что не знай — то не знай. Бик сомневаюсь!

Фәния. А как думал? Шулкадәр озын юлга чыксын да, сәмәне дә булмасын. Әле бит аның кире дә кайтасы бар. Бе-

ренчедән, үзең күрәсең, сугышта катнашкан. Сугышта катнашканнарның пенсиясе особый.

Ф л о р и д. Акча хәзер өч кешедә. Алыпсатарда, бизнесменнарда һәм, әзме-күпме, менә боларда.

Ф ә н и я. Өченче көнге объект... Ә?

Ф л о р и д. Ул көнне кояш елмайган иде безгә. Бу картка үзеңнең тактикаңны кулланалмассың. Капкан саен, калҗа булмас.

Ф ә н и я. Әгәр бүгенге охота десяткага тисә, төн син уйлаганча булачак.

Ф л о р и д. Тагын теге чебенең алып китәр әле.

Ф ә н и я. Бүген аның дежурствосы түгел, борчылма.

Ф л о р и д. Кайсысының? Алар бит дуңгыз көтүе хәтле.

Ф ә н и я. Кайсысының, кайсысының?! Шул инде — «стиляга»ның дежурствосы түгел, дим.

Ф л о р и д. Анысы яхшы. Кайчан килеп бәйләнер микән дип кенә уйлап утыра идем. Өченче көнге выручкадан аңа әле өлеш бирелмәгән.

Ф ә н и я. Ничек бирелмәгән?! Син бит аның өлешен алып калдың.

Ф л о р и д. Ты, зануда, заткнись! Мин ул синең ментларыңнан зонада да — менә моннан. *(Кулы белән муенына күрсәтеп.)* В гробу не хочу видеть!

Ф ә н и я. Үзеңә кара. Тагын таш капчыкка эләгәсең килсә... Әле дә алар бар.

Ф л о р и д. Ладно! Не базарь! Не учи ученого. Чебен чебен булыр инде. Кирәк тапса, сине дә яшерер.

Ф ә н и я. Минем өчен борчылма. Мин аның үзен итәк астыма яшердем инде.

Ф л о р и д. Аның өчен ул җәннәт түгел. Яшьрәген табар.

Ф ә н и я. Хватит! Йә, нишлибез?!

Ф л о р и д. Нишлибез?! Сине өйрәтәсе юк.

Ф ә н и я. Картлачны кунак итәбез.

Ф л о р и д. Давай, действуй!

Ф ә н и я. Аллага тапшырып башлыйм.

Ф л о р и д. Удачи. Ни пуха, ни пера!

Ф ә н и я. К черту!

Фәния урыныннан тора, тәрәзә янына килә, тәрәзәдән карап торганнан соң, ипләп кенә Шәйхулла карт янына килеп утыра.

Ш ә й х у л л а к а р т *(авызындагы ризыгын чәйнәп бетерә, ике кулын йөзенә китереп, авыз эченнән генә бисмилла укый)*. Аллаһы әкбәр! *(Чемодан өстендәге ризыкларын янчыгына тутыра башлый.)*

Фәния, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, күз төпләрен сөртә.

Ш ә й х у л л а к а р т. Дученка, что случилось? Зачем плачешь?

Ф ә н и я. Әй бабай, шатлыктан елыйм. Улым, бердәнберем армиядән отпускага кайта.

Ш ә й х у л л а к а р т. Сөбханалла. Мөэмин-мөслимә икәнсең. Бик шатлыклы көнең икән, кызым. Бәхете, тәүфыйгы белән сау-сәламәт кайтсын.

Ф ә н и я. Яратам үзебезнең татар картларын.

Ш ә й х у л л а к а р т. Минем мөселманлыгымны каян белдең?

Ф ә н и я. Кыяфәтеңнән, бабай. Безнең татар бабайлары сөйкемле. Үз-үзләрен карап, өс-башларын, сакал-мыекларын гел чиста йөртәләр. Урыс картлары кебек йонга батып йөрмиләр.

Ш ә й х у л л а к а р т. Әй кызым. Төрле чак буладыр инде. Җитешалмаган чаклар да була. Яшең сиксәннең аргы ягына чыккач, бик пөхтә булып булмый икән ул. Тырышкан булам да, булдырып булмый.

Ф ә н и я. Алай димәгез. Бик матур, бик күркәм күренәсез.

Ш ә й х у л л а к а р т. Рәхмәт, кызым, җылы сүзеңә, рәхмәт. Менә бит. Ходай бар ул. Өч суткыга якын поездда килеп, үзебезчә сөйләшергә тәмам гаҗиз булган идем, күрсәң-баксаң, чепчи урыс шәһәрендә мөэмин-мөслимә очратырмын дип һич кенә дә башыма китермәгән идем. Бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына дигәндәй... Исемең ни атлы, кызым?

Ф ә н и я. Фәния исемле мин, бабай.

Ш ә й х у л л а к а р т. Затлы исем. Фәния! Фәния! Фәнгә ия! Гыйлемгә ия. Атаң-анаң исәннәрме?

Ф ә н и я. Әтинең үлгәненә 5 ел була инде.

Ш ә й х у л л а к а р т. Урыны оҗмахта булсын. Авыр туфрагы җиңел булсын.

Ф ә н и я. 57 яшендә дөнья куйды.

Ш ә й х у л л а к а р т. Яшьли киткән, бахыр!

Ф ә н и я. Әни исән.

Ш ә й х у л л а к а р т. Анысы әйбәт икән. Сәламәтме үзе?

Ф ә н и я. Аяклары авырта.

Ш ә й х у л л а к а р т. Язын кырмыска оясына утырып карасын. Иртәнге чыкта яланаяк йөрү дә кайбер сырхауларга килешә. Минем үземнең дә аякларым бик сызлый иде. Сугышта, окопта салкын тидердем. Яз көне ел саен тирескә күмелеп утырам. Аннары яхшылап мунчада чабынам, шул миңа ел буена дәва бирә.

Яннарына Ф л о р и д килә.

Ф л о р и д. Фена, әйдә кайтабыз!

Ш ә й х у л л а к а р т. Фена?.. Кем ди ул сиңа, кызым?

Ф ә н и я. Фена ди, бабай. Бу — минем ирем Флорид. Безнең халыкны әйтәм, татар халкын, гомергә ата-анабыз кушкан

исем белән яши алмадык. Мондагы марҗалар мине Фена, ә иремне Фред дип кенә йөртә.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Урыс халкының телен сындырып булмый. Минем үземне дә сугышта урыс егетләре Шәйхулла дип түгел, үзләренә җайлырак итеп, Шурик дияләр иде. *(Өчесе дә көләләр.)* Хәзер безнең якта исемнәрне җайладылар. Менә минем күршем Солтангәрәйнең олы улы Вил исемле. Владимир Ильич Ленин. Уртанчы улы Джон, кечкенә төпчек улы Робсон. Кызларының берсе Рево, икенчесе Люция. Әле шул Люциянең улы туды. Исем ашына чакырдылар. Револьвер дип куштылар. Әйттем шунда: «Кызларыгыз туса, миндә запас исемнәр бар,— дидем.— Пепельниция, Скумбрия, Внутрия». *(Флорид белән Фәния кычкырып көлеп җибәрәләр.)* Нигә көләсез? Безнең колхоз рәисе Алекс исемле. Прорабыбыз Флүс, конюхыбыз Милс, Милсның улы Филикс. Вәт.

Ф ә н и я. Алдыйсың, бабай!

Ш ә й х у л л а  к а р т. Валлаһи.

Ф л о р и д. Шутник син, бабай.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Һич ялгансыз. Ә сез улыгызга нинди исем куштыгыз?

Ф ә н и я. Обрегин!

Ш ә й х у л л а  к а р т. Анысы тагын нинди мәгънәне аңлата?..

Ф л о р и д. Этем белсен, бабай. Ярамаган бала-чагага, дип кушкан идек...

Ф ә н и я. Үсеп җиткәнен сизми дә калдык. Урыска җиңел булсын дип куштык инде, бабай.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Булдыргансыз, молодец! Урыска гына түгел, чуашка да җайлагансыз бугай.

Ф л о р и д. Әй бабай, кайтсын гына. Хикмәт исемдәмени. Әнә поездлар тоткарлана, ди әле.

Ф ә н и я. Ничек тоткарлана?

Ф л о р и д. Смоленск поезды рельстан төшкән, ди.

Ф ә н и я. Кит аннан, нәрсә сөйлисең?!

Ф л о р и д. Борчылма. Үлем-китем юк, ди. Кайтыр. Иртәгә каршы алырбыз. Шулай бит, бабай?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Шулаен шулай да, ана бала өчен ирләрдән ныграк кайгыра, борчыла шул ул, кем, улым... Флорид.

Ф ә н и я. Вагоннар аумагандыр бит. Ай Аллам, ай Аллам!

Ф л о р и д. Юк инде, аумаган. Борчылма инде, безнең Обрегин утырган поезд түгел ләбаса.

Ф ә н и я. Ну, Фред... Причем безнең Обрегин?! Ул поездда да адәм балалары ич! Кемнеңдер йөрәгеннән өзелеп төшкән... *(Күз яше чыгара.)*

Ф л о р и д. Бигрәк нечкә күңелле инде син, Фена. Кеше өчен җанын бирә инде минем хатын, бабай.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Күренеп тора.

Ф л о р и д *(халыкка)*. Күрсәтер әле ул сиңа! *(Шәйхулла картка.)* Бигрәк күңеленә авыр ала шул. *(Фәниягә.)* Зыянлы түгел, ди. Хатын-кызга сөйләсәң, шул булыр инде. Вокзал хуҗасы Иван Захарович янына кергән идем, борчылма, Флорид Аферистович, барысы да тәртиптә, иртәгә поездлар йөри башлыйлар, Фена Алдаровна белән кайтып тыныч кына ял итегез, диде.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Да... Минем дә башка кайгы салдың әле син, энем. Болай булгач, миңа иртәгә дә көне буе биредә утырырга туры килмәгәе.

Ф ә н и я. Ә сезгә кая кирәк иде?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Нәкъ менә минем поезд рельстан төшкән түгелме соң?

Ф ә н и я. Ярый әле, бабай, үзең шул поездда булмагансың.

Ф л о р и д. Алла сакласын. Хәзер без кара кайгыда булыр идек.

Ф ә н и я. Әле кайчан юлны ачалар, вагоннарны утырталар. Наверно, вам придется долго ждать. Әй бабай, бабай. Шушы яшьтә берьялгызың озын юлга чыгалармы инде?! Балаларың янына барасыңдыр инде?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Юк, кызым. Минем бер улым Казанда, икенчесе Чистайда. Ә үзем авылда яшим. Вәсилий янына барам.

Ф л о р и д. Нинди Василий янына?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Дустым янына. Хат алдым. Хәле бик мөшкел.

Ф ә н и я. Нәрсә булган?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Инфарт бугазыннан алган.

Ф л о р и д. Дус, дип... Яшең сиксәндә килеш, дус, дип, шулкадәр юлга чыгарга инде. Башыңа тай типкәндер. Үзең белән берәр нәрсә булуы бар.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Әй улым Флорид. Дусларның туганнардан да яхшылары була. Дуслар өчен җирнең аръягына да барасың.

Ф л о р и д. Хәзер кайберәүләр аналарын күмәргә дә кайталмыйлар.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Кайтканнар кайта. Минекеләр кайтты. Әниләрен ап-ак кәфенгә төреп, бик зурлап җирләделәр. Ап-ак мәрмәр таш куйдылар. Чардуган да алып кайтканнар иде дә, анысын куйдырмадым. Үземнең куясым килде. Үзем, үз кулларым белән агачтан сандугач оясы кебек ясап, чардуганны үзем куйдым.

Ф ә н и я. Бабай, сандугачның оясы нинди була соң аның?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Күргәнем юк. Сиксәннең аръягына чыгып 90 ны кусам да, күргәнем юк. Алдый алмыйм. Тик шуны беләм: андый асыл кошның оясы да асылдыр. Мин гомер буе авыл халкына тәрәзә өлгеләре, умарта, кияүгә киткән кызларга

сандык, тирә-якка гармун ясадым. Гөлнисамның үләренә ярты ел чамасы кала, шулай ишегалдында тәрәзә өлгеләре җыеп ятам. Яныма Гөлнисам чыкты. Озак кына карап торганнан соң, минем кулларымны үз кулларына алды да: «Шәйхулла,— диде,— мин үлгәч, минем каберемә чардуганны менә шушы кулларың белән, үз кулларың белән яса. Каберем өстенә бал чәчәге утырт. Синең бал кортларың, минем өстәге чәчәкләргә килеп, көн дә синнән миңа сәлам алып килерләр. Мин синең исәнлегеңне белеп, тыныч күңел белән ятармын»,— диде. Шулай эшләдем дә. Малайларга әйттем: «Мин үзем исән чакта анагызга чардуганны үзем куям. Мин үлгәч, анагыз янына мине җирләрсез дә, теләсә нишләрсез. Телисез икән — агачтан, телисез икән — тимердән куярсыз»,— дидем.

Флорид. Анысы шулай. Ара якын булгандыр.

Шәйхулла карт. Хикмәт арада түгел. Хикмәт — бербереңне хөрмәт итүдә. Безнең бабайлар ничек җырлый иде, ә?! *(Җырлый.)*

Ай, әле бик еракта идек без,
Җитмеш чакрым җирне килдек без.
Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

Җитмеш чакрым якын җир түгел,
Бер күрешү — үзе бер гомер.
Ак калфакның табылган чагы,
Туганнарның сагынган чагы.

Фәния. Дөрес, бабай, дөрес! Хәзер юл кыйммәт бит, бабай, юл...

Шәйхулла карт. Юл кыйммәт түгел, кеше гомере кыйммәт. Бер күрешү бик кыйммәт. Без бу дөньяга мәңгегә килмәгән. Узып кына барышыбыз. Кемнәрдер бик тиз уза. Ә кемнәрдер, минем кебекләр, озак атлый. Китеп баручылар белән хушлашып, саубуллашып калырга кирәк, балалар.

Флорид. Шулай бик дуслар идегезмени?

Шәйхулла карт. Васылий беләнме?

Фәния. Әйе.

Шәйхулла карт. Аерылмас! Дөнья бәясе кеше. Кеше генә түгел, әүлия иде ул зәңгәр күзле, сары чәчле урыс малае. Дүрт ел бергә салкын окопларда яттык. Бер кисәк сохарине икегә бүлеп ашадык. Бер шинельне икебезгә ябындык. Ә бүген ул, килеп, миңа хыянәт итмәкче була. Үлем түшәгенә менеп яткан. Оятсыз! Молокосос! Миннән 3 ай да 7 көнгә яшь, мине ташлап китеп бармакчы була.

Флорид. Кем аңа шундый право биргән диген?!

Шәйхулла карт. Сөйлисе юк! Сугышта кургаш алалмады, ачлык алалмады, окоп салкыннары алалмады. Ә бүген,

күрсәң-баксаң, үлем түшәгенә менеп яткан. Әй Вәсилий, Вәсилий, оятсыз!

Фәния. Дөньяда кемнәр генә юк.

Флорид. Сөйлисе юк. *(Халыкка.)* Диваналар җитәрлек!

Фәния. Патриот! *(Халыкка.)* Диваналарны чәчеп үстерміләр!

Флорид. Да, бабай. Бер күрешү — үзе бер гомер, дисең инде.

Шәйхулла карт. Шулай димен, улым. Без бу җирдән ашап-эчеп китәргә түгел, ә тирә-юньгә бәхет, шатлык чәчеп китәргә тиешбез.

Флорид. Әйдә булмаса, җыен, бабай. Безнең өйгә дә бәхет, шатлык сибеп кит.

Фәния. Без шатлыкка бик мохтаҗ!

Флорид *(халыкка)*. Демагог!

Шәйхулла карт. Рәхмәт, балалар. Мин сезгә әллә ни шатлык вәгъдә италмыйм мәшәкатьтән башка.

Фәния. Алай димә, бабай.

Флорид. Каян беләсең?

Фәния. Бәлки, шундый бәхетле итәрсең...

Флорид. Үзең дә белми калырсың.

Шәйхулла карт. Бирсен Ходай.

Фәния. Ходайдан әллә ни көтеп булмый.

Флорид. Менә син безгә барсаң, без бик бәхетле булыр идек.

Шәйхулла карт. Юк, юк, мәшәкать ясыйсым килми.

Флорид. Нинди мәшәкать?!

Фәния. Мәшәкатьтә бәрәкәт, бабай.

Шәйхулла карт. Менә монысы хак, кызым.

Флорид. Шуны үзең белә торып, карышма, бабай.

Шәйхулла карт. Тамагым тук, өс-башым калын, бераз гына менә шушында черем итеп алырмын. Таң атыр да, кич булыр.

Флорид. Үз халкыңны, үз татарыңны авыр хәлдә калдыру ярамас. Әйдә, бабай, кайткач, бераз «чиртербез» дә, җылыныр өчен.

Шәйхулла карт. Юк, Флорид улым. Ул «чиртү» дигәннәр онытылды инде. Адымнар салмаклангач, иңсәләр төшкәч, теге дөньясына да ышана башлыйсың икән ул.

Фәния. Ул дөнья бардыр дип уйлыйсыңмы, бабай?

Шәйхулла карт. Анысын тәгаен генә әйтә алмыйм. Элек бик ышанып бетми идем. Яшь кире якка киткән саен уйландыра. Адәм баласы гомер буе өмет белән яши бит ул. Бу якты дөньяның читенә килеп җиткәч, теге дөньяга өметләнә башлыйсың. Намазын да укыйсың, догаларын да өйрәнәсең.

Фәния. Бигрәк әйбәт. Урыс шәһәрендә яшәп, өебезгә дога кергәне юк. Дога укырсың.

Шәйхулла карт. Мөэмин-мөселман затын догадан калдыру гөнаһ санала үзе. Сезнең сүзгә күнәрмен, ахрысы.
Флорид. Яхшы гына итеп хәер дә бирербез.
Фәния. Әле синең акча мәсьәләсе дә әлле-мәлледер?
Шәйхулла карт. Акчага аптыраган юк. Аллага шөкер. Хөкүмәтебезне сүксәк тә, без пенсионерларны онытып бетерми. Ә безне, сугыш ветераннарын, инвалидларын — бигрәк тә. Меңнән артык пенсия түләп тора. Минем итем, бәрәңгем, җиләк-җимеш, яшелчәм үземнеке. 25 баш умартам бар. Колхуз икмәген дә бирә. Шулай булгач, ялгыз башыма минем пенсиям менә моннан җитә. *(Кулы белән муенына күрсәтеп.)*
Фәния. Прекрасно, бабай!
Флорид. Нәкъ безнең кеше икәнсең.
Фәния. Җыен, бабай. Киттек безгә.
Шәйхулла карт. Әллә бармыйм микән?
Флорид. Юкны сөйләмә.
Шәйхулла карт. Әллә мәшәкать ясамыйм микән?
Фәния. Булмаганны сөйләмә.
Шәйхулла карт. Ярый, сезгә каршы торып булмас. Үз халкым, үз татарым. Йортыгызга дога укырмын.

Флорид Шәйхулла картның капчыгын аркасына аса да кулына чемоданын ала.

Флорид. Әйдә, Шәйхулла абзый.
Шәйхулла карт. Әй Ходаем, кодрәтең киң.
Флорид. Киң, киң, бабай.
Шәйхулла карт. Рәхмәтлемендер үзеңә. Нинди генә юньле бәндәләр юлдаш итмисең.
Фәния. Сөйлисе юк.
Шәйхулла карт. Рәхмәт, балалар.
Флорид. Рәхмәтеңне соңыннан әйтерсең, бабай.
Шәйхулла карт. Соңыннан да әйтермен, Алла боерса. Аллага шөкер, дөнья киң, дөнья матур.
Фәния. Дөрес, бабай, Аллага шөкер, дөнья киң! Тар булса, нишләр идек, шулай бит, бабай?
Шәйхулла карт. Дөрес сөйлисең, кызым.
Флорид. Безгә бик кыен булыр иде.
Шәйхулла карт. Кая гына барма, үз халкың, үз татарың колач җәеп каршы ала.
Фәния. Дөрес, бабай.
Шәйхулла карт. Кая гына барма, якты йөз, якты күңел...
Флорид. Совершенно верно, так точно, бабай, деньги давай! Әйдә кузгалыйк.
Шәйхулла карт. Ерак торасызмы, балалар?

Ф л о р и д. Турыдан сәгать ярым, әйләнгечтән 90 минут. Кайсысын сайлыйсың, бабай?

Ш ә й х у л л а  к а р т. Сәгатьләп йөрмәбез, вакыт соң инде. Шул минутлысы ярар.

Ф л о р и д. Минут икән — минут! Алга, җиңү яуларга!

Музыка. Өчесе дә чыгып китәләр. Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, начар гына җиһазландырылган бер бүлмәле фатирның өй эче. Ишектән Ф л о р и д, Ш ә й х у л л а  к а р т һәм Ф ә н и я керәләр.

Ф ә н и я. Әйдә, бабай, чишенеп түргә уз.

Ш ә й х у л л а  к а р т *(өс-башын сала-сала)*. Рәхмәт, кызым.

Ф л о р и д. Үз өеңдәге кебек бул.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Рәхмәт, Флорид улым.

Ф ә н и я. Без бик иркен яшәмибез инде. Бар булганыбыз шушы.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Бар булганына шөкер кылып яшәгез. Тән сихәтеннән аермасын Ходай. Сәламәтлек — зур байлык. Хәзер бит адәм баласы фатирын үзе өчен алмый, өендәге шкафлары өчен ала. Йөри шулар арасында абынып-төртелеп. Гомеренең узганын сизми дә кала. Ә сезнең иркен, клуб кебек. Рәхәтләнеп йөрисең.

Ф л о р и д. Вакытында акча бирмиләр. Менә җиде ай инде акча күргән юк.

Ф ә н и я *(халыкка)*. Эшләмәгәч, кем бирсен!

Ш ә й х у л л а  к а р т. Ул мәсьәләдә дөнья буталыбрак китте шул. Җайланыр әле.

Ф ә н и я. Әй Аллам, аш та салмаган идем. Мондый зур кунак киләсен белгән булсам...

Ф л о р и д *(халыкка)*. Кәлҗемә бәлеше пешергән булыр идеңме?! *(Шәйхулла картка)*. Минем әтәй карт белән әнкәй үз йортлары белән биредә яшиләр. Малайны, Обрегинны, бик көтәләр. Ә ул һаман кайтмый. *(Халыкка.)* Тау-таш арасында җәнлек аулап йөри. *(Шәйхулла картка.)* «Оныкны туп-туры үзебезгә алып кайтыгыз, мунча ягып, гөбәдия пешереп көтәбез» дигәч...

Ф ә н и я. Шулай шул. Аларга ышанып, бүген базарга да чыкмадым. Обрегин белән бергәләп, әбиләреннән кайтканда, базарга керербез, аның яраткан ризыкларын алырбыз дип уйладым.

Ф л о р и д. Берәү әйткән ди бит: «Эх, ботка пешерер идем, тозы белән маен күршедән дә алыр идем, ярмасы юк»,— дип.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Борчылмагыз. Төнлә белән кем ашый. Мин үзем вокзалда да капкалаган идем.

Ф ә н и я. Хәзер чәй куям. (*Икенче бүлмәгә чыгып китә.*)

Ф л о р и д (*өстәлгә аракы чыгарып куя*). Фена, ике стакан чыгар әле! Шәйхулла абзый, әйдә булмаса, танышу хөрмәтенә берәрне тотабыз. (*Бүлмәгә, өч стакан тотып, Фәния чыга.*)

Ш ә й х у л л а  к а р т. Әй улым Флорид, минем исемемә бабай сүзе өстәлде шул. Шәйхулла гына булсам, әле бер хәл. Үзең туксанны ку, намазлык өстендә утыр... Язмаганны.

Ф л о р и д (*стаканнарга аракы сала-сала*). Аракы кан тарата, бабай. Тәмәке тарткан, аракы эчкән егетләрне чибәр-чибәр кызлар ярата.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Яратыр... Бездә күпләр шул аракы аркасында яраткан балаларыннан да колак кактылар инде. Авыл булып авыл җирендә.

Ф ә н и я. Фред, миңа да сал. Бабай, мин булып мин дә сезнең хөрмәткә салам. (*Стаканны Шәйхулла картка суза.*) Әйдә инде, Шәйхулла абзый.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Кыстамагыз. Булмый, балалар. Әле намаз да укыйсым бар.

Ф л о р и д. Ярый алайса. Әйттем исә кайттым.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Сез үзегезгә карагыз. Сез әле яшьләр. Ә мин юынып, тәһарәт яңартып алыйм.

Ф л о р и д. Мин үзем дә бу нәрсә белән дус түгел. Ә Фена турында сөйлисе дә юк. (*Халыкка.*) Әллә сизенә инде картлач. (*Шәйхулла картка.*) Әйдә, ванна бүлмәсен күрсәтәм.

Икенче якка чыгып китәләр. Бераздан Ф л о р и д әйләнеп керә.

Ф л о р и д. Фена, Фена, кил әле?!

Ф ә н и я (*пышылдап*). Нәрсә?

Ф л о р и д. Хитрый карт. Сизенә бугай. Аракы белән алып булмады.

Ф ә н и я. Үзебезгә калыр.

Ф л о р и д (*пышылдап*). Молодец! Син бу картны яхшы кармакка эләктердең.

Ф ә н и я (*пышылдап*). Хәзер барысы да синнән тора. Жилканы ныклап тот, өзеп качмасын.

Ф л о р и д. Беләм. Только кармакка наживканы ныклап сапла. Наживканы йоткач, селкенерлеге калмасын. Үзенә йокы даруын 5-6 ны җибәр. Зуррак кружкага яса, тәмен сизмәсен.

Ф ә н и я. Өйрәтмә. Беренче тапкыр түгел. Бу юлы наварның 70 %ы минеке.

Ф л о р и д (*Фәниянең бугазыннан эләктереп ала*). Замолчи, стерва! Әле наварыңны күргән юк.

Бүлмәгә Ш ә й х у л л а  к а р т килеп чыга.

Ф ә н и я (*аны күреп*). Нишлисең инде, Флорид? Бигрәк сабырсыз инде үзең. Йә инде, йә. Бабай бар дип тормыйсың.

Гафу ит инде, Шәйхулла бабай. Кич җитсә, аза шушы Флорид, нишләгәнен белми башлый.

Шәйхулла карт *(игътибар итмәгәнгә сабышып)*. Шәһәр фатирының шул ягын яратмыйм. Бәдрәфен яратмыйм. Бәдрәфе эчтә. Рәхәтләнеп, авылдагыча тышка чыгасы түгел. Чистайдагы малайларга баргач та азапланам. Килен кухняда пешеренеп йөри. Ә син шуның янында, кәгазь калынлыгы ишек артында йомыш йомышлап утырасың. Өлкән малайларда рәхәт. Ерак түгел генә урман бар.

Флорид. Авылда берьялгызың яшисеңме?

Шәйхулла карт. Җәмәгатем, Гөлнисамның дөнья куйганына сигез ел тулып, тугызынчы елына китте. Шуннан бирле берьялгызым.

Фәния. Ә нигә малайларың үз яннарына алмыйлар?

Шәйхулла карт. Син, Фәния сеңлем, үзең бик акыллы кешегә охшагансың. Син дә эч пошырып утырма әле. Малайларның теңкәгә тиюләре җитмәгән, өстәвенә — син. Сигез ел бәгъремне игәүлиләр инде.

Фәния. Юк, үзеңә генә яшәү авырдыр дип уйлаганнан әйтүем генә.

Шәйхулла карт. Ничек ташлап китим? Туган җирем бит ул минем. Туган җиремдә җан биреп, туган җиремдә туфрак булырга тиеш мин.

Флорид. Хак, бабай. Менә, Фена, үзең әткәй белән әнкәйне күпме чакырасың, киләләрме соң?

Фәния. Трактор белән дә сөйрәп китереп булмый. Ярый, мин чәйнекне карыйм әле. *(Чыгып китә.)*

Флорид. Монда килеп бер кич тә кунганнары юк. Менә шушы квартирага ремонт ясарга да ирек бирмиләр. «Нигә ул сиңа шәһәр фатиры? Бирегез аптырап, сусап йөргән берәр бәндәгә»,— диләр. Әткәй әйтә: «Минем йорт — синең йорт, минем нигез — синең нигез», — ди.

Шәйхулла карт. Күрәм: атаң-анаң акыллы кешеләр.

Флорид. Сөйлисе юк инде, бабай. *(Халыкка.)* Үзләрен күрү бәхетенә генә ирешкәнем юк!

Шәйхулла карт. Гөлнисам, атам-анам, бабамнар шунда җирләнгән. Печән чапкан болыннарым, Гөлнисам белән җиләк җыйган аланнарым... Чишмә суы эчеп кенә яшәдем мин. Шуңа да, 83 кә җитеп, бүлнис койкасы күрмәдем. Сугыштан ранен булып кайтуыма карамастан.

Бүлмәгә, чәйнек күтәреп, Фәния килеп керә.

Фәния. Утырышыгыз. Хәзер чәй ясыйм.

Шәйхулла карт. Вәсилийне күпме чакырдым. «Кайт минем янга, ятма шул болгавыр шәһәреңдә...» дидем. Юк, тың-

ламады. Ә менә хәзер бирешкән. Минем янга кайткан булса, 100 не тутыра иде әле ул.

Флорид. Таза идеме?

Шәйхулла карт. Типсә, тимер өзәрлек иде. Әй Василий, Вәсилий...

Фәния (*чәй ясый-ясый*). Ул Василийның гаиләсе бармы соң?

Шәйхулла карт. Юк. Бәхетсез булды Вәсилий. Сугыштан кайтып, соң гына өйләнде. Улы туды. (*Кулъяулыгын чыгарып, яшьле күзен сөртә.*) Көннәрдән бер көнне Марфаны да, улы Серужаны да югалтты. Суга төшеп югалгандай югалдылар.

Фәния. Ничек?

Шәйхулла карт. Марфа, биш яшьлек Серужаны ияртеп, кибеткә чыгып киткән җиреннән бүтән әйләнеп кайтмады. Икесе дә машина астына эләгеп харап булдылар.

Флорид. Башка өйләнмәдеме? (*Елаган була.*)

Шәйхулла карт. Юк, яшьли ялгыз-тол калса да, бүтәнгә күз салмады.

Фәния. Әйдә, чәйдән җитеш, Шәйхулла абзый. Чәй суына.

Шәйхулла карт. Туктагыз әле, минем күчтәнәчләрем бар иде ләбаса. Кая әле минем капчык белән сандыгым. (*Ишек бусагасы янындагы капчыгы белән чемоданын өстәл кырыена алып килә.*)

Флорид. Кирәкмәс иде инде.

Шәйхулла карт. Кирәкмәснең күзе юк, ди, улым Флорид. (*Капчыгын чишеп, каклаган каз чыгара.*) Менә монысы каклаган каз.

Флорид. Фена, видишь, копченый гусь!

Шәйхулла карт. Кәпчуный түгел, каклаган каз.

Фәния (*әйберләрдән күзен ала алмыйча, үзе дә сизмәстән ике кулы белән казга үрелгән хәлдә*). Кирәкмәс иде инде, бабай.

Шәйхулла карт. Бик кирәк, кызым.

Флорид. Ә дустыңа... Василий бабайга каламы соң?!

Шәйхулла карт. Вәсилийгә мин табармын. Без аның белән сохари кимерергә ярата идек. Бер телем икмәкне урталай сындырып капса, аягына торып баса әле ул. (*Чемоданны ачып, банка белән бал чыгара.*) Менә монысы үз умартамнан бал.

Фәния. Кирәкмәс инде, бабай.

Шәйхулла карт. Кирәген карап торма, авыз итүеңне бел. Монда җитәрлек ул. Ә менә монысы үзебезнең татар чәкчәге. Чәкчәкне күрше Мөслимәгә пешерттем. Аның кулы тәмле. Шулай берчак фронтка әнкәй белән әткәйдән миңа посылка килде. Чәкчәк салганнар. Посылканы ачкач, урыс малайла-

ры хәйран калды. Әй, туйганчы яратып ашадылар. Кайберләренә икешәр бөртек эләкте.

Фәния. Яртысын кисәм, бабай?

Шәйхулла карт. Шулай эшлә, кызым. Яртысын Вәсилийгә тыгам. Хикмәте бар аның.

Фәния (*яртысын кисә дә, Шәйхулла картка суза*). Тыгып куй, бабай.

Шәйхулла карт. Рәхмәт, кызым. Сөйләп бетерим әле. Шуннан посылкадагы, чәкчәктән авыз иткәч, ике бармагына чәкчәк бөртеге күтәреп, Вәсилий минем янга килде дә... (*Шәйхулла карт өстәлдәге чәкчәктән бер бөртек чәкчәк кубарып ала да, ике бармагы белән халыкка күрсәтеп, Василий булып.*) «Шайгулла, это фрукт или орех? Как ты назвал? Чак...» Мин кычкырып көлдем, «чәкчәк» минәйтәм. «Да, да,— ди.— Чакчак! Какой дерево растет это самый чакчак?» Ә мин әйтәм: «Такая дерево у нас у татаров түлке растет. Бульше нигде». «Кончется война,— гәвәрит, — приеду тебе в гости. Сарву твою чакчак и поем дасыта»,— ди. Килалмады. Күпме чакырдым — килалмады. Агачтан чәкчәк өзалмады Вәсилий.

Флорид. Чемоданыңны алып куй, Шәйхулла абзый.

Шәйхулла карт. Бу — чумадан түгел, бу — хикмәтле сандык, Флорид улым. Үзем, үз кулларым белән ясадым. Спициально Вәсилий янына барырга.

Фәния. Йә, йә, күрсәт әле, нинди хикмәте бар?

Флорид. У любопытной Варвары нос оторвали.

Шәйхулла карт. Күрсәтәм. (*Чемоданны ача да чүпрәккә төрелгән хромка гармун чыгара. Чүпрәген сүтә. Кулына ала.*) Менә ни өчен ясадым мин бу сандыкны. Вәсилий гармуны бу. Фронтовой гармун. Дүрт ел безнең белән фронттан фронтка, окоптан окопка йөрде ул. Җиңү алып килгән инвалид гармун бу! Дүрт раненИесе генә бар. Менә монда ике тишек, менә монда бер тишек, ә дүртенчесе менә шушы җирдә иде. (*Кулы белән гармунның тишекләрен күрсәтә.*) Шул тишекләргә, портянканы кисеп, чүпрәк тутыра идек тә, сызып уйнап җибәрә идек...

Флорид. Гаҗәп...

Шәйхулла карт. Гаҗәпме?! Тагын бер гаҗәеп әйбер күрсәтәм. (*Чемоданыннан укалап чигелгән түбәтәй чыгара.*) Ә менә бу укалы түбәтәйне үзем, үз кулларым белән чиктем. Хатын-кыз кулы кермәде. Вәсилийгә! Шәпме?!

Флорид. Урыс түбәтәй кими бит.

Шәйхулла карт. Ә Вәсилий кия! Түбәтәйне кырын салып, хромкада сыздырып уйнап җибәрә әле ул.

Шәйхулла карт түбәтәен үз башына кырын сала да гармунның каешларын кия башлый.

Флорид (*халыкка*). Саташкан бу тиле карт!

Шәйхулла карт. *(Сыздырып уйнап җырлап җибәрә.)*

Теплый ветер дует, развезло дороги,
И на Южном фронте оттепель опять.
Тает снег в Ростове, тает в Таганроге,
Эти дни когда-нибудь мы будем вспоминать.

Об огнях-пожарищах,
О друзьях-товарищах
Где-нибудь, когда-нибудь мы будем говорить.
Вспомню я пехоту,
И родную роту,
И тебя — за то, что ты дал мне закурить.
Давай закурим, товарищ, по одной,
Давай закурим, товарищ мой!

Нас опять Одесса встретит как хозяев,
Звезды Черноморья будут нам сиять,
Славную Каховку, город Николаев,
Эти дни когда-нибудь мы будем вспоминать.

А когда не станет горя и в помине
И к своим любимым мы придем опять,
Вспомним, как на Запад шли по Украине,
Эти дни когда-нибудь мы будем вспоминать.

Фәния *(Шәйхулла карт җырлап бетергәч)*. Ну тавыш синдә, бабай!..

Шәйхулла карт. Минем авылдагы кушаматым — Сандугач Шәйхулласы. Ә менә Вәсилий җырласа... *(Башын селкеп тора.)* Тау-таш селкенә иде.

Флорид. Шәп сылый иде, да?!

Шәйхулла карт. Ничек кенә әле. Иң кызыгы: ул миңа урыс җырларын өйрәтә иде. Менә, ягъни мәсәлән, «Землянка»-ны... ул миңа өйрәтте. *(Җырлап җибәрә.)*

Бьется в тесной печурке огонь,
На поленьях смола, как слеза.
И поет мне в землянке гармонь
Про улыбку твою и глаза.

Про тебя мне шептали кусты
В белоснежных полях под Москвой.
Я хочу, чтобы слышала ты,
Как тоскует мой голос живой.

Ты сейчас далеко, далеко,
Между нами снега и снега...
До тебя мне дойти не легко,
А до смерти — четыре шага.

Пой, гармоника, вьюге назло,
Заплутавшее счастье зови.
Мне в холодной землянке тепло
От моей негасимой любви.

Ә мин аңа «Тәфтиләү»не, «Иске карурман»ны, «Баламишкин» көйләрен өйрәттем.

Фәния. Карале, Шәйхулла бабай, безгә дә үзебезнең халыкның берәр җырын тыңлат инде.

Шәйхулла карт. Була ул. Кайсысын? «Тәфтиләү»неме? «Карурман»нымы? Әллә «Арча көе»нме? Бәлки, «Уел»ныдыр?! Юк, мин сезгә күңел күтәрә торганны җырлыйм. «Баламишкин»ны! *(Уйнап җырлап җибәрә.)*

Әй дусларым, дусларым ла,
Дусларым дус-ишләрем.
Сез дуслардан аерылгач,
Ялгыз башым нишләрмен?

Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
Алмагач чәчәге кебек
Минем дус-ишләрем дә.

Фәния. Ну, бабай. Яшь чакта кызлар хут бирмәгәндер сиңа.

Шәйхулла карт. Андый чаклар да бар иде. Элек бит клублар юк иде. Аулак өйгә җыела идек. Минем урын түрдә иде. Таңга кадәр яшьләрне биетә идем. Ә менә син үзең бии беләсеңме?

Фәния. Юк. Татарча бии белмим.

Шәйхулла карт. Белмисез шул. Гаҗәп түгел. Хәзер авыл кызлары да татарча бии белмиләр. Бер урынга басалар да, магнитафун акыртып, бизгәк тоткан сарык кебек... Менә болайрак... *(Гәүдәсе белән бер урында селкенеп тора.)* Холодец кебек селкенәләр. Кара, без яшь чакта кызларны ничек биетә идек.

Шәйхулла карт торып баса да уң аягын урындыкка куя. Сыздырып бию көе уйнап җибәрә. Бию көенә Фәния бии башлый. Аңа Флорид кушыла.

Флорид *(халыкка)*. Эшне боза, карт тәре!

Фәния *(Флоридка)*. Бөтен шәһәрне уята бу тиле карт.

Шәйхулла карт. Әй яшь чаклар, яшь чаклар. Кесә тулы борчаклар! *(Гармун тавышына магнитофон тавышы килеп кушыла, Шәйхулла карт, гармунын өстәлгә куеп, биеп җибәрә.)* Эх-ма, әйттер дөньясын! *(Биеп туктагач.)* Рәт беткән. Булдырып булмый хәзер. Ә менә Василий «Тәфтиләү»не аеруча яратып уйный иде. Ул уйный иде, мин, читкә

китеп, туган җиремне, дус-ишне, туганнарымны, Гөлнисамны сагынып җылый идем. Ә сез берәр татар җыры беләсезме?

Фәния. Конечно, беләбез.

Шәйхулла карт. Ниндине?

Фәния. Ниндине?! «Ай былбылым»ны...

Шәйхулла карт. Ну-ка.

Флорид. Жалко, гитара юк. Бар әле, Фена, кастрюль алып чык.

Фәния икенче бүлмәгә кереп китә һәм кастрюль төбенә сугып уйный һәм җырлый башлый.

Фәния. Ай былбылым, вай былбылым,

Аңа Флорид һәм гармун белән Шәйхулла карт кушыла.

Шәйхулла карт, Фәния, Флорид *(өчесе бергә).*

Агыйделдә таң ата.
Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата.
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Елата да җырлата.
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Елата да юата.

Шәйхулла карт. Таба төбенә сугып җырларга калгач, милләт үлеп бара дигән сүз. Башта исемнәр китә, аннары моң, тел юкка чыга. Милләт сүнә, югала. Ә бит безнең халык нинди генә уен коралларында уйнамаган. *(Түш кесәсеннән кубыз чыгара да, халыкка күрсәтеп.)* Кечкенә генә ике бармак зурлыгындагы шушы тимер кисәге гөрләп торган туйларны биеткән, җырлаткан. *(Кубызны иреннәренә китерә дә «Әпипә»не уйнап җибәрә. Уйнап бетергәч.)* Урманга кергәч, үсеп утырган кураны кисеп алган да шуның белән халыкның үткәнен, киләчәген уйнап биргән.

Флорид. Шәйхулла бабай, таңнар ата, өзелә үзәк дигәндәй, таң сызылып килә. Әйдә әле, чәеңә үрел. Чәең суына. Үз күчтәнәчеңә дә өлгер.

Шәйхулла карт. Үз күчтәнәчен ашаган кеше озын гомерле булыр, ди. Рәхмәт, балалар, рәхмәт! Барысына да өлгерәм. *(Чәй эчә.)*

Флорид. Фена, бабайга тагын чәй яса. Теге, кунаклар өчен ясый торган чәеңне жәлләмә.

Фәния . Фред, җитәр. Кирәкмәс. Йокласын бабай.

Флорид. Яса, диләр сиңа! Биеп, җырлап тамак туймый. Яса, диләр! Кунак чәе яса.

Фәния. Кая, бабай, чәеңне яңартып кертим.

Шәйхулла карт. Бик кыен булса да, берәрне яса инде,

кызым. Картайган саен, карт кешенең эче яна икән ул. Авылда да гел чәй эчеп кенә торам. Мөслимә күрше көн дә кәҗә сөте кертә. Сөтләп, мәтрүшкәләп, юкә балы белән чәй эчәм дә сызгырып кына йөрим. *(Фәния чыгып китә.)*

Фәния *(чәй ясап алып керә дә бабайның алдына куя)*. Суытмагыз, эчегез.

Флорид. Карт кешегә кайнар чәй эчәргә ярамый. Салкын кирәк. *(Калак белән Шәйхулланың чәен болгата.)* Син кунак чәе ясадыңмы?

Фәния. Кунак чәе булмыйча. *(Шәйхулла картка.)* Безнең чишмә суы түгел инде.

Флорид. Авызга алып булмаган чаклар була. Бүген дә хлор тутырганнар.

Шәйхулла карт. Ара-тирә анысы да кирәктер. Эчкә дезинфекция ясарга.

Флорид *(халыкка)*. Ашыкма, картлач. Күп көтәсең калмады. *(Шәйхулла картка.)* Озын юлга чыгуын чыккансың да, дустың көтсә ярый инде.

Шәйхулла карт. Көтми кая барсын. Көтәр! Мин бит аңа телеграмм суктым. Көтми карасын... Сөйләсәң — сүз, төртсәң — күз дигәндәй, сөйлим әле. Күптәннән бушанганым юк.

Флорид *(Фәния колагына пышылдап)*. Сөйли белмәгән телдән нәрсә яхшырак, диләр әле?

Шәйхулла карт. Ә, төрле якта төрлечә әйтәләр аны, кем, энем Флорид. Безнең якта болайрак дип сөйлиләр. Бер юлчы аты белән авыл капкасыннан килеп кергән дә кое янына килеп туктаган, ди. Коеның чиләге юк икән. Кое янындагы йортның капка төбендә бер хатын басып тора икән. Юлчы сорый: «Чиләк биреп тормассызмы, атымны эчертәсем бар иде»,— дип. Теге хатын: «Бирәм, атыгызны эчерткәч, үзегез дә безгә кереп чәй эчеп чыгыгыз»,— дигән. «Рәхмәт, атымны кая бәйлим соң?» — дип сораган юлчы. Теге хатын әйтте ди: «Менә тик тормаган телемә бәйләрсез».

Флорид. Менә мин дә шул хатын хәлендә инде, бабай. Сине гел шул сүз белән генә сыйлыйм.

Шәйхулла карт. Ярый. Үземнең дә арыган сиздерә башлады. Шулай, бер бәрелештән соң, бик каты яраланганмын. Аңымны югалтканмын. Аңыма килгәндә, носилкада ятам. Баш очымда Вәсилий утыра. Үзе елмая, үзенең күзеннән яшь тама. «Шайгулла,— ди бу миңа.— Жить будем, чакчак срывать будем! Гармошка сыграем. «Тафтилау» споем.— Вәсилий үзенең хромкасын үз шинеленә төрде дә минем баш очыма носилкага куйды.— Вот, друг мой, брат мой дорогой, тебе на память наш третий фронтовой друг Храмков. Он инвалид. Пусть у тебя живет»,— диде дә миңа капланып елады. Без аерылыштык һәм бер-беребез белән бүтән очрашмадык. Ул миңа килә ал-

мады, мин — аңа. Хат алышудан узалмадык. Ә мин бу дустыбызны лечить иттем. Яңа күрек ясадым. Үз кулларым белән. Менә ул бүген туган җиренә, үз хуҗасы янына кайтып бара. Авыр чакларда ул миңа рух өрде, мине аякка бастырды. Кайгылы чакларымда кайгымны уртаклашты. Хәзер ул үз хуҗасын аякка бастырыр.

Ф л о р и д. Дөрес сөйлисең, бабай. Уйнасын Василий бабай. Яшьлегенә кире кайтсын.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Моң кайтара ул. Моң ул бәгырьләргә үтеп керә. Мин беттем, балалар. Күз кабагымны күтәрә алмыйм. Таш бастырганнармыни. Өстәл артында йокыга китәм.

Ф л о р и д. Фена, тиз бул, урын җәй.

Ф ә н и я *(урын җәя)*. Менә бирегә ятыгыз, бабай.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Миңа идәндә дә ярый иде инде. Үзегез кая ятасыз соң?

Ф ә н и я. Безнең өчен борчылма. Табарбыз.

Ф л о р и д. Менә чемоданың белән капчыгыңны баш очыңарак куям.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Әй карт тиле, карт тиле... Коръән укырмын дигән идем бит.

Ф ә н и я. Борчылма, бабай, иртә белән укырсың.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Рәнҗемәгез инде. Рәт калмады. Иртәгә бәхилләтермен үзегезне. Мин ятыйм инде.

Ф л о р и д. Фена, чыгып тор. Бабай чишенә.

Ф ә н и я. Ярый. *(Чыгып китә.)*

Ф л о р и д. Ятыгыз, Шәйхулла бабай. Тыныч йокы, тәмле төш.

Шәйхулла карт, чалбарын салып, ап-ак кальсоннан йокларга ята. Бераздан гырылдап йокыга китә.

Ф ә н и я *(керә. Пышылдап)*. Нәрсә, нәвем базарына киттеме?

Ф л о р и д *(пышылдап)*. Китте. Бабаң бүрәнә тарттыра.

Ф ә н и я. Китми кая барсын, 6 таблетка димедрол эчкәч. Отравиться итеп үлмәс бит?

Ф л о р и д. Дед саф һавада чишмә суыннан мәтрүшкәле чәй эчеп кенә яшәгән. Пычак та булмас.

Ф ә н и я. Нишлибез?!

Ф л о р и д. Тормози! Ныклап тирән йокыга китсен.

Ф ә н и я. Бар, чемоданын алып кил.

Ф л о р и д. Нигә?

Ф ә н и я. Акчасын карыйбыз.

Ф л о р и д. Дура! Акчасын фанера сандыкта йөртергә ул бит ул кадәр дивана түгел. Бар, проверь! Чынлап йоклыймы?

Ф ә н и я *(Шәйхулла карт янына килә, селкетә)*. Бабай, бабай, гырлыйсың. Борылып ят. *(Флоридка.)* Готов! Труба! Тере покойник!

Ф л о р и д. Отлично!

Ф ә н и я. Чемоданын алып килимме?

Ф л о р и д. Не дергайся, дура! Акча чемоданда түгел!

Ф ә н и я. Кайда соң?

Ф л о р и д. Гомер эчендә бер тапкыр озын юлга чыккан авыл кешесе акчасын үзеннән ерак йөртми ул.

Ф ә н и я *(Шәйхулла картның чалбар кесәсен актара башлый. Флоридка)*. Нәрсә карап каттың? Бар, пальто кесәсен обшарь.

Ф л о р и д. Акчалар анда түгел. Азапланма, мескен! Бар, лезвие алып чык.

Ф ә н и я. Не надо! Не надо, Фред! Только аны эшләмә!

Ф л о р и д. Безмозглый баран! Ул болай да покойныйдан хуже. Тере мәет! Сыртыңа күтәреп алып чыгып китсәң дә уянмый. Менә хәзер аягыннан болгап балконнан ыргытам, уянмый. Бар, ваннада лезвие күрдем, шуны алып чык.

Фәния йөгереп чыга да лезвие алып керә.

Ф ә н и я. Мә лезвия!

Ф л о р и д *(Шәйхулла карт янына килә)*. Әй Шәйхулла абзый, гырлыйсың. Әйләнеп ят әле, гырлыйсың. Җайлап ят әле. *(Селкеткән булып, трусик тирәсен капшый.)* Точно — ялгышмаганмын! Капитал здесь! Мин аны биегәндә үк капшап чыктым инде. Мә, кальсонын күтәреп тор. Мин кискәндә, лезвие тәненә тимәсен.

Ф ә н и я *(Шәйхулла бабайның кальсонын күтәреп, тартып тора)*. Ну и жулик!

Ф л о р и д. Бөтен авыллары белән җыелып, Шәйхулла картның трусигына кесә теккәннәрен төшемдә күргән идем.

Ф ә н и я. Тиз бул, кис!

Ф л о р и д *(кесәне кисә дә халыкка күрсәтә)*. Вот удалили. Плохого опухоля удалили. Бабай җиңеләеп китте. *(Кесәдән 100әр сумлык акчаларын тартып чыгара.)* Да... Операция удалась нормально!

Ф ә н и я. Гонорар большой. Кая, бир миңа акчаларны.

Ф л о р и д. Акырма! Үз өеңдә түгел. Күрәсең, минем кулда лезвие! Муеныңа бер генә сызармын. Бабаң белән бергә каласың. Да, жирный кусок. Монда берничә мең бар.

Ф ә н и я. Бир миңа, бир!

Ф л о р и д. Акырма, дим, дура! Уятасың. Хәзер чыгып таябыз. Чыккач бүләрбез.

Ф ә н и я. Мин сиңа ышанмыйм. Син аның яртысын яшереп калдырасың.

Ф л о р и д. Телисеңме, хәзер шушы акчаларны синең бөтен тишек-тошыгыңа тутырам. *(Фәнияне стенага терәп куя да бугазына лезвие тери.)* Хочешь!

Ф ә н и я. Фред, не надо!

Ф л о р и д. Не надо так не надо! Замолчи. Үз өлешеңне алырсың, вакыты җиткәч.

Ф ә н и я. 70 % минеке. Объектны мин таптым.

Ф л о р и д *(йодрык күрсәтеп)*. Менә моны күрәсеңме?! Менә бу түбәңә менеп төшкәч, 70 % синеке булыр. Покага сиңа 30 җитәр.

Ф ә н и я. Ну ладно. Чукынып кат! Кара аны, өченче көнге кебек алдасаң!..

Ф л о р и д. Тиз бул, җыен. Таярга кирәк.

Ф ә н и я. Кая?

Ф л о р и д. Кая, кая! Бүтән шәһәргә. Хәзер беренче очраган поездга билет алабыз да бу шәһәрдән үкчәне күтәрәбез. Озакламый бу шәһәрдә безгә шлагбаум куялар.

Ф ә н и я. Безнең монда крыша бар.

Ф л о р и д. Стилягамы? Таптың крыша. Чебеннең кайчан ышанычлы булганы бар. Күп ашаттык инде.

Шәйхулла картның пальто кесәсеннән документлар тартып чыгара.

Ф ә н и я. Анда да акчасы юкмы?

Ф л о р и д. Бар. Безгә юлга җитә.

Ф ә н и я. Документларын калдырыйк.

Ф л о р и д. Болары да акча аның. Мә, яшер! *(Өстәлдәге аракыны ала да Шәйхулла картның әйберләренә сибә. Кесәсеннән акча чыгарып өстәлгә куя.)* Менә сиңа ун сум, картлач. Мы не жадные. Иртәгә столовойга керерсең. Киттек.

Икесе дә чыгып китәләр. Музыка. Ут сүнә.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ут янганда, яңа көн туган. Ш ә й х у л л а  к а р т йокысыннан уяна. Киерелә.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Озак йоклаганмын. Яктырып беткән. Бисмиллаһир-рахманир-рахим. Хәерле иртә, балалар! *(Үз-үзенә.)* Йоклыйлар, ахры. Йокласыннар. Тәһарәтемне яңартыйм да йортларына иминлек теләп, дога кылыйм. *(Тора да ваннага кереп китә. Озак тормыйча, кире бүлмәгә чыга. Идәнгә намазлык урынына чүпрәк җәеп, кыйблага карап баса. Укый. Үз-үзенә.)* Ата-бабаларының исемнәрен сорап каласы булган. Ярар, Ходайга тапшырып башлыйм. *(Бер иелә, бер баса укыганнан соң.)* Әй Ходаем, ярабби, шушы нигездә яшәүче Миңлефлорид һәм Миңлефәнияне үз ярдәмеңнән ташлама. Амин! Аларны һәрьяклап дәүләтле ит. Амин! Эшләгән эшләрен, кылган гамәлләрен тормышка ашырып, бу якты дөньядан киткәч тә, оҗмах ишекләреңне ачып, түреңнән урын бирсәң иде. Амин!

Ерак җирләрдә солдат хезмәтендә йөргән Миңлефлорид һәм Миңлефәниянең уртак никах белән туган бердәнбер уллары Миңле... *(Үз-үзенә.)* Миңле кем соң әле? Ә... Обрегинны усал күзләрдән сакласаң иде. Шушы ике баланың дөньялыктан киткән ата-бабаларын, ир туганнарын, кыз туганнарын үз ярдәмеңнән ташламасаң иде. Барлык укыган догаларны аларга да җиткерсәң иде. Амин! Ахыр заман көннәрендә һәрбарчабызга тел ачкычлары биреп, тәмуг күперләрен кичкән чакта, ярдәмеңнән ташламасаң иде. Ярабби бер Ходаем. *(Намазын үзалдына пышылдап укый.)* Амин! *(Тора да чүпрәген җыеп, урындык башына элә. Үрелеп кенә кухняга карый. Алгы планга килә.)* Болар өйдә юк лабаса. Минем өчен борчылып, базарга йә булмаса кибеткә киттеләр микән? *(Куллары белән кальсоныының арткы кесәсен капшап карый. Куллары кальсон тишегенә кереп китә.)* Әстәгъфирулла! Нинди җил өрә дисәм... *(Әйләнеп, кесәсен карый. Тишек кальсонын күреп.)* Кискәннәр!.. *(Халыкка карап, үз-үзенә ашыкмыйча гына.)* Шәйхулла туган, кесәңне кискәннәр!.. Валлаһи, кискәннәр! *(Кычкырып җибәрә.)* Талаганнар! *(Сәхнә буйлап йөгереп йөри башлый.)* Коткарыгыз! Коткарыгыз! *(Йөгереп ишек төбенә бара, ишекне ачмакчы була. Ишек ачылмагач, ике кулы белән ишекне дөбердәтә башлый.)* Коткарыгыз! Ярдәм итегез! Таладылар!.. Люди, на помощь! *(Йөгереп керә дә идәндә аунап яткан пальтосының кесәләрен карый башлый. Бернәрсә дә тапмагач, пальтосын идәннән өстерәп, сәхнә уртасына, алгы планга килә. Идәнгә тезләнә. Ике кулын югарыга күтәреп.)* Ярабби бер Ходаем. Хараплар гына булдым. Кая барыйм? Кемнән ярдәм сорыйм? *(Идәнгә йөзе белән капланып үкси-үкси елый.)*

Музыка. Ут сүнә.

Ут янганда, шул ук бүлмәдә өстәл артында милиция сержанты Ф р о л о в, аның янында тишек кальсоннан Ш ә й х у л л а к а р т утыра.

Ф р о л о в. Фамилия?

Ш ә й х у л л а к а р т. Ә?

Ф р о л о в. Фамилия как?

Ш ә й х у л л а к а р т. Фәхрисламов.

Ф р о л о в. Имя?

Ш ә й х у л л а к а р т. Шәйхулла.

Ф р о л о в. Как, как?

Ш ә й х у л л а к а р т. Шәй-хул-ла.

Ф р о л о в. Не понял!

Ш ә й х у л л а к а р т. По-нашему, по-татарски — Шәйхулла. А по-вашему, по-салдатскому — Шурик.

Ф р о л о в. Не понял. Как это Шурик?..

Ишектән милиция капитаны Г а р ә п ш и н белән фатир хуҗасы М а р и я П а в л о в н а керә. Фролов торып баса, Гарәпшинга честь бирә. Гарәпшин Фролов белән кул биреп күрешә.

Гарәпшин. Что случилось?

Фролов. Пока ничего не ясно, товарищ капитан. Даже свое имя не знает.

Шәйхулла карт. Как так мин үземнең исемемне белмим. Как так я свое имә не знаю. Шәйхулла я!

Гарәпшин Фролов утырган урындыкка утыра.

Гарәпшин. Имя как?!

Фролов. Он говорит — Шурик.

Гарәпшин. Ладно, разберемся. Фамилия как?

Шәйхулла карт. Минекеме? Мая фамилия?..

Гарәпшин. Да, да, синеке!

Шәйхулла карт *(үз-үзенә)*. Әстәгъфирулла. Колакларым дөрес ишетәме... Шәйхулла мин. Шәйхулла Фәхрисламов.

Фролов. Как сюда попали?

Шәйхулла карт. Как, как! Дверьдән!

Фролов. Знаем, что не через окно!

Шәйхулла карт *(Фроловка)*. Туктале син. *(Гарәпшинга якынрак утырып.)* Мин, улым, фронтавик Фәхрисламов Шәйхулла булам. Орден-медальләремне күрсәтимме? Әнә тегендә чөйдә кәчтүмем эленеп тора. Орден-медальләргә тимәгәннәр.

Гарәпшин. Не надо! Кирәкми.

Шәйхулла карт. Ә син үзең кем атлы буласың?

Гарәпшин. Сорауны монда мин бирәм.

Шәйхулла карт. Бир, бир, улым. Берне түгел, меңне бир.

Гарәпшин. Каян монда килеп чыктыгыз?

Шәйхулла карт. Каян, дип... Татариядән, Тау ягыннан.

Гарәпшин. Бирегә каян килеп эләктегез, дим?

Шәйхулла карт. Ничек бирегә?

Гарәпшин. Бу квартирага!

Шәйхулла карт. Төнге 12 ләр тирәсендә. Коръән укырга.

Гарәпшин. Гражданка Мария...

Мария Павловна. Павловна. Мария Павловна.

Гарәпшин. Гражданка Мария Павловна, вы этого гражданина знаете?

Мария Павловна. Первый раз вижу.

Шәйхулла карт. Мин дә бу хатынны беренче тапкыр күрәм.

Гарәпшин. Слышишь, Фролов? Я спрашиваю: «Как вы в эту квартиру попали?» Он мне отвечает, что в 12-ом часу пришел читать молитву.

Фролов. Артист.

Шәйхулла карт. Я не артист. Я уже давно не работаю. Я фронтовик, я пенсионер!

Гарəпшин. Юк. Сез ничек бу квартирага эләктегез? Бикле ишектән ничек кердегез?

Шәйхулла карт. Ишек бикле түгел иде.

Гарәпшин. Гражданка! Скажите, пожалуйста, дверь была заперта?

Мария Павловна. Конечно, заперта была.

Гарәпшин. А он говорит, дверь не заперта была.

Мария Павловна (*Шәйхулла картның өстенә килә*). Как не заперта была? Алкоголик несчастный! Что ты говоришь, сволочь!

Гарәпшин. Спокойно, спокойно, гражданка Мария Павловна.

Мария Павловна. Вот у меня ключи, вот! (*Өстәлгә ачкычлар ыргыта.*)

Шәйхулла карт. Ну и что? У твоего сына и твоей снахи тоже ключи есть. Товорищ, иптәш милиционер. Сорагыз аңардан, ул үз йорты белән яшиме? Әллә...

Гарәпшин. Вопросларны мин бирәм, гражданин.

Мария Павловна. Какой сын, какая сноха?!

Шәйхулла карт. Твой сын Флорид — жулик! Вот меня обокрал. Видишь? (*Торып басып, тишек кальсонны күрсәтә.*) Твоя снаха, как еще завут... А, Фәния. Вот они со мной делали. Чучила делали.

Мария Павловна. Нет у меня ни сына, ни снохи. У меня никого нет. Я одна.

Гарәпшин. Вы давно дома не были, гражданка Мария Павловна?

Мария Павловна. Вы же сами меня сегодня из больницы забрали. Уже 3 недели на больничной койке.

Гарәпшин. Вы свои запасные ключи где-нибудь оставляли?

Мария Павловна. Нет. Иногда соседям оставляла.

Гарәпшин. Фролов, ты соседями не интересовался?

Фролов. Да, товарищ капитан. Сосед, тот самый дважды судимый Хромов Виталий Алексеевич, с матерью живет.

Гарәпшин. Ясно. Гражданка, вы ключи в какой квартире оставляли?

Мария Павловна. В 68-ой квартире.

Фролов. Та самая квартира.

Гарәпшин. Понятно.

Шәйхулла карт. Алдый. Малае бар, килене бар, оныгы да бар. Малае белән киленен төрмәгә утыртмас өчен алдый.

Гарәпшин. Подождите. Бабай, яхшылап аңлат әле.

Шәйхулла карт (*елап җибәрә*). Татар башың белән маржа сүзенә ышанып, фронтовик Шәйхулла бабаңны мыскыл итеп утырасың.

Гарәпшин. Гражданин! Безнең эштә татар, урыс юк. Кем ул Флорид?

Шәйхулла карт. Обрегинның әтисе.

Гарәпшин. Обрегин кем?

Шәйхулла карт. Фәниянең улы.

Гарәпшин. Фәниясе кем?

Шәйхулла карт. Флоридның хатыны, хәләл җефете.

Гарәпшин. Ничего не понимаю. Юньләп кенә аңлат әле, гражданин Фәхрисламов?!

Шәйхулла карт. Аңлаттым бит инде. Менә шул мине талаган Фред, Фред кына булып чыкмады, фриц булып чыкты. *(Торып баса.)* Менә минем, кесәмне кисеп, 3 меңнән артык акчамны алып качты.

Гарәпшин. Гражданин, сез миңа подробно, ипләп кенә аңлатыгыз. Кем ул Флорид?

Шәйхулла карт. Менә шушы хатынның жулик, бандит малае. Фенаның ире.

Гарәпшин. Фенасы кем?

Шәйхулла карт. Менә шушы хатынның килене. Фредның хатыны.

Гарәпшин. Ничего не понимаю. Бернәрсә дә аңламыйм.

Шәйхулла карт. Аңламыйсың шул. Безнең авылның ат караучы Зәкәрнең диваналар мәктәбендә укый торган малаена аңлатсам, ул да аңлаган булыр иде инде.

Гарәпшин. Гражданин! *(Шап итеп өстәлгә йодрыгы белән суга.)* Не оскорблять! Нигә, алар дүртәү идемени?

Шәйхулла карт. Кемнәр?

Гарәпшин. Флоридлар!

Шәйхулла карт. Этем белсен. Минем белән икәү генә иделәр. Бәлки, икесе урамда калгандыр.

Гарәпшин. Син аларның дүртесен дә күрмәдеңмени?!

Шәйхулла карт. Юк, күрмәдем. Икесен генә күрдем. Фред белән Фенасын гына күрдем.

Гарәпшин. Ә үзең, Флорид талады, дисең.

Шәйхулла карт. Әлбәттә, Флорид белән Фәния кесәмне кистеләр. Алардан башка кем киссен?!

Гарәпшин. Бу ханымның ничә малае бар соң?

Шәйхулла карт. Ике малае бар.

Гарәпшин. Берсе Фред, икенчесе Флорид.

Шәйхулла карт. Нишләп инде, Фред шул Флорид бит инде ул.

Гарәпшин. Нишләп соң ике улы бар, дисең?

Шәйхулла карт. Ике улы булгач, бер генә улы бар, дип әйтиммени? Әйтәләр иде аны, милициядә акны кара дип әйттерәләр, дип.

Гарәпшин. Син, в конце да концов, юньләп аңлатасыңмы,

юкмы, әллә уйларга вакыт биримме? Берәр атна изоляторда яткырсам, тиз аңлатырсың! Бу гражданканың ничә малае бар?

Шәйхулла карт. Ничә малае бар дип әйтим соң?

Гарәпшин. Дөресен әйт!

Шәйхулла карт. Дөресен әйтсәм, сүгәсең бит. Ике малае бар.

Гарәпшин. Берсе?

Шәйхулла карт. Берсе — Фред... Әй, Флорид. Икенчесе — Обрегин.

Гарәпшин. Хәзер сиңа соңгы сорауны бирәм. Әгәр юньләп аңлатмасаң, илтеп ябам.

Шәйхулла карт. Менә бу марҗаның Флорид исемле улы бар. Флоридның солдат хезмәтендә Обрегин дигән малае бар. Соң бу марҗаның ничә малае була соң?

Гарәпшин. Ике малае була. Ә Фред?

Шәйхулла карт. Фред — урысча. Ә Флорид, белмим, кемнеңчәдер. Только татарча түгел.

Гарәпшин. Тагын бутый.

Шәйхулла карт. Бу марҗаның ике малае бар. Берсе — Фред, икенчесе — Обрегин.

Гарәпшин. Фред шул ук Флорид булып чыга, шулаймы?

Шәйхулла карт. Әлбәттә, шулай.

Гарәпшин. Аңлашылды. Димәк, бу ханымның ике малае бар. Берсе — Флорид, ягъни Фред, икенчесе — Обрегин.

Шәйхулла карт. Әлбәттә.

Гарәпшин. Хәзер шуны әйт. Фәния кайсысының хатыны?

Шәйхулла карт. Фәния Флоридның хатыны.

Гарәпшин. Фена — Обрегинның хатыны, шулаймы?

Шәйхулла карт. Юк. Фена да Флоридның хатыны.

Гарәпшин. Нәрсә, ул берьюлы ике хатын белән яшимени?

Шәйхулла карт. Юк. Фена да, Фәния дә Обрегинның әниләре бит инде.

Гарәпшин. Тагын бутый.

Шәйхулла карт. Бутамыйм.

Гарәпшин. Фәния шул Фена диген инде, надан!

Шәйхулла карт. Миңа сезнең кебек уку эләкмәде шул.

Гарәпшин. Гражданка, вам знакомо имя Флорид по кличке Фред?

Мария Павловна. Нет.

Гарәпшин. Гражданка, вам знакомо имя Фания по кличке Фена?

Мария Павловна. Нет. Я никакого Флорида, Фреда, Фанию, Феню не знаю.

Шәйхулла карт. Знает, знает. Белә, белә. Обманывает. Алдый. Алар миңа, әти белән әни дә шушы шәһәрдә үз йортлары белән яши, диделәр.

Гарәпшин. Мария Павловна, у вас муж есть?

Мария Павловна. Нет.

Шәйхулла карт. Кичә генә мунча ягып йөргән ире төн чыкканчы үлгәнмени?!

Гарәпшин. Бутама әле. Нинди мунча?

Шәйхулла карт. Бу марҗаның мунчасы.

Гарәпшин. Син аларга бардыңмыни?

Шәйхулла карт. Юк, бармадым.

Гарәпшин. Бармагач, нинди мунча турында сөйлисең?

Шәйхулла карт. Обрегин өчен ягылган мунчаны сөйлим.

Гарәпшин. Саташма, гражданин. Сине алдаганнар. Бернинди дә Обрегин юк.

Шәйхулла карт. Димәк, мине ике кеше түгел, 4 кеше талаган булып чыкты инде, шулай бит, энем милиционер?

Гарәпшин. Юк, сине 6 кеше талаган булып чыга.

Шәйхулла карт. Целый банда диген, ә?

Гарәпшин. Сезнең нинди документларыгыз бар?

Шәйхулла карт. Бернинди дә документларым юк.

Гарәпшин. Документларыгыз кая?

Шәйхулла карт. Пальто кесәсеннән суктылар. (*Торып баса да, тишек кесәсенә сугып.*) Хәтта сукыр бер тиен дә калдырмаганнар. Кис-кән-нәр! Поезд билетымны да калдырмаганнар.

Гарәпшин. Билетыгыз кая кадәр иде?

Шәйхулла карт. Смоленскига кадәр иде.

Гарәпшин. Гражданин Фәхрисламов, Смоленск поезды, бары тик ярты сәгатькә соңарып, сәгать икедә китте бит.

Шәйхулла карт. Китмәде шул. Вагоннар рельстан чыкты.

Гарәпшин. Күпме акчаң бар иде?

Шәйхулла карт. Трусик кесәсендә 3 мең 700 сум акчам бар иде. Пальто эчендәгесен төгәл генә әйтә алмыйм.

Гарәпшин. Сине бу квартирага кемнәр алып кайтты инде?

Шәйхулла карт. Менә шушы марҗаның улы белән килене.

Гарәпшин. Флорид белән Фәния, шулаймы?

Шәйхулла карт. Шулай.

Гарәпшин. Алар вокзалда нишләп йөриләр иде?

Шәйхулла карт. Армиядән Обрегин дигән уллары отпускага кайтырга тиеш булган, шуны каршы алырга дип килгәннәр. Шулар миңа, Смоленск поезды бүген килми, рельстан төшкән, иртәгә генә килә, әйдә безгә кайтабыз, дип, көчләп диярлек, үзләренә алып кайтып киттеләр.

Гарәпшин. Вакыт күпме иде?

Шәйхулла карт. Сәгатем юк. Точно әйтә алмыйм. Шул, чама белән уникеләр тирәсе булгандыр.

Гарәпшин. Фролов, здесь афера. Его обманули. Двое. Мужчина и женщина.
Фролов. Гражданин, сколько им лет?
Шәйхулла карт. Нәрсә ди, ишетмәдем?
Гарәпшин. Аларга чама белән ничә яшьләр тирәсе?
Шәйхулла карт. Иренә 35–40 яшьләр тирәсе, хатыны яшьрәк. Утызлар тирәсе булыр.
Гарәпшин. Мужчине 35–40, а женщине около тридцати.
Фролов. Гражданин, как они были одеты?
Шәйхулла карт. Ире, мужы зәңгәр, зеленый...
Гарәпшин. Зәңгәрме, әллә зеленыймы?
Шәйхулла карт. Нет, не зеленый. Зәңгәр, синий чалбар. Куртка чорный. Ә башындагы шапкасы спортсменнарский. Ә хатыны...
Гарәпшин. Әгәр рәсемнәрен, карточкаларын күрсәтсәк, таныйсыңмы?
Шәйхулла карт. Төне буе җырлап утыр да, шуларны таныма. Мичкә керсәләр, арт саннарыннан таныйм.
Гарәпшин. Җырлап та утырдыгызмы?
Шәйхулла карт. Җырлап кына ди сиңа! Биедек тә.
Гарәпшин. Ничә бутылка аракы эчтегез?!
Шәйхулла карт. Син нәрсә, энем. Минем 20 ел авызыма аракы алганым юк.
Гарәпшин. Бабай, башыңны тотып карале?!
Шәйхулла карт. Нигә?
Гарәпшин. Беренче очраган, күрмәгән-белмәгән кешеләр белән күбрәк җырлап-биеп йөрсәң, кесәңне генә түгел, башыңны да кисеп китәрләр. Ул Флорид та, Фред та түгел, алар мошенниклар, бандит, жуликлар. Ярый әле үзеңне суймаганнар. *(Фроловка.)* Товарищ Фролов, помоги, пожалуйста, вещи положить на стол. Проверим, что там есть.
Фролов. Хорошо. *(Фролов өстәлгә капчыкны куя. Гарәпшин яза.)*
Гарәпшин. Гражданин Фахрисламов, мешок, капчык твой, синекеме?
Шәйхулла карт. Да, да, минеке.
Фролов *(капчыктан буш шешә чыгара)*. Пустая бутылка. Московского производства, выпуска 24-ого числа этого месяца. Недавно только употребляли.
Шәйхулла карт. Минеке түгел. Не мое.
Фролов. Гражданин, у вас не спрашивают!
Шәйхулла карт. Чәйдән башка берни дә эчмим.
Фролов. Отпечатки возьмем, товарищ капитан?
Гарәпшин. Брось! Убийства нет. Зачем лишние хлопоты?
Фролов *(капчыктан төенчек чыгара, сүтә)*. Больше ничего. Закуски и все.

Гарәпшин. Гражданка Мария Павловна, в мешке есть ваши вещи?

Мария Павловна. Нет.

Гарәпшин. Вот здесь подпишитесь! (*Мария Павловна кул куя.*)

Фролов (*капчыкны тутыра да идәнгә куя. Чемоданны өстәлгә куеп ача*). Товарищ капитан, пишите. Какая-то сладость.

Гарәпшин. Да, татарская национальная сладость.

Фролов. Банка литровая, с капроновой крышкой. (*Капкачын ачып исни, бармагын тидереп, теленә китерә.*) Вроде бы мед.

Гарәпшин. Мед натуральный.

Фролов (*каз чыгара*). Мясо птичье, половинка, копченое.

Гарәпшин. Каклаган каз. Күптән ашаган юк.

Фролов (*түбәтәй тартып чыгара*). Чаплашка!

Гарәпшин. Сержант Фролов, не чаплашка, а тюбетейка!

Фролов. Гармошка. Не знаю какая марка. Вроде бы баян.

Шәйхулла карт. Не баян, а хромка!

Гарәпшин. Гармонь двухрядная. (*Яза.*) Хромка — тульская. Гражданка Мария Павловна, ваши вещи есть в чемодане?

Мария Павловна. Есть. Гармошка моя.

Шәйхулла карт. Что?! Какой синеке?

Мария Павловна. Не верьте. Гармошка моего покойного мужа Ивана.

Шәйхулла карт. Гармун минеке. Сез рәхәт яшәсен дип, 4 ел буе фронттан фронтка, окоптан окопка йөреп, туңган солдатларны биетеп җылытучы, яраланганнарга гомер бирүче, хәлсезләнгән сугышчыларга көч бирүче, илгә, сезгә җиңү алып килүче гармун бу. Ышанмыйсызмы?! (*Торып баса да халыкка «Землянка» ны үзе уйнап, үзе җырлап җибәрә.*)

Бьется в тесной печурке огонь,
На поленьях смола, как слеза.
И поет мне в землянке гармонь
Про улыбку твою и глаза...

Җыр бетүгә, Мария Павловна әкрен генә тора да озак кына сагышлы итеп халыкка карап торганнан соң.

Мария Павловна. Нет. В чемодане у меня ничего нет. У меня дома все на месте.

Гарәпшин. Гражданка, если у вас дома все нормально, все на месте, вот здесь распишитесь. «У меня дома все на месте, никаких претензий не имею». Число, год и подпись.

Мария Павловна яза һәм кулын куя.

Мария Павловна. Мне очень трудно и стыдно. Изви-

ните, пожилой человек. Что-то сердце... Я же своего мужа на фронте потеряла. Разрешите мне свежим воздухом подышать.

Г а р ә п ш и н. Фролов, проводи гражданку.

Ф р о л о в. Слушаюсь!

Мария Павловна белән Фролов чыгып китәләр.

Ш ә й х у л л а  к а р т *(озак кына гармунына карап торганнан соң)*. Эх, дустым, дустым, Храмков. Карт бер ханымның йөрәгенә тимер ярчык булып кадалдың, ә яшьләр йөрәгенә үтеп керә алмадың. *(Салмак адымнар белән өстәл янындагы урындыкка килеп утыра да тезенә гармунын куя. Карашын еракка ташлый.)*

Г а р ә п ш и н. Бабай, бәхетеңә, миңа килеп каптың. Мин булмасам, сине ябалар иде.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Нәрсә өчен? Дүрт ел сугышып, илемне саклаган өченме?! Нәрсә өчен? Сез яхшы яшәсен дип, күкрәгемә өч пуля алган өченме?! Нәрсә өчен? Сез тук булсын дип, 40 ел икмәк үстергән өченме?!

Г а р ә п ш и н. Юк, квартира, фатир баскан өчен!

Ш ә й х у л л а  к а р т. Мин квартира бастым?..

Г а р ә п ш и н. Әйе, син төнлә белән фатир бастың.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Мин түгел! Алар!

Г а р ә п ш и н. Кемнәр алар? Фред, Флоридлармы, әллә Фена, Фәнияләрме, бәлки, Тоня, Тәнзиләләрдер... Эзлә син аларны?! Син, син хәзергесе минутта бу фатирда басып торасың. Сиңа җавап бирергә туры киләчәк иде. Бәхетеңә, миңа килеп каптың. Кулыңны куй. Һәм тиз арада бу шәһәрдән үкчәләреңне күтәр. Милләт буяп йөрмә.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Юк, куймыйм. Башта акчамны, документларымны табып бирегез!

Г а р ә п ш и н. Яхшы, гражданин Фәхрисламов. Мин сине кулга алырга тиеш булам. *(Өстәлгә наручник чыгарып сала.)* Следствие ачылганчы, сез изоляторда 2—3 ай ятарга тиеш буласыз. Йә булмаса менә шушында кулыгызны куясыз да, дүрт ягыгыз кыйбла.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Кадалып кына китегез.

Кул куя. Музыка. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, вокзал стенасына сөялеп, ап-ак сакалга баткан, бетәшкән Ш ә й х у л л а  к а р т басып тора. Идәндә гармуны, кулында орден-медальләре тагылган костюмы. У р а м  м а л а е алдына кепкасын салып, идәнгә тезләнгән дә хәер сораша. Янынннан үтеп барган я ш ь  е г е т к ә ялвара.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Сынук, минем орден-медальләремне алмассыңмы? Бер атна ашаганым юк.

Я ш ь  е г е т. Ты что, дед? Я же не металлист! *(Узып китә.)*

Ш ә й х у л л а  к а р т *(үз-үзенә)*. Нәрсә ди, мин металлист түгел, диме? *(Янынннан узып барган яшь кызны туктата.)* Доченька, купи мои ордена-медали. Дорого не прошу. Ал инде, кыйммәт сорамыйм.

Я ш ь  к ы з. Ты что, дед? Ордена — не серьги, на уши не повесишь! *(Китеп бара.)*

Ш ә й х у л л а  к а р т. Алкам юк шул, кызым. *(Урта яшьтәге бер ханымны туктата.)* Җаным, сеңлем, сатып ал минем орден-медальләремне. Женщина, пожалуйста, очень прошу, купи мои награды. Кыйммәт сорамыйм. Дорого не прошу.

Х а н ы м. Балаларыма икмәк алырга акчам юк, синең тимер-томырларың гына кирәк иде. *(Китеп бара.)*

Ш ә й х у л л а  к а р т. Минем дә атна буе авызыма ипи валчыгы капканым юк. *(Олы яшьтәге бер ирне туктата.)* Товарищ, может купишь мои награды?

О л ы  я ш ь т ә г е  и р. Извини, товарищ. Я сам свои цыганам продал. *(Китеп бара.)*

Ш ә й х у л л а  к а р т *(үз-үзенә)*. Чегәннәргә саттым, диме? *(Олы яшьтәге ир киткән якка карап кычкыра.)* Әй, товарищ, где они, цыгане? *(Теге кешенең китеп барганына үртәлеп.)* «Чегәннәр кайда?» дип сорыйм мин синнән. *(Бик яхшы киенгән 50 яшьләр тирәсендәге интеллигент бер ирне туктата.)* Товарищ, ты серьезный человек. Помоги старику. Купи мои ордена-медали. Дорого не прошу.

И н т е л л и г е н т  и р. Бабай, кемгә кирәк синең бу наградаларың?! Син аларны театрга илт. Бездә урыс театры бар. Бәлки, алар алыр.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Үзең татар да икәнсең. Бу шәһәрдә дүртенче татарны очратам. Булыш татар абзаңа.

И н т е л л и г е н т  и р. Гафу итегез, күргән, очраткан бер татар абзаңа ярдәм итә башласаң, абзыйлар күбәеп китәр шул. *(Ишектән үк чыгып китә.)*

Шәйхулла карт залның уртасына килеп баса да халыкка карап.

Ш ә й х у л л а  к а р т. Иптәшләр! Товарищи! Люди! Купите мои награды. Минем орден-медальләремне, зинһар, сатып алыгыз. Кыйммәт сорамыйм. Дорого не прошу. Бары тик, Смоленскига урыс дустыма барыр өчен, общий вагонга билет алырлык кына акча бирегез?! Күрәсезме, видите! Менә бу медаль — Белоруссияне азат иткән өчен, «За освобождение Белоруссии». Ә менә монысы — аеруча батырлык өчен бирелгән медаль — медаль «За Отвагу». Ә менә бу орден — Дан ордены — орден Славы! Монысы Украинаны азат иткән өчен, «За освобождение Украины». Ә менә монысы, соңгысы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены. *(Халыкның көлгән тавышлары ишетелә. Үз-үзенә ишетелерлек итеп.)* Берегезгә дә кирәкми. *(Орден-медаль-*

*ләр тагылган костюмына озак кына карап торганнан соң тезләнә.)* Их, Вәсилий, Вәсилий, Васек! Очрашмадык. Хуш, бәхил бул, Вәсилий! *(Башы түбән иелә. Янына урам малае килә.)*

Урам малае. Дед... дед...

Шәйхулла карт. *(тавыш килгән якка башын күтәрә, гаҗәпләнеп).* Кто ты? Кто ты, сынок?..

Урам малае *(солдатларча честь биреп).* Я — Василий, бабай. *(Шәйхулла картның иңсәсенә орден-медальле костюмын сала.)* Пошли, дед.

Шәйхулла карт. Куда, сынок?

Урам малае. Туда, где нас нет... *(Шәйхулла картның гармунын култык астына кыстыра да, малайны җитәкләп, акрын гына сәхнәнең арткы өлешенә китә.)*

Пәрдә

# *Көттереп килгән яңгыр*

*Публицистик драма ике картинада, җиде күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Н у р ф а т и х.
Ф ә р и х ә  а п а — Нурфатихның әнисе.
С ә р б и я  ә б и — Нурфатихның әбисе.
Р ә с и м ә — Нурфатихның хәләл җефете.
Р ә ш и т — Нурфатихның биш яшьлек улы.
Г ө л ш а т — сәркатип кыз.
А й г ө л— көнкүреш мәсьәләләре буенча урынбасар.
М ә р х ә б ә  ә б и — өлкәннәр йортында яшәүче.
М у л л а.
И л н у р — унике яшьлек малай.
Ч а н д ы р.
Ү ш ә н.
I  т ө з ү ч е.
Т ө з ү ч е л ә р.

Вакыйга бүгенге көннәрдә район үзәгендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә ачылганда, алгы планда затлы кабинет. Түрдә өстәл. Өстәл артында күннән эшләнгән кресло. Уң як порталда күренеп торган күн диван. Ә сул якта китаплар тезелгән шкаф. Кресло артындагы стенада акбүз ат сурәте. Сәхнәнең арткы планында кабинеттан өстә зур гына мәйданчык. Шул мәйданчыкта, уң якта, прожектор яктысында, тамашачыга карап, ап-ак киемнән С ә р б и я  ә б и басып тора. Аскы кабинетның алгы планында, сул якта, шулай ук прожектор яктысында, тамашачыга карап, Н у р ф а т и х басып тора.

С ә р б и я  ә б и. Улым, Нурфатих, таң сызылып килә, капкаңны ачтыңмы?

Н у р ф а т и х. Нигә, әби?

С ә р б и я  ә б и. Таң алдыннан урамнан бәхет йөрер, ди, балам. Кемнең капкасы ачык, шунда керер, ди. Капка ачык булмаса, кире китәр, ди.

Нурфатих. Әби, капканы кичтән ачып булмыймы?

Сәрбия әби. Кергән бәхет төнлә ишегалдыннан чыгып китәр, ди,бәбкәм.

Нурфатих. Ә тегеләргә, капкасызларга рәхәт. Иртүк торып капка ачасы юк. Җил капкалыларга...

Сәрбия әби. Капкасыз җирдә бәхет тормый, балам.

Музыка астында прожекторлар сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Өстәге мәйданчыкта Нурфатихның әнисе Фәрихә апа пәйда була. Аның җилкәсендә ак шәл. Ул да прожектор яктысында. Астагы кабинетта, диванда, Нурфатих йоклап ята.

Фәрихә апа (*йомшак, назлы тавыш белән пышылдап*). Улым, улым, Нурфатих, әллә торасыңмы? Уятырга кушкан идең!..

Нурфатих. Торам, торам, әнкәй. (*Киерелә.*) Сәгать ничә?

Фәрихә апа. Дүртенче китте, балам.

Нурфатих. Күбрәк йоклаганмын. Иртәрәк уят, дидем бит, әнкәй.

Фәрихә апа. Кызгандым, балам. Бигрәк аз йокладың. Башыңны мендәргә тидерергә дә өлгермәдең.

Нурфатих. Капканы ачасы бар, әнкәй. Капканы...

Фәрихә апа. Үзем ачармын. Үзем...

Нурфатих. Юк, әнкәй, һәр кеше үз капкасын үзе ачарга тиеш. Кеше капкасын кеше ачканга, урам тулы бәхетсезләр. Кеше капкасын кеше ачканга, шушы хәлдә яшибез дә.

Фәрихә апа. Сагындырдың, балам. Таң атса да көтәм, кич булса да көтәм. Хыялымда син уйнап үскән Кәпәч таллары арасыннан сабый чак авазыңны ишетәм. Бер күрергә, бер кәлимә сүз әйтергә тилмереп яшим.

Нурфатих. Кайтырмын, әнкәй. Бер кайтырмын әле. Икмәкне җыйгач, эшләр җиңеләйгәч. Иркенләп кайтырмын. Сагындым. Кәпәч талларын сагындым. Сине, синең ризыкларыңны, коебызның суын сагындым.

Фәрихә апа. Кайталмыйсың, улым, кайталмыйсың. Булмас... Озын чәчәсең, көзен урасың. Әнә синең дә чәчләргә чал төшеп, ап-ак булып бара. Бергә картаябыз, балам.

Нурфатих. Ә нигә үзең бирегә килмисең? Мин дә бит синең балаң.

Фәрихә апа. Балам — вак алмам. Бармыйм түгел, барам, улым. Анда барып нишлим? Анда да сине күрмим, монда да сине күрмим. Соң кайтасың, иртә китәсең. Бүген өеңә дә кайтмадың. Килен нәрсә уйлар инде?

Нурфатих. Соңга калып эшләргә туры килә бит, әнкәй. Иртән-иртүк торасы. Аларны борчыйсым килмәде.

Фәрихә апа. Ул балага Ходай сабырлык бирсен.

Нурфатих. Сабырлыгы бетеп килә инде, әнкәй.

Фәрихә апа. Әйт әле, улым. Бәхетлеме ул бала, бәхетлеме?

Нурфатих. Белмим, әнкәй. Бездән дә бәхетсезләр күбрәк. Иртә таңнан торам да шуларның капкаларын ачам, кич белән ябам. Гомеремнең узганын сизми дә калам. Таң ата да кич була. Ә аның капкасы нык. Мин аны җил капкага алып кайтмадым. Вакытында ачыла, вакытында ябыла.

Фәрихә апа. Кешеләргә бәхет өләшәсең, ә үзең?!

Нурфатих. Алар бәхетсез булса, миңа нинди бәхет?! Алар авыз тутырып икмәк ашамаса, миңа нинди бәхет?! Аларның шат йөзен күрмәсәм, минем йөземдә нинди шатлык?! Шат йөз, шат күңел белән өемә кайтмасам, ул балага нинди шатлык?! Тик елмаерга иртәрәк шул әле, әнкәй. Эшлисе дә эшлисе. *(Торып, сәхнәнең алдына килә. Карашын еракка, тамашачыга юнәлтә.)*

Фәрихә апа. Нигә уйга баттың, балам? Ник ямансу?

Нурфатих. Болытлар куерганын көтәм, әнкәй.

Фәрихә апа. Яңгыр көтәсеңме?

Нурфатих. Көтәм, әнкәй. Таңны да көтәм, кичен дә көтәм. Менә ничә еллар инде күктән күземне алмый, язын, җәен яңгыр, көзен болытларның таралганын көтеп яшим.

Фәрихә апа *(иңсәсеннән шәлен сала да алга тамашачыга суза)*. Ал, балам, иңсәңә сал. Таң белән һава җиләс була. Салкын тидермә. Сәламәт тәндә — сәламәт акыл, диләр.

Нурфатих. Рәхмәт, әнкәй. Көзен салырмын. Көзге яңгыр шәбәртә. Шәбәртеп кенә калмый, җилкәмә ява. Җилкәмә генә явып калмый, бәгъремә үтеп керә. Бәгъремә үтеп керә дә йөрәгемә кадала.

Фәрихә апа. Их, балам, балам. Балам — вак алмам. Кодрәтемнән килсә, кояш-айны алып бирер идем.

Нурфатих. Кирәкми, әнкәй, юк, кирәкми. Миңа ай да, кояш та кирәкми. Миңа күңел җылысы, миңа өйдә үземне аңлаучы кирәк. Бусагамда елмаеп каршы алучы, озатканда, мәңгелеккә озатып калгандай, озатып калучы кирәк.

Музыка. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Нурфатих өстәл артында креслода утыра. Бүлмәгә Гөлшат килеп керә.

Гөлшат. Нурфатих Аббасович, сезгә бер әби килгән, кертергәме?

Нурфатих. Әбиме, әллә апамы?

Г ө л ш а т. Яшен сорамадым.

Н у р ф а т и х. Синнән яшьме, әллә картмы?

Г ө л ш а т *(көлеп җибәрә)*. Миңа бит әле 24 кенә.

Н у р ф а т и х. Ә мин сиңа 84 дип уйлаган идем.

Г ө л ш а т *(көлә)*. Нигә алай?

Н у р ф а т и х. Хәтерең алама. Исәнләшергә онытасың. Син кайда эшлисең?

Г ө л ш а т. Биредә.

Н у р ф а т и х. Кайда инде ул биредә?

Г ө л ш а т. Хакимияттә.

Н у р ф а т и х. Хакимияттә?! Нәрсә соң ул хакимият?

Г ө л ш а т. Хакимлек итә торган орган.

Н у р ф а т и х. Син шул хакимлек итә торган органда нинди вазифа башкарасың?

Г ө л ш а т. Секретарь булып эшлим.

Н у р ф а т и х. Сеңлем, без хакимлек итәргә тиеш түгел. Без халыкка хезмәт итәргә тиеш. Будь добр. Служи, халкыңа хезмәт ит. Хуҗаңның исәнлеген сорарга да онытып, йоклап йөрмә. Син әлегә секретарь-сәркатип булалмагансың. Син әлегә бу органның члены гына икәнсең. Бар, чакыр.

Гөлшат чыгып китә. Бүлмәгә кулына сумка тоткан М ә р х ә б ә  ә б и килеп керә.

М ә р х ә б ә  ә б и. Әссәламегаләйкүм. Хәерле көн, Нурфатих Абб... Абб...

Н у р ф а т и х. Вәгаләйкемәссәлам. Үзегезгә дә хәерле көн. Әйдәгез, түргә узыгыз, апа. *(Аңа кулы белән урындык күрсәтә.)*

М ә р х ә б ә  ә б и. Хәтер аламаланды. Атагызның исемен оныттым. Гафу итегез.

Н у р ф а т и х. Зыян юк. Исемне беләсез бит. Исем белән генә сөйләшегез, апа.

М ә р х ә б ә  ә б и. Апа түгел инде. Кызымны кияүгә биреп, улымны өйләндерә алмасам да, күптәннән әби. Быел гыйнварда 83емне тутырам.

Н у р ф а т и х. Бирсен Ходай. Әйдә, әйдә, менә монда өстәл артына, түргә утыр, Мәрхәбә әби. Тартынма.

М ә р х ә б ә  ә б и. Бәй, каян килеп исememне белдегез әле? Теге приемдагы бала да исememне сорамаган кебек иде.

Н у р ф а т и х. Өлкәннәр интернатыннан бит сез.

М ә р х ә б ә  ә б и. Әйе шул, картлар йортыннан.

Н у р ф а т и х. Интернаттагы 29 әби, 3 бабайның исемен дә белмәгәч, минем монда утыруымның нигә кирәге бар?

М ә р х ә б ә  ә б и. Алай димә. Безнең күпләребезнең үз балалары да исемнәребезне хәтерләмиләрдер инде. Мин ул яктан бәхетле. Минем беркемем дә юк. Ә менә Сәгыйдә... Өч баласы бар килеш тә картлар йортында. Ә Мәсрүрәнең —

икәү. Мин бәхетле. Минем беркемем дә юк. Иң авыры, иң ачысы, иң аянычлысы — балаң була торып, картлар йортында яту. Балаң була торып та, беркемгә дә кирәгең юклыкны белүдә.

Н у р ф а т и х. Алай димәгез. Сез безгә кирәк. Без яңа туган баладан алып иң өлкән кешегә кадәр белеп, аңа ярдәм итеп торырга тиеш.

М ә р х ә б ә  ә б и. Рәхмәт инде. Ярый әле хөкүмәт бар. Ярый әле сездәй кешеләр бар. Картлар йорты булмаса, без кая барыр идек.

Н у р ф а т и х. Картлар йорты дип сөйләшмик әле, Мәрхәбә апа, интернат дип сөйләшик.

М ә р х ә б ә  ә б и. Исемне үзгәртеп, җисем үзгәрми шул.

Н у р ф а т и х. Күпне белгәнгә охшыйсың син, Мәрхәбә апа.

М ә р х ә б ә  ә б и. Күпне белгәнгә, картлар йортында яшим дә инде. 40 елдан артык балалар укыттым.

Н у р ф а т и х. Менә монысын белми идем.

М ә р х ә б ә  ә б и. Әйе, 43 ел балалар укыттым. 43 ел кешеләргә ничек яшәргә өйрәттем. Ә үзем яши белмәдем. Күпне белдем, аздан колак кактым.

Н у р ф а т и х. Нигә алай дисез? Әллә интернатта рәнҗетәләрме?

М ә р х ә б ә  ә б и. Алланың биргәненә шөкер. Хәзер бу сүзләрне әйтергә курыкмыйбыз. Җәннәттә яшәтәсез. Без бу хөрмәтне, сый-мөлкәтне элек бәйрәмдә дә күрми идек.

Н у р ф а т и х *(өстәлдәге селекторга баса)*. Сеңлем Гөлшат, чәй керт әле.

М ә р х ә б ә  ә б и. Гомер буе тарих укыттым. Авылның тарихын яздым. Син килгән кеше. Элеккеләрне бик белеп тә бетермисеңдер. Гомер буе Алланы сүктем. Район радиосыннан да, трибунадан да сүктем. Атеист идем. Үзем гомер буе Аллаһы Тәгаләгә ышанып яшәдем. Партия кушкач, кая барасың. Хәзер шуның әҗерен күрәмдер. Догалар укыган булам. Коръән Кәримне яттан беләм.

Бүлмәгә, поднос белән чәй күтәреп, Г ө л ш а т килеп керә дә Нурфатих белән Мәрхәбә әбинең алдына чәй куя.

Г ө л ш а т. Чәегез тәмле булсын!

Н у р ф а т и х *(Гөлшатка)*. Менә син хәзер член гына түгел инде. Настоящий секретарь. *(Гөлшат чыгып китә.)* Чәенә җитешегез, Мәрхәбә апа.

М ә р х ә б ә  ә б и. Рәхмәт. Чәй эчеп кенә килгән идем.

Н у р ф а т и х. Анысы сезнең кое суы, монысы безнең кое суы. Безнең кое суын да эчеп карагыз.

М ә р х ә б ә  ә б и. Адәм баласы кошлар кебек, Нурфатих энем. Тик канатлары гына юк.

Н у р ф а т и х. Хыял канатлары бар.

Мәрхәбә әби. Адәм баласы, күзләрен соңгы тапкыр йомгач, хыял канатларыннан да мәхрүм кала шул. Әлегә ярый да хыял канатлары бар. Шул хыялым канатлары белән очып китәм дә туган-үскән якларга, сабый чагым узган яшел болыннарга, әби-бабай, әти-әни, улым яткан җирләрдән әйләнеп кайтам. Ә менә хыялым канатлары сынгач, мин кайда ятармын? Кем мине җирләр? Дөньялыкта җанымны асраган гәүдәм кая куелыр? Менә нинди үтенеч белән килдем мин сезгә, энем Нурфатих.

Нурфатих. Без эшне сезнең хатаны төзәтүдән башлыйк. Әле бит тегендә дә хаталыларга бик шәптән түгел, диләр.

Мәрхәбә әби. Яшең 83кә җиткәч, ялгышларны төзәтеп булмый шул.

Нурфатих. Нишләп булмасын икән. Менә коммунистларны сүгеп утырабыз бит. Кайсыбыз коммунист түгел идек. Кайсыбыз, без дөрес эшләмибез, дип, чаң кактык. Билетларны өстәлгә ыргыттык та демократия төзи башладык. Ә менә бүген шул чактагы ялгышларны төзәтеп утырмыйбызмы?! 70 елга кире кайттык та, хәзер үз ялгышларыбызны төзәтеп утырабыз. Кемнәрнедер гаеплибез. Ә бәлки, без үзебез дә гаепледер.

Мәрхәбә әби. Әйе, дөньялар яхшыра. Кайда карама муллык. Нәрсә телисең, шул бар. Дөнья дөрес юлдан атлый башлады.

Нурфатих. Кем белә, бәлки, бу юл да дөрес түгелдер. Аны беркем дә әйтә алмый. Бәлки, аны Ходай Тәгалә үзе генә белә торгандыр.

Мәрхәбә әби. Сез дә белмәгәч, кемнәр белергә тиеш соң аны, энем Нурфатих?

Нурфатих. Иманга кайтырга кирәк. Адәм баласы ниндидер көчкә ышанып, табынып яшәргә тиеш. Ата — улны, ана кызны белми. Мәхшәр! Әнә мәчетне күрәсеңме?

Мәрхәбә әби. Күрәм. Кем йөри соң анда, кем?

Нурфатих. Менә сезнең кебек атеистлар, безнең кебек элекке коммунистлар.

Мәрхәбә әби. Әйе, безнең кебек атеистлар, сезнең кебек коммунистлар.

Нурфатих. Нигә, бу начармыни? Кеше олыгайган көндә иманга кайта икән, бу начармыни? Тәнебезнең берәр җире чәнчесә, йә булмаса бәрелсә, сугылса, нәрсә дибез?

Мәрхәбә әби. Алла, дибез.

Нурфатих. Алла, дибез шул. Димәк, әле безнең геннарда Алла дигән төшенчә бар. Нәрсә ди безнең халык? Бер ярмадан ботка пешереп булмый, әмма ярмасыз да ботка пешереп булмый. Озакламый мәдрәсә салабыз. Элек сез трибунадан, радиодан Ходайны сүксәгез, бүген мактагыз. Үзегезнең хаталарыгызны күрсәтегез. Әнә район телевидениесе, һәр җомга саен

чыгыгыз да яшь буынга дин сабакларын укытыгыз. Мәктәпләрдә дин сабаклары буенча өстәмә дәресләр булдырыйк. Ходай күрә ул. Ярлыкавыннан ташламас. Менә күрерсез. Ул вакытта сезгә минем дә кирәгем калмаячак. Сез иманга, денгә керткән балалар сездән әүлия ясаячаклар. Кемнәрдер ышанмаган, күзгә күренмәгән Ходай Тәгаләнең рәхмәте шул булыр, ди.

Мәрхәбә әби. Узганнар куркыта шул. Артка борылып карыйм да...

Нурфатих. Ә сез артка борылып карамагыз. Арттан тарихчылар барсын. Сез соңгы минутларыгызны ничек үткәрерсез, без тарихка шулай язарбыз. Тарихны язучылар тарихны үзләре булдырырга тиеш. Тарих моң-зар өчен түгел, тарих кешелекнең көнкүрешен, яшәү рәвешен яхшыртыр өчен хезмәт итәргә тиеш. Минем әби әйтә торган иде. Улым, артыңа борылып карама, тарткан йөгең авыр булыр. Гел алга, яхшылыкка, матурлыкка омтыл, дия торган иде. Шулай, Мәрхәбә апа. Без иманны бергә кайтарыйк. Имансыз җирдә икмәк үстереп булмый. Икмәк булмаса, сәламәтлек булмый. Сәламәт тәндә — сәламәт акыл.

Мәрхәбә әби. Үзең кайсы яктан, энем Нурфатих?

Нурфатих. Мин Татарстанның төньягыннан. Шүрәлеләр яшәгән урманны ишеткәнегез бардыр.

Мәрхәбә әби. Белмәгән кая. Барып күрмәсәм дә, су анасы яши торган күлләрендә су коенганым бар. Бәлки, сез безнең якка, безнең күңелләрне үстерергә, безнең кәефебезне күтәрер өчен Ходай тарафыннан җибәрелгәнсездер дә.

Нурфатих. Әмма кытыклап түгел.

Мәрхәбә әби. Рәхмәт, Нурфатих энем, рәхмәт. *(Сумкасыннан оекбаш чыгара.)* Бирергә дә оялам инде.

Нурфатих. Ә мин бирергә оялмыйм, сорарга гына оялам.

Мәрхәбә әби. Сезнең кебек кешеләр мондый оекбаш кимиләрдер дә инде. Үзем бәйләгән идем.

Нурфатих. Мәрхәбә апа, бирегә килегез әле.

Мәрхәбә әбине сәхнә алдының уң як порталына бастыра. Машина, трактор гөрләгән тавышлар ишетелә. Сәхнәнең арткы ягы яктыра. Анда иске кәкрәйгән йортның тәрәзәләре белән стенасы күренә. Сәхнәдә башларына каска кигән төзүчеләр кайнаша.

I төзүче. Уңгарак, уңгарак, өскә, өскә. Менә шулай. Хуп мало! *(Сәхнәнең өске өлешендә ут сүнә. Машина, трактор тавышлары бетә.)*

Нурфатих. Җимерәбез, Мәрхәбә апа, җимерәбез. Моннан 20 ел элек төзелгән булган, бүген җимерәбез. Төзүчедән киткәнче, хуҗасына барып җиткәнче дип төзелгән. Фундаментын, нигезен дөрес төземәгәннәр. Ә сез оекбаш киясезме, дип сорыйсыз. Кешегә озын гомер өчен нәрсә кирәк?

Мәрхәбә әби. Сәламәтлек.

Нурфатих. Сәламәтлек өчен нәрсә кирәк? Аяк белән башны җылыда, корыда тотарга кирәк. Йорт та шулай. Нигезе нык, түбәсе су үткәрмәсә, ул безнең балаларның балаларына җитә. Кеше дә шулай. Сәламәтлеген сакласа, аннан сәламәт балалар туа. Мин дә менә шушы җылы оекбаш белән үземнең фундаментымны ныгытырмын. Рәхмәт сезгә. Сез үзегезне Ходай каршында гаепле, дисез. Кара әле, Мәрхәбә апа, болытлар куера. Озакламый яңгыр була. Рәхмәт сезгә төкле аягыгыз өчен, рәхмәт. *(Шкафтан мамык шәл алып, әбинең җилкәсенә сала.)* Ә менә монысы сезгә яңгыр бүләге. Көттереп килгән беренче яңгыр бүләге.

Мәрхәбә әби. Юк, юк, кирәкми. Болай да күп вакытыгызны алдым. Миңа бүләк кирәкми.

Нурфатих. Ә бу шәл миннән генә түгел, сез укыткан шәкертләрдән дә. Аларның күбесе шушы җирдә яшәп, шушы җирдә хезмәт итәләр бит. Алыгыз. Укучыларыгызның җылы истәлеге итеп алыгыз.

Мәрхәбә әби *(шәлен, ике кулы белән тотып, күкрәгенә куеп)*. Рәхмәт. *(Тамашачыга.)* Рәхмәт, балалар.

Нурфатих *(селекторга баса)*. Гөлшат сеңлем, безнең көнкүреш мәсьәләләре буенча урынбасар үзендәме?!

Селектордан Гөлшатның тавышы ишетелә.

Гөлшат. Үзендә.

Нурфатих. Бирегә керсен.

Гөлшат. Яхшы.

Нурфатих. Хәзер бирегә минем зам керә. Ул сезне озатып куяр.

Бүлмәгә Айгөл керә.

Айгөл. Исәнмесез! Тыңлыйм сезне, Нурфатих Аббасович.

Нурфатих. Өйрәндегез гел мине тыңларга. Сезне кайчан тыңларбыз икән. Кайчан указкасыз эшләргә өйрәнәсез. Сез бу ханымны беләсезме?

Айгөл. Каядыр күргәнем бар.

Нурфатих. Ярый әле мине таныйсыз. Әниең исәнме?

Айгөл. Юк. Үлгәненә биш ел.

Нурфатих. Сагынасыңмы?

Айгөл. Әнине ничек сагынмыйсың инде.

Нурфатих. Сагынсаң, өлкәннәр яши торган интернатка ешрак баргалап йөр. Андагы әбиләрне күреп, үзеңә юаныч табарсың. Мин хәзер хуҗалыкларны карарга чыгып китәм. Син Мәрхәбә апаны биредә яхшылап сыйла да, машинаңа утыртып,

тегүчеләр янына алып бар. Өлкәннәр интернатына намазлыклар, кәләпүшләр эшләт. Ә менә бу *(шкафтан 3 түбәтәй алып бирә)* түбәтәйләрне минем исемнән бабайларга кигерт. Аңлашылдымы, әллә шылдымы?

Айгөл. Аңлашылды.

Нурфатих. Ярый, исән булып торыгыз, Мәрхәбә апа. Җомгага кич район телевидениесеннән сезнең вәгазьне тыңлыйм. *(Чыга башлый. Айгөлгә.)* Ә, онытканчы шуны әйтим. Иртәгә иртән тугызларда мулла абзый бирегә булсын. Исән булыгыз. *(Чыгып китә.)*

Мәрхәбә әби. Исән бул, улым. Юлың уң булсын. Ачуланма инде, кызым. Минем аркада әләкте үзеңә.

Айгөл. Ул безнең шундый коры инде. Әле бу чепуха. Аның янында эшләгән кешегә и күз, и запасной аяк кирәк. Таләпчән.

Мәрхәбә әби. Күрәм. Булган бала. Иманлы бала.

Айгөл. Картлар йортында ничек соң, Мәрхәбә әби? Условиеләр бардыр бит?

Мәрхәбә әби. Өлкәннәр интернатындамы? Аллага шөкер. Алланың биргәненә шөкер.

Айгөл. Әйдә, Мәрхәбә әби, чәеңне яңартам.

Мәрхәбә әби. Юк, юк, шушы чәемне генә эчеп бетерәм дә... Үзең ир хатынымы? Соравым өчен ачуланма.

Айгөл. Юк әле, Мәрхәбә әби.

Мәрхәбә әби. Күп укыгансыңдыр. Гадәттә, шундыйлар ялгыз кала.

Айгөл. Университет бетердем, һөнәрем буенча укытучы. Башта мәктәп директоры булып эшләдем. Аннары менә бирегә эшли башладым.

Мәрхәбә әби. Соравымның сәбәбе шул: мин үзем дә 43 ел тарих фәненнән балалар укыттым. Элек бит күпләргә уку эләкмәде. Заманасы авыр иде. Җиде класслылар да сирәк иде. Ә мин югары белемле идем. Бәлки, шуңа да бүген өлкәннәр йортында яшимдер дә. Укыган кеше сайлана. Бигрәк тә руководящий органнарда эшләгәннәр. Мин инде бу җиһаннан китеп барам. Сиңа васыятем шул. Үз тиңеңне эзләгәндә, нәселен кара. Нәселсез агач — җимешсез агач. Алма агачыннан ерак төшми.

Айгөл. Ә сез үзегез кияүдә булмадыгызмы?

Мәрхәбә әби. Булдым. Бала да таптым. Мине яратып йөргән егет Мөстәкыйм атлы иде. Сөләйләр нәселеннән. Гади бер колхозчы иде. Заманында Сөләй картны сөргенгә сөргәннәр. Авылыбызның иң затлы кешесе булган, дип сөйлиләр. Улым туды. Гадел исеме куштым. Гадел булсын, дидем. Улымның атасы Ибраһим белән очрашкан минутларымны бүгенге-

дәй хәтерлим. Сугыш беткәннең икенче елы иде. Шомыртлар чәчәк аткан чор. Әйе, әйе, шомыртлар чәчәк аткан чор. Без, авыл яшьләре, урман аланында күңел ачабыз. Авылга бер егет килгән икән. Бөтенләйгә, безнең авылда яшәргә. Әти-әнисен җирләгән, үзе укымышлы икән. Сөйләүләре буенча инженер-строитель икән. Буй-сынга карап тормалы. Өстендә китель головей, хром итекләр, сыздырып тальян тарта. Бар кызларның күзе аңарда. Әйтерсең лә барысы да егетләрен онытткан. Минем дә күз алдымнан Мөстәкыйм эреп юкка чыкты. Шул минуттан мин гел аның турында, тальян тарткан егет хакында гына уйлый башладым. Аны уйлап йокыга киттем, аны уйлап йокымнан уяндым. Көткән минутым килде. Күп тә үтмәде, кулымны сорады. Мәрхүм эткәй әйтте: «Кешене кешедән аера белмисең, ялгышасың, кызым»,— диде. Килешмәдем. Эткәйнең фатихасын да алмыйча, шатланып кияүгә чыктым. Ул минутларда миннән дә бәхетле кеше юк иде. Бала туып бер ел да үтмәде, өйгә ике военный килде. Гаделемнең атасы Ибраһимны кулга алдылар. Ибраһимның сөйләве буенча, уналты яшьтән гаиләләре белән бәхет эзләп, Донбасс якларына чыгып киткән, шуннан сугышка китеп, күп батырлыклары өчен күкрәге тулы орден-медальләр белән бүләкләнгән, үз вакытында фашист концлагеренда үз дусларын саткан, күрше Чуваш республикасында туып үскән, сарык урлап, унҗиде елга хөкем ителгән Гыйззәтулла улы Гыйльмулла булып чыкты. Китте, шул китүдән югалды. Көннәрдән бер көнне ишегемне Мөстәкыйм шакыды. Бусагама аркылы бастым. «Чык миңа кияүгә. Балаңның атасы булырмын»,— диде. «Мин аны көтәм»,— дидем. «Кайтмый ул,— диде.— Чык, Мәрхәбә, чык миңа, мин бит сине яратам»,— диде. «Мин баламны үги ата белән үстермим. Баламның чит кеше, чит ата күзенә карап, кимсенеп үсүен теләмим»,— дидем. Гаделемне ялгызым тәрбияләргә булдым. Күпме генә тәрбияләргә тырышсам да, булдыра алмадым. Ул баланың бөтен гәүдәсе, бөтен кан тамырлары аша атасы Гыйльмулла каны ага иде. Шуңа күрә дә бердәнберемне, 25 е дә тулыр-тулмас, җир куенына салдым да. Мин улыма Гадел исеме куштым. Гадел булсын, дидем. Гадел булмады. Мин шомырт чәчәкләрен яратмыйм. Шомырт чәчәкләре табигатькә салкын китерә. Мин шомырт чәчәкләрен яратмыйм. Шомырт чәчәкләре минем күңелемне өшетә. Мин шомырт чәчәкләренең исен яратмыйм. Шомырт чәчәкләре мине гомерлеккә исертте. Бүген дә мин алардан айный алмыйм, бу җиһаннан китеп барам. Васыятем шул: нәсел агачы бик юмарт китерер сиңа...

*Музыка. Ут сүнә.*

П ә р д ә

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ут янганда, Нурфатих үз кабинетында мулла белән сөйләшеп утыра.

Нурфатих. Әйт әле, мулла абзый, безнең кылган яхшылыкларыбызны, эшләгән гөнаһларыбызны кемнәр язып бара?

Мулла. Фәрештәләр, фәрештәләр, кем, энем Нурфатих. Адәм баласының ике як җилкәсендә ике фәрештә утырыр, ди Коръән Кәрим. Берсе аның — Кирам, икенчесе — Кәтибин.

Нурфатих. Менә мин Кирам булсам да, булмасам да, сезнең җилкәгә утырмас идем.

Мулла. Нигә алай дисез, кем, энем Нурфатих?

Нурфатих. Түбәтәең бик каешланган. Аннан әллә нинди исләр киләдер. Тукта. Эшне, сөйләшүне без моннан башлыйк. Салып ташлагыз әле ул түбәтәегезне. Менә мин сезгә яңасын бүләк итәм. *(Мулла башына түбәтәй кидерә.)*

Мулла. Оятлы иттең, Нурфатих Аббасович, оятлы иттең. Әле сабантуйда гына бүләк иткән идегез бит.

Нурфатих. Иткән идем дә бит...

Мулла. Хатын-кыз инде. Хатын-кыз. Мәсрүрә апаң, Мәсрүрә...

Нурфатих. Синең башта аның ни эше бар?!

Мулла. Хатын-кыз инде, хатын-кыз... Саран тәреләр! Районның иң хөрмәтле кешесе бирде, шкафта гына торсын, дип, баштан салдырды бит.

Нурфатих. Кирам белән Кәтибинне шкаф башында утыртмыйк инде, җилкәңдә йөрсеннәр. 40 ел бер түбәтәйне йоклаганда да салмыйча, каешланганчы киясез дә, аннары урыска үпкәлисез. Билгеле, чаплашка, диләр. Инде аңлаган кешегә аңларлык. Әнә президентыбыз үзенә түбәтәй кигертте. Ә сез... *(Бераз вакыттан соң.)* Мәчеткә йөриләрме?

Мулла. Аз. Бик аз. Җиде-сигез карттан башка йөрүче юк.

Нурфатих. Димәк, интерес юк. Яшьләр йөриме?

Мулла. Яшьләр бит имансыз.

Нурфатих. Аларга иман нәрсәгә?! Яшьлекләре бар, сәламәтлекләре җитәрлек.

Мулла. Аларга пивнушка төбе күбрәк ошый.

Нурфатих. Димәк, анда күңеллерәк. Иман бит ул сәламәтлек беткәч, картлык үкчәгә баскач, газраил якадан алгач, теге дөньяга китәр вакыт җиткәч кенә кирәк.

Мулла. Шулай шул.

Нурфатих. Минем сүзне җөпләп утыру җиңел. Юлларын эзләргә кирәк. Яшьләрнең пивнушка төбеннән урап уза торган юлларын табарга кирәк. Әнә гарәп илләрендә урап уза-

лар. Урамда исерек күрмисең. Карак та юк. Олыны — олы, кечене кече итәләр. Нигә төрмәләрдә хәзер мәчетләр ачыла? Адәм баласының кешелеккә ышанычы бетеп бара. Алар да бит карак, кеше үтерүче булып тумаган. Кемнәндер күреп эшләгәннәр. Ә ул утыра, килька консервасы урлап, ә миллионлап урлаган ирекгә йөри. Кемгә табынсын?! Законгамы, әллә Аллагамы?! Яшьтәшләрең янына, өлкәннәр интернатына баргаларга кирәк.

Мулла. Картлар йортынамы?!

Нурфатих. Әйе. Картлар йортына.

Мулла. Үз балаларына кирәкмәгән бәндәдә иман бардыр дип уйлыйсызмы?!

Нурфатих. Нәкъ үзе. Үз балаларына ышанып, өмете беткән кеше нәрсәгә табына дип уйлыйсыз. Сиңа, миңамы?! Ходайның үзенә! Вәгазьләрегез искерде. Хәзер аңа яшь буын түгел, 90 яшьлек әби дә ышанмый.

Мулла. Коръән беркайчан да искерми, кем, энем Нурфатих Аббасович. Коръән мәңгелек!

Нурфатих. Мәңгелеген мәңгелектер. Ләкин аны заманга яраклы итеп аңлата белергә кирәктер. Сез халыктан алда барырга, киләчәкне алдан әйтергә тиешсез. Шул вакытта гына сез халыкны үз артыгыздан ияртә аласыз. Сез һаман да бер балык башы чәйнисез. Чүп чәйнәп, май чыкмый. Ә безгә май кирәк.

Мулла. Коръән нәрсә кушса, шуны сөйлибез.

Нурфатих. Әйтегез әле, Ходай Җир йөзендәге бар тереклекне дә тигез яратканмы?

Мулла. Ходай Коръән Кәрим аркылы безгә шуны җиткерә. Мин һәр яратканыма җан өрермен, тигез яратырмын, ди.

Нурфатих. Мин гомер буе очарга хыялланам. Әмма очалмыйм. Чыпчык оча.

Мулла. Ходай сиңа аяклар биргән.

Нурфатих. Ә менә Ходай черкигә аяк та биргән, канат та биргән. Ә сыерга хәтта кул да бирмәгән. Менә сез абыстай белән ничә метрдан сөйләшә аласыз? Ничә метрдан бер-берегезне ишетәсез.

Мулла. Талашкан вакытта районның бер башыннан икенче башына тавышыбыз ишетелеп тора.

Нурфатих. Ә менә дельфиннар йөзәр чакрымнан берсе белән берсе сөйләшә, ди.

Мулла. Адәм баласына Ходай Тәгалә андый мөмкинлекләр бирмәгән.

Нурфатих. Нишләп бирмәсен, биргән. (*Кесәсеннән шырпы кабы кадәрле кәрәзле телефон чыгара.*) Менә мин хәзер океан артындагы Америкада яшәүче дустыма шалтыратам.

Мулла. Ул бит телефон.

Нурфатих. Ә кем уйлап тапкан?! Адәм баласы. Кем

аңа мондый мөмкинлекне биргән? Димәк, Ходай аңа бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр биргән. Дөрес, канат бирмәгән. Уйлау-фикерләү сәләте, көч биргән. Кеше секундлар эчендә орбитадан чыгып китә ала. Дөрес, кеше канатсыз, әмма оча. Кешегә саңак бирелмәгән, ләкин океан төбенә төшә. Аңлат балаларга шуны.

Мулла. Алар фәнгә бәйли.

Нурфатих. Кызыксыну уят. Бәйләсә, ач миңа шуның серләрен, диген. Галим булырсың, рәхәт яшәрсең, гомерең җәннәттә үтәр, диген. Пивнушка төбендә йөрергә вакытың калмас, диген.

Мулла. Яхшы. Ходай Тәгалә адәм баласына фикерләү көче биргән. Ә менә әлеге дә баягы сыер нишләргә тиеш?!

Нурфатих. Бәлки, сыер бездән бәхетлерәктер. Аңа уйлау-фикерләү сәләте бирелмәгән. Кайчан туганын, кайчан үләсен белми. Шуның белән бәхетле. Адәм баласы шуның белән бәхетле — уйлау-фикерләү сәләтенә ия булу белән. Адәм баласы шуның белән бәхетсез — уйлау-фикерләү сәләте булу белән. Менә хәзер дөньяны компьютерлар басты. Дөньяның кайсы ноктасы белән аралашасың килсә, минутлар җитә. Интернетка гына тоташ. Менә шул сезнең җилкәдәге, минем җилкәдәге уй-фикерләрне язып баручы фәрештәләр Кирам белән Кәтибин, бәлки, шушы очып барган дулкыннардыр. Балаларга шуны аңлатырга кирәк. Риза булмасалар, серләрен ачсыннар. Әлегә кадәр аларны бер генә кешенең дә, бер генә галимнең дә дөп-дөрес итеп ачканы юк. Әле бүгенге көндә адәмнең каян яралганын әйтүче табылганы юк. *(Озак кына тынлыктан соң.)* Иртәгә мәдрәсәгә нигез салабыз. Ишеткәнсездер.

Мулла. Ишеттем.

Нурфатих. Уйлагыз, уйла, мулла абзый. Уйланасы эшләр күп. Бу әле минем сүз башы гына. Иманны кайтарыйк. Имансыз җирдә хөрлек, муллык булалмый. Имансыз җирдә тыныч йоклап булмый. Сау булыгыз. Иртәгә очрашканга кадәр. *(Өстәлдәге селекторга баса.)* Гөлшат, бирегә кер әле.

Бүлмәгә Гөлшат керә.

Гөлшат. Тыңлыйм сезне, Нурфатих Аббасович.

Нурфатих. Тәрәзәдән кара әле! *(Гөлшат тәрәзәгә барып карый.)* Минем машинаны күрәсеңме?

Гөлшат. Күрәм.

Нурфатих. Минем машина янында бер атна бөтерелгән малайны күрәсеңме?

Гөлшат. Күрәм. Хәзер куып җибәрәм мин аны.

Нурфатих. Машина янында йөргән малайларны куып җибәрмиләр, киресенчә, машина, техника янына ияләштерәләр. Менә шундыйлардан менә дигән механизаторлар, инженерлар чыга да инде.

Г ө л ш а т. Малай-шалай гына бит әле ул, Нурфатих Аббасович.

Н у р ф а т и х. Менә шушы яшьтән эзләргә кирәк аларны. Бар, алып кер әле.

Г ө л ш а т. Хәзер. *(Чыгып китә.)*

Н у р ф а т и х *(селектордагы кнопкага баса)*. Алло, бу синме Хәйриев?! Чөгендереңне бүлдеңме?! Юк әле?.. Кайчан бүләсең? Син аңлыйсыңмы?.. Аңлыйм, аңлыйм... Аңлыйсың пычагымны! Һөнәрең буенча кем син?! Агроном... Агроном түгел син, аңгыраном. Ат духтыры чөгендер үстерергә өйрәткәч, нинди агроном син. Син беләсеңме, молокосос, бүгенгесе көндә син ике атналык үсешне югалттың. Бүген җиреӊ бүленгән булсын. Иртәгә лично үзем тикшерәм. *(Селектор кнопкасына баса.)*

Икенче бүлмәдән И л н у р белән Г ө л ш а т н ы ң тарткалашканы ишетелә.

И л н у р. Кермим мин анда.

Г ө л ш а т. Нурфатих Аббасович чакырды.

И л н у р. Чакырса соң. Сиңа ул Нурфатих. Мин ул кешене белмим.

Г ө л ш а т. Хәзер милиция чакыртам.

И л н у р. Нәрсә, әллә мин приступникмы?!

Гөлшат Илнурны, кулыннан өстерәп, бүлмәгә алып керә.

Н у р ф а т и х. Нихәл, егет?

И л н у р *(кырыс)*. Әйбәт әле.

Н у р ф а т и х. Бир бишне!

И л н у р. Кул пычрак.

Н у р ф а т и х. Кая?

И л н у р. Менә!

Н у р ф а т и х. Бу бит пычрак түгел.

И л н у р. Чиста да түгел инде.

Н у р ф а т и х. Бу бит туфрак. Туфрак пычрак буламыни? Бир бишне!

И л н у р. Мә инде! *(Борын астыннан мыгырдап.)* Күңелең булсын.

Н у р ф а т и х. Исемең ничек?

И л н у р. Илнур.

Н у р ф а т и х. Кара әле, Илнур дус. Менә бер атна инде син әнә теге машина янында бөтереләсең, әллә...

И л н у р. Юк, абый, мин аның бернәрсәсенә дә тимәдем. Валлаһи менә.

Н у р ф а т и х. Ышанам. Алайса, нигә машина янында йөрисең?

И л н у р. Шоферын көтәм.

Нурфатих. Әллә берәр җиргә барасың бармы?
Илнур. Юк. Андый машинага кем утыртсын мине?
Нурфатих. Әллә ошыймы?
Илнур. Класс! *(Баш бармагын күрсәтеп.)* Во! Шоферы гына ялкау.
Нурфатих. Нигә?
Илнур. Машинасын юмый.
Нурфатих. Үзең әйбәт укыйсыңмы соң?
Илнур. Бер дүртле бар.
Нурфатих. Молодец! Дүртле нәрсәдән?
Илнур. Пениедан.
Нурфатих. Калганнары бишлеме?
Илнур. Тоттырганнар ди.
Нурфатих. Үскәч, кем буласың?
Илнур. Уйлыйм әле.
Нурфатих. Ничәнчене бетердең?
Илнур. Алтыны бугай.
Нурфатих. Нишләп «бугай»?
Илнур. Әле күчкәнне белмим бит.
Нурфатих. Ә кем белә?
Илнур. Укытучы. Күзгә калдырмаган булсалар.
Нурфатих. Димәк, начар укыйсың?
Илнур. Начар укымыйм, слабый укыйм. *(Стенадагы ат сурәтен күреп көлеп җибәрә.)*
Нурфатих. Нигә көләсең?
Илнур. Болай гына.
Нурфатих. Болай гына көлмиләр. Миннән көләсеңдер әле.
Илнур. Нишләп синнән көлим?
Нурфатих. Кемнән көләсең соң?
Илнур. Әнә теге аттан.
Нурфатих. Кайсы?
Илнур. Әнә стенадагы аттан.
Нурфатих. Аның нәрсәсе кызык?
Илнур. Бик югары кунаклаган. Безнең директор кабинетында ул урында президент тора.
Нурфатих. Ә син ат яратасыңмы?
Илнур. Яратам дип... Мин машинаны ныграк яратам.
Нурфатих. Нигә?
Илнур. Скоросте бешанный. Ә менә минем дустым Әптеригә ат җене кагылган.
Нурфатих. Шулаймы?
Илнур. Әйе. Ат күрсә, селәгәе агып төшә.
Нурфатих. Кызык.
Илнур. Патаму што әтисенең аты бар.
Нурфатих. Шулаймы?

Илнур. Шулай шул.

Нурфатих. Атланып йөриме соң?

Илнур. Ат өстеннән төшкәне юк. Арбадан — утарга, утардан арбага хәтле.

Нурфатих. Ә синең атка атланганың бармы?

Илнур. Ишәккә атланганым бар. Мин бит местный район егете, авыл егете түгел. Ә синең үзеңнең?

Нурфатих. Мин хәзер дә атланып йөрим. *(Илнур көлеп җибәрә.)* Нигә көләсең?

Илнур. Син атланган атны кызганып.

Нурфатих. Димәк, сиңа теге машина ошады инде?

Илнур. Һе, ошамаска... Класс!

Нурфатих. Ә синең техникаң бармы?

Илнур. Әйттең инде. Мин бит әле молодой. Каян килеп булсын ди.

Нурфатих. Сәгатең дә юкмыни?

Илнур. Юк.

Нурфатих. Ә иптәш малайларыңныкы бармы соң?

Илнур. Кайберләренең бар, кайберләренеке юк. Ә менә Сыбызгыныкы өчәү!

Нурфатих. Берүзенә өчәүме?

Илнур. Ә ул барыбер ватып бетерә. Әйбер кадерен белми ул Сыбызгы.

Нурфатих. Кем инде ул Сыбызгы?

Илнур. Дус малай. Исеме — Габделфәрт.

Нурфатих. Нигә инде Сыбызгы?

Илнур. Борыны гел сызгырып йөри. Йоклаганда да сызгыра. Сәпитләрен гел мин ремонтлап бирәм. Әле бүген дә иртә белән кергән иде. Тәгәрмәч тишелгән, рәтләп бир әле, дип. Домкратсыз булмый, дип чыгардым. Домкрат эзли торгандыр.

Нурфатих. Ә нигә син дә алмыйсың?

Илнур. Нәрсә?

Нурфатих. Велосипед.

Илнур. Кем алсын миңа?

Нурфатих. Әтиең.

Илнур. Мин туганчы, әти Каспий диңгезенә тоз чыгарырга киткән бит.

Нурфатих. Кайтканы юкмы?

Илнур *(күңелсезләнеп)*. Әти юк шул минем, абый.

Нурфатих. Шулаймыни? Ә син борчылма. Озакламый үзең әти булырсың. Ә минем синең яшьтә велосипед бар иде.

Илнур. Әтиең алып биргәндер.

Нурфатих. Үзем алдым.

Илнур. Алдың... Ялганла. Минем яшьтә сәпит алырсың бар. Әнидән сорап-сорап караган идем дә, мотоцикл бәясе ул, ди. Идән юган акчага алып булмый, ди.

Нурфатих. Ә мин көрәшеп алдым. Сабантуйда.

Илнур. Мин дә көрәшкә йөргән идем дә, тренер әйтте, хәлең юк, көрәшче чыкмый. Авызыңнан бәрәңге күренеп тора, диде. Хәзер кушаматым да Бәрәңге.

Нурфатих. Кайсы тренерга йөрдең?

Илнур. 2 нче мәктәпкә.

Нурфатих. Борчылма. Без ул тренердан кишер ясарбыз. Димәк, син теге машинаның шоферын көтәсең инде.

Илнур. Көтмим. Көтүдән файда юк. Барыбер чыкмый ул. Йокларга ярата бугай ул. Караңгы төшкәнче көткәнем бар.

Нурфатих. Ул машинаның шоферы мин булам.

Илнур. Юк. Мин синең машинаңны беләм. Үзеңне дә беләм. Зур начальник син. Сине күрүгә, урамдагы бөтен исерекләр качып бетә. Милицияләр дә честь биреп кенә калалар. Кем булып эшлисең син, абый?

Нурфатих. Минме? Мин... Син башта үзең әйт. Үскәч кем буласың?

Илнур. Башта сорауны мин бирдем.

Нурфатих. Глава.

Илнур. Алайса, мин дә глава булам.

Нурфатих. Нигә?

Илнур. Главаның машинасы шәп икән.

Нурфатих. Ә мин синнән хәзер үк глава ясыйм.

Илнур. Шаяртма. Мин әле мәктәп баласы гына.

Нурфатих. Ә мин мәктәптә укыганда ук глава идем.

Илнур. Ничек инде глава?

Нурфатих. Сиңа сәпит кирәкме, әллә юкмы?

Илнур. Кирәген кирәк тә...

Нурфатих. Кирәк булгач, димәк, сәпиттән башлыйбыз. Дусларың күпме?

Илнур. Дачурта.

Нурфатих. Менә шуларга син глава булырсың.

Илнур. Ничек итеп?

Нурфатих. Чөгендер чүбен утый беләсезме?

Илнур. Юк.

Нурфатих. Өйрәтерләр. Иртәгә күпме дусларыңны җыя аласың, барысын да чөгендер басуына алып бар. Чөгендер басуын беләсеңме?

Илнур. Табарбыз.

Нурфатих. Эш беткәч, барыгызга да велосипед алып бирәм.

Илнур. Ну да. Алдыйсың.

Нурфатих. Алдакчы кеше глава булалмый.

Илнур. Күпме килсәк тәме?

Нурфатих. Күпме килсәгез дә.

Илнур. Алар миңа ышанмас. Бәрәңге кушаматы да бик җиткән. Сәпит тагарлар.

Нурфатих. Ә син ышандыр. Глава ышандырырга тиеш.

Илнур. Ничек итеп?

Нурфатих. Анысын үзең уйла инде. Син аларны чөгендер басуына җибәр. Ә үзең бирегә, минем янга кил. Җидегә килеп җиталасыңмы?

Илнур. Җитәм.

Нурфатих. Ә без, ике глава, минем машина белән барырбыз. Менә шул агроном абыең кушканны җиренә җиткереп, сыйфатлы итеп эшләсәгез, барыгыз да велосипедлы булырсыз. Аннары көз көне стадионда велосипед ярышы үткәрербез. Кем тизрәк йөри, аңа спортивный велосипед бүләк итәбез. 45 скоростьлы.

Илнур *(гаҗәпләнеп)*. 45 скоростьлы?!

Нурфатих. Кем белә. Бәлки, сезнең арадан да чемпионнар килеп чыгар. Чемпион буласың икән, минеке кебек машиналы буласың. Менә үз эшеңнең главасы буласың да куясың. Килештекме?

Илнур. Килештек.

Нурфатих. Бир бишне!

Илнур *(Нурфатих Аббасовичка кулын суза)*. Глава булу чепуха икән ул.

Нурфатих. Аның бернәрсәсе дә юк. Җидедә көтәм.

Илнур. Абый, машинаңны юыйммы?

Нурфатих. Булачак главага машина юдыру килешмәс. Син лутчы чөгендердән башла.

Илнур. Рәхмәт, абый. Җидедән дә соңга калмый килеп җитәрмен.

Нурфатих. Давай! *(Илнур шатланып чыга башлый.)* Ә, тукта әле. Чөгендер чүбен утарга нәрсә кирәк?

Илнур. Кәкре көрәк.

Нурфатих *(шаркылдап көлеп)*. Син үзең кәкре көрәк. Кәтмән, диген.

Илнур. Аңладым, абый, әйе, әйе, кәлтән. *(Чыгып йөгерә.)*

Нурфатих *(көлеп)*. Ә кем белә. Бәлки, шушы кәлтәннәр арасындадыр югары белемле агрономнар. *(Селектор кнопкасына баса.)* Гөлшат, Үзәк белән тоташтыр.

Гөлшат *(тавышы селектордан ишетелә)*. Аңладым, Нурфатих Аббасович.

Нурфатих *(рәхәтләнеп көлеп)*. Кәкре көрәк. Кәлтән...

Гөлшат *(селектордан)*. Нурфатих Аббасович, Үзәк сезне тыңлый.

Нурфатих *(селекторга баса)*. Үзәкме?! Хәйриевме? Хәйриев, иртәгә иртән җидедә чөгендер басуына 5—6 велосипед илтеп куй! Нәрсә?! Конечно, яңаны. Иске велосипед җыеп,

чөгендер басуында сервис ачарга иртәрәк әле, Хәйриев. Акча юк?! Тап! Син бит авыл хуҗасы. Тап, димен! Синең ничә машинаң бар?! Икәү... Ә менә Кәлтәновның утырып йөрергә велосипеды да юк. Нинди Кәлтәнов, нинди Кәлтәнов?.. Районның киләчәге. Менә үзегез икешәр машинага утырып чабасыз да, җирдән кәлтәләр кача. Аңлашылдымы?! Аңлашылса, эшлә! Ишетсен колагың, иртәгә сәгать җидедә яңа глава белән синең чөгендер җирендә булабыз. Нинди яңа глава дисеңме?.. Кәкре Көрәк Кәлтәнович белән. *(Селектор кнопкасына баса да тәрәзә янына килә.)* Кара, кара тегене, минем машинаны юып ята түгелме?! Урамда трай тибеп, тәмәке тартып йөргәнче, акчаның тәмен сизәрләр. Кем белә, бәлки, шушылар арасындадыр көчле инженер-механизаторлар, шушылар арасындадыр дөнья чемпионнары.

Бүлмәгә Гөлшат килеп керә.

Гөлшат. Нурфатих Аббасович, приемныйда, исәнлек-саулык та сорашмыйча, ике кеше туп-туры сезнең кабинетка кермәкче була.

Нурфатих. Сеңлем, ашыгып кергән кеше ашыгып чыгып та китә ул. Керсеннәр!

Гөлшат чыгып китә. Бүлмәгә ике кеше килеп керә. Берсе — чандыр гәүдәле, кара костюм-чалбардан, ак күлмәк, галстуктан, икенчесе — кыска чәчле, төптән юан чыккан таза гәүдәле, күн җиңсез куртка кигән, үзе бертуктамый сагыз чәйни. Чандыр, исәнлек-саулык та сорашмыйча, Нурфатих янына килеп утыра да аякларын аякка куя. Үшән ишек төбендә кала.

Чандыр *(сәгатенә карап)*. Стоп паровоз. Мин билгеләнгән вакытка килеп җиттем. *(Куен кесәсеннән ике конверт чыгарып, Нурфатих Аббасович каршына куя.)* Үзеннән сезгә сәлам хаты.

Нурфатих *(ишек төбендәге диванга ишарә ясап, кыска чәчлегә)*. Утырыгыз! Аяк өсте күшәп торган кешене сөймим. Алдында ризык беткән сыерны хәтерләтәсең. *(Үшән креслога утыра. Конвертларны кулына ала.)* Сәлам хаты, дисез инде. *(Конвертның беренчесен ача.)* Карап карыйк. Нинди сәлам икән. *(Конверттан чек тартып чыгара.)* Крупная сумма. Моңа берне түгел, икене алып була.

Чандыр. Безгә бирәү дә җитә.

Нурфатих. Юмарт күренәсез.

Чандыр. Үзе!

Нурфатих. Кем инде ул үзе?!

Чандыр. Күзгә күренмәс, кулга тотып булмас безнең шеф!

Нурфатих. Кулга тотып булмас, күзгә күренмәс... Да... Значит, безнеңчә, сквозняк! *(Икенче конвертны ача.)* Монда

нинди хикмәт бар икән?! *(Конверт эченнән бер бөртек шырпы тартып чыгара.)* Да... *(Шырпыны өскә күтәрә.)* Шырпы!.. Аңлашылды. *(Селекторга басмакчы була, Чандыр урыныннан тора.)*

Чандыр. Шаярмагыз! Кулыгызда шырпы. Сызгычы бездә.

Нурфатих. Өстәвенә сез куркак та икәнсез. Мин секретарьны чакырмакчы идем.

Чандыр. Без секретаря обойдемся!

Нурфатих. Нет, не обойдемся. Мин бит татар. Татар кунакны болай каршы алмый. *(Эчке бүлмәгә кереп китә дә ике кулына 4 шешә күтәреп чыга.)* Сеңлем Гөлшат, кер әле!

Бүлмәгә Гөлшат керә.

Гөлшат. Тыңлыйм сезне, Нурфатих Аббасович!

Нурфатих. Өстәлгә кабымлыклар куй!

Гөлшат. Яхшы. *(Эчке бүлмәдән кабымлыклар чыгара башлый.)*

Нурфатих *(кулы белән Чандырга ишарә ясап)*. Биредә утырыгыз! Өстәл янына. *(Чандыр өстәл янына килә башлый.)* Ә сез үз урыныгызда утырыгыз! Сыерлар тоз ялаганда, бозаулар боз ялый.

Гөлшат. Нурфатих Аббасович, сезгә чәйме, әллә кофемы?

Нурфатих. Чәй эчкән бар. Әнә тегесен, катысын!

Гөлшат *(Чандырга)*. Сезгә?

Нурфатих. Кытай чәй белән нәрсә эшләгән, ди. Аңа да миңа салганны. Аңа түгел, икебезгә дә 12 кырлы стаканга тутырып сал!

Гөлшат. Яхшы. *(Стаканнарга тутырып аракы сала.)*

Нурфатих *(Гөлшатка)*. Бар, теге бүлмәдән видеокамераны алып чык та, әнә теге ишек төбендә утырган абыеңа бир!

Гөлшат. Яхшы. *(Эчке бүлмәдән видеокамера алып чыга да Үшәнгә бирә.)* Рәхим итегез.

Нурфатих *(Гөлшатка)*. Ә хәзер безне калдыр.

Гөлшат. Ашларыгыз тәмле булсын! *(Чыгып китә.)*

Үшән *(видеокамераны әйләндереп карый-карый)*. Не понял?!

Нурфатих. Поймешь! Куллана беләсеңме?

Үшән. Когда-то учили.

Нурфатих. Ну и вот. Молодец! Ученого учить не надо. *(Кулына стаканны тотып торып баса.)* Ә син снимай!

Үшән. Зачем?!

Нурфатих. Потому! На память. Үзенә алып кайтып би-

рерсез. Хәзер минем тостны тыңлагыз. *(Өстәлдә яткан чекны кулына ала.)* Бу чекны мин сезгә бүләк итәм. Ә шырпыны истәлеккә алып калам. Кайбер булдыксызларны чәйнәп йотканда, теш казырга кирәге чыгар. Ә атны мин сезгә бушлай бирәм.

Чандыр. Безне кызыксындырганны.

Нурфатих. Ягъни.

Чандыр. Безнең шефның атын узганчы.

Нурфатих. Тост! *(Ушәнгә.)* Ә син снимай! Атка атланасы кеше һәрбер әйтелгән тостка шушы стаканга салынган эчемлекне төбенә кадәр эчеп бетерергә тиеш.

Чандыр. Ә соңыннан?

Нурфатих. Әйтеләсе тостлар әйтелгәч, эчәсе аракылар эчелеп беткәч, атларга атланабыз. Кем кемне аттан бәреп төшерә, шул атлы була. Хөрмәтле кунак, әйдәгез, без атланасы атлар исәнлегенә! *(Стакандагы аракыны эчеп куялар.)*

Чандыр. Сез миннән Балда ясамагыз.

Нурфатих. Сез миңа ике конверт бирдегез. Мин сезгә бер генә конверт ачам. Йә бушлай атлы буласыз, йә булмаса...

Чандыр. Булмаса нәрсә?!

Нурфатих. Синең бер хикмәтле хикәя ишеткәнең бармы?

Чандыр. Сөйлә.

Нурфатих. Бер бай кеше авырып урынга яткан. Телсез калган. Янына хатыны, балалары җыелган. Хатыны әйткән: «Карт, китәсең бугай инде. Алтыннарыңны кая яшердең?» Карт көч-хәл белән ике бармагын өскә күтәргән дә хәлсезлектән аңын җуйган. Тегенең балалары өй артында үскән куш каенны да, сиртмәле коеның пар баганасын да чокып аударганнар, әмма алтынны тапмаганнар. Бер атнадан карт терелеп аягына баскан. Хатыны сорый икән: «Әй карт, тәмам котны алдың. Үлә дип торабыз бит. Алтыннарың кая дип сорагач, ике бармагыңны күрсәттең, ул нәрсәне аңлата иде соң?» Карт: «Әй карчык, карчык. Хәл юк иде бит. Өченчесен китерә алмадым. Ул менә моны аңлата иде» *(Чандырның борын астына кукиш ясап куя)*,— дип әйткән, ди.

Чандыр. Ә мин эчмим!

Нурфатих. Көчләмим. Ат кирәк булса, эчәрсең. Минем условия, минем конверт.

Чандыр. Бездә сухой закон!

Нурфатих. Нинди илдә яшәгәнеңне беләсеңме?!

Чандыр. Беләм!

Нурфатих. Беләм. Безнең илдә өч кеше җыела да законны үзгәртә. Күрәсең, без дә өчәү!

Чандыр. Аракы белән бу эшне хәл итеп булмый.

Н у р ф а т и х. Ялгышасың! Урыс дәүләтендә аракысыз бер эшне дә хәл итеп булмый.

Ч а н д ы р. Яхшы... *(Эчә.)* Сал тагы.

Н у р ф а т и х. Үзеңә үзең сал! Кул артым авыр. Аттан егылып төшәрсең дә, мин эчерткән, диярләр. *(Ушәнгә.)* Ә син снимай, снимай! *(Икесе дә стаканнарга тутырып аракы сала.)*

Ч а н д ы р. Сезнең исәнлеккә! *(Эчеп куя.)*

Н у р ф а т и х. Рәхмәт. Миңа исәнлек кирәк. Балаларны аякка бастырасы бар. Нәселгә килсәк, нәсел озын гомерле. 90 га кадәр яшәргә исәп. *(Эчеп куя. Тагын стаканнарны тутыралар.)* Син атланасы атның исәнлеге өчен! *(Эчеп куя.)*

Ч а н д ы р. Ә мин син атланасы атның исәнлеге өчен эчәм! *(Эчеп куя. Тагын стаканнарга аракы салалар.)*

Н у р ф а т и х *(стаканны өскә күтәрә)*. Дәвам итәбезме?

Ч а н д ы р *(җырлап җибәрә)*. Стоп паровоз!

Н у р ф а т и х. Дөрес. Атланма тайның биленә, сындырырсың. *(Җырлап җибәрә.)* Замирзал ямщик.

Ч а н д ы р. Ә мин сине кызык итәм. Сиңа үч итеп, җәяү кайтам.

Н у р ф а т и х. Дөрес эшлисең. Ат өстенә менеп имгәнгәнче, җәяү кайтуың хәерлерәк. *(Ушәнгә.)* Китер камераны?! *(Ушән камераны Нурфатих Аббасовичка китереп бирә. Нурфатих Аббасович кассетаны чыгара да Чандырга бирә.)* Мә! Истәлек өчен үзенә алып кайтып бир!

Ч а н д ы р. Болай булмый. Бу не честно!

Н у р ф а т и х. Мин ике стакан аракы эчеп, үз маңкасы белән үзе уйнаган кешене ат көтүчесе итеп тә куймыйм. Сезнең белән разговор бетте! *(Ушәнгә.)* Ә менә бу шырпыны шефыгызга алып кайтып бирегез. Артык җоннарын өтә торсын. Кулы җитмәгән җирен үзем барып өтеп кайтырмын. Нинди әле ул сезнең, күзгә күренмәс, кулга тотып булмасмы?! Мин ат духтыры. Кайтып әйтегез! Аның бердәнбер йомшак җире менә минем уч төбендә. Менә шушы кулларым белән шундый итеп кастрировать итәрмен, газиз хатынына да керәге калмас. Ә хәзер күземнән югалыгыз! Быстро! *(Чандыр белән Ушән чыгып китәләр.)* Ат кирәк булган... Атка атланыр өчен, аттан акыллы булырга кирәк әле үзеңә.

Бүлмәгә Г ө л ш а т килеп керә.

Г ө л ш а т. Нурфатих Аббасович, өстәлне җыештырсам ярыймы?

Н у р ф а т и х. Юк. Соңрак. Утыр әле. Мине бүген кемнәр эзләде?

Г ө л ш а т. Казаннан Рәсимә апа шалтыратты. Сезнең хуҗалыкларга чыгып киткән чагыгыз иде.

Н у р ф а т и х. Нәрсәгә икәнен әйтмәдеме?

Г ө л ш а т. «Казанга кайчан килә икән. Килгәч, керми китмәсен әле» диде. Берсекөнгә бара, дидем.

Н у р ф а т и х. Әйт әле, сеңлем, хатын-кызның бәхетле мизгелләре нәрсәдә?

Г ө л ш а т. Сәламәтлектә.

Н у р ф а т и х. Тагын?

Г ө л ш а т. Минем әни әйтә: «Кыз баланың бәхете иреннән тора,— ди.— Хатын-кыз ир бәхете, ир дәрәҗәсе белән яши»,— ди.

Н у р ф а т и х. Әниеңә кайтып әйт. Әниең дөрес әйтми. Менә Рәсимә апаң алай уйламый. Рәсимә апаң башкача уйлый. Бар, кайт. Соң инде.

Г ө л ш а т. Ә өстәл?..

Н у р ф а т и х. Иртән Мәхфүрә апаң җыештырыр.

Г ө л ш а т. Исән булыгыз, Нурфатих Аббасович!

Н у р ф а т и х. Сау бул! *(Гөлшат чыгып китә. Нурфатих бүлмә буйлап йөри.)* Рәсимә башкача уйлый... *(Барып утны сүндерә. Әкрен генә музыка астында ут сүнә башлый. Нурфатих диванга килеп ята.)* Рәсимә алай уйламый.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнәнең бер ягында ут сүнә, ә өстәге мәйданчыкны прожекторлар яктырта. Сәхнәнең ике ягыннан, шат күңел белән көлешә-көлешә, Н у р ф а т и х белән Р ә с и м ә йөгереп менәләр. Аларның яшь чагы.

Н у р ф а т и х. Кызый, без кайчан бергә булырбыз?!

Р ә с и м ә. Бергә басып торабыз лабаса.

Н у р ф а т и х. Басып тору туйдырды шул, ятып торасы килә. Сиңа балалар бүләк итәсе килә. Ата буласы килә.

Р ә с и м ә. Нәрсә, безнең авылга килү туйдырдымыни?

Н у р ф а т и х. Мин иренә торганнардан түгел, колхоз атларын җәллим. Мине күрүгә, башларын читкә боралар. Төннәрен күпме урларга була инде аларны. Көндез арба тартып, төнлә минем белән свиданиегә йөреп, тәмам арыдылар, бичаралар.

Р ә с и м ә. Ә син җәяү кил! Җәяү килергә иренәсеңмени?

Н у р ф а т и х. Җәяү килергә иренмим, җәяү кайтырга иренәм. Килгәндә, ашкынып киләм, синнән аерылгач, кайтасым килми. Яратам мин сине, кызый. Йә кияүгә чыгасың, йә мин иртәгә үк башкага өйләнәм.

Р ә с и м ә. Мин дә сине яратам.

Н у р ф а т и х. Яраткач, чык инде миңа кияүгә?!

Р ә с и м ә. Ашыкмыйк инде, Нурфатих. Институтны бетерик.

Н у р ф а т и х. Бетте дияргә була бит инде.

Р ә с и м ә. Ә син миннән туймассыңмы?

Н у р ф а т и х. Тәмле әйбер туйдырмый ул.

Р ә с и м ә. Күп ашасаң, туйдыра.

Н у р ф а т и х. Ә бит син күп түгел. Күрәсең, минем янда кеп-кечкенә, җимеш кенә.

Р ә с и м ә. Ә син мине бәхетле итәрсеңме?

Н у р ф а т и х. Миңа исемне әбием кушкан. Нурфатих булсын, дигән. Бөтен җиһанга нур бөркеп торсын, ә фатих — яулап алучы, җиңүче мәгънәсен аңлата. Мин синең күңелеңне яулап алып, аңа нур сибүче булырга тиеш.

Р ә с и м ә. Нәрсә соң ул нур?

Н у р ф а т и х. Нур ул — безнең икебездән туган балаларның идән тотырып, шат йөз, шат күңел белән йөгереп йөрүләре.

Р ә с и м ә. Идән тутырып...

Н у р ф а т и х. Әйе, әйе, Рәсимә, идән тутырып.

Р ә с и м ә. Минем көчем җитәрме?

Н у р ф а т и х. Җитәр, Рәсимә, җитәр. Мин сиңа сабантуй батырлары бүләк итәрмен.

Р ә с и м ә. Ашыкмыйк, Нурфатих, ашыкмыйк. Мин синеке, бары тик синеке генә. Бу җирдә бергә яшәп, бу җирдән бергә җитәкләшеп китәргә язсын, Ходаем!

Н у р ф а т и х. Көзен туй ясарга ризамы син?

Р ә с и м ә. Риза, Нурфатих, көзгә риза.

Н у р ф а т и х. Мин сине гомерем буе салкын җилләрдән саклармын.

Р ә с и м ә. Минем теләкләремне тормышка ашыра алырсыңмы син? Әзерме син? Син, син мине бәхетле итәрсеңме, Нурфатих?!

Н у р ф а т и х. Бәхет ул — мизгел! Адәм баласының төрле чаклары була: көлгән, елмайган чаклары да, елаган чаклары да. Син миннән кояшны сорарсың, мин алып бирә алмам. Сиңа күңелсез булыр. Син миннән бала сорарсың — мин сиңа аны бирермен. Син шатланырсың. Синең өчен, Рәсимәм өчен, кулымнан килгәннең барысын да эшләрмен. Ә син миңа күп итеп таза балалар табарсың. Без әти белән әнинең идәнен тутырып үстек.

Р ә с и м ә. Миннән генә торса, табармын, Нурфатих, табармын.

Н у р ф а т и х. Рәсимә, әнә күрәсеңме, безгә карап ай елмая.

Р ә с и м ә. Күрәм, Нурфатих, күрәм. Ярым ай.

Нурфатих. Ә мин шул айдан бишек ясармын да, син балаларны шунда тирбәтерсең.

Рәсимә. Ә без анда ничек менәрбез?!

Нурфатих. Җылы яңгырдан соң салават күперенә басып менәрбез.

Рәсимә. Ул бит ерак.

Нурфатих. Ә мин сине нурлы атка атландырып алып менәрмен.

Рәсимә. Иярне син тотарсыңмы?

Нурфатих. Мин тотармын.

Рәсимә. Төшкәндә, ничек төшәрбез?

Нурфатих. Ләйсән яңгыр булып җиргә яварбыз.

Рәсимә. Юк. Без ул бишектә улыбызны үстерербез дә кире салават күперенә басып төшәрбез.

Нурфатих. Иярне кем тотар?

Рәсимә. Улыбыз тотар. Ә син, салкын җилләрдән безне ышыклап, яныбыздан атларсың. Нурфатих, әнә күрәсеңме, бер йолдыз атылды.

Нурфатих. Күрәм.

Рәсимә. Ә ул безнең йолдыз иде.

Нурфатих. Юк, юк, ул безнең йолдыз түгел.

Рәсимә. Ул безнең йолдыз иде, безнең йолдыз иде, вакытсыз атылган безнең йолдыз.

Музыка. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Астагы кабинет урынында Нурфатихлар фатирының бер бүлмәсе. Нурфатих хатынына аптырап карап тора. Рәсимә ишек төбенә чемоданын китереп куя.

Нурфатих. Китәм, дисең инде?

Рәсимә. Безнең йолдыз атылды, Нурфатих.

Нурфатих. Мине ялгыз калдырып китәсеңме?!

Рәсимә. Нурфатих, син мине яхшы беләсең. Сәламәтлегем юк икәнен дә беләсең. Син таза, сау-сәламәт. Мин сиңа хатын була алмыйм. Син әле көчле. Синең әле чәчәк аткан чагың. Мин сиңа аш-су әзерләп торудан ары берни дә эшли алмыйм.

Нурфатих. Миңа шунысы да җиткән.

Рәсимә. Юк, Нурфатих. Сиңа таза, яшь хатын кирәк. Сиңа берсеннән-берсе таза, сау-сәламәт балалар кирәк. Син башкага өйлән. Бәхетле бул. Безне ташлама. Казанга килгән чакларыңда, безне урап узма. Безнең йорт — синең йорт. Синең анда ике балаң бар.

Нурфатих. Рәнҗемә миңа, Рәсимә. Мин сине бәхетле итә алмадым.

Рәсимә. Бәхет ул — мизгел. Адәм баласы тоташ бәхетле генә була алмый. Бу синең сүзләр. Бу хак сүзләр. Син миңа бәхетле мизгелләр күп бүләк иттең. Көрәшче малай таптырдың — шатландым. Кыз бүләк иттең — куандым. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа. Мин бу җирдә кала алмыйм. Балаларым янына китәм.

Нурфатих. Мин сине айга алып менә алмадым.

Рәсимә. Мендек, Нурфатих, мендек. Узган гомеребездә атның ияреннән син тоттың. Ә инде хәзер иярдән балалар тота.

Нурфатих. Ә мин?..

Рәсимә. Ташлама безне, Нурфатих. Яныбыздан бар. Салкын җилләр килеп бәрелгәндә, синең барлыгыңны тоеп яшик. Бәхетле бул. *(Чыгып китә.)*

Көчле музыка. Ут сүнә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Прожекторларның берсе салмак кына сәхнәнең өске ягын яктырта. Сәрбия әби басып тора. Ә аскы мәйданда, диванда, Нурфатих йоклап ята.

Сәрбия әби. Улым, арыгансың. Әллә тарткан йөгең авырмы?

Нурфатих *(микрофоннан тавышы ишетелә)*. Авыр шул, әби.

Сәрбия әби. Башыңны югары тот, балам. Артыңа борылып карама.

Нурфатих. Борыласы килгән минутлар да була шул, әби.

Сәрбия әби. Артка борылу егетлек түгел. Артыңнан улың килә, балам.

Нурфатих. Ышанычымны аклармы, әби?

Сәрбия әби. Аклар, улым, аклар.

Нурфатих. Билен бирмәсме?

Сәрбия әби. Хакы юк. Сез Аббаслылар. Аббаслыларның бил бирергә хакы юк. Бил өчен нәрсә кирәк соң, улым?

Нурфатих. Сәламәтлек!

Сәрбия әби. Сәламәтлек өчен нәрсә кирәк, балам?

Нурфатих. Икмәк!

Сәрбия әби. Икмәк үстерер өчен нәрсә кирәк соң, балам?

Нурфатих. Хезмәт!

Сәрбия әби. Хезмәтне сөяр өчен нәрсә кирәк, әй бала?

Нурфатих. Аек акыл.

Сәрбия әби. Аек акылда — аек тормыш, балам.

Салмак кына музыка астында ут сүнә. Ут янганда, сәхнә буш. Шыбырдап яңгыр ява, күк күкри. Нурфатих яланаяк яңгыр астында йөри, куллары югарыда. Бераздан, йөгереп, алгы планга килә. Тамашачыга карап тезләнә, кулларын алга суза.

Нурфатих. Улым, улым, кил әле яныма, кил! *(Сәхнәгә биш яшьлек Рәшит килеп чыга.)* Улым, салып ташла әле аягыңнан! Җир кешесе бит син, балам! *(Рәшитнең аяк киемнәрен салдыра.)* Әйт әле, улым, нәрсә ява?

Рәшит. Яңгыр.

Нурфатих. Яңгыр түгел, улым, икмәк ява! *(Рәшитне иңсәсенә утырта.)* Хөрлек, муллык ява!

Музыка. Ут сүнә.

Пәрдә

# Кызлар капкыны

*Комедия ике пәрдәдә, җиде күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Миненур — артистка.
Зөбәрҗәт — артистка.
Галия — артистка.
Мәрдән — артист.
Рөстәм — Миненурның ире.
Гөлҗәүһәр — Мәрдәннең әнисе.
Сәмига — ирдән иргә йөрүче хатын.
Миңлехәбиб — тире җыю артеленең тире тозлау цехы мөдире урынбасары.

Вакыйга бүгенге көннәрдә шәһәр җирендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Театр артистлары бизәнә торган грим бүлмәсе. Галия белән Зөбәрҗәт җырлый-җырлый бизәнеп утыралар.

Галия (*җырлый*).

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр пыяла.
Хәзер дөнья егетләре,
Кызлар күрсә, ояла.

Зөбәрҗәт (*җырлый*).

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр мунчала.
Безгә кияү чыкмый калмас,
Ышанабыз, иншалла!

Зөбәрҗәт, Галия (*икесе бергә*).

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр ислемай.

Безгә дигән егетләрнең
Борын асты кипмәгән.

Бүлмәгә кабалана-кабалана Миненур килеп керә дә үз өстәле артына бизәнергә утыра.

Миненур. Сәлам кызларга, һавадагы йолдызларга!

Галия. Алланың биргәненә шөкер. Йолдыз ук булмасак та, милләтебез күгендә балкыйбыз. Таныйлар. Трамвай-троллейбуста да төртеп күрсәтәләр.

Миненур. Танырлар шул. Егерме ел буена бер пальто киеп йөргәч...

Зөбәрҗәт. Әле кичә бер кибеткә кергән идем. Чираттагы кешеләрнең күзләре миндә.

Миненур. Миңа рәхәт, мине танымыйлар.

Галия. Гомер буе эпизодта уйнап, сәхнәгә башыңны тыгып кына алгач, билгеле, танымыйлар.

Миненур. Бер тыгам — берәгәйле тыгам. Миннән соң сәхнәдә калганнарга ничу делать. Пәрдәне ябасы гына кала.

Зөбәрҗәт. Туйдым, кызлар. Гомер буе героиняларны уйнап туйдым. Хут бирмиләр. Шәһәрдә бер алдыма, бер артыма төшәләр.

Миненур. Тирә-якка бер чибәр бит.

Зөбәрҗәт *(операда җырлана торган тавыш белән җырлый башлый)*.

Мин чибәр, мин гүзәл,
Шуңа күрә йолдыз да.
Мин чибәр, мин матур,
Шуңа күрә йолдыз да.

Миненур *(аңа каршы җырлый)*.

Син чибәр, син гүзәл,
Күрсәң, гайрәтең чигәр.
Син чибәр, син гүзәл,
Күрсәң, гайрәтең чигәр.

Битеңә кило ярым грим сөрткәч, түзәрлек.

Зөбәрҗәт. Үзең соң, үзең?!

Миненур. Ходай матурлыкны бирмәгән, чибәрлекне җәлләмәгән. Шулай да, Аллага шөкер, кияүгә чыгып кайттым.

Зөбәрҗәт. Чыгып кына кайттың шул.

Галия *(торып баса да, уң кулын алга сузып, горур кыяфәт ясап)*.

Әй Зөбәрҗәт, һай Зөбәрҗәт,
Сәхнәләрдә уйныйсың да көләсең!
Җитәр инде, чык кияүгә...
Кияү күрми үләсең!

Зөбәрҗәт. Минем әле барысы да алда!

Миненур *(куллары, аяклары белән паровоз ясап)*. Птчк,

птчк, птчк, птчк, птчк, птчк... *(Паровоз булып кычкырып.)* По-о-о... Паровоз ушел... Яшь бит утызда...

Галия. Миненур, җитте. Бар кеше дә син түгел. Кияүгә чыгу дан түгел. Ошаса, чык та кайт, чык та кайт.

Миненур. Минем быелга нормам тулды. Эх, кызлар. Нигә бу дөньяда гаделлек юк икән?

Галия. Нигә?

Миненур. Рөстәмкәем белән егерме өч кенә көн яшәп калдым. Егерме өч көн егерме өч минут кебек узды да китте. Нинди егет иде! Күземә генә карап тора иде. Ят, дисәм — ята, тор, дисәм — тора, шуыш, дисәм, мунчаласы белән идән буйлап шуыша иде.

Галия. Шуңа да синнән тизрәк качкан инде ул.

Миненур. Иҗатыма гашыйк иде. Җир йөзендә синең кебек артистка юк, дия иде. Синең кебек усал хатыннарны тормышта түгел, сәхнәдә дә уйнап булмый, дия торган иде.

Зөбәрҗәт. Дөрес әйткән.

Миненур. Настоящий критик!

Галия. Хәзер үзен күргәнең бармы соң?

Миненур. Булмыйча. Мине күрсә, урамның икенче ягыннан уза. Бер бөртек ирем булды, тормышта яшәрлек итеп күзен ачып җибәрдем. Миннән соң аңа кияүгә чыккан хатын-кыз бик бәхетле була инде.

Галия. Нигә?

Миненур. Ашарга пешерергә өйрәттем, кер юарга өйрәттем, үтүкләргә өйрәттем. Тагын нәрсә кирәк?!

Зөбәрҗәт. Булдыргансың, молодец! Синнән котылу бәхетеннән түшәмгә сикергәндер. Галия, бүген спектакльдән соң минем белән барасыңмы?

Галия. Кая?

Миненур. Мин барам.

Зөбәрҗәт. Миненур, кая барасың?

Миненур. Синең белән.

Зөбәрҗәт. Мин кая барам соң?

Миненур. Охотага! Егетләр ауларга!

Зөбәрҗәт. Уеңда гел егетләр. Мин туйга барам.

Галия. Кемнең туена?

Зөбәрҗәт. «Яңа татар» кызын кияүгә бирә.

Миненур. Мин барам. «Яңа татар»ларның өстәлләре шәп була.

Галия. Туганыңмыни?

Зөбәрҗәт. Юк инде. Тамада булып, туй алып барырга.

Миненур. Күпме түлиләр?

Зөбәрҗәт. Өч мең.

Миненур. Доллар беләнме?

Зөбәрҗәт. Юк, алтын белән.

Миненур. Тоттырганнар ди алтын! Мин бармыйм. Өч мең доллар бирсәләр дә, бармыйм.

Зөбәрҗәт. Бик барыр идең дә, сине чакырмыйлар шул. Аның өчен талант кирәк шул, тел кирәк!

Галия. Бии белергә кирәк.

Зөбәрҗәт. Җырлый белергә кирәк.

Миненур. Эчегез инде, эчегез, дип, сигезгә бөгелергә кирәк. Миңа институтта капкорсак «яңа татар», «яңа урыс» тыгынганда, каршыларында биеп, тәлинкә тотып торырга диплом бирмәделәр. Минем эш урыным — сәхнә, вазифам — тамашачы тәрбияләү.

Зөбәрҗәт. Син бит бай. Сиңа акча кирәкми. Минем кебек егерме ел бер пальто киеп йөрмисең. Театрдан алган барлы-юклы акча белән кая барыйм?

Миненур. Пальтомның кире ягын әйләндереп кисәм киям, әмма алар алдына чыгып, артистка дигән исемемә тап төшермим. Акча ул... акча җирдә аунап ята. Ә талантлар йөз елга бер туа. Телисезме, мин сезне үзем эшкә алам?

Галия. Кем итеп?

Миненур. Артистка итеп. Халык тәрбияләргә, халыкны, кешеләрне бәхетле итәргә. Адашканнарга туры юл күрсәтергә. Театрга! Яңа образлар тудырырга!

Зөбәрҗәт. Без болай да театрда эшлибез.

Миненур. Яңа театрга! Минем театрга!

Галия. Синең театрга?!

Миненур. Әйе, минем театрга.

Зөбәрҗәт. Сиңа тагын театр ачу.

Галия. Ачылган театрны ябарга торалар...

Зөбәрҗәт. Нинди театр ачмакчы буласың инде?

Миненур. Сатира театры.

Галия. Ә репертуар?

Миненур. Без яшәгән бүгенге көн — үзе сатира.

Зөбәрҗәт. Кайда уйнамакчы буласың?

Миненур. Иптәш кызым бер елга чит илгә контракт белән эшкә китте. Аның залы тамашачы залы кадәр. Өстәвенә өч бүлмә.

Зөбәрҗәт. Декорация?

Галия. Костюмнар?

Зөбәрҗәт. Хезмәт хакы?

Галия. Освещение?

Зөбәрҗәт. И так далее, и так далее...

Галия. Акча?

Миненур. Уйныйбыз, эшлибез, яңа образлар иҗат итәбез, акча табабыз.

Зөбәрҗәт. Хозрасчет?!

Миненур. Мишәр әйтмешли, до...

Галия. Сатира уйнар өчен табарсың, бар, артистлар.

Миненур. Сезне алам.
Зөбәрҗәт. Ә егетләр?
Миненур. Егетләр әзер. Ниндие кирәк? Эзләп тә йөрисе юк. Бер сызгырсам, тезелешеп басалар. Бәлки, кияү табарсыз. Йә, барасызмы минем театрга, әллә юкмы?
Зөбәрҗәт. Барды ди. Синең театрыңа ышанып эшсез калырга.
Миненур. Ике театрда эшләрсез. Миндә контракт беләң.
Галия. Күпме түлисең?
Миненур. Талантыгызга карап.
Зөбәрҗәт. Режиссерың кем була?
Миненур. Үзебез дип торабыз.
Зөбәрҗәт. Син? Син режиссер?!
Галия. Драматург?!
Зөбәрҗәт. Әле директордадыр.
Миненур. Әйе. Үзем режиссер, үзем актер, үзем директор, осветитель, завпост, завлит — барысы да үзем.
Зөбәрҗәт. Массада уйнап йөргәнен оныткан.
Миненур. Йә, миңа эшкә киләсезме?
Зөбәрҗәт, Галия } (*икесе бергә*). Безме?
Миненур. Әйе, сез.
Галия. Башта пьесаңны укыт.
Миненур. Ә мин тормышның чынбарлыгын куям.
Зөбәрҗәт. Театрның исеме?
Галия. Әйе, исеме?
Миненур (*торып баса да, уң кулын алга сузып, тантаналы рәвештә*). Театрыбызның исеме... Театрыбызның исеме...

Ике такта — бер басма,
Уртасында мәхәббәт.

Килештекме?! Бирегез кулыгызны.
Зөбәрҗәт. Җүләр сатып утырма.
Миненур. Менә син, туй алып барам, тамада булам, дисең, моңа синең режиссерың ничек карый?
Зөбәрҗәт. Бик тыныч карый.
Миненур. Бу сәнгатьме?
Галия. Сәнгать булмасын ди. Синең өч бүлмәле фатирыңда сәнгать була аламы?
Миненур. Менә син шул туйда нинди образлар тудырасың да нинди агарту эше алып барасың?
Зөбәрҗәт. Күңелләрен күтәрәм.
Миненур. Ә син минем театрда да шундый образлар иҗат итәрсең. Гомерең буе хыялланган рольләреңне уйнарсың. Минем театрда рольләр юк, дип йөрисе юк. Көне-төне уйна да уйна. Өстәвенә күпме тамашачыны тәрбиялисең. Күпме кешене фаш итәсең. Халыкны, кире юлга җибәрмичә, туры юлга илтәсең.

Галия. Артист халкы — беркатлы. Мин риза.
Зөбәрҗәт. Мин дә риза.
Миненур (*уң кулын сузып*). Килештекме?
Галия (*аның кулына үз кулын салып*). Килештек!
Зөбәрҗәт (*алар кулына үз кулын салып*). Килештек!
Миненур. Безнең девиз!

Музыка.

Миненур
Зөбәрҗәт } (*бергә*).
Галия

Халыкка гыйбрәттер — театр, театр!
Йоклаган аңны уятыр — театр, театр!
Театр яктылыкка, яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, алга илтә.

Сәхнәдә ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Өч бүлмәле фатирның залы. Ике якта ике якка керә торган ишекләр. Бүлмәнең сул ягында — өстәл. Өстәл өстендә лампа, магнитофон, картотекалар салынган тартма. Өстәл янәшәсендә ике урындык. Уң якта диван күренеп тора, аның янында олы гына тәбәнәк өстәлгә ак җәймә җәеп, ике кешелек ашау-эчү приборлары куелган. Сул як өстәлдә, лампа яктысында, Миненур язып утыра. Звонок шалтырый.

Миненур. Рәхим итегез. Керегез, кер! Ишек ачык.

Бүлмәгә таза гына, уртача буйлы, кыска чалбарына озын пиджак кигән, өстендәге шакмаклы бумази күлмәгенә галстук таккан, кәкре ботинкалы, кыршылып беткән портфель күтәргән, кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге Миңлехәбиб килеп керә.

Миңлехәбиб. Исәнмесез! Здрасьте! Можнымы?
Миненур. Мөмкин, мөмкин.
Миңлехәбиб. Мин дөрес кердемме? Бу — дом знакомствамы?
Миненур. Әйе, әйе. Бу — танышу бюросы. Сез кем буласыз?
Миңлехәбиб. Мин — дүртенче номер. Шәһәрдә бердәнбер тире җыю комбинатының тире тозлау цехы заведующиеның урынбасары Миңлехәбиб Миңлехәбирович.
Миненур (*үзе янындагы буш урындыкка күрсәтеп*). Менә монда, бирегә утырыгыз.
Миңлехәбиб (*башта урындыкка өрә, аннары кесәсеннән кулъяулык чыгарып, кулъяулыгын кага. Кулъяулык-*

*тан порошок коела)*. Тоз. Тоз коела. *(Кулъяулыгын урындыкка җәеп, өстенә утыра.)* Рәхмәт сезгә.

Миненур. Димәк, сез — дүртенче номер?!

Миңлехәбиб. Әйе, дүртенче номер.

Миненур *(картотека тартмасыннан бер карточканы тартып ала да укый)*. Димәк, сез — Миңле...хә...биб. Миңле...

Миңлехәбиб. Азапланмагыз. Телегезне сындырырсыз. Хәбиб Хәбирович дип кенә әйтегез. Үзегезгә җиңел булыр.

Миненур. Сез нәрсә? Ходай биргән шундый матур исемегезне бозарга. Әлбәттә, Миңлехәбиб Миңлехәбирович.

Миңлехәбиб. Ходай бирмәгән. Әткәй тапкан, әнкәй әләктереп алган.

Миненур. Атагызга гомер буе рәхмәт укыйсыздыр.

Миңлехәбиб. Укымаган кая. Исемем искә төшсә, сыер эчәгесе сөйрәп чапкан тавык күз алдыма килә. Бичара. Миңа, улының зур начальник буласын белмәгәндер инде. Белсә, кыскарак исем кушкан булыр иде.

Миненур. Кайда эшлим дидегез әле?

Миңлехәбиб. Мин бүгенгесе көндә шәһәребезнең бердәнбер тире җыю комбинатының тире тозлау цехы начальнигының уң кулы, ягъни беренче урынбасары. Әллә кыяфәтемә чыкмаганмы?

Миненур. Кыяфәтегезгә генә түгел...

Миңлехәбиб. Кая гына барсам да, километр ярымнан таныйлар. Бар җиргә дә чиратсыз кертәләр.

Миненур. Шулайдыр, шулайдыр. Мин дә тизрәк тотарга тырышырмын. Димәк, сез алтынчы номер белән очрашырга теләк белдердегез.

Миңлехәбиб. Язуыгызга караганда, әүлия, дөньяның бер чибәре бит.

Миненур. Безгә ямьсезләр хат язмый.

Миңлехәбиб. Буе күпмерәк әле?

Миненур. Хәзер карыйбыз. *(Тартмадан тагын бер карточканы тартып ала да укый.)* Шәһриҗиһан Гыйләҗи кызы. Буе бер метр да җитмеш ике сантиметр.

Миңлехәбиб. Исемен кыскартабыз. Җиһан! Үкчәле туфлиен салдырабыз. Так... Миннән бер ун сантиметрга озынрак кала. Бата. Биле ничегрәк?

Миненур. Ничегрәк, дисезме? Биле, биле... Ну инде...

Миңлехәбиб. Әйе, әйе, минем колач җитәрлекме?

Миненур. Үзегез ничегрәк уйлыйсыз соң?

Миңлехәбиб. Мин теләгәнчә булса... Где-то ике йөз ел утырган имән юанлыгы булса...

Миненур. Япон көрәшчеләрен күргәнегез бармы?

Миңлехәбиб. Булмыйча. Нәкъ үзе. Нәкъ мин эзләгән фигура! Ә күкрәге?

Миненур. Күкрәге, күкрәге булыр-булмас... Сыерныкы кадәр.

Миңлехәбиб (*урыныннан сикереп торып, кулларын уып*). Тизрәк танышырга, кавышырга иде.

Миненур. Ашыкмагыз. Паспортыгызны бирегез.

Миңлехәбиб. Паспорт нигә? Мин бит аның белән загска барырга уйламыйм. (*Як-ягына каранып ала да, куен кесәсеннән паспортын чыгарып, аның эченә тимер берлек тыга. Миненурга паспортын сузган хәлдә иелеп, ярым пышылдап.*) Анонимно гына булмыймы? (*Миненур паспортны алмакчы була.*) Чу, төшерә күрмәгез.

Миненур (*паспортны ала да эчен ача, тимер берлекне кулына ала. Тамашачыга күрсәтеп*). Нәрсә бу?

Миңлехәбиб (*йөгереп барып ишекне тарта, Миненур янына килеп, пышылдап*). Взятка!

Миненур. Алыгыз! Без взятка алмыйбыз. (*Акчаны кире бирмәкче була.*)

Миңлехәбиб (*урындыкка утырып*). Ялгышасыз. Мин кая гына барсам да, берәр кесә генә булса да, тоз тутырып барам. Алалар. Сөенә-сөенә алалар.

Миненур. Ә без алмыйбыз. Акчагызны кире алыгыз.

Миңлехәбиб (*сөенә-сөенә акчасын ала*). Ай рәхмәт, ай рәхмәт. Мондый дөреслек театрда, сәхнәдә генә була ала.

Миненур. Без сезнең турыдагы данныйларны беркемгә дә бирмибез. Үзебездә генә саклыйбыз.

Миңлехәбиб. Минем паспортта бераз гына гөнаһларым бар инде. Әмма үзем чиста. Чык тамчысы кебек чиста.

Миненур. Димәк, сезнең яшәү урыныгыз, фатирыгыз — Пушкин урамы, сигезенче йорт, уналтынчы фатир.

Миңлехәбиб. Тоттырганнар ди фатир. (*Сузып.*) Хатын-ны-кы.

Миненур. Өч балагыз да бар икән.

Миңлехәбиб. Әллә күпсенәсезме? Борчылмагыз. Өч хатынга бит ул. (*Иелеп, Миненурга ишетелерлек итеп пышылдап.*) Алтынчы номерның фатиры бармы икән?

Миненур (*өстәлгә күкрәге белән ятып, бармагы белән Миңлехәбибне чакыра да аның колагына пышылдап*). Фатирымы?

Миңлехәбиб (*пышылдап*). Әйе, әйе, фатиры.

Миненур (*пышылдап*). Фатиры... Фатиры юк.

Миңлехәбиб (*урыныннан торып баса*). Юк?! Ничек юк?! Сездә бүтән номер юкмы?

Миненур. Нигә?

Миңлехәбиб. Алтынчы номер миңа ошамый.

Миненур. Нигә?

Миңлехәбиб. Буе артык озын.

Минeнур. Коттежды бар.

Миңлехәбиб. Коттежды бар?! Яхшы. Алтынчы номерны бәхетле итәргә килгәнмен икән, алтынчы номерда тукталам. *(Сәгатенә карый.)* Тизрәк күрергә иде үзен. *(Тамашачыларга карап.)* Уннан соңга калсам, хатын өйгә кертми.

Минeнур. Яхшы. Димәк, сез риза.

Миңлехәбиб. Риза!

Минeнур. Риза булсагыз, хәзер сез, безнең клубның тулы члены булу өчен, бер мең дә биш йөз сум күләмендә взнос кертергә тиеш буласыз.

Миңлехәбиб. Минем член буласым килми.

Минeнур. Членсыз без таныштырмыйбыз.

Миңлехәбиб. Бәлки, ул миңа ошамас.

Минeнур. Ихтыярыгыз. Алыгыз паспортыгызны. Сау булыгыз.

Миңлехәбиб. Тукта әле син, сеңлем, кызма әле син. Бигрәк каты каерасыз бит. Без яшь чакта ратдомда эп-эсвижи кызның да бәясе өч тәңкә генә иде.

Минeнур. Ихтыярыгыз. Без мәҗбүр итмибез.

Миңлехәбиб. Чәнчелеп китсен. Бер генә тапкыр яшим. Кем белә, бәлки, үземә бәхет елмаер. Җүнле хатын табу — лотерея уены белән бер ул. Йөзгә, меңгә берсе генә отышлы. Йә отасың, йә ыштансыз каласың, йә пан, йә пропал, дип, акчаңны саласың. *(Кесәсеннән акча чыгарып саный да Минeнурга суза.)*

Минeнур. Санап тормыйм. *(Акчаны ала.)*

Миңлехәбиб. Санагыз, сана. Бәлки, артыграк киткәндер.

Минeнур. Дөрес уйлыйсыз. Бәлки, кимдер. *(Акчаны саный.)* Менә ун сумыгыз артык киткән.

Миңлехәбиб *(куанып, акчаны алып утыра)*. Менә бит. Ә сез санамыйм, дисез. Өйгә кайткач, шул ун тәңкәмне чыгара алмыйча, төн йокым кача иде.

Минeнур. Чәчәк заказать итәсезме?

Миңлехәбиб. Мин үзем чәчәк.

Минeнур. Дөрес. Хуш исле чәчәк. *(Борынын тота.)*

Миңлехәбиб. Безнең яшьтә нинди чәчәк инде ул?!

Минeнур. Күп очракларда сезнең кебек кавалерларны чәчәкләр коткара.

Миңлехәбиб. Шулай дисеңме? Ярый алайса.

Минeнур өстәлдәге кнопкага баса. Күрше бүлмәдә звонок шалтырый. Бүлмәгә кулына ручка һәм блокнот тоткан Галия килеп чыга.

Галия. Тыңлыйм сезне.

Минeнур. Дүртенче номер чәчәк заказать итә. Заказын алыгыз.

Галия. Яхшы. *(Миңлехәбиб янына килә дә язарга әзерләнә.)*

Миңлехәбиб. Иң очсызын.

Галия. Иң очсызын? Шундый күркәм туташкамы?

Миңлехәбиб. Минем чәчәк исеннән аллергия. Борыным тыгыла.

Галия. Бәлки, розалар алырсыз?

Миңлехәбиб. Күпме торалар?

Галия. Кыйммәт түгел. Җиде йөз дә илле сум.

Миңлехәбиб. Җиде йөз дә илле сум?! Әбиең сызгыра беләме, диярсең. Сез, сеңлем, үз акылыгыздамы?

Галия. Нигә?

Миңлехәбиб. Кем инде беренче тапкыр танышкан кызы янына роза чәчәкләре күтәреп бара? Роза бит ул чәнечкеле. Нәрсә, мин аңа, менә сиңа чәнечкеле розалар, безнең тормышыбыз да шушы розалар төсле чәнечкеле булсын, димме? Юк, розалар батмый, сеңлем, батмый.

Галия. Алайса, гладиолуслар алыгыз.

Миңлехәбиб. Алты йөз сум тора торганмы?

Галия. Алты йөз илле сум.

Миңлехәбиб. Эх, сеңлем, сеңлем. Кем сине бирегә эшкә алды? Син әтәч кикриге төсле гладиолуслар тәкъдим итәсең. Нәрсә, алдагы киләчәк тормышыгызда әтәчләр кебек сугышып яшәгез, диясең киләме? Батмый, сеңлем, батмый. Гладиолуслар батмый.

Галия. Алайса, канәфер чәчәге инде.

Миңлехәбиб. Син нәрсә, сеңлем? Кавышмас борын безне гробка саласың. Канәферне кеше үлгәч, исләнмәсен өчен салалар. Давай миңа очсыз кыр чәчәкләре.

Галия. Бездә кыр чәчәкләре юк.

Миңлехәбиб. Сездә нәрсә генә бар соң, сеңлем?

Галия. Бездәме? Бездә сирень чәчәкләре бар.

Миңлехәбиб. Август аендамы? Гаҗәп җир бу. *(Үз-үзенә мыгырдап.)* Ыштаныңны салдыралар, Хәбиб туган, каешыңны кысыбрак куй, валлаһи, салдыралар. *(Галиягә.)* Алып чык. *(Галия чыгып китә.)* Бу кызыгыз некудышный. Кем тапты моны? Клиентларыгызның ыштанын салдыра бу. Тиз арада моннан котылыгыз. Клиентларыгыз качып бетә. Фирмагызны ябарга туры килә.

Ясалма сирень букеты тотып, Галия чыга да чәчәкләрне Миңлехәбибкә суза.

Галия. Алыгыз.

Миңлехәбиб *(чәчәкләрне кулына алып, әйләндерә-әйләндерә)*. Күпме тора?

Галия. Ике йөз дә илле сум.

Миңлехәбиб *(иснәп карап)*. Ике йөз дә илле сум?! Шушымы? Шушы пластмассмы?

Галия (*чәчәкләрне тартып ала да шап-шоп өстәлгә сугып*). Зато коелмыйлар. (*Миңлехәбибкә чәчәкләрне кире бирә.*)

Миңлехәбиб. Ике йөз дә илле сум?! Иссез чәчәкләрме?

Галия. Ә, сезгә исе дә кирәкмени? Яхшы. (*Куен кесәсеннән духи чыгара да чәчәкләргә сиптерә.*) Хәзер өч йөз дә илле сум.

Миңлехәбиб (*тамашачыларга карап*). Ялгыш эләктем. Дөрес кермәдем. Шуллерлар. Аферисткалар. (*Миненурга.*) Гафу итегез. Мин адресын бутаганмын. Миңа паспортымны, акчамны кире бирегез дә мин киттем.

Миненур. Ихтыярыгыз. (*Паспортын суза.*)

Миңлехәбиб (*паспортын ала да актарып карап*). Ә акча?

Миненур. Нинди акча?

Миңлехәбиб. Взнос.

Миненур. Гафу итегез. Сез безнең һәм алтынчы номерның кадерле минутларын алдыгыз. Без бу вакыт эчендә бүтән клиентны кабул итә идек. Акчагыз за ущерб.

Миңлехәбиб (*тамашачыларга карап*). Көпә-көндез кычкыртып талыйлар. (*Галиягә ике йөз дә илле сум акча санап бирә.*) Ал!

Галия. Тагын йөз сум һәм паспортыгызны бирегез.

Миңлехәбиб. Нәрсә?

Галия. Чәчәкнең исе өчен.

Миңлехәбиб (*йөз сум чыгарып бирә*). Мә, күрмәгәнегез шул булсын. Ә паспорт тагын нәрсәгә?

Галия. Чыгып киткәндә бирербез. (*Миңлехәбиб паспортын кире бирә.*) Сезгә чек бирергәме?

Миңлехәбиб (*тамашачыларга карап*). Хатынга алып кайтып бирергәме? (*Галиягә.*) Үзеңә истәлеккә калдыр. Бер дивана624ы алдаган идем, дип мактанып сөйләрсең.

Галия. Өстәлгә нәрсәләр заказать итәсез?

Миңлехәбиб. Нинди өстәл тагын?

Галия. Танышу табынына.

Миңлехәбиб. Сеңлем, мин туй үткәрергә җыенмыйм. Минем яшьтә өстәл турында түгел, кровать хакында уйлыйлар.

Миненур. Миңлехәбиб Миңлехәбирович, сездәй дәрәҗәле асыл егет белән танышканда, сезгә сүз кушу түгел, сезгә күтәрелеп каравы да читен. Ышаныгыз минем сүзләремә. Мин сезгә хатын-кыз буларак әйтәм. Кыюлык өчен өстәлсез булмый.

Миңлехәбиб. Шулай дисезме? Менә монысы кешеләрчә. Алайса, одеколон сибеп, пластмасс чәчәк бирәләр, понимаешь ли. Мин каршы түгел. Кыюлык өчен үземә дә берәр кырлы стакан җиппәрсәм мешать итмәс иде.

Галия. Коньяк. Биш йолдызлы.

Миңлехәбиб. Унбиш йолдызлы түгелме? Простой, Мензелинский егерме сумлык аракы.

Галия. Ә туташка?

Миңлехәбиб. Иң очсыз, кырык сумлык илле грамм вино.

Галия. Яхшы. Йөз дә илле өч сум җитмеш биш тиен.

Миңлехәбиб (*Галия булып*). Җитмеш биш тиен. (*Үз-үзенә мыгырдана.*) Ул сезнең алтынчы номерыгыз алтыннан коелгандыр инде. Балга манып кына бирәсегез калды.

Миненур. Без каршы түгел. Әгәр телисез икән, балдан ясалган гель салып, ваннада коендырып бирәбез.

Миңлехәбиб. Юк, юк. Аллам сакласын. Мин бал корты түгел, мин кеше. Миңа хатын-кыз үз исе белән кирәк.

Галия. Закускага?

Миңлехәбиб. Редиска.

Миненур. Сынатмагыз. Артып калса, үзегез артыннан үзегез җыештырып алып китәрсез.

Миңлехәбиб. Яхшы. Мин ашап кына килдем. Иң очсыз бәяне әйтегез.

Галия. Барысы бергә, эчемлекләрне дә кертеп, ике мең дә бер йөз җитмеш биш сум да илле бер тиен.

Миңлехәбиб (*Галия булып*). Илле бер тиен. (*Акчасын санап бирә.*) Илле бер тиен.

Галия. Әгәр бер-берегезне ошатсагыз, бездән соң рестораnga керерсез.

Миңлехәбиб. Син мине өйрәтмә. Кая керергә мин үзем белермен. Төшеп калганнардан түгел. (*Үз-үзенә мыгырданып.*) Җебеп торсаң, бал суында болгатып бирәләр иде. Ярый әле үзем үткен.

Галия. Музыка заказать итәсезме?

Миңлехәбиб. Сеңлем, чалбарымны салып бирәм, зинһар, күз алдымнан югал.

Галия (*күрше бүлмәгә кереп барган җиреннән туктап*). Музыка өчен биш йөз сум.

Миңлехәбиб. Минем бүтән акчам юк.

Галия. Без ашыкмыйбыз. Паспортыгыз бездә бит. Акчагызны түләрсез дә паспортыгызны килеп алырсыз. (*Кереп китә.*)

Миңлехәбиб. Мин сезгә савым сыеры түгел. Кигәвен кебек ябышмагыз. Туйдым мин синнән, сеңлем, ай туйдым!

Миненур. Тынычланыгыз, иптәш, тынычланыгыз, Миңлехәбиб Миңлехәбирович, сез хәзер өч йөз сумыгызны әзерләгез дә, менә бирегә, күрше бүлмәгә керегез. Анда сезне бизәндерерләр. Ислемай сибәрләр. Аннары мин үзем сезне чакырырмын.

Миңлехәбиб. Мин болай да чибәр. Кая, кая керергә? Бирегәме?

М и н е н у р. Әйе, әйе. Бирегә. (*Миңлехәбибне бер ишектән кертеп җибәрә.*) Галия! Галия!

Г а л и я (*чыга*). Нәрсә?

М и н е н у р. Бар, тизрәк Зөбәрҗәтне чакыр.

Галия кереп китә дә З ө б ә р җ ә т белән чыга.

З ө б ә р җ ә т. Нindiрәк роль уйнарга?

М и н е н у р. Буең бер метр да җитмеш ике сантиметр.

З ө б ә р җ ә т. Мин бит метр да алтмыш ике генә.

Г а л и я. Хәзер, биек үкчәле туфли алып чыгам. (*Йөгереп кереп китә дә биек үкчәле туфли алып чыгып, Зөбәрҗәткә киярgә булыша.*)

М и н е н у р. Билең ике йөз илле ел утырган имән юанлыгы.

З ө б ә р җ ә т. Ә минем билләрем, үзегез күрәсез...

Г а л и я. Нишлибез?

М и н е н у р. Галия, анда, балконда, суда батмас өчен кабарта торган круг бар, шуны алып чык.

Г а л и я. Була ул. (*Йөгереп кереп китә дә, круг алып чыгып, Зөбәрҗәтнең биленә кидерә.*) Кабартыйммы?

М и н е н у р. Кабарт. (*Зөбәрҗәткә.*) Аң бул! Бик саран. Өч хатыны, өч баласы бар.

Г а л и я (*өрүеннән туктап*). Булдымы?

М и н е н у р. Юк әле, бераз өр. (*Зөбәрҗәткә.*) Үзеннән чи тире исе килә. Түз, балалары хакына түз.

Г а л и я (*өрүеннән туктап, башын күтәреп*). Ә мин аңа одеколон сиптем. (*Миненурга.*) Җиттеме? Тагын өримме?

М и н е н у р. Җитте, җитте. Алайса шартлый. Бар, Галия, иң зур күлмәкне алып чык.

Г а л и я. Була ул. (*Күлмәкне алырга чыгып йөгерә. Күлмәк алып кереп, Зөбәрҗәткә кидерә.*)

З ө б ә р җ ә т. Бу кадәр гәүдәгә минем күкрәк имән чикләвеге генә булып калды.

М и н е н у р (*кесәсеннән ике шар чыгарып, берсен Галиягә бирә*). Мә, кабарт.

Г а л и я. Нигә?

М и н е н у р. Кабартып, күкрәгенә тыгабыз.

Г а л и я. Айн момент.

Галия белән Миненур шар кабарта башлыйлар.

М и н е н у р. Кая, булдымы? Бир шарыңны. (*Зөбәрҗәт шаркылдап көлеп җибәрә.*)

Г а л и я. Нигә көләсең?

З ө б ә р җ ә т. Соң бит минем бер имием уникеле, икенчесе алтынчы размерлы була түгелме соң?

М и н е н у р. Галия, җүләрме әллә син? Бераз һавасын чыгар.

Галия. Яхшы. (*Һавасын чыгара башлый, шар очып китә.*) Ай! Хараплар булдык.

Миненур. Күкрәк очып китте. Мә, икенчесен кабарт. Бездә «күкрәкләр» җитәрлек. (*Кесәсеннән алып, Галиягә икенче шарны бирә, Зөбәрҗәтнең куенына үзе кабарткан шарны тыга да, кесәсеннән помада чыгарып, Зөбәрҗәтнең иреннәрен буйый башлый.*) Кая әле, иреннәреңне чабата хәтле итеп буйыйбыз.

Галия. Минеке дә булды.

Миненур. Күкрәгенә тык.

Галия. Айн момент. (*Шарны Зөбәрҗәтнең күкрәгенә тыга.*) Булды бу. Абзыйның заказы үтәлде.

Миненур. Ишетсен колагың, Зөбәрҗәт. Син бик бай, коттеджда яшисең. Бар әле, Галия, зуррак дамский сумкага бишалты пачка бутафорский долларлар салып, Зөбәрҗәтнең кулына тоттыр.

Галия. Очтым. (*Йөгереп чыгып китә дә сул кулына сумка, уң кулына дүрт пачка долларлар күтәреп чыга.*) Менә, Зөбәрҗәт (*долларларны селкеп*), бүгенгесе көндә син — иң бай хатыннарның берсе. Онытып бетермәссең дип уйлыйм. Коттеджыңа безне дә чакырырсың.

Зөбәрҗәт. Сиңа көлке. Ә минем тез буыннарым дерелди.

Галия. Нишлисең бит, премьера. Беренче спектакль. Дулкынланасыңдыр. (*Долларларны сумкага салып, Зөбәрҗәткә тоттыра.*)

Зөбәрҗәт (*Миненурга*). Иптәш режиссер, минем задача?

Миненур. Серләрен белергә, хатыны алдында ялганын фаш итәргә.

Зөбәрҗәт. Сверх задача?

Миненур. Бездәге акчаларын гаиләсенә, балаларына кайтарырга. Сез әзерме?

Зөбәрҗәт, Галия (*икесе бергә*). Әзер.

Миненур. Әзер булсагыз, урыннарыгызда булыгыз. Мин музыка куюга, Зөбәрҗәт, син бүлмәңнән чыгарсың. Аңлашылдымы?

Зөбәрҗәт. Аңладым.

Миненур. По местам.

Зөбәрҗәт, Галия (*икесе бергә*). Есть, иптәш режиссер.

Бүлмәләренә чыгып китәләр.

Миненур. Хөрмәтле тамашачылар! Сезнең игътибарыгызга драматург Данил Салихов әсәре буенча куелган «Ике

такта — бер басма, уртасында мәхәббәт» спектаклен башлыйбыз. (*Барып, магнитофон төймәсенә баса, Мендельсон маршы яңгырый. Миңлехәбиб Миңлехәбирович кереп киткән бүлмәнең ишекләре ачыла. Аннан, пластмасса букет күтәреп, Миңлехәбиб килеп чыга да тамашачыга баш ия.*)

Миңлехәбиб. Миңлехәбиб Миңлехәбирович ролендә театрыбызның артисты ... (*Икенче ишекләр ачыла. Аннан Зөбәрҗәт чыга.*) Зөбәрҗәт ролендә театрыбызның артисты ... (*Тамашачыларга карап.*) Рәхим итегез, хөрмәтле дуслар!

Көй көчәя. Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Өстәл өсте ризыклардан сыгылып тора. Миңлехәбиб исерә төшкән. Ул, уң кулы белән Зөбәрҗәтне кочаклап, диванда утыра. Сул кулы аның күкрәгенә үрелә.

Миңлехәбиб. Күкрәгеңнән тотарга ярыймы?

Зөбәрҗәт. Оялам, җитеп бетмәде.

Миңлехәбиб. Эй, официантка! (*Бармагын шартлатып.*) Бирегә чык!

Галия чыга.

Галия. Тыңлыйм сезне.

Миңлехәбиб. Син биредә кем утырганын беләсеңме?

Галия. Белмәсәм дә сизәм. (*Тамашачыларга карап.*) Борыным ис сизә.

Миңлехәбиб. Сизгәч, коньяк чыгар.

Галия. Бик шатланып. (*Чыгып китә.*)

Миңлехәбиб (*күкрәгенә үрелә*). Бераз гына уйнарга ярыймы?

Зөбәрҗәт. Сабыйлар кебек туйганчы уйнагыз. Тик шартлата гына күрмәгез.

Миңлехәбиб. Мин осторожно гына. Менә бу ичмасам күкрәк!

Зөбәрҗәт. Шыгырдап торамы?

Миңлехәбиб. Шыгырдап тора. (*Коньяк күтәреп, Галия килеп керә. Шешәне ачмакчы була.*) Үзем ачам. Хатынкыз кулыннан аракы эчмим.

Галия. Ихтыярыгыз. (*Чыгып китә.*)

Зөбәрҗәт. Сез шундый юмарт.

Миңлехәбиб. Сездәй гүзәл өчен берни дә жәл түгел. (*Шешәне ача башлый. Зөбәрҗәтнең күкрәгендәге бер шар шартлый. Миңлехәбиб сикереп куя.*) Нәрсә булды?

Зөбәрҗәт. Ни бит, ни. Шешәң атты.

Миңлехәбиб. Коньякмы? Гаҗәп. Хәзер коньяклар да шампан шәрабы кебек аталармыни?

Зөбәрҗәт. Демократия бит. Һәркемнең, һәрнәрсәнең үз ирке. Тели икән, ата, тели икән, ята.

Миңлехәбиб. Сенсация! *(Рюмкаларга коньяк сала да кулына рюмкасын тотып.)* Әйдәгез, сезнең өчен!

Зөбәрҗәт. Рәхмәт.

Миңлехәбиб. Сезнең нәфис, йомшак кулларыгыз өчен! *(Кулыннан үбеп ала.)* Сезнең чиядәй иреннәрегез өчен! *(Үбәргә дип үрелмәкче була, күзләре Зөбәрҗәтнең күкрәгенә төшә, сискәнеп чайкалып куя, артка атлый.)* Сезнең күкрәгегез...

Зөбәрҗәт. Нәрсә булган?

Миңлехәбиб. Шартлаган.

Зөбәрҗәт *(күкрәгенә карап, исе дә китмичә)*. Ә, шуышкандыр. *(Исән калган шарын күкрәк уртасына этеп куя.)* Шартлау булды бит.

Миңлехәбиб. Шартлау?

Зөбәрҗәт. Курыкканда югалып тора ул.

Миңлехәбиб *(шикләнеп)*. Кызык. *(Өзек итеп.)* Сезнең күк-рә-ге-гез өчен!

Зөбәрҗәт. Рәхмәт. *(Чәкештерәләр. Миңлехәбиб эчеп куя. Зөбәрҗәт, ул күрмәгәндә, коньягын түгә.)*

Миңлехәбиб *(капкалап)*. Сезнең алдагы планнарыгыз?

Зөбәрҗәт. Әйтергә оялам.

Миңлехәбиб. Кияүдә булдыгызмы?

Зөбәрҗәт. Юк. Юлымда сездәй кеше очрамады.

Миңлехәбиб. Димәк, хыялыгыз тормышка ашты?

Зөбәрҗәт. Яшермим. Сездәй кешенең хатыны булу — күптәнге хыялым.

Миңлехәбиб. Фатирың бармы соң?

Зөбәрҗәт. Мин әти белән әнинең бердәнбер кызы. Коттеждда яшибез.

Миңлехәбиб. Әти-әниең картлармы?

Зөбәрҗәт. Әни — сиксәндә, әти — туксанда.

Миңлехәбиб. Болай булгач, күптәнге хыялың тормышка ашыр. Борчылма. Мин үзем дә төшеп калганнардан түгел. Фатирым булмаса да *(куен кесәсеннән сберкнижка чыгарып)*, менә монда бер машиналык акча.

Зөбәрҗәт. Сиңа нигә машина?

Миңлехәбиб. Сине утыртырга.

Зөбәрҗәт. Юк. Мин сине үзем утыртырга җыенам.

Миңлехәбиб. Әтиеңнәр риза булырмы?

Зөбәрҗәт. Нәрсәгә?

Миңлехәбиб. Мине утыртырга.

Зөбәрҗәт. Шатланып. Синдәй кешене утыртсам, минем хыялым тормышка аша.

Миңлехәбиб. Мин риза.
Зөбәрҗәт. Нәрсәгә?
Миңлехәбиб. Утырырга.
Зөбәрҗәт. Ашыкма әле.
Миңлехәбиб. Нигә?
Зөбәрҗәт. Сбережениеңне гаиләңә кайтарып биреп, фатирыңнан пропискадан төш.
Миңлехәбиб. Мин акчасыз ничек утырырмын?
Зөбәрҗәт. Утырганда, акча нигә? Утырткан өчен мин синнән акча сорамыйм. *(Сумкасыннан долларларын чыгарып.)* Акча бездә — бер букча.
Миңлехәбиб. Долларлар! Пачкалап! Йөзәрлекләр! Ә мин кайда яшәрмен?
Зөбәрҗәт. Борчылма. Синең кебек булган егеткә урын табарбыз.
Миңлехәбиб. Иртәгә үк пропискадан төшәм. Книжкамнан акчамны алып, балаларыма тигез итеп бүлеп бирәм.
Зөбәрҗәт. Тик хатыннарыңа бирә күрмә.
Миңлехәбиб. Бетемне тотсыннар. Квартирам да аларга бик җиткән.
Зөбәрҗәт. Димәк, риза?
Миңлехәбиб. Нәрсәгә?
Зөбәрҗәт. Утырырга.
Миңлехәбиб. Синдәй утыртучы булганда, ничек риза булмыйсың ди.
Зөбәрҗәт. Килештек алайса.
Миңлехәбиб. Килештек.
Зөбәрҗәт. Мә бишне.
Миңлехәбиб *(кулын бирә)*. Ун булсын.
Зөбәрҗәт. Йөргән юлларың уң булсын.
Миңлехәбиб. Рәхмәт.
Зөбәрҗәт. Рәхмәтне әле соңыннан әйтерсең.
Миңлехәбиб. Кайчанрак?
Зөбәрҗәт. Бүтән тормышта яши башлагач.
Миңлехәбиб. Киттекме?
Зөбәрҗәт. Кая?
Миңлехәбиб. Сезгә.
Зөбәрҗәт. Хәзер үкме?
Миңлехәбиб. Хәзер үк.
Зөбәрҗәт. Туйдан соң.
Миңлехәбиб. Туй кайчан?
Зөбәрҗәт. Син гаиләңне тынычлыкта калдыргач.
Миңлехәбиб. Иртәгә үк пропискадан төшәм.
Зөбәрҗәт. Менә сиңа безнең коттеджның адресы. Киемнәреңне генә ал да шунда кил.
Миңлехәбиб. Мине кем каршы алыр?

З ө б ә р җ ә т. Казбек.
М и ң л е х ә б и б. Кем ул?
З ө б ә р җ ә т. Безнең коттеджның сторожы.
М и ң л е х ә б и б. Тот әйдә. Бәхетле гаилә өчен.

Рюмкаларын чәкештерәләр. Музыка. Ут сүнә.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук картина. М и н е н у р өстәл артында язып утыра. Сәхнә артында тавышлар ишетелә.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Улым, дим, Мәрдән, балакаем, нигә ояласың? Оялма. Сине тотып ашамыйлар. Әйдә керәбез.

М ә р д ә н. Юк. Мин кермим. Оялам.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әйдә, дим мин сиңа, малай актыгы.

М ә р д ә н. Юк инде, юк, кермим. Үзең генә кер. *(Ишек ачылып китә. Гөлҗәүһәр Мәрдәннең беләгеннән тоткан да бүлмәгә өстери. Алар Миненурны күрмиләр.)*

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әйдә, дим мин сиңа, малай актыгы. Хатынсыз картаясың бит.

М ә р д ә н. Җибәр, дим, әнкәй. Барыбер кермим.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әй, барсана. *(Кулын җибәрә.)* Кадалып кит. Киребеткән. *(Миненурны күреп.)* Нихәл, кызым? Исән-саумы? Керергә ярыймы?

М и н е н у р. Керегез, кер, апа. Менә бирегә рәхим итегез. Минем янга урындыкка утырыгыз.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Мин дөрес кердемме соң? Бу — танышукавышу оешмасымы, кызым?

М и н е н у р. Әйе, әйе. Дөрес кергәнсез.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Мин — җиденче номер. Улым белән бергәләп икенче номерга хат язган идек.

М и н е н у р. Ә, шулаймыни? Хәзер... *(Ящиктан карточка тартып чыгара. Сискәнеп китә.)* Тукта әле. Күзлегемне алыйм, апа. *(Күзлеген кия дә тагын карточкага текәлә, томлыгып.)* С... с... сез... Г...ай...син?!

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әйе, әйе. Мин Гайсин Мәрдән Хөснимәрдәновичның анасы Гөлҗәүһәр апагыз булам.

М и н е н у р. Малаегыз килдемени?

Г ө л җ ә ү һ ә р. Килде, керми. Ояла. Оялчан ул. Утызны тутырып кырыкка чыкты. Өйләнә алмый. Кызлардан ояла. Әртис ул. Татар театрында әртис булып эшли.

Миненур. Артист? Мәрдән Гайсин? *(Утырган урыныннан өстәлгә ава.)*

Гөлҗәүһәр. Ай Аллам, ай Аллам. Ни булды? Кем бар монда? Кем бар? Чыгыгыз әле! Чыгыгыз! Харап булды. Харап булды. Үлде бугай. *(Сәхнә буйлап йөри.)*

Бүлмәгә Зөбәрҗәт белән Галия керә.

Галия. Нәрсә булды?

Гөлҗәүһәр. Менә бу бала утырган җиреннән һушыннан язды. Әллә үлде инде.

Галия. Зөбәрҗәт, бар, тиз генә су алып чык.

Зөбәрҗәт. Хәзер. *(Ашыга-ашыга кереп китә дә су алып чыга.)* Мә.

Галия *(Миненур ирененә су тидерә)*. Зөбәрҗәт, нашатырка алып чык.

Зөбәрҗәт кабалана-кабалана кереп китә дә нашатырный спирт алып чыгып, Миненурга иснәтә. Миненур каты итеп төчкерә.

Миненур *(куркуыннан сикереп куя. Үзе басып торган урынга карап, үз-үзенә)*. Юешләнмәгәнме?

Зөбәрҗәт. Галия, су бөркергә кирәк аңа, су. *(Авызына су ала да Миненурга өреп җибәрә.)*

Миненур *(сикереп тора)*. Нишлисез?

Зөбәрҗәт. Үләсең бит.

Галия. Күзеңнең карасы калмаган бит.

Зөбәрҗәт. Егет күрдем дигәч тә...

Миненур. Менә сез, егетне күргәч, нишләрсез. *(Гөлҗәүһәргә, тотлыгып.)* Д... д... ди... мәк, с... с... сез Г... Гайсин а... артист...

Гөлҗәүһәр. Юк, юк, мин әртис түгел. Минем улым, улым Гайсин. Мәрдән әртис.

Галия
Зөбәрҗәт } *(икесе бергә)*. Гайсин Мәрдән? Артист?

Гөлҗәүһәр. Әйе, әйе. Әртис. Утызны тутырып кырыкка чыкты. Өйләнә алмый. Кызларга сүз ката алмый. *(Миненур тагын һушын югалта.)*

Зөбәрҗәт. Апа, сез чыгып торыгыз. Бераздан керерсез. Безнең бу кызыбызның өянәге бар. Хәзер аны рәткә кертәбез дә, сезне чакырабыз.

Гөлҗәүһәр. «Скурый» чакыртыйммы?

Зөбәрҗәт. Юк, юк. Кирәкми. Хәзер аңына килә ул.

Гөлҗәүһәр. Алайса, улым Мәрдәнне чакырам. Ул көчле. Күтәреп, диванга салыр.

Галия. Юк, юк. Аллам сакласын. Керә күрмәсен.

Зөбәрҗәт. Үзебез, үзебез. *(Миненурны күтәрмәкче була.)* Сез чыгып торыгыз, апа.

Гөлҗәүһәр. Әй бичара. Егет күрмәс борын егылды, диген. *(Үз-үзенә.)* Өянәге бар диме? Кияү куенына кергәч нишләмәс? *(Кызларга.)* Ярый, чыгыйм әле.

Миненур *(аңына килеп, зәгыйфь тавыш белән)*. Чакырырбыз, апа, чакырырбыз.

Гөлҗәүһәр. Әй бичара. Тавышы көчкә чыга. Үзе һаман да кеше бәхете өчен көрәшә. Борчылма, кызым, сиңа борчылырга ярамый. Көтәрбез. Минем вакытым күп. Мин — пенсионер. Ә Мәрдәннең кичке җиде генә спектакле. *(Чыгып китә.)*

Миненур. Нишлибез?

Галия. Уйла. Син — режиссер.

Миненур. Режиссер?! Каян килеп режиссер булыйм ди мин.

Зөбәрҗәт. Син — директор.

Миненур. Мин — директор? Тапкансыз директор.

Галия. Өстәвенә драматург.

Миненур. Шулаймы? Яхшы. Пәрдә ачылган, халык җыелган, уйнагыз. Кайчан сезнең режиссерның, йә булмаса директорның сәхнәгә чыгып уйнаганын күргәнегез бар. Сез артисткалар, уйнагыз. Өйрәнгәнсез спектакльдән спектакльгә бер үк грим, бер үк тавыш белән бер үк рольләр уйнарга. Уйнагыз шундый итеп, Мәрдән танымаслык итеп. Үз гомерегездә бер генә тапкыр булса да партнер да таный алмаслык образ иҗат итегез. Йә, кайсыгыз?

Галия. Мин!

Зөбәрҗәт. Юк, мин.

Галия. Нишләп гел син?! Театрда да син, монда да син. Кичә дә син, бүген дә син. Син генә күз өстендә каш. Бүген минем чират.

Миненур. Бәхәсләшмәгез. Монда мин режиссер. Санныйм. Аладан, каладан, карга йөри колгадан. Мин санныймын, син йөрисең, син йөрисең, мин санныймын. Син калып тор, ә син чык. *(Тамашачыларга карап.)* Хөрмәтле тамашачылар! «Ике такта — бер басма, уртасында мәхәббәт» спектаклен дәвам итәбез. Төп рольдә «Танышу һәм кавышу» театрының артисткасы Галия Җәләлова. *(Кызларга.)* Тиз арада гримнарыгызны сылагыз.

Галия. Есть! *(Башындагы паригын салып, Миненурга ыргыта. Биленә озын толымнары төшә.)*

Миненур *(аптырап)*. Син гомер буе парик киеп йөрдең?

Зөбәрҗәт. Шундый толымнарың була торып.

Миненур. Күрәсең, Зөбәрҗәт, без артисткаларыбызның эчке дөньяларын гына түгел, тышкы кыяфәтләрен дә ачып бетерә алмыйбыз. Безгә әле эшләргә дә эшләргә. *(Галиянең паригын кия.)* Зөбәрҗәт, син Галияне эчке бүлмәгә алып кереп, грим сал. Ә мин кияү егетен, татар халкының яраткан артисты Мәрдән Гайсинны сәхнәгә чакырам. *(Зөбәрҗәт белән Галия күрше бүлмәгә кереп китәләр.)* Маэстро, музыка!

Музыка башлана. Ишек ачыла. Бүлмәгә Гөлҗәүһәр килеп керә.

Гөлҗәүһәр (*аптыраулы кыяфәттә*). Теге бала ни хәлдә?

Миненур (*өстәл артына килеп утыра. Калын тавыш белән*). Әйбәт. Аның хәле әйбәт, апа.

Гөлҗәүһәр. Үзе кая соң әле? (*Урындыкка килеп утыра.*)

Миненур. Биредә.

Гөлҗәүһәр. Күрше бүлмәдәмени?

Миненур. Юк, каршыгызда утыра.

Гөлҗәүһәр. Күрмим ич.

Миненур. Менә ич, мин ич ул.

Гөлҗәүһәр (*көлемсерәп*). Шаярмагыз. Аның тавышы нәфисрәк иде.

Миненур. Өянәктән соң минем тавышым бер-ике сәгатькә калыная, апа.

Гөлҗәүһәр. Ә чәчегез?

Миненур. Бөдрәләнә.

Гөлҗәүһәр. Кызык. Аяз көнне яшен суккан кебек булды. Әллә мин, әллә ул саташа.

Миненур. Димәк, сезнең улыгыз артист.

Гөлҗәүһәр. Әртис кенәме соң? Театрның герое!

Миненур. Беләм.

Гөлҗәүһәр. Нәрсәне беләсез?

Миненур. Телемнең тик тормаганын беләм.

Гөлҗәүһәр. Борчылмагыз. Теге дөньяга барып кайткач, тиз генә аңга килү авырдыр, билгеле.

Миненур. Артистларны кыю була, диләр.

Гөлҗәүһәр. Әртисләрне гулящий, дип тә сөйлиләр, балакаем. Әртис халкы сәхнәдә ике сәгать гыйшык-мыйшык уйный да, шул бер үбешкәненә риза булып, гомер уздыра ул, кызым. Менә безнең күршедә бер бай гаилә яши. Ире дә, хатыны да иномаркада җилдерәләр. Кич җитсә, берсе бер якка, икенчесе икенче якка чыгып китәләр. Кайтсалар, кайталар, кайтмасалар, калалар. Коммунизм.

Миненур. Улыңның бер дә кызлар белән йөргәне юкмыни?

Гөлҗәүһәр. Юк. Оялчан ул.

Миненур. Театрда кызлар юкмыни?

Гөлҗәүһәр. Буа буарлык: Галия дигәне бар, Җәмилә дигәне бар.

Миненур. Минем күршедә дә бер артистка яши.

Гөлҗәүһәр. Кем ул?

Миненур. Миненур.

Гөлҗәүһәр. Беләм, бик яхшы беләм. Көлдерә торган артистка ул. Күп тә уйнамый. Сәхнәгә башын гына тыгып ала, халык шуны карар өчен йөри.

Миненур. Улыңны шуның белән кавыштырсаң?

Гөлҗәүһәр. Миненур беләнме?

Миненур. Әйе.

Гөлҗәүһәр. Аллам сакласын. Ул минем юаш улымны ике көн алдына утыртып биетә дә өченче көнне бәреп үтерә. Минем бозау белән нишләсен ул. Ул бит кияүгә озакка чыкмый. Атна-ун көнгә генә.

Миненур. Аңлашылды. Димәк, икенче номер белән таныштырып карыйбыз.

Гөлҗәүһәр. Язуына караганда, икенче номер әйбәт булыр кебек иде.

Миненур. Сез хәзер чыгыгыз да җиденче номерны алып керегез.

Гөлҗәүһәр. Җиденче номерны?

Миненур. Әйе, улыгызны. Мин икенче номерны чакырам.

Гөлҗәүһәр. Әллә икенче номер килеп җитте? Күрми калдым.

Миненур. Килеп җитте.

Гөлҗәүһәр. Җакшы. Хәзер алып керәм.

Миненур. Алып кермәгез. Үзе генә керсен.

Гөлҗәүһәр. Җакшы. Ярый да үзе генә керсә. *(Урыныннан тора-тора.)* Мәрдән, Мәрдән, чакыралар. Кер әле, чакыралар. *(Чыгып китә. Коридорда тарткалашкан тавышлар ишетелә.)* Бар, бар. Кер, димен, имгәк! Оялма. Тотып ашамаслар. *(Ишек ачыла. Гөлҗәүһәр Мәрдәнне бүлмәгә өстери.)* Кер инде, кер! Оялма. Хатынсыз картаясың бит. Минем дә картайган көнемдә оныклар сөясем килә.

Мәрдән *(кыюсыз гына ишек төбенә кереп баса)*. Мөмкинме? Исәнмесез. *(Гөлҗәүһәр ишекне яба.)*

Миненур. Мөмкин, мөмкин. Исәнмесез. Менә бирегә, диванга утырыгыз.

Мәрдән *(кыюсыз гына)*. Рәхмәт. *(Диванга таба китә.)*

Гөлҗәүһәр *(ишектән башын тыгып)*. Кая барасың мүкләк сыер сыман. Каршына утыр. Урындыкка утыр.

Мәрдән *(нык ачуланып)*. Чыгам да китәм.

Гөлҗәүһәр. Кыю бул. Каршысына утыр. Хатынсыз кайтмыйбыз.

Миненур. Апа, ишекне ябыгыз.

Гөлҗәүһәр. Җакшы. *(Ишекне яба.)*

Миненур. Юк, юк, диванга утырыгыз. Минем каршыма утырырга ярамый. Миндә грипп. Сезнең исемегез Мәрдән бит әле? *(Диванга барып утыра.)*

Гөлҗәүһәр *(ишектән башын тыгып)*. Әйе, әйе, аның исеме Мәрдән. Атаеның Хөснимәрдән, бабасының Галимәрдән.

Мәрдән. Әнкәй, чыгам да китәм.

Гөлҗәүһәр. Үзеңә кәләш сайлагач, чыгарсың.
Миненур. Апа, ишекне ябыгыз.
Гөлҗәүһәр. Җакшы. *(Ишекне яба.)*
Миненур. Мәрдән, бер дә күз атып йөргән кызыгыз юкмыни соң? *(Паузадан соң.)* Ник дәшмисез? Бармы, әллә юкмы?
Гөлҗәүһәр *(ишек ярыгыннан башын тыгып)*. Әллә үзем генә керимме соң, кызым? Ул пешмәгәннән ул да тумас, кыз да тумас. Туса да тормас. Харап булабыз, хатынсыз кайтып китәбез.
Мәрдән. Әнкәй!
Гөлҗәүһәр. Нәрсә әнкәй, нәрсә әнкәй? Синең өчен мин өйләнә алмыйм бит инде.
Миненур. Апа, ишекне ябыгыз.
Гөлҗәүһәр. Җакшы. *(Ишекне яба. Киредән ишекне ача.)* Сез аңа каты торыгыз.
Миненур. Апа!
Гөлҗәүһәр. Җакшы, җакшы. *(Ишекне яба.)*
Миненур. Димәк, күз атып йөргән кызыгыз юк.
Мәрдән *(оялып)*. Берәү бар иде анысы...
Миненур. Кайда?
Мәрдән. Театрда.
Миненур. Исеме ничек?
Мәрдән. Әй, оялам.
Миненур. Сиңа нинди чәчле кызлар ошый?
Мәрдән. Сезнең чәчегез төсле.
Миненур. Сезнең театрда гашыйк булып йөргән кызыгызның чәче нинди төстә?
Мәрдән. Суйган да каплаган, сезнеке төсле.
Миненур. Сезгә нинди исемнәр ошый?
Мәрдән. Алар күп. Ә сезгә?
Миненур. Миңа Галия исеме ошый.
Мәрдән *(шатланып)*. Миңа да Галия исеме ошый.
Миненур. Миңа тагын Миненур исеме ошый. Ә сезгә?
Мәрдән. Миңа ошамый. Мирсәлим абыйга ошый.
Миненур. Теге бабайлар ролен башкара торган җитмеш яшьлек Мирсәлим Борһановкамы?
Мәрдән. Әйе, безнең театрда да Миненур исемле артистка бар. Мирсәлим абый әйтә, безнең Миненурның дәрте бар, душасы юк, ди. Мин аннан менә дигән хатын ясар идем, ди.
Миненур. Болай чибәрме соң үзе?
Мәрдән. Миненурмы?
Миненур. Әйе.
Мәрдән. Алай куркырлык түгел инде.
Миненур. Урамда мине гел аның белән бутыйлар, әллә без охшаганмы?
Мәрдән. Әкият. Сез Миненур янында красавица!

М и н е н у р. Алай икән. Ярый, мин чыгыйм әле. Сезгә икенче номерны чакырыйм.

М ә р д ә н. Апа, чыкмагыз. Миңа беркем дә кирәкми. Минем яраткан кешем бар. Кайчан да булса мин аңа мәхәббәтемне аңлатачакмын.

Г ө л җ ә ү һ ә р *(ишек ярыгыннан башын тыгып)*. Алдый ул, алдый. Унҗиде ел инде мәхәббәт аңлата.

М ә р д ә н. Әнкәй!

Г ө л җ ә ү һ ә р. Җакшы, җакшы, улым, ябам. *(Ишекне яба.)*

М и н е н у р. Маэстро, музыка. *(Музыка башлана.)* Хөрмәтле икенче номерыбыз! Сезне танышу-кавышу бүлмәсенә чакырабыз.

Бүлмәгә Г а л и я килеп керә. Музыка тына.

Г а л и я. Исәнмесез.

М и н е н у р. Таныш булыгыз. Җиденче номер.

Мәрдән оялып кына башын түбән ия.

М ә р д ә н. Исәнмесез.

М и н е н у р *(Галиягә)*. Таныш булыгыз. Сезнең каршыгызда җиденче номер.

Г а л и я *(әз генә бер тезен бөгеп ала)*. Рәхмәт.

М и н е н у р. Уңышлар сезгә! *(Чыгып китә.)*

Г а л и я. Сез минем номерны ошаттыгыз?

М ә р д ә н. Мин түгел. Әни ошаткан номер.

Г а л и я. Сезнең янга утырырга мөмкинме?

М ә р д ә н. Әнә ич урындык. Урындыкка утырыгыз.

Г а л и я. Минем диванга утырасым килә.

М ә р д ә н *(урыныннан торып)*. Утырыгыз. Ә мин урындыкка утырам.

Г а л и я. Ә минем сезнең белән утырасым килә.

М ә р д ә н *(җитдиләнеп)*. Шаярмагыз. Ишек төбендә әнкәй утыра.

Г ө л җ ә ү һ ә р *(ишек ярыгыннан башын тыгып)*. Утырсын инде, утырсын. Укаң коелмас. Утыр, килен, әйдә, кызым, утыр. Астыңа салып утырсаң да, сүзем юк.

М ә р д ә н. Әнкәй!

Г ө л җ ә ү һ ә р. Чүпрәк түгел, бөгәрләнмәссең!

М ә р д ә н. Әнкәй!

Г ө л җ ә ү һ ә р. Ябам бит инде, ябам. *(Ишекне яба.)*

Г а л и я. Исемең ничек, матур егет?

М ә р д ә н *(оялып, авыз эченнән мыгырданып)*. Мә... ә...

Г а л и я. Кем? Мәм-мәм?

М ә р д ә н. Мәрдән.

Г а л и я *(кулын сузып)*. Мин — Галия.

М ә р д ә н *(аптырап)*. Галия?

Галия (*кулын кире ала*). Нигә аптырадыгыз?

Мәрдән. Сез безнең театрдагы Галиягә охшагансыз.

Галия. Күзләремме?

Мәрдән. Белмим.

Галия. Әллә бергә эшләгән дустыгызның күзләрен дә күргәнегез юк?

Мәрдән. Мин аның күзләренә карый алмыйм.

Галия. Бәлки, иреннәребез охшагандыр?

Мәрдән. Белмим.

Галия. Үбешкәнегез юкмыни?

Мәрдән. Оятсыз!

Галия. Юк, тормышта түгел, сәхнәдә...

Мәрдән. Мин сәхнәдә Галиянең күзләренә карый алмыйм. Мин сәхнәдә Галия белән үбешмим. Мин сәхнәдә Галия иҗат иткән образ белән үбешәм, тутырып-тутырып аның күзләренә карыйм.

Галия. Димәк, сез чын Галияне яратмыйсыз? Образдагы Галияне яратасыз? Ник дәшмисез? Яхшы. Мин барысын да аңладым. Мин киттем.

Мәрдән. Китмәгез, зинһар, китмәгез. Мин чын Галиянең күзләренә карарга оялам. Мин чын Галиянең иреннәренә кагылырга, чәчләреннән сыйпарга, назларга, колакларыннан үбәргә...

Галия. Кирәкми. Колагымнан кытыгым килә.

Мәрдән. Менә, менә. Чын Галиянең дә кытыгы килә. Мин аның үзенә генә хас исенә исереп яшим. Юк, юк. Карамагыз миңа алай тутырып. Мин болай да сезнең серле карашларыгыздан исереп утырам. Тыныч кына башны түбән иеп утырыйк. Сездән миңа шул да җиткән.

Гөлҗәүһәр (*ишектән башын тыгып*). Улым, Мәрдән, алты тулып килә. Җидедә спектаклең башлана. Театрга соңга каласың.

Мәрдән. Әнкәй, чукынып китсен театры.

Гөлҗәүһәр. Кызлар дип театрдан куарлар. (*Ишекне яба.*)

Галия. Сез соңармагыз. Сәхнәдәге Галиягезгә мәхәббәтегезне аңлатыгыз.

Мәрдән. Минем тормышта Заһир булып яшисем килми. Минем Мәрдән булып та яшисем килә.

Галия. Бәлки, аның да чын Галия булып яшисе киләдер. Бәлки, ул сезгә тормышта да гашыйк булып яшидер.

Мәрдән. Нигә соң ул, театрда мине күрсә, башын түбән ия? Кешеләр белән сөйләшкәндә килеп керсәм, тынып кала.

Галия. Димәк, сезгә чын мәхәббәт саклый. Чын мәхәббәт кенә телсез була, чын мәхәббәт кенә сүзсез була. Чын мәхәббәттә җаннар гына сөйләшә.

Мәрдән. Минем Галия белән чын-чынлап, күзгә-күз карашып сөйләшәсем, мәхәббәт аңлашасым килә.

Г а л и я. Барып чыкмыймы?

М ә р д ә н. Барып чыкмый шул... Ә синең үзеңнең яратканың бармы?

Г а л и я. Бар.

М ә р д ә н. Кем?

Г а л и я. Сәхнәдәге Мәрдән.

М ә р д ә н. Нигә соң алайса бирегә килдең?

Г а л и я. Җан кушуы буенча. Синең җан минем җанны, минем җан синең җанны чакырды.

М ә р д ә н. Ялгышасың. Минем җан бүтән җанга тартыла.

Г а л и я. Бик шатмын. Озакламый кулларыгыз кулга, ирennәрегез иренгә бәйләнсен.

М ә р д ә н. Амин. Гафу итегез. Мин ашыгам. Ярты сәгатьтән мин сәхнәдә булырга тиеш. Мине анда Галиям көтә.

Г а л и я. Рәхмәт сиңа, Мәрдән. (*Башыннан тотып, Мәрдәнне суырып үбә.*) Рәхмәт!

М ә р д ә н. Нишлисең?

Г а л и я. Шатлыгымнан тилерәм. Мин бәхетле, мин шундый бәхетле.

М ә р д ә н (*тамашачыларга карап*). Кияү тапса, нишләмәс иде. (*Галиягә.*) Сау булыгыз. (*Чыгып китә. Ишектән Гөлҗәүһәрнең башы күренә.*)

Г ө л җ ә ү һ ә р. Барып чыкмадымы?

Г а л и я (*йөгереп барып Гөлҗәүһәрне үбеп ала*). Булды, булды, Гөлҗәүһәр апа.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әллә, Ходаем, гашыйк булдымы?

Г а л и я. Миңа түгел.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Әй Ходаем. Кемгә?

Г а л и я. Театрдагы Галиягә. Туйга әзерлән, Гөлҗәүһәр апа, туйга.

Г ө л җ ә ү һ ә р. Бирсен Ходай. Килеп чыккан. Төкле аягы белән килсен.

Музыка. Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

М и н е н у р, Г а л и я, З ө б ә р җ ә т аптыраган хәлдә бер-берсенә карашып утыралар.

М и н е н у р. Көймә комга терәлде. Озакламый унбишенче номер алтынчы номер артыннан килеп җитә.

З ө б ә р җ ә т. Нишлибез?

Г а л и я. Ишеккә аркылы такта сугабыз да качабыз.

М и н е н у р. Чигенергә ярамый.

Г а л и я. Ярамый, ярамый. Минем үз гомеремдә ир кеше образы тудырганым юк.

Зөбәрҗәт. Театрдан берәр ир-атны чакырсак?

Миненур. Ягъни мәсәлән?

Зөбәрҗәт. Ягъни мәсәлән, Мәрдәнне.

Галия. Прочь руки Мәрдәннән. Мәрдән сезгә нәрсә...

Миненур. Таптым.

Зөбәрҗәт. Нәрсә?

Миненур. Шобага салабыз. Кем өскә чыга, шул уйный.

Галия. Өчебез дә тотам тотышабыз. Теге юлы да син читтә калдың.

Миненур. Тотам, мин дә тотам. Кая, китер уклауны.

Галия *(уклау алып чыга)*. Башладык. *(Тотам тотышалар.)* Ура, Миненур өстә калды.

Миненур. Димәк, мин алтынчы номер. Син, Зөбәрҗәт, администратор, ә син, Галия, официантка. Киттек, Галия. Миңа грим сал.

Зөбәрҗәт. Ашыкмагыз. *(Ящиктан карточканы тартып чыгара.)* Унбишенче номерның теләгән белик. Аңа таза ир кирәкме, ябыкмы, мыексызмы, мыеклымы, сакаллымы, сакалсызмы?

Миненур. Вакыт аз калды. Озакламый килеп җитә. Рәтен беләсең.

Миненур белән Галия эчке бүлмәгә кереп китәләр. Звонок шалтырый. Зөбәрҗәт ашыга-ашыга өстәл артына кереп утыра. Чәчләрен рәтли, җырлый.

Зөбәрҗәт. Син кайларда йөрисең икән,
Бәхетем, көләч йөзле иркәм.
Кайтырсың дип, мин өмет итәм,
Мин сине һаман сагынып көтәм.
Керегез, кер. Ишек ачык.

Бүлмәгә попугай кыяфәтендәге төрле төстәге киемнәр кигән, бик каты бизәнгән Сәмига килеп керә.

Сәмига. Можнымы?

Зөбәрҗәт. Можно, можно, даже нужно.

Сәмига. Здравствуйте.

Зөбәрҗәт. Исәнмесез. Рәхим итегез. Менә минем янга, бирегә утырыгыз.

Сәмига. Яхшы. *(Утыра.)*

Зөбәрҗәт. Сез ничәнче номер?

Сәмига *(тәмәке кабыза)*. Унбишенче номер дип торабыз.

Зөбәрҗәт *(Галиягә эндәшеп)*. Әй, сез, унбишенче номерга көллек чыгарыгыз. *(Галия көллек чыгара да кире бүлмәсенә кереп китә.)*

Сәмига. Минем исем, фамилиям, отчеством бар. Мине номер белән атамавыгызны сорыйм. Мин сезгә зек та, тоткын да түгел. Мин — Сәмига апагыз Чайбалсанова Кадышовна булырмын.

Зөбәрҗәт. Яхшы. Сез алтынчы номер белән танышырга теләк белдердегез.

Сəмига (*калын ирлəр тавышы белəн көлеп*). Əйе, белдердем. Əй бичара алтынчы номер.

Зөбəрҗəт. Паспортыгызны бирегез.

Сəмига. Что?

Зөбəрҗəт. Паспортыгызны бирегез.

Сəмига. Что за безобразия? Кая барма паспорт сорыйлар. Əле загска барып җитмəгəн, аларга паспорт давай.

Зөбəрҗəт. Борчылмагыз. Без ананимно эшлибез. Кем белə, бəлки, без сезне таныштырган кеше берəр бандиттыр. Аның да паспортына күз төшерəчəкбез.

Сəмига. Бандит? Мин үзем бандит, сеңлем. Бандитларны күп күргəн. (*Сумкасыннан паспортын чыгарып, Зөбəрҗəткə суза.*) Тизрəк кыймылдасагыз иде. Ярты сəгатьтəн соң минем бер важный персон белəн очрашасым бар.

Зөбəрҗəт (*паспортны карап*). Димəк, сез Свердлов урамы, җиденче йорт, сигезенче фатирда яшисез?

Сəмига. Сеңлем, мине үземнең йорт, ничəнче фатирда яшəвем кызыксындырмый, аның фатиры кызыксындыра.

Зөбəрҗəт. Ике балагыз бар икəн.

Сəмига. Əйе, танышасы кешемə ул мəшəкатьне калдырмадым. Димəк, бу нəрсəне аңлата?

Зөбəрҗəт. Нəрсəне?

Сəмига. Димəк, миңа сиксəн, туксан яшьлəрдəге берəр бай бабай табып бирсəгез, калганын үзем карармын.

Зөбəрҗəт. Алай димəгез, Сəмига Кадышевна. Бəлки, без сезгə по-блату гына яшь тə, бай да, баласыз да берəр кавалер табып бирербез.

Сəмига. Сез бик тə сөйкемле.

Зөбəрҗəт. Шулаймы?

Сəмига. Шулай.

Зөбəрҗəт. Сөйкемлелек сөяк сындырмый, тамак та туйдырмый.

Сəмига. Шулай дисезме?

Зөбəрҗəт. Шулай димен.

Сəмига. Күпмерəк дисез инде?

Зөбəрҗəт. Биш.

Сəмига. Биш меңме?

Зөбəрҗəт. Биш йөзгə роддомда хəзер үз балаңны төреп тə бирмилəр. Яхшы товар урамда аунап ятмый, хатыннарыннан да артмый.

Сəмига. Шулай дисезме?

Зөбəрҗəт. Шулай димен.

Сəмига. Яхшы. Мин риза. Бай гына булсын. Мин аны меңе белəн кире кайтарам əле. (*Сумкасыннан акчаны чыгарып саный.*) Алыгыз. Төгəл биш мең.

Зөбəрҗəт. Рəхмəт. Ə сез паспортыгызны алыгыз.

*(Кычкырып сөйли башлый.)* Бай. Сезнең яшьләрдә. Примерно илле, илле биш яшьләр тирәсендә. Хатыны үлгән. Балачагасы юк.

Сәмига. Туктагыз әле, туктагыз!

Зөбәрҗәт *(шул ук тонда)*. Машинасы бар.

Сәмига *(җикеренеп)*. Туктагыз, дим, туктагыз!

Зөбәрҗәт *(пышылдап)*. Нәрсә булды?

Сәмига. Тик торганда нигә акырасыз?!

Зөбәрҗәт. Ишетелсен дип.

Сәмига. Кемгә?

Зөбәрҗәт. Аңа.

Сәмига. Кемгә аңа?

Зөбәрҗәт. Ну инде, кемгә, кемгә? Аларга.

Сәмига. Кемгә аларга?

Зөбәрҗәт. Ну, сезгә. Сәмига Кадышевнага.

Сәмига. Сеңлем, Сәмига Кадышевна чукрак түгел, пышылдап сөйләшсәң дә ишетә.

Зөбәрҗәт. Яхшы. *(Иреннәрен селкетә.)*

Сәмига. Нәрсә? *(Зөбәрҗәт тагын иреннәрен селкетә.)* Нәрсә дисең? Нәрсә? Ишетмим.

Зөбәрҗәт *(акырып җибәрә)*. Кайда эшлисең, димен.

Сәмига *(куркуыннан урындыгыннан егылып төшә)*. Уф! Үтерәсең, сеңлем. *(Җайлап урындыгына утыргач.)* Кем?

Зөбәрҗәт. Алтынчы номер.

Сәмига. Ну, берәр зур нәрсә инде. Йә булмаса, бизнесмен.

Зөбәрҗәт. Нәрсә?

Сәмига. Бизнесмен.

Зөбәрҗәт *(колагын Сәмигага сузып)*. Нәрсә?

Сәмига *(ачуы чыгып, акырып)*. Чукрак, димен.

Зөбәрҗәт. Юк. Мин чукрак түгел. Үз тавышым үземне глушить итте. Нәрсә дисең?

Сәмига *(сузып)*. Биз-нес-мен. Бизнесмен.

Зөбәрҗәт. Ә, бизнесмен. Шулай диген аны. Хәзер минем сорауларга кычкырып җавап бир инде.

Сәмига. Яхшы, яхшы.

Зөбәрҗәт. Сезгә сакаллы кирәкме?

Сәмига *(кычкырып)*. Сакалы булмаса, сакал үстереп була. Бик юан булмасын иде.

Зөбәрҗәт. Нәрсә?

Сәмига *(сузып)*. Бик ю-ан бул-ма-сын и-де. Юан булмасын иде.

Зөбәрҗәт. Бик теләсәң дә, юанын таба алмыйбыз. Күкрәкләре — во!

Сәмига. Во!

Зөбәрҗәт. Гомер буе спорт белән шөгыльләнгән. Хатын-кызларныкыннан ким түгел.

Сәмига. Аяклары ничегрәк?

Зөбәрҗәт (*чәнти бармагын күрсәтеп*). Менә.

Сәмига. Шулай бик нечкәмени?

Зөбәрҗәт. Сабый чагында рахит белән авырган.

Сәмига (*шикләнеп*). Рахит?

Зөбәрҗәт. Зато хәзер үгез кебек.

Сәмига. Үзе кайчан килер микән?

Зөбәрҗәт. Күптәннән биредә. (*Галия белән Миненур бүлмәләренә карап.*) Әй, сез, әзерме?

Галия (*эчке бүлмәдән*). Әзер.

Зөбәрҗәт (*Сәмигага*). Сез әзерме?

Сәмига. Әзер.

Зөбәрҗәт. Аллага тапшырып башлыйбыз. Маэстро, музыка.

Мендельсон маршы яңгырый. Түр бүлмәнең ишеге ачылып китә. Ишектән башына шляпа, уң кулына капрон сирень букеты, сул кулына сырлап ясалган таяк тоткан, кап-кара сакал-мыектан, кап-кара костюм, ак күлмәк, ялтырап торган кырык алтынчы размерлы туфлидән Миненур чыга да озак кына Сәмигага текәлеп карап тора. Музыка беткәч, җырлап җибәрә.

Миненур.

Син кайларда йөрисең икән,
Бәхетем, көләч йөзле иркәм.
Кайтырсың дип, мин өмет итәм,
Мин сине һаман сагынып көтәм.

Җырлап бетергәч, шляпасын сала да башын түбән ия. Яңадан шляпасын сырлап ясалган таяк башына элә.

Миненур (*ашыкмыйча*). Исәнмесез!

Шляпа белән сырлап ясалган таякны Галиягә суза, Галия ашыгып килеп ала да чыгып китә. Миненур Сәмига янына килә дә букетны суза.

Сәмига (*калтырый-калтырый букетны алып*). Рәхмәт сезгә! (*Исни.*) Шундый хуш исле сиреньнәр.

Миненур (*ашыкмыйча*). Пластмасс чәчәкләр. Үземнең заводымда йөрәк җылымны биреп эшләткән чәчәкләр. (*Уң кулын алга суза. Аның кулына Сәмига сул кулын сала. Миненур тезләнә дә сул кулын алга сузып.*) Маэстро, музыка. (*Сәмигага.*) Мадам, танго! (*Сәмиганы бөтереп алып куенына тыга да «Ну, погоди» мультфильмындагы Бүре ролендәге Папанов тавышы белән җырлап.*)

Ты, Снегурочка, где была,
Ты, Снегурочка, как жила?

Сәмига (*Куян ролендәге Румянова тавышы белән*).

За тобой бежал я, Дед Мороз,
Пролила не мало я горьких слез.

Миненур.

А ну-ка, давайка,
Плясать выходи!

Сәмига.

Нет, Дед Мороз,
Нет, Дед Мороз, погоди!

Миненур. Әйдәгез, йомшакка, диванга! *(Диванга утыралар.)* Таныш булыйк. Мин — Миңнур Биктәнурович Хикмәтов.

Сәмига *(торып баса да тезен чүгеп)*. Ә мин — Сәмига Кадышевна!

Миненур *(аның кулын үбеп)*. Танышуыбызга мин бик шатмын. *(Сәмига кире диванга утыра.)* Сезгә нинди вино?

Сәмига. Сухой.

Миненур. Кайсы илнекен?

Сәмига. Үзегезгә карагыз.

Миненур. Белое португальское вино, тысячелетним выдержками.

Сәмига. Үзегезгә карагыз.

Миненур. Или... Индийский чәй шәрабы лимонаттий...

Сәмига. Беренчесе яхшырак булыр.

Миненур. Яхшы. Әй, сез, официантка!.. *(Галия чыга.)*

Галия. Тыңлыйм сезне.

Сәмига. Белое португальское вино, тысячелетним выдержками!

Миненур. Миңа гаванское сигаро, бразильский школад!

Галия. Яхшы. *(Чыгып китә.)*

Миненур. Сөйләгез. Ничегрәк яшисез?

Сәмига. Зарланмыйм. Уртача. Ирем юк. Үзем генә.

Миненур. Ә балаларыгыз?

Сәмига. Балаларга тәрбияне бывший ирем бирә.

Миненур. Кайда яшисез?

Сәмига. Иремнең фатирында.

Миненур. Ә ирегез кайда яши?

Сәмига. Әти-әнисе, ике балам белән аталары йортында.

Миненур. Йортлары коттеждмы, әллә вилламы?

Сәмига. Аларга тагын коттежд, вилла... Усак бүрәнәдән салынган йортта.

Галия чыга да өстәлгә ике фужер, сигарет, шоколад куя.

Галия *(пышылдап, Миненурның колагына)*. Бездә португальское вино юк.

М и н е н у р *(пышылдап)*. Кухняда, өстәл астында португальский буш шешә ята. Шуңа гөмбә суы сал да алып кер.

Г а л и я. Яхшы. *(Керел китә.)*

С ә м и г а. Нәрсә ди?

М и н е н у р. Сез шундый пар килгәнсез, ди.

С ә м и г а. Мондагы обслуга миңа бик тә ошый.

М и н е н у р. Миңа да.

С ә м и г а. Ә сез үзегез?

М и н е н у р. Минем биредә коттежд! Кара диңгез буенда вилла!

С ә м и г а. Миңнур Биктәнурович, сер булмаса, үзегез өйләнгәнме?

М и н е н у р. Кайчандыр.

С ә м и г а. Балаларыгыз?

М и н е н у р. Кызганычка каршы, булмады шул.

Бүлмәгә шешә күтәреп, Г а л и я чыга да фужерларга эчемлек сала.

Г а л и я. Күңелле ял итегез! *(Керел китә.)*

М и н е н у р. Рәхмәт.

С ә м и г а. Рәхмәт сезгә.

М и н е н у р *(кулына фужер алып)*. Әйдәгез, безнең танышу хөрмәтенә.

С ә м и г а. Рәхмәт. *(Кулына фужер ала, фужерларын чәкештерәләр дә эчәләр.)*

М и н е н у р. Йә, ничек Португалия виносы?

С ә м и г а. Искиткеч. Шундый аромат!

М и н е н у р. Сезнең заказ белән үзем кайтарттым. Шәһәрдә кибетләрдә мондый вино юк.

С ә м и г а. Юктыр шул. Мондыйны авыз иткәнем юк иде. Әйтегез әле, Миңнур Биктәнурович, сез бирегә нинди ният белән килдегез? *(Фужерларын өстәл өстенә куялар.)*

М и н е н у р. Сезне эзләп.

С ә м и г а. Сезгә миннән башка да гүзәлләр бетмәгән.

М и н е н у р. Миңа урам, бар кызлары кирәкми. Кимсетмәгез мине. Миңа үземне эзләгән кеше кирәк.

С ә м и г а. Аңламыйм...

М и н е н у р. Бирегә мин сезне эзләп килдем. Сез мине эзләп килгәнсез. Безгә сездәй хатын кирәк. Безнең юлыбыз сездәйләрне яктылыкка алып чыгу.

С ә м и г а. Дөрес. Яктылык күрсәтүчеләр булмады анысы. Беренче ирем чуаш иде. Чуаш иде — юаш иде. Хатынын күз алдында алып китсәләр дә карап кала иде. Үз хатынын да саклый алмаган ир белән яшәгәнче, дип аерылыштым.

М и н е н у р. Ә икенчесе?..

С ә м и г а. Икенчесе?.. Яшермим. Икенчесе артык гадел иде. Сөйләшеп, товар складына зав итеп урнаштырдым. Эштән өйгә алып кайтыр урынына, өйдән эшкә ташый иде. Бу аңгыра белән яшәгәнче дип, фатирын бүлдем дә үзен башка чыгардым.

М и н е н у р. Өченчесе, өченчесе?..

С ә м и г а. Өченчесе... Өченчесе тора башлаганда ничего иде. Бераздан характерын күрсәтә башлады. Соңга калсаң, ярамый. Соңга калам, диеп, машина белән озаттырсаң, ярамый. Син нәрсә, мин әйтәм, синең хатының соңга кала дип, верталет белән озатмаслар бит. Хатыныңның вакытында кайтуын теләсәң, машина алып бир, дидем. Булдыралмады. Ике баламны җитәкләттем дә куып чыгардым. Сезнең хатыныгызның машинасы бар идеме?

М и н е н у р. Көймәсе бар иде. Причалы миндә иде.

С ә м и г а. Менә бит. Юньле ирләрнең хатыннарының көймәләренә кадәр бар. Ә минем мәхлукларга причал тагын. Көймәсе дә тәтемәде.

М и н е н у р. Сезне танецка чакырырга мөмкинме?

С ә м и г а. Мөмкин, әлбәттә.

Бүлмә уртасына чыгып бии башлыйлар. Сәмига Миненурның муеныннан кочаклап ала. Миненур аның биленнән кочаклый.

М и н е н у р. Сез шундый күркәм.

С ә м и г а. Ә сез шундый йомшак, әйтерсең лә кызлармыни?

М и н е н у р. Кит аннан, булмас.

С ә м и г а. Сез спорт белән шөгыльләнмәдегезме?

М и н е н у р. Нигә?

С ә м и г а. Күкрәкләрегез хатын-кызларныкыннан бер дә ким түгел, төртеп торалар.

М и н е н у р. Әйе, мин гомерем буе спорт белән шөгыльлләндем!

С ә м и г а. Сез нинди одеколон сөртәсез?

М и н е н у р. Нигә?

С ә м и г а. Бик йомшак, нәфис ис.

М и н е н у р. Юк, мин одеколон кулланмыйм. Минем кул астымда бик күп хатын-кызлар эшли. Бирегә килер алдыннан планерка җыйган идем. Шуларның духи исе сеңгәндер.

С ә м и г а. Ялгышмаганмын. «Шанель» исе.

М и н е н у р. Әллә көнләштегез инде.

С ә м и г а. Әллә ярамыймы?!

М и н е н у р. Әлбәттә, ярый. Мин бик шатмын. Димәк, мин сезгә күпмедер дәрәҗәдә ошыйм.

С ә м и г а. Юк, сез миңа аеруча бик-бик тә ошыйсыз. Бүгеннән планерканы икәү генә уздырырбыз. *(Үпмәкче була.)*

М и н е н у р. Ярамый!

С ә м и г а. Нигә?

Миненур. Миннән вино исе килә.

Сәмига. Гафу итегез. Ә мин винодан исердем.

Миненур (*тамашачыларга карап*). Чын вино салып бирсәң, нишләмәс. (*Сәмигага.*) Миңа кайткач.

Биюләреннән туктап, бер-берсенә карап.

Сәмига. Ә кайчан сиңа кайтабыз?

Миненур. Алла боерсаңны онытма.

Сәмига. Алла боерса... (*Диванга барып утыралар.*)

Миненур. Минем бер гадәтем бар. Мин үземнең йортыма, гомерлеккә киләсе кешене пропискага кертмичә, өемә, ягъни коттеждыма кертмим.

Сәмига. Ә минем иремнән калган өч бүлмәле фатирымда пропискам бар.

Миненур. Ә син аннан төш тә миңа кер.

Сәмига. Фатирымны нишләтим?

Миненур. Иреңә бир.

Сәмига. Тотсын!

Миненур. Балаларың хакына.

Сәмига. Балаларым хакына дисең инде...

Миненур. Безгә ул фатирның нигә кирәге бар? Икебезгә болын кадәрле коттеждыбыз бар.

Сәмига. Яхшы. Сез кушкач, мин риза. Сезнең һәр сүзегез минем өчен закон!

Миненур. Сез түгел, син! Карап-карап торам да, тагын бер тапкыр карап куям. Син шундый акыллы хатын!

Сәмига. Ә син, син үзең...

Миненур. Беләм, мин усал хатын!

Сәмига. Шутник син! (*Битеннән үбеп ала.*) Кайчан туй ясыйбыз?

Миненур. Кара диңгез өстен боз каплагач.

Сәмига. Нигә?

Миненур. Туебызны кара диңгез буендагы виллабызда үткәрер өчен.

Сәмига. Туйдан соң нишләрбез?..

Миненур. Кара диңгез өстендә, бозда, тимераякта шуарбыз.

Сәмига. Ә мин тимераякта шуа белмим.

Миненур. Шуарсың. Дөнья өйрәтә ул. Дөнья шудыра ул.

Сәмига. Син шундый юмарт. Өстәвенә акыллы. Ә бүген нишлибез?

Миненур. Өйләребезгә кайтабыз.

Сәмига. Минем синнән бер генә минутка да аерыласым килми.

Миненур. Озакламый гел бергә булырбыз. Бүген мин ике сәгатьтән Америкага консилиумга очам. Бер атнадан кай-

там. Син шул арада фатирыңнан пропискадан төш тә, ирең, ике балаңны шунда пропискага керт. Ә инде шушы айның утыз берендә, кичке сәгать җидедә «Ак каен» ресторанының ишек төбендә үсеп утырган ялгыз каен төбендә очрашырбыз.

Сәмига. «Ак каен» рестораныңда?..

Миненур. Әйе.

Сәмига. Ялгыз каен төбендә?

Миненур. Әйе.

Сәмига. Утыз берендә?

Миненур. Кичке җидедә! Менә сиңа биш мең сум акча, кесә расхотына. *(Урыныннан тора. Кесәсеннән акчалар чыгарып бирә.)*

Сәмига. Юк, кирәкми, сез нәрсә?..

Миненур. Алыгыз, ал. Үзегезнеке кебек итеп алыгыз.

Сәмига. Рәхмәт. Сез нинди юмарт.

Миненур. Мин ашыгам. Хәзергә исән-сау булыгыз. Пока! *(Тавышын күтәреп.)* Әй, сез!.. *(Ишектән, атылып, Галия килеп чыга.)*

Галия. Тыңлыйм сезне!

Миненур. Шляпамны! Ашыгам. Сәгать ярымнан самалетым оча.

Галия. Яхшы. *(Кереп китә дә сырлап ясалган таяк белән шляпа алып чыгып Миненурга тоттыра.)* Рәхмәт сезгә!

Миненур. Үзегезгә рәхмәт. Шушындый гүзәл зат белән мине таныштырганыгыз, кавыштырганыгыз, аның балаларын, ирен, бигрәк тә мине бәхетле иткәнегез өчен сезгә зур-зур рәхмәтләр яусын. Исән булыгыз. *(Сәмигага.)* Сөеклем, утыз берендә кичке җидедә очрашканга кадәр сау булыгыз! *(Чыгып китә.)*

Сәмига *(бүлмә буйлап йөренә. Куанычыннан кая басарга белмичә бөтерелеп)*. Мин бәхетле бүген, мин бәхетле, кызлар! Мин очам!.. Мин байлыкта йөзәм!..

Галия *(тамашачыларга карап)*. Әй бичара.

Сәмига *(бөтерелгән җиреннән Галияне кочаклап туктап кала)*. Менә сиңа өч тәңкә! Минем счеттан мороженый алып ашарсың!

Галия. Рәхмәт. Мин мороженый яратмыйм.

Сәмига. Ал инде, ал!

Галия. Үзегезгә булсын.

Сәмига. Әллә азсынасыз?..

Галия. Мин сезнең өч тәңкәгезгә калмаган.

Сәмига. Йолкыш. Тонын күтәргән була. Өч тәңкәгезгә калмаган, имеш. Биш минуттан миллионер хатыны булырга торсам да, миннән артмый ул. *(Арт санын уйнатып чыгып китә.)*

Галия *(ул чыгып киткән якка карап торганнан соң)*. Гөмбә!

Музыка. Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Г а л и я диванда, З ө б ә р җ ә т өстәл янындагы урындыкта утыра. М и н е н у р, кулына хат тоткан килеш, үзен-үзе кая куярга белмичә, бүлмә буйлап арлы-бирле йөри.

М и н е н у р. Вот сволочь! Миңа нәрсә дигән була бит. Әгәр синнән аерылсам, унсигез яшьлек кызга өйләнәм дигән була бит. Өтәчке.

З ө б ә р җ ә т. Бәлки, ул синең Рөстәмең түгелдер?..

М и н е н у р. Шул булмыйча. Менә *(хатка карап)* буе туры килә, чәче дә туры килә. Җырларга яратам, дигән. Җырларга дигәндә, минем Рөстәмем ашавын оныта. Өстәвенә гармунда да уйныйм, дигән. Артист! Күрсәтәм әле мин сиңа филармонияне!

Г а л и я. Нигә аңа исең китте. Ул бит инде барыбер синеке түгел.

М и н е н у р. Каян беләсең? Бәлки, ул кире уйлар.

З ө б ә р җ ә т. Уйлар, бар. Уйласа, монда хат язмый инде ул.

Г а л и я. Алай димә әле син, Зөбәрҗәт. Юаштыр... Миненурга да өйләнмәде, кияүгә чыкты түгелме соң ул!

М и н е н у р. Нигә кияүгә чыксын ул. Ул мине, беләсең килсә, яратып өйләнгән иде бугай.

Г а л и я *(шаркылдап көлеп)*. Бугай... Яратса, ташлап китмәс иде.

З ө б ә р җ ә т. Ә син үзең, Миненур, аны ярата идеңме?

М и н е н у р. Кирәге бар иде.

З ө б ә р җ ә т. Исеңә дә кереп карамыймы?

М и н е н у р. Бөтен бәла дә шунда шул. Төшкә кереп азаплый. Җыры колагымда чыңлый.

Г а л и я. Йә, ярый, кызлар, аның белән кемне очраштырабыз?

З ө б ә р җ ә т. Билгеле инде, Миненурны.

М и н е н у р. Булмый! Аның белән очрашуга, тез буыннарым калтырый башлый.

З ө б ә р җ ә т. Бәлки, үзем очрашырмын...

Г а л и я. Кычкыртып талыйм үзен. Мин администратор булам.

М и н е н у р. Кызлар, бер тиененә дә тиясе булмагыз. Ишетсен колагыгыз, безнең задача кеше талау түгел, безнең задача — адашканнарга туры юл күрсәтү.

З ө б ә р җ ә т. Мин аңа туры юлны күрсәтәм. Туры юлны күрсәтәм мин аңа.

Г а л и я. Ник килгәненә үкенсен.

З ө б ә р җ ә т. Ул ниндирәк характердагы кызларны ярата?

Миненур. Борчылмагыз. Ул сезнең икегезнең берегезгә дә борылып карамаячак. Куркыта гына күрмәгез.

Галия. Әй, сөйләгән була. Синнән курыкмаган бит әле.

Миненур. Аның үз вкусы бар.

Галия (*көлеп*). Зөбәрҗәт, ишетәсеңме, үз вкусы бар, ди. Ха... ха... ха... Үз вкусы...

Миненур. Ярый, телеңә салынма, эшеңдә бул!

Галия (*көлә-көлә*). Ишетәсеңме, нәрсә ди...

Зөбәрҗәт. Үз вкусы бар, ди. Ха... ха... ха...

Миненур белән Зөбәрҗәт эчке бүлмәгә кереп китәләр. Галия өстәл артына барып утыра. Ишектә звонок шалтырый.

Галия (*чәчләрен рәтли-рәтли*). Керегез. Ишек ачык!

Бүлмәгә ап-ак костюм, кара күлмәк, кара туфлидән кулына роза чәчәкләре тоткан Рөстәм килеп керә. Миненур, Рөстәмгә сиздермичә, үз бүлмәсенең ишеген ачып куя.

Рөстәм. Исәнмесез, кызлар! Шаяннар-наяннар!

Галия. Исәнмесез. Шаян икәнебезне каян беләсез? Экстроциянс түгелдерсез бит?

Рөстәм. Юк, экстросекс!

Галия. Шулайдыр шул. Үзегез кызлар белән таныша алмагач, белдерү буенча танышырга килгәнсездер шул. Менә бирегә утырыгыз. Минем каршыма.

Рөстәм (*урындыкны алып читкәрәк китеп утыра*). Юк, мин сездән читкәрәк китеп утырам.

Галия. Мин кеше ашамыйм.

Рөстәм. Сезнең матурлыгыгызны күреп, һуштан язармын дип куркам.

Галия. Сез, егет, бирегә ялгыш килгәнсез. Сезнең тел белән безгә килеп торасы юк.

Рөстәм. Беренчедән, егет түгел, хатын аерган ир, икенчедән, тел бар, кыяфәт юк. Өченчедән, тиз арада миңа өйләнергә кирәк.

Галия. Нигә?

Рөстәм. Хатыныма үч итеп.

Галия. Өйләнеп хатыннан үч алып буламыни?

Рөстәм. Була. Чөнки ул алдан кияүгә чыкса — мин, мин алдан өйләнсәм — ул көнчелегеннән шартлаячак.

Галия. Исемегез?

Рөстәм. Хатымда язылган.

Галия. Номерыгыз?

Рөстәм. Бәхетсез! Үзем дә бәхетсез, номерым да бәхетсез! Унөч!

Г а л и я (*өстәлдәге тартмадан унөченче номерны тартып чыгара да укый*). Тулай торакта торасыз икән! Әллә фатирыгыз да юк?

Р ө с т ә м. Юк! Үзем дә күзем!

Г а л и я. Аерылган хатыныгыз Миненур икән.

Р ө с т ә м. Әйе, Миненур.

Г а л и я. Миненур Хөрмәтова!

Р ө с т ә м. Әйе, Миненур Хөрмәтова!

Г а л и я. Туктагыз, туктагыз...

Р ө с т ә м. Ә без туктап торабыз.

Г а л и я. Миненур Хөрмәтова артистка түгелме соң ул?

Р ө с т ә м. Нәкъ үзе. Өстенә бастыгыз.

Г а л и я. Шушы матурлыгыгыз белән шул Миненур Хөрмәтовага өйләндегезме?

Р ө с т ә м. Аның үз матурлыгы, сезнең үз матурлыгыгыз.

Г а л и я. Аерма?

Р ө с т ә м. Аерма шунда ки, аның эчке матурлыгы бар.

Г а л и я. Сәхнәдә уйнавын әйтер идем инде.

Р ө с т ә м. Әй җаным, һәрхәлдә, Галия белән Зөбәрҗәт түгел инде. Мин ул Галияне, пичкә керсә, арт саныннан таныйм.

Г а л и я. Таныйсыңмы?

Р ө с т ә м. Галиянеме? Запросто! Уйнап азапланмасын да. Ә менә Миненур сәхнәдән узып кына китә, бөтен зал егыла.

Г а л и я. Алай булгач, нигә аерылдың соң?

Р ө с т ә м. Үзем гаепле. Аңлап җиткермәгәнмен мин аны.

М и н е н у р (*эчке бүлмәдән*). Юк, юк, син гаепле түгел!

Р ө с т ә м (*сискәнеп китә*). Кем ул?

Г а л и я. Ә, ул. Ул — күрше бүлмәдәге попугай.

Р ө с т ә м. Нәкъ Миненур тавышы.

Г а л и я. Кит аннан.

Р ө с т ә м. Миненурда шул попугай башы булсын иде.

Г а л и я. Сез ничәнче номер белән очрашырга теләк белдергән идегез?

Р ө с т ә м. Миңа нинди номер да ярый. Мин Миненурга үч итеп кенә өйләнәм. Аннан башка миңа барыбер тормыш юк.

Г а л и я. Сез танышырга теләгән унҗиденче номер килеп җитмәде шул. Бәлки, килмәведер. Мин үзем дә парсыз, әллә соң мин әйтәм...

М и н е н у р (*әби киеменнән ишектән башын чыгарып*). Нишләп килмәсен, килде, килде ул бала.

З ө б ә р җ ә т (*бүлмәдән килеп чыга*). Менә ич мин, менә! (*Бүлмә уртасында бөтерелеп.*) Менә мин ич ул унҗиденче номер. (*Галиянең ачуы килеп, бүлмәдән чыгып китә.*)

Р ө с т ә м (*утырган урыныннан торып*). Исәнмесез.

З ө б ә р җ ә т. Исәнмесез.

Р ө с т ә м *(Зөбәрҗәткә чәчәк сузып)*. Алыгыз!

Бүлмәдән әби кыяфәтендәге М и н е н у р килеп чыга.

М и н е н у р. Кыҗым, чәчәгеңне суга утыртыйммы?

З ө б ә р җ ә т. Утыртмый тор әле!

М и н е н у р. Шиңә, валлаһи, шиңә!

З ө б ә р җ ә т. Шиңсә! Нигә борчыласың?! Сиңа түгел, миңа бүләк ителгән.

М и н е н у р. Нәчтә закаҗат итәсез?

Р ө с т ә м. Борчылмагыз, әби. Берни дә кирәкми.

З ө б ә р җ ә т. Ә минем коньяк эчәсем килә.

М и н е н у р *(Рөстәмгә ишетелерлек итеп пышылдаган булып)*. Эчмичә дә холкың чамалы, ишетсен колагың, кияүне качырасың! *(Рөстәмгә.)* Һи... һи... һи... Җарый, улым, җарый.

Р ө с т ә м *(шикләнеп)*. Әби, ике йөз грамм җитәр. Аннары шиколад кирәк булыр. *(Зөбәрҗәткә.)* Тагын нәрсәләр заказать итим.

З ө б ә р җ ә т. Фрукты!

М и н е н у р. Фрукты җук! Фрукты Әчтерханда.

З ө б ә р җ ә т. Әби, сездә нәрсә генә бар соң?

М и н е н у р. Чиснук!

З ө б ә р җ ә т. Син үзең чиснук!

М и н е н у р. Португальский вино.

З ө б ә р җ ә т. Рәхмәт инде. Музыка куй!

М и н е н у р. Соң инде. Күршеләр ачулана.

З ө б ә р җ ә т. Әбекәй, егет янында үзеңне генә калдырып чыгып китәм бит.

М и н е н у р. Куям, куям. *(Магнитофон янына барып, бик ямьсез рок музыка куя да икенче бүлмәгә чыгып китә.)*

З ө б ә р җ ә т *(барып музыканы алмаштыра. Утны сүндерә)*. Белый танец! *(Рөстәмне биергә чакыра.)*

М и н е н у р *(калтырый-калтырый кулына коньяк, шоколад, ике рюмка куелган поднос күтәреп чыга да Зөбәрҗәткә)*. Яндыр утны! Күрмисеңмени, кулымда поднос. *(Зөбәрҗәт утны яндыра. Арт саны белән Зөбәрҗәткә бәрелеп китә.)* Читкәрәк кит! Өлкән кешегә җул бир!

З ө б ә р җ ә т. Әби, мин хәзер үк администраторны чакырам.

М и н е н у р. Администраторны?! Чыкмый ул! Бу балага гашыйк булып җылый-җылый шешенеп бетте. Булмый сезнең белән. Бу оешманы ябарга туры килер.

Р ө с т ә м. Әби, безне үзебезне генә калдырсагыз иде.

М и н е н у р. Җарый, җарый. Рәҗве мин каршы. *(Подносны өстәл өстенә куя. Керер китkәндә, ишеген ябып бетерми.)*

Р ө с т ә м (*өстәл янына барып, рюмкаларга коньяк сала*). Минем исемем — Рөстәм. (*Рюмканың икенчесен Зөбәрҗәткә суза.*) Сезнең исемегез?

З ө б ә р җ ә т (*тезен бөгеп, уң кулын Рөстәмгә суза*). Зөбәрҗәт! (*Рөстәм аның кулын үбәргә иелүе була, Миненур идәнгә кашык төшереп җибәрә.*)

М и н е н у р (*эчке бүлмәдән*). Прәс, мөртәт! (*Рөстәм белән Зөбәрҗәт сикереп куялар.*) Юньле кеше ана мәче асырыймы?!

Р ө с т ә м (*рюмкасын өскә күтәрә*). Сезнең исәнлеккә! (*Рөстәм белән Зөбәрҗәт рюмкаларын чәкештерергә үрелгәч, Миненур килеп чыга да тәрәзә янына килә.*)

М и н е н у р. Тәрәҗәне ныклап ябыйм әле, радиудан давыл, диделәр. (*Тәрәзә пәрдәсен тарта да кире бүлмәсенә кереп китә, ишекне ярым ачык калдыра.*)

Р ө с т ә м. Булмас монда. Әллә берәр ресторанга барып утырабызмы?

З ө б ә р җ ә т. Бик шатланып.

М и н е н у р (*ишек ярыгыннан башын чыгарып, ягымлы тавыш белән сөйкемле елмаеп*). Балалар, балалар, димен. Мин сезгә кирәк булмасам, йокларга ятар идем.

Р ө с т ә м. Ят, ят, әби. Рөхсәт, бик рөхсәт.

З ө б ә р җ ә т. Өч көн, өч төн йокласаң да, сүзебез юк.

М и н е н у р. Җарый алайса. (*Ишек ярыгыннан башын ала.*)

Р ө с т ә м. Менә монда бирегә, диванга, минем янга, йомшакка утырыгыз.

З ө б ә р җ ә т. Бик шатланып. (*Икесе дә диванга барып утыралар.*)

Р ө с т ә м. Гафу итегез, мондый сорау биргәнгә, сез кияүдә булдыгызмы?

М и н е н у р (*ишек ярыгыннан башын тыгып*). Кара әле, кыҗым. Мин җоклыйм диюен дидем дә, синең кыҗыңны сәдиктән аласы җукмы суң?

З ө б ә р җ ә т. Нәрсә сөйлисең син?! Нинди кыз?!

М и н е н у р. Игеҗәкнең сыңарын.

З ө б ә р җ ә т. Әби, әйттерәсең!..

М и н е н у р. Җәрдәм итмәкче идем. Җарый, җоклыйм.

Р ө с т ә м. Бу әбинең белмәгәне юк.

З ө б ә р җ ә т. Нәрсә белә?!

Р ө с т ә м. Синең игезәк балаларыңа кадәр белә.

З ө б ә р җ ә т. Минем балаларым юк! Мин әле кияүгә чыкмаган.

Р ө с т ә м. Яшермәгез. Мин үзем дә бер тапкыр өйләнгән. Өйләнмәгән, кияүгә чыкмаган кеше бирегә игълан буенча танышырга килми, билгеле. Зыян юк.

З ө б ә р җ ә т. Мин самым деле кияүдә булмадым.

Р ө с т ә м. Ышанды дип уйлагыз. Ә мин бер актрисага өйләнгән идем.

З ө б ә р җ ә т. Мин театрга еш йөрим. Барлык артисткаларны да беләм. Сер булмаса, кем иде ул?

Р ө с т ә м. Улмы, ул... Бик талантлы артистка ул. Тели икән, яшь кызларны, тели икән, усал хатыннарны, тели икән...

З ө б ә р җ ә т. Усал әбиләрне! Миненур Хөрмәтова ул.

Р ө с т ә м. Нәкъ үзе!

З ө б ә р җ ә т. Дөресен генә әйт әле, егет. Син аны яратасыңмы, әллә бүтән хатын эзлисеңме?!

Р ө с т ә м. Яратам! Үлеп бетеп яратам!

З ө б ә р җ ә т. Үлеп беткәнче, бәлки, аның янына ашыгырсың?!

Р ө с т ә м. Кич ятсам да аны уйлыймын, таң атса да уйлыймын, төшләремдә күреп уянам.

З ө б ә р җ ә т. Яраткач, нигә бирегә килдең?! Бар, аның фатирына йөгер!

Р ө с т ә м. Юк, ул мине гафу итмәс.

З ө б ә р җ ә т. Ә ул сине ярата идеме? *(Ишек ярыгыннан Миненурның башы килеп чыга.)*

М и н е н у р. Ярата, ярата!

Р ө с т ә м. Син каян беләсең, әби?!

М и н е н у р. Беләм! Ходай сиздерә! *(Башын ишек ярыгыннан ала.)*

З ө б ә р җ ә т. Беләсеңме, егет, менә нәрсә?!

Р ө с т ә м. Нәрсә?

З ө б ә р җ ә т. Син миңа ошамыйсың!

Р ө с т ә м. Шулай дисеңме?! Ай, рәхмәт! Әллә Миненурга барып карыйм микән?.. Бәлки, гафу итәр.

Зөбәрҗәт тиз-тиз атлап кереп китә. Бүлмәгә, атылып, М и н е н у р килеп чыга.

М и н е н у р. Бар, бар, балакаем. Валлаһи, гафу итә ул сине.

Р ө с т ә м. Шулай дисеңме, әби?

М и н е н у р. Шулай димен.

Р ө с т ә м. Ятып калганчы, атып кал, дигәннәр. Рәхмәт, әби! *(Диваннан торып, Миненурны кочаклап үбә. Миненур аның муенына асылына. Рөстәм Миненурның кулларын көч-хәл белән үз муеныннан алып.)* Нишлисең син, әби?!

М и н е н у р. Бәхет телим, балакаем, бәхет!

Р ө с т ә м. Чаптым. *(Йөгереп чыгып китә.)*

М и н е н у р. Мин дә! *(Яулыгын салып ыргыта да чыгып йөгерә.)*

Музыка. Ут сүнә.

Подъезд. Бер фатирның ишек төбендә, баскычта, таушалган кыяфәттә, Сәмига утыра. Подъезд стеналарына туйга кагылышлы сүзләр язылган: «Совет да любовь», «Ир — баш, хатын муен», «Теле-теле тесто, здесь живет невеста» кебек плакатлар эленгән. Баскычтан кабалана-кабалана өсте-башы умырылып беткән Миңлехәбиб менә дә бер ишекнең тоткасын тарта башлый.

Сәмига. Борчыма аларны. Алар туйга әзерләнәләр.

Миңлехәбиб. Нинди туй?! Мин аларны судка бирәм! *(Куен кесәсеннән газета чыгарып.)* Аннары менә шушы газетның баш мөхәррирен судка бирәм!

Сәмига. Бүген ничәсе?

Миңлехәбиб. Бересе!

Сәмига. Кичә ничәсе иде?

Миңлехәбиб. Бүген бересе булгач, кичә ничәсе булырга тиеш соң?

Сәмига. Утыз бере...

Миңлехәбиб. Көтмә утыз берен. Быел булмый ул. Икенче елга килерсең.

Сәмига. Икенче елга кадәр шактый шул.

Миңлехәбиб. Шушы газета ашамы?

Сәмига. Синең белән нәрсә булды?

Миңлехәбиб. Бер коттеждга игълан буенча кәләш эзләп барган идем. Капкаларын ачып керүем булды, бозау кадәрле этнең өскә менеп атлануы булды. Авызымнан хатын сүзе чыгуга, коттедж хуҗасы үземә өстәп тә чыгарды. Көчкә качып котылдым. Судка бирәм.

Мендельсон маршы яңгырый. Астан, туй күлмәгеннән кулына кызыл розалар тоткан Галияне күтәреп, Мәрдән, аның артыннан түшләренә кызыл ленталар аскан шаһитлар Миненур һәм Рөстәм күренәләр. Фатир ишеге ачылып китә, ишектән бал һәм май күтәргән Гөлҗәүһәр чыга да, кәләш белән кияүгә бал һәм май каптыра. Аның артында басып торган Зөбәрҗәт ишек төбенә мендәр сала. Мәрдән кулындагы Галиясен мендәргә бастыра. Рөстәм шампан шәрабын ачып җибәрә, шартлау тавышына Миңлехәбиб белән Сәмига шыпырт кына баскычтан төшеп югалалар. Көчле музыка. Шатлыклы авазлар.

Пәрдә

# Мөгез

*Комедия ике пәрдәдә*

КАТНАШАЛАР:

Мирвәли — амбар каравылчысы.
Заһидә — Мирвәлинең хатыны.
Гөлдания — авылдагы таушалган хатын.
Нургали — кәнүшни каравылчысы.
Мәүлихан Ханович — колхоз рәисе.
Фәсхетдин — мулла.
Мөзәйәнә — әби.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачылганда, төн. Багана башындагы фонарь каравыл йортының бер як бүрәнә стенасын яктырта. Стенага терәтеп, эскәмия куелган. Эскәмиядә Мирвәли. Башында бүрек, өстендә каешланган телогрейка, аягында хатын-кыз оегы киертелгән чучинкә. Стенага сөяп күсәген куйган. Җырлый-җырлый тәмәке пыскытып утыра.

Мирвәли.

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам.
Күзге ачы җилләрдә ләй,
Туган үскән илләргә.

*(Караңгылыктан аяк тавышы ишетелә. Кинәт җырлавыннан туктап кала.)* Стой! *(Таягын мылтык кебек караңгылыкка төзи.)* Пароль?! *(Сәхнә артыннан, караңгылыктан Нургалинең тавышы ишетелә.)*

Нургали. Пошел ты... Знаешь куда?!

Мирвәли. Знаю, на баню.

Нургали *(килеп чыга. Кулын биреп исәнләшә)*. Нихәл, кордаш?

Мирвәли. Ат мөгезе кебек. Ике ел постта торам, дип әйтте ди армиядәге бер чукча. Ике елга бер генә тапкыр да

парольне үзгәрткәннәре юк. Пошел ты да, пошел ты, дип көрсенде ди мескен. Әйдә, чүмәш. Пыскытып җибәр. *(Нургали эскәмиягә утыра.)*

Нургали *(тәмәке кабыза)*. Тынычлыкмы?

Мирвәли. Кабер тынлыгы.

Нургали. Тыныч булмыйча. Буш амбарга карак киләме.

Мирвәли. Сөйлисе юк. Элегрәк күселәр чинашканын тыңлап юана иде күңел, икмәк беткәч, алары да качышып беттеләр.

Нургали. Шулай инде. Бер яклап Мәүлихан Ханович, икенче яклап син, ыштан балагы тутырып, бөтен колхоз икмәген ташып бетердегез.

Мирвәли. Сөйләмә, колхозның инәсенә дә тигәнем юк. Мәүлихан Ханович түгел, Мәүлихан Хамович ташып бетерде аны, машиналап!

Нургали. Хи-хи-хи. Сөйләмә, кордаш. Чалбар балагына салкын икмәк тутырып ташып харап булган кеше бит син.

Мирвәли. Хатын гаепле, Заһидә. Юри эшләделәр. Мәүлихан белән бердәм булып. Кем инде чалбар балагы бәйләргә капрон җеп биреп җибәрә. Кызның башына бәйли торган бантигын биреп җибәргән бит. Колхоз правлениесенә генә килеп җиткән идем, сүтелде-китте, каһәр. Өстәвенә бөтен дөньяны яктыртып багана башында лампочка яна. Шуны гына көтеп торган Хам килеп тә чыкты, милициягә алып та китте. Синең ничек анда, кәнүшнидә?

Нургали. Озакламый тынычлап калам. Атлар бетә колхозда. Өч ат бар иде, аның да кичә төнлә берсе тирескә батып җан тәслим кылган.

Мирвәли. Да... Буш амбар саклаганчы, хатынны кайтып сакласаң, әйбәт булыр иде ул, ә, ахир?

Нургали. Утырма, күзле бүкән кебек. Кайт та рәхәтләнеп йокы симерт.

Мирвәли. Симертерсең, бар. Кайтып кына кара! Мәүлихан җиденче бабаңны исенә төшерер.

Нургали. Ә син аңа күренмә. Ул Югары очтан, ә син Түбәннән. Ул Түбәннән, ә син Югары очтан...

Мирвәли. Югарыдан, түбәннән... Юк шул. Ул өстән йөрергә ярата. Күренмә, имеш. Беләсең ич инде. Минем каравылга киткәнне көтеп кенә тора. Бакча артлатып кына минем хатынның, Заһидәнең куенына йөгерә.

Нургали. Әй, кордаш, кордаш. Мин сине берни дә белми бу дип йөрим, ә син...

Мирвәли. Белеп нишлисең?! Бар, кайтып кара. Чалбар балагы чишелеп харап булдым бит. Алты айга мәҗбүри эшкә илтеп тыкты. Хәзер чәбәләнеп кара.

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Өченче көн кайткан идем. Өйдән Хам килеп чыкмасынмы?! Нишләп йөрисең монда, дигән идем, сине тикшерергә килдем, ди. Син әле шулай эш ташлап өеңдә йоклап йөрисеңмени?! Мин сине бөтенләйгә рәшәткә арасына яшерәм бит, ди.

Н у р г а л и. Син шушы хәлгә түзеп яшисеңме?

М и р в ә л и. Яшәми нишлисең?

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Түзәргә туры килә, ахир. Төрмәгә дә барасы килми, үләсе дә килми. Аннары ояты кемгә?

Н у р г а л и. Кемгә?

М и р в ә л и. Хатынга, Заһидәгә. Мин үләрмен дә котылырмын. Ә бит әле аның авыл халкы белән яшисе бар.

Н у р г а л и. Тинтәк! Син шул Хамга бер сүз дә әйтмәдеңме?

М и р в ә л и. Нишләп әйтмим, әйттем. Син мине ул кадәр җебегәнгә санама инде. Фонаремны оныткanмын, бик авыр булмаса, алып чыгып кына бирмәссеңме, дидем.

Н у р г а л и. Ярый әле, баш очларында да фонарь күтәреп басып торырга кушмаганнар.

М и р в ә л и. Анысы булмас. Фонарьның керосины юк иде.

Н у р г а л и. Асылын да үл.

М и р в ә л и. Керосинсыз лампа, фонарь тоттырып, озатып калды. Менә хәзер өйгә кайтырга куркып утырам.

Н у р г а л и. Әйттем бит мин сиңа, кордаш, чалбарга салкын бодай тутыру, ир-ат өчен зарарлы, дип. Тыңламадың. Да, асылын да үл!

М и р в ә л и. Ярый, түзәм. Мин күрәсен кеше күрмәс. Бер йомырка маяда да чери.

Н у р г а л и. Да, асылын да үл!

М и р в ә л и. Ходай бар, Ходай барысын да күрә.

Н у р г а л и. Асылын да үл!

М и р в ә л и. Син нәрсә соң, асылын да үл, асылын да үл! Бик рәхәт булса, үзең үл!

Н у р г а л и. Син алай димә әле, кордаш.

М и р в ә л и. Теге чакта, бер ярты алып киләм дип, акчамны алдап алып качкан идең, шуннан котылырмын дип уйлыйсыңдыр.

Н у р г а л и. Син алай димә әле, кордаш. Син асылынып үлсәң, гомергә рәхәттә яшәячәксең.

М и р в ә л и. Дивана, үлгәч яшәп була димени?

Н у р г а л и. Үлгәч инде ул рәхәтләнеп яшисең оҗмахта.

М и р в ә л и. Яшәрсең, бар. Оҗмахка безне кем кертсен. Анда да акча түләп керештер әле ул. Әнә безнең авылның мулласы Фәсхетдин акча җыймас иде.

Н у р г а л и. Каян беләсең?

М и р в ә л и. Әнә бит, Пыскый Фәсхетдинне әйтәм. Башта сәвит чагында парторг, аннары авыл советы рәисе булып колхозны талады, хәзер мулла булып, карт-корыны, авыл халкын талый. Оҗмах алар өчен инде ул.

Н у р г а л и. Юк. Оҗмах синең өчен ул. Бар, берәрне алып кил, оҗмахка керәсең килсә.

М и р в ә л и. Бар, алып кил! Каян килгән фәрештә!

Н у р г а л и. Ярый алайса. Оҗмахта яши башлагач, бер ярты урынына бер ящик куярсың!

М и р в ә л и. Әбиең сызгыра беләме?

Н у р г а л и. Тыңла. Хәзер син асылынасың.

М и р в ә л и. Таптый-таптый күмәр идегез бугай. Бөтен авылыгыз белән җыелып.

Н у р г а л и. Җүләр син, кордаш. Син асылынып үлсәң, икебез дә рәхәттә яшәячәкбез.

М и р в ә л и. Йә, сөйләп кара. Мине үтереп, ничегрәк рәхәттә яшәрбез икән?

Н у р г а л и. Син хәзер, әнә теге сарайга керәсең дә, муенына элмәк салып, телеңне чыгарып ятасың.

М и р в ә л и. Шуннан.

Н у р г а л и. Шуннан соң мин авылга чаң кагам. Кешеләрне уятам. Синең өеңә чабам.

М и р в ә л и. Нигә?

Н у р г а л и. Атаң башына! Мирвәли кордаш асылынып үлгән, әле генә баудан кисеп төшердем, әйдәгез, тизрәк, димен.

М и р в ә л и. Аннары мине терелләй таптый-таптый күмеп куясызмы? Күмеп куясыз да, син хәер акчасына бер ярты алып саласыңмы? Кит, иблис! Син бит ярты өчен тудырган анаңны сатасың.

Н у р г а л и. Кем күмсен сине? Кемгә кирәк син?

М и р в ә л и. Күмми, җир өстендә калдырмассыз бит инде.

Н у р г а л и. Тыңлап бетер. Калганы минем эш.

М и р в ә л и. Калганы минем эш. Юк, син аңлатып сөйлә.

Н у р г а л и. Сине күтәреп алып кайтабыз, җыелышып юабыз.

М и р в ә л и. Юарга син оста...

Н у р г а л и. Кәфенгә урыйбыз, зиратка алып китәбез дигәндә...

М и р в ә л и. Аңладым. Мин торып утырам.

Н у р г а л и. Нигә?

М и р в ә л и. Авыл халкы белән саубуллашырга.

Н у р г а л и. Тинтәк! Зиратка алып китәбез дигәндә, мин, хәйлә табып, синең янга җыелган халыкны урамга чакырып чыга-

рам. Син кәфенлектән чыгасың да үзең урынына мендәрме, ягъни берәр төрле иске чикмәнме саласың.

Мирвәли. Ә үземне кая куям?

Нургали *(үз чигәсенә төртеп)*. Син әллә мондыйрак инде. Үзең чоланнан абзарга качасың.

Мирвәли. Аннары йорт иясе бичура кебек лапаста, абзарда сарыклар арасында яшимме? Мин бит печән ашап яши алмыйм.

Нургали *(халыкка, тамашачыга карап)*. Кешеләр арасында сарык булып яшәгәнче, үз ишләрең арасында яшәвең хәерлерәк. *(Мирвәлигә.)* Юк инде. Караңгы төшкәч, минем мунчага күчәсең. Берәр ай шунда яшәп, сакал-мыек үстереп, башка киемнәр киеп, көннәрдән бер көнне мосафир, Алла кешесе, йә булмаса, җен булып авылга кайтып төшәсең.

Мирвәли. Кызык бит бу, ахир. Ә мине танысалар?

Нургали. Кем танысын. Үлгән кеше кайтамыни, тинтәк?

Мирвәли. Тавышымны бераз үзгәртермен.

Нургали. Кирәкми. Нигә үзгәртергә. Соңыннан, уен узгач, мин чын Мирвәли, дисәң дә, авыл халкын ышандыралмый азапланырсың әле.

Мирвәли. Кызык, кызык. Ә ялгышып, чынлап күмеп куйсалар?!

Нургали. Кем күмсен, аңлатып торам лабаса.

Мирвәли. Әгәр чынлап күмә башласалар, сикерәм дә торам! Шулай бит, ахир?

Нургали. Анысы кирәкмәс.

Мирвәли. Нигә, бигрәк кызык була.

Нургали. Булыр кызык. Синең аркада бөтен җыелган халыкны күмәргә туры килер.

Мирвәли. Мәүлиханның йөрәге шартлар иде, ә? Ха-ха-ха!.. Мин риза!

Нургали. Риза булсаң, билеңдәге бавыңны муеныңа сал да теге келәткә чап. Ә мин авылга...

Мирвәли. Тукта әле, ахир. Син бит мине юабыз, дидең?! Юганда кытыгым килмәс микән?

Нургали. Килмәс. Оҗмахта яшисең килсә, түзәрсең!

Мирвәли. Түзәрсең?! Заһидә минем кайсы җирдән кытыгым килгәнен белә ул. Ярый, алайса, мине юганда Заһидәне кертмәссез.

Нургали. Ярый, кертмәбез.

Мирвәли. Тукта әле, Нургали туган. Әллә нигә күңел тулып, җылыйсы килеп китте. Үлгәндә ямансу була икән. Кара әле, ахир, әгәр мине ялгышып күмеп куйсалар, теге аракыга дип алган бурычыңны Заһидәгә кертеп бирерсең, яме?!

Нургали. Ярар, ярар, кертермен!

Мирвəли. Хəзер аракы кыйммəтлəнде, хəзерге бəясе белəн кертерсең, яме?

Нургали. Ярар, ярар, хəзерге бəясе белəн кертермен.

Мирвəли. Оныта күрмə, ярыймы?

Нургали. Ярар инде, ярар. Үлгəч, сиңа нəрсə, керттем ни дə, кертмəдем ни.

Мирвəли. Алай димə, кешедəн аласым булса, тынычлап яталмыйм.

Нургали. Ярар, ярар, кертермен. *(Халыкка, тамашачыга.)* Бакыр акча корты!

Мирвəли. Карале, кем, Нургали, тукта əле, ашыкма! Безнекелəрне саграк уят! Мəүлихан бабай шатлыгыннан эчке ыштаны белəн йөгереп килмəсен, авыл халкы алдында оятлы итəр үземне.

Нургали. Ярый, саграк уятырмын. *(Утырган урыннарыннан торалар. Нургали чыгып йөгермəкче була.)*

Мирвəли. Туктале! Кеше күмəргə дигəндə, бөтен дөньяңны онытасың. Кабаланма! Заһидə апаң хəернең артыгын бирмəс ул. Саранлыгы Аллага шөкер. Үземə охшамаган.

Нургали. Тагын нəрсə инде?!

Мирвəли. Мунчада очрашкач, хəер акчаларын үземə кайтарырсың, яме?

Нургали. Да...

Мирвəли. Да түгел, Нургали кордый, Заһидə акчасы минем акча, минем акча Заһидə акчасы булыр ул. Килештек алайса?!

Нургали. Килештек!

Мирвəли. Мə бишне! *(Кулын суза.)*

Нургали. Мə! *(Кулын суза.)* Ун булсын!

Мирвəли, Нургали *(икесе бергə)*. Эшлəребез уң булсын!

Музыка астында ут сүнə.

Ут янганда, Мирвəлилəрнең өй эче күренə. Стенадагы сурəтлəргə ак чүпрəк капланган. Сəгатьнең телен туктатканнар. Бүлмəнең уртасына, башын кыйблага каратып, Мирвəлине салганнар, аның өстендə одеял. Мирвəлине əйлəндереп, Гөлдания, Нургали, Мəүлихан Ханович, Мөзəйнə, баш очындарак Фəсхетдин белəн Заһидə утыралар. Барысының да кулында тəсбих. Хатын-кызлар башларына яулык, ирлəр түбəтəй кигəннəр.

Мəүлихан Ханович. Əйбəт кеше иде, мəрхүм. Урыны җəннəттə булсын. Нинди генə эшкə алынмасын, үз эшен намус белəн башкара иде. Төннəрен колхоз каралтыларын барлап чыга торган гадəтем бар. Амбарга кайчан барма, арлы-бирле ул йөри торган иде.

Мирвәли (*җайлабрак ята*). Бигрәк катыга салдылар*.

Мөзәйәнә. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, мәет селкенде түгелме?

Фәсхетдин. Җәмәгать, мәет хак сүзгә әйләнеп ятыр, ди китап.

Мөзәйәнә. Әстәгъфирулла, әллә картая башладым инде. Ходайның рәхмәте, күпме мәетләр саклап, беренче тапкыр мондый хәлгә очравым.

Нургали. Йокламауның галәмәте, Мөзәйәнә әби. Яшең алга бармый. Бар, чыгып башыңны мендәргә төртеп тор.

Мирвәли. Минем янга ятып тор, Мөзәйәнә әби. Монда иркен.

Мөзәйәнә (*арт санын урындыктан күтәреп, мәеткә сузыла*). Ә? Нәрсә дисең? (*Кире урынына утыра.*)

Нургали (*аңа иелеп, үз маңгаена ике бармагы белән мөгез ясап.*) Мө! (*Халыкка.*) Чукрак, ди!

Фәсхетдин. Нишлисең син, энем Нургали? Нишләп олы кешене тик торганда үртисең?

Нургали. Юк, үлгән кеше белән сөйләшеп утыра бит. Мине таный микән дип, тикшереп карамакчы идем.

Мөзәйәнә. Игътибар итмә, Фәсхетдин. Нургали һәрвакыт шук булды инде ул.

Мәүлихан Ханович. Үзе китте дә барды, колхозны ятим итте. Аны алмаштырырга кемне табарбыз?

Мирвәли. Сине! Репетиция ясый башладың бит инде. Утыр, утыр мине саклап, мин рәхәтләнеп йоклыйм. (*Селкенеп куя.*)

Нургали (*тамашачыга*). Мәлгунь, Мирвәли, тик кенә ят! Башны бетерәсең!

Мирвәли. Табан асты кычыта, кашы әле?!

Нургали (*Фәсхетдин муллага карап*). Кара әле, мулла абзый, мәрхүмнең аягы җайсызрак яткан кебек, җайлап куйсаң ярыйдыр?..

Фәсхетдин. Ярый, ярый, кем, энем Нургали. Китап җайлап куйганга каршы түгел.

Нургали (*Урыныннан торып, Мирвәлинең сул аягын тегеләргә күрсәтмичә генә кашый. Аннары пышылдап*). Булдымы?

Мирвәли. Уң аягымны кашы, имгәк!

Мөзәйәнә. Әләй, әләй, карагыз әле, мәет селкенә.

Фәсхетдин. Син нәрсә инде, Мөзәйәнә, алмашына башладыңмы әллә?!

---

* Искәрмә. Одеял астындагы Мирвәлинең кулында микрофон булу шарт.

М и р в ә л и. Алмашынырсың, 24 сәгатькә якын как тактада ятып кара әле.

М ө з ә й ә н ә. Мин каты итеп чәй эчеп керим әле. *(Чыгып китә.)*

Ф ә с х е т д и н. Изге кешене юып кәфенгә салгач, җайлабрак ятыр, ди китап.

М и р в ә л и. Җайлабрак! Бик рәхәт булса, үзең ятып кара! Ястык салалар аны, Пыскый Фәсхетдин.

З а һ и д ә. Күпме яшәп, тырнагы белән дә чирткәне булмады мәрхүмнең. *(Елый.)*

Г ө л д а н и я. Берәр әйберем җимерелсә, гел шуңа керә идем. Хәзер кемгә барырмын?

М и р в ә л и. Мактамагыз, хәзер җылап җибәрәм!

Ф ә с х е т д и н. Әләй, әләй, нишли ул? Селкенде түгелме?

Н у р г а л и. Син нәрсә инде, мулла абзый? Үзең Алла кешесе, Ходайга каршы килеп утырасың? Җаны чыгып очкандыр.

Ф ә с х е т д и н. Юк, кем, энем Нургали, аның җаны амбардагы келәттә үк гәүдәсеннән чыккан инде.

Н у р г а л и. Син беләсең инде, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н. Беләм, беләм, Нургали энем.

Н у р г а л и *(тамашачыга)*. Беләсең әбиеңнең келәсен!

Ф ә с х е т д и н. Хәзер аның җаны гәүдәсе янында очып йөрер, ди китап. 40 көнгә кадәр өйгә кайтып йөри ул җан.

Н у р г а л и. Менә бит нәрсәләр сөйли ул изге китап. Ишеттеңме, Мәүлихан Ханович? 40 көнгә кадәр өенә кайтып йөрер диме?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч *(Куркып китеп)*. Кит аннан. 40 көнгә кадәр диген, ә, мулла абзый?

М и р в ә л и. 40 көннән сакал-мыек үстереп, үзе кайтыр, ди.

Ф ә с х е т д и н. Юк, үзе кайтмый. Үзе үлгән була бит инде.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Син нәрсә инде, Фәсхетдин абзый, үзең белән үзең сөйләшеп утырасың. Соң без беребез дә ул кадәр дивана түгел, үлгән кешенең кайтмаганын гына беләбез.

Ф ә с х е т д и н *(аптырап)*. Нигә, кайсыгыздыр сорады түгелме соң?

Н у р г а л и. Картаясың, олыгаясың, мулла абзый.

Ф ә с х е т д и н. Колагыма шулай ишетелде. Булмаса, һавага чыгып керим әле. *(Чыга башлый, Мирвәлинең аягы турысына килеп җиткәч, ул Гөлданияне кочаклап ала, шул вакытта Мирвәли аңа аягы белән тибә.)*

М и р в ә л и. Бар, карт ишәк, кеше алдап йөрмә!

Г ө л д а н и я. Нишләвең бу, Фәсхетдин абзый, килешмәгәнне. Үзең дин юлында йөргән буласың, үзең... Элек парторг ча-

гында дояркаларның капшамаган җирен калдырмый торган идең, һаман да шул оятсызлыгыңны ташламагансың.

Фәсхетдин (*артта утырган Мәүлиханга озак кына карап тора да*). Дурак син, энем Мәүлихан. Олы кешене мыскыл итеп утырмасаң...

Мәүлихан Ханович. Кем әле сине мыскыл иткән?!

Фәсхетдин. Син! Именно менә син! Нигә тибәсең минем арт саныма?!

Мәүлихан Ханович. Әллә котыра башладыңмы?!

Фәсхетдин. Син булмыйча, үлгән Мирвәли типкәндер шул!

Мәүлихан Ханович. Хатын-кыз күргәч, кулларыңны тик тоталмаганыңны барыбыз да беләбез, мулла абзый.

Фәсхетдин. Сөйләп кенә торма, сине белмиләр! Син җиттең Мирвәлинең башына, Заһидәсе белән типтереп.

Мәүлихан Ханович. Ә, шулаймыни?! Тоттыңмы?! Юк, син әйт, тоттыңмы?! Мин сине судка бирәм! Аһ, син, сволочь! (*Урыныннан торып, бугазыннан эләктереп ала.*)

Фәсхетдин (*таягы белән кизәнә*). Мин карап торырмын. Менә бу таяк белән башыңны тишәрмен!

Мирвәли. Нургали, мулла абзыйга хәер бир әле, тынычлана ул.

Нургали. Җәмәгать! Мәет өстендә тавыш күтәрүне китап яратмый.

Фәсхетдин. Бирерсең син мине судка! Синең урлаганнарыңны кем кем, мин белми идем.

Чыгып киткәндә, ишек төбендә Мөзәйәнә белән очраша.
Мөзәйәнә керә.

Мөзәйәнә. Фәсхетдин, комганда җылы су бар. (*Җайлап кереп утыра.*)

Фәсхетдин. Рәхмәт. (*Чыгып китә.*)

Мөзәйәнә. Кара әле, кызым Заһидә, Мирвәли мәрхүм сөннәтле идеме?

Заһидә. Аның сөннәте белән нишлисең? Кияүгә чыгарга уйламыйсыңдыр бит?

Мөзәйәнә. Абау, нишләгәннәр болар?

Гөлдания. Сөннәтле иде, сөннәтле...

Заһидә (*Гөлданиягә карап*). Кит аннан. Каян беләсең?

Гөлдания. Нигә, Мирвәлинең каршысына утырып булмый иде бит. Юньле-рәтле ыштан кигәне булмады.

Фәсхетдин керә.

Фәсхетдин. Нургали энем, бар, зиратка барып кил. Ка-

бер әзер булса, ясин чыгарбыз да мәрхүмне өйләгә кадәр җир куенына урнаштырырбыз.

Н у р г а л и. Хәзер, хәзер, белешәм, мулла абзый. (*Чыгып китә.*)

Ф ә с х е т д и н (*җайлап утыра, куен кесәсеннән китап чыгара. Аның янына Мөзәйәнә әби якынаеп утыра*). Йәә сишшин. Вәлкурьәнил хәкиим. Иннәкә ләминәл мурсәмин. Галәә сыйраатыйм мустәкыйм. Тәнзиләл гәзиизиррахим. Литунзира каумәм мәәәә унзира әәбәәәьуһим фәһум гаафилүүн. Ләкаду хәккаль каулу гәләә эксәриһим фәһум ләә йуьиинүүн. Иннәә җәгәлнәә фишин әгнәәкыйһим әгъләәлән фаһия иләл әзкаани фәһум лукьмәхүүн.

М ө з ә й ә н ә (*муллага төртеп ала, пышылдап*). Ялгыштың, мулла абзый Фәсхетдин.

Ф ә с х е т д и н (*пышылдап*). Тик тор, бүкән, хәере бүтән. Иннәмәәәәә әмраһүүү изәәә әраадә шәйьән әййәкуулә ләһүү күн фәйәәкүү фәсубухәәнәлләзин бийдиһим мәләкүту кулли шәйьнү вә иләйһи тәрҗәгуүн. Амин!

Б а р ы с ы  б е р г ә. Амин!

Ф ә с х е т д и н. Ярый, мөэмин-мөселман мөслим, мөслимәләр. Мәрхүмне калдырып торыйк. Мәрхүм янында якын туган-тумачалары гына калсын. (*Мөзәйәнә әби, Фәсхетдин мулла, Мәүлихан Ханович урыннарыннан торып чыга башлыйлар.*) Нигә, син калмыйсыңмыни, Мәүлихан Ханович?

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Нигә калыйм. Мин бит аның туганы түгел. (*Чыгып китәләр.*)

З а һ и д ә (*үксеп елый*). Әй, Мирвәликәем, Мирвәликәем, бәгырь кисәгем. Зинһар, рәнҗеп китмә. Хуш! Бәхил бул!

М и р в ә л и. Пока.

Г ө л д а н и я. Әйдә, ахир, үз-үзеңне бетермә. Бер алкаш үлгәннән дөнья җимерелмәс. Дөньяда ирләр бетмәгән. Әнә минем мәрхүмнең үлгәненә бишбылтыр, бер ятып төшемә дә кергәне юк. Тегенең белән рәхәтләнеп яшәрсең. Бүген иртә белән төялеп хатыны китеп барды.

М и р в ә л и. Алла боерсаңны онытма.

Г ө л д а н и я. Әйдә, әйдә чыгабыз. (*Чыгып китә.*)

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч (*килеп керә*). Ярый, хуш, Мирвәли туган.

М и р в ә л и. Пока, бажай! Яңадан очрашканга кадәр.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч (*Заһидәгә*). Әйдә, үз-үзеңне бетермә, чыгабыз.

З а һ и д ә. Җылаган булыйм инде. Авыл халкыннан яхшы түгел бит.

М и р в ә л и. Биегән чакларың да булыр әле.

Мәүлихан Ханович. Минем хатын китте. Кудым үзен. Кырыгы гына үтсен, бергә яши башлыйбыз.

Нургали *(ишектән башын тыгып)*. Заһидә, Мәүлихан иптәш, чыгыгыз әле, мулла абзый чакыра. *(Икесе дә чыгып китәләр.)*

Мирвәли. Нургали, Нургали кордаш! Нургали мөртәт, чыгып беттеләрме әле?

Нургали *(ишектән башын тыга)*. Беттеләр! Кабаланма! Тиз генә кермиләр. Мулла абзыйның садакасы өйалды идәненең ярыгына төшеп китте. Шуны алалмый азаплана. *(Ишекне яба.)*

Мирвәли *(торып утыра)*. Ирек бирсәң, чын-чынлап күмеп куярлар. Валлаһи, күмәләр. Ярый әле, үлеп карадым. Кайчан әле бу кадәр матур сүзне ишетер идем. Үзем белмәгән яхшылыкларым да бар икән. Уф, суткадан артык как тактада ятып, үзем тактага әйләнә яздым. Өстәвенә арт саным юеш. Бөтен кайгым, идәнгә акмаса ярар иде, дип курыктым. *(Күзе стенадагы сәгатькә төшә.)* Вәт, Мирвәли туган, 1997 елның 7 гыйнварында 3 сәгать 15 минут 13 секундта дөньядан китеп бардың. *(Басмакчы була.)* Әстәгъфирулла! Вәт сволочьлар, трусикка кадәр салдырганнар. Оятлы булуыңны көт тә тор. *(Простыняга уранып торып баса. Үз урынына мендәр салмакчы була.)* Юк, мендәр җиңел булыр. Тукта әле... *(Мич арасына кереп китә дә аркасына капчык күтәреп чыга. Капчыкны үз урынына сала.)* Шикәре жалко. Ярты еллык хезмәт хакы өчен биргәннәр иде. *(Капчыкны әйбәтләп каплый да мич арасына кереп югала. Бераздан бүлмәгә кешеләр керә һәм алар урындыкларга утырышалар.)*

Мәүлихан Ханович. Хөрмәтлебез Мирвәли туган! Син безнең колхозыбызның иң хөрмәтле кешесе идең.

Мирвәли *(мич артыннан)*. Рәхмәт!

Мәүлихан Ханович *(Фәсхетдин муллага)*. Хәер биргәч, рәхмәт әйтерсең!

Фәсхетдин. Кем әле синнән хәер сорый?!

Мәүлихан Ханович. Синең колхозга керткән өлешең һәрвакыт колхозчыларыбыз күңелендә тирән сакланыр.

Мирвәли *(мич артыннан)*. Рәхмәт!

Нургали. Нишлисең, Мирвәли, телеңне тый!

Мирвәли. Мактыйлар бит, түзеп булмый.

Мәүлихан Ханович *(Фәсхетдин муллага)*. Җиттеме сиңа, юкмы? Чабата кайтарып торасың.

Фәсхетдин. Нигә булышасың минем белән.

Заһидә
Гөлдания } *(икесе бергә)*. Җитте инде сиңа, Мәүлихан Ханович, рәнҗетмә инде өлкән кешене.

Мәүлихан Ханович. Сүз саен минем әйткәнне җөпләп бармасын. Рәхмәт тә рәхмәт, рәхмәт тә рәхмәт! Фикеремне чуалтма!

Фәсхетдин. Мәетегезне ташлыйм да кайтып китәм! Теләсә нишләгез! Хәерегезне дә алып тормыйм!

Заһидә *(барып, Фәсхетдин мулланың уч төбенә хәер сала)*. Мә, мулла абзый. *(Кире урынына утыра.)*

Фәсхетдин. Бисмиллаһир-рахманир-рахим! Вәссәламе галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтү-ү...

Мәүлихан Ханович. Нишлисең син?!

Фәсхетдин. Нигә, син әйтеп бетермәдеңмени? Хәер бирә башладылар бит, укыйм.

Мәүлихан Ханович. Тинтәк! Авыр туфрагың җиңел булсын, изге иптәшебез...

Фәсхетдин. Минем өчен кайгырма. Үзеңнеке җиңел булсын!

Заһидә. Мирвәликәем, рәнҗеп китмә, бәхил бул.

Мөзәйәнә. Мирвәли энем, Гарәфетдин бабаңа сәлам әйт.

Мирвәли. Әбиең утырмага килә, диярмен.

Фәсхетдин. Ярый, мөслимәләр, сез чыгып торыгыз. *(Хатын-кызлар чыгып китә.)* Мәетне аягы белән ишектән чыгара башласак та ярыйдыр. *(Мирвәли, мич арасыннан чыгып, ишеккә бармакчы була, аны Нургали туктата.)*

Нургали. Кая барасың, имгәк!

Мирвәли. Нигә? Мулла абзый аягы белән чыксын, диде бит.

Нургали. Сиңа әйтми бит ул, тинтәк! *(Төртеп мич арасына кертеп җибәрә. Җыелган халыкка.)* Әйдәгез, җәмәгать! *(Мәүлихан Ханович, Нургали, Фәсхетдин мулла «мәетне» күтәрә башлыйлар, простыняга төренгән Мирвәли мич арасыннан чыга да булыша башлый.)* Мирвәли, дурак, нишләп йөрисең, дивана!

Мирвәли. Сезгә булышам! Үзегезгә генә авыр бит. Анда алагаем бер капчык шикәр!

Нургали. Күземнән югал, тинтәк!

Мирвәли. Ярый, алайса җайлабрак күтәрегез. Ялгыш төшереп җибәреп, муенымны сындырмагыз!

Фәсхетдин *(Нургалигә)*. Кем иде ул синең янында?

Нургали. Кайда?

Фәсхетдин. Синең янында, мәет янында?

Мәүлихан Ханович. Кем янында?

Фәсхетдин. Нургали энекәш янында.

Мәүлихан Ханович. Менә ич мин. Мин аның янында басып торам. Әллә мине дә танымый башладыңмы? Бу карт кеше күмә-күмә тилерә, саташа башлаган, ахрысы.

Нургали. Әйтәсе юк.

Фәсхетдин. Кызык... Бу мәетнең үлеме дә сәер, күмелүе дә сәер!

Мәүлихан Ханович. Әй, кем бар анда? *(Ишектән Гөлдания башын тыга.)* Чакырыгыз әле яшьләрне. Бу шәлперәйгән тиле-миле карт белән мәет күтәреп буламыни. *(Нургалигә озак кына карап торганнан соң.)* Әстәгъфирулла! Монысы алкоголик. Кулы белән бөтен гәүдәсе селкенә. Настоящий холодис!

Ут сүнә. Пәрдә ябыла.

Бераздан ап-ак кальсоннан, яланаяк, чәче-башы тузган, күзе акайган, абынасөртенә, ашыга-ашыга Мәүлихан Ханович пәрдә алдына килеп чыга.

Мәүлихан Ханович. Бармы бу авылда берәр кеше? Җәмәгать! Авылдашлар! Каравыл! Үтерәләр, каравыл! Коткарыгыз, коткарыгыз!

Тавышка Нургали килеп чыга.

Нургали. Нәрсә булды, Мәүлихан иптәш? Ник акырасың? Ут чыкмагандыр бит?

Мәүлихан Ханович. Ут чыгу ерунда. Дөньяда булмас хәл. *(Сәхнә алдына төрле яктан кешеләр чыга башлый.)*

Гөлдания. Нәрсә булган, кеше суялармы әллә?

Нургали. Юк, менә бит Мәүлихан иптәш... Койрыгын капкага кыскан кәҗә тәкәсе кебек акыра.

Мәүлихан Ханович. Минем урынга үзегезне куеп карагыз! Акыру гына түгел, акылдан шашарсыз.

Нургали. Кит инде, Мәүлихан иптәш, килешмәгәнне, председатель башың белән урам уртасында бөтен авыл халкы алдында эчке ыштаннан...

Гөлдания. Нигә алай дисез, юрганы астына шөпшә кергәндер. Ха-ха-ха!

Зәһидә *(мыскыллап)*. Теге чәчбие куып чыгаргандыр. Ул бит аннан уттан курыккандай курка.

Мәүлихан Ханович. Җыен дивана. Мирвәли кайткан.

Барысы бергә. Мирвәли кайткан?! Ха-ха-ха! Мирвәли кайткан?!

Фәсхетдин *(тамашачыга)*.Өендә качып эчеп ятып, белогорячка башланган.

Нургали. Нәрсә, иптәш председатель, күзеңә җеннәр күренә башладымы әллә?

Мәүлихан Ханович. Син үзең җен! Ышанмасагыз, әйдәгез, минем өйгә, күрмәгәнегезне күрерсез!

Мөзәйәнә (*килеп керә*). Нәстә булды? Әллә миңа әйтмичә генә көтүче сайлыйсызмы? Быел чиратлап көтәбез. Узган елда бер кәҗәмне суеп ашадыгыз.

Мәүлихан Ханович. Синдә көтүче кайгысы. Мирвәли теге дөньядан кайткан!

Мөзәйәнә. Син, энем Мәүлихан, ычкына башлагансың түгелме соң? И Ходаем, каршы сугылгандыр. (*Мәүлихан янынарак килә дә.*) Бисмиллаһир-рахманир-рахим! (*Мәүлиханның йөзенә төкерә башлый.*)

Мәүлихан Ханович. Нишлисең, җен корткасы?! Нигә миңа төкерәсең?! (*Мөзәйәнә әбине төртеп җибәрә.*)

Мөзәйәнә. Абау, абау, котырган бит бу.

Мәүлихан Ханович. Син үзең котырган! Әйдәгез, ышанмасагыз, үз күзегез белән күрерсез.

Фәсхетдин. Мәүлихан энем, син безне авылыбыз белән диванага санама.

Мәүлихан Ханович. Ышанмыйсыз?!

Гөлдания. Тилермә, үлгән кеше кайта димени?

Мөзәйәнә. Яшем 83 тә, балалар. 83 яшемә җитеп, берәүнең дә теге дөньядан кайтканын күргәнем юк әле.

Мәүлихан Ханович. Күрмәсәң, күрерсең! Минем дә күргәнем юк иде.

Нургали. Туктале, Мәүлихан иптәш, нигә ул нәкъ сиңа кайткан?

Мәүлихан Ханович. Этем белсен. Каян белим мин.

Фәсхетдин. Әйе! Нигә үз өенә, Заһидәсе янына кайтмаган?!

Мәүлихан Ханович. Каян белим?

Нургали. Чыннан да, нигә ул именно сиңа кайткан? Миңа да түгел, Фәсхетдин муллага да түгел, бүтәнгә дә кайтмаган, именно сиңа кайткан?! Син нәрсә, аның братымы? Син бит аңа не брат, не сват? Нәрсә, берәр бүлешә алмаган әйберегез бар идемени?

Заһидә (*Мәүлихан Хановичка пышылдап*). Бар инде, адәм көлдереп йөрмә, кайтып йокла. Җенләнә башлагансың бит, дивана! (*Җыелган халыкка.*) Бүген генә Мирвәликәемнең каберендә булдым. Кабере күпереп тора. (*Күз төпләрен сөртеп ала.*) Бармак төртерлек урыны да юк, бал кортлары сырып алган.

Нургали. Бал корты?..

Фәсхетдин. Изгеләр рәтендә булгандыр Мирвәли. Бал корты — оҗмах корты, ди китап.

Нургали. Булыр, булыр, мулла абзый. Синең китап әйтсә, хак әйтә инде ул. Бал корты кунса, балга куна да, шикәргә куна инде ул.

Фәсхетдин. Бар, энем Мәүлихан, кайт та, бисмилланы әйтеп, йокларга ят.

Мәүлихан Ханович. Юк, мин ул өйгә кайтмыйм!

Гөлдания. Нигә кайтмыйсың?

Мәүлихан Ханович. Куркам.

Заһидә. Кемнән куркасың?

Мәүлихан Ханович. Мирвәлидән!

Гөлдания. Нигә, хатының Сылу өйдә юкмыни?

Нургали. Мирвәли үлгән көнне үк куып җибәрде бит ул аны.

Мөзәйәнә. Бар, энем Мәүлихан, өеңә кайт. Тәһарәтеңне яңарт, бисмилланы әйтеп, ятып йокла.

Мәүлихан Ханович. Алла бәндәләре, кайтмыйм мин ул өйгә. Сез миңа ышанмыйсыз инде. Кая Коръәнегез, Коръән тотып ант итәм. Менә шушы күзләрем белән күрдем. *(Күзләренә кулы белән төртеп күрсәтә.)* Атам-анам рухы белән ант итәм. Эштән кайттым, ишекне ачып кердем, юындым, ашадым-эчтем, урын җәйдем дә, ишекне бикләп, утны сүндереп йокларга яттым. Бераздан ишек шыгырдап ачыла башлады. Кем бар анда? димен. Дәшми. Тыңлап ятам, аяк тавышы... Кем бар? димен. Дәшми. Өстәл янындагы урындык селкенде. Юрган астына кереп постым. Кемдер мыш-мыш килә. Курка-курка гына башымны юрган астыннан чыгардым да баш очымдагы лампочканы яндырып җибәрүем булды, ни күзем белән күрим, өстәл артында Мирвәли утыра. Кулында мөгез!

Нургали. Мөгез?!

Мәүлихан Ханович. Әйе, мөгез! Син кем? дип сорыйм. Мирвәли, ди. Мирвәли үлде, без аны күмдек, дим. Ә мин теге дөньядан кайттым, ди. Нигә? мин әйтәм. Сиңа мөгез кайтардым, ди. Астым җылынып киткәндәй булды. Кулым белән астымны капшап карыйм, тәһарәтем бозылган. Урынымнан сикереп торсаммы? Башта тәрәзәгә атылдым, тәрәзәгә сыймагач, ишеккә. Ишек келәсе шартлап өзелде, ә мин урамга чыгып очтым. Аңыма килсәм, бирегә басып торам. Менә, ышанмасагыз, тотып карагыз, тәһарәтем бозылган. *(Кулы белән чалбар төбенә күрсәтә.)* Менә, менә, мулла абзый. Мөзәйәнә әби, Гөлдания, тотып карагыз, юешме? Юеш!

Фәсхетдин. Туктале, кем, Мәүлихан энем, кайткач ишегеңне ачып кердеңме? Йозак бар идеме?

Мәүлихан Ханович. Ат башы кадәр йозакны менә шушы кулларым белән ике тапкыр борып ачып кердем, Фәсхетдин абзый.

Заһидә. Тәрәзәләрегез ачык түгел идеме?

Мәүлихан Ханович. Ничек ачык булсын! Тәрәзәләр бит ике катлы, эчтәгеләре ачылмый.

Мөзәйнә. Мич юшкәгезне карадыңмы? Ябык идеме?

Нургали. Син бигрәк инде, Мөзәйнә әби, Мирвәли мичтән кералмый торгандыр инде.

Мөзәйнә. Ә бәлки ул Мирвәли түгел, ә Мирвәли кыяфәтендәге җендер!

Фәсхетдин. Энем Мәүлихан, ак белән кызылны бутамаган идеңме?

Мәүлихан Ханович. Ә нигә?

Фәсхетдин. Юк, болай гына...

Нургали. Үземнән чыгып әйтәм диген, Фәсхетдин абзый.

Фәсхетдин. Ходай Тәгаләне оныттыгыз, балалар. Өйләрегезгә Коръән укытмыйсыз. Бозылды халык, бозылды...

Мөзәйнә. Ата — улны, ана кызны белми.

Заһидә. Бар, бар, Мәүлихан, күзеңә генә күренгәндер, кайт.

Мәүлихан Ханович *(ыштанын тотып)*. Ә бу нәрсә? Ярый, минем күземә генә күренгән ди, ә бу нәрсә? Мә, тотып кара. Юешме? Юеш!

Нургали. Юеш кенә булса, бер хәл...

Мәүлихан Ханович. Шулай булгач! Мирвәли юк, ди. Ә тәһарәт кая киткән? Туктагыз! Шым! *(Барысы да тынып калалар, бераздан.)*

Барысы бергә. Фу...

Нургали. Вәт! Доказательство!

Гөлдания. Җәмәгать! Авылдашлар! Ни генә әйтсәгез дә, Мәүлихан Ханович авылыбызның дәрәҗәле кешесе, хуҗасы. Кызганырга кирәк үзен. Бергәләп озатып куярга кирәк.

Мәүлихан Ханович. Юк, мин анда кайтмыйм. Әйтеп торам бит мин сезгә, куркам, дип.

Нургали. Бәлки, Заһидәләргә кайтырсың?! Ул ялгыз, өендә иркен.

Заһидә. Әйе, тагын нәрсә?

Мәүлихан Ханович. Сеңлем Заһидә, кайтыйм сезгә генә?

Заһидә *(Мәүлиханга пышылдап)*. Ап-ак ыштаннарыңны урам буйлап җилфердәтә-җилфердәтә, сасыган йомырка исләре чыгара-чыгара минем белән кайтыр иде бугай. Юк. *(Җыелган халыкка.)* Юк, авылдашлар, булмый. Килешмәгәнне. Иремнең үлгәненә 40 көн булмаган. Үз өендә күзенә Мирвәли күренгәнне, Мирвәли өендә аның күзенә Мирвәлинең җиденче бабае күренәчәк. Чит ир ияртеп кайтырга сез мине кемгә санныйсыз, Ходай кушмаганны?!

Мәүлихан Ханович. Фәсхетдин абзый, сезгә генә кайтыйм!

Фәсхетдин. Бик алып кайтыр идем дә, карчыгым сырхаулап тора шул.

Г ө л д а н и я *(Заһидәгә пышылдап)*. Әллә соң үземә генә алып кайтыйммы, ахир?

З а һ и д ә *(пышылдап)*. Җүләрләнмә, исе соң, исе...

Г ө л д а н и я *(Заһидәгә пышылдап)*. Нигә, таска салып юсаң, менә дигән ир була әле бу. *(Җыелган халыкка.)* Үземә генә алып кайтыр идем дә, тараканнар агулаган идем шул.

Н у р г а л и. Ялгышма, Гөлдания, ныклап уйла, мондый ир чүплектә аунап ятмый.

Г ө л д а н и я. Анысы, шулаен шулай... Тик...

М ө з ә й ә н ә. Бу инде килде-китте кәрәвник төзергә килгән әрмәннәр түгел.

З а һ и д ә. Акыл өйрәтмә, Мөзәйәнә әби. Бик акыллы булсаң, үзеңә алып кайт.

М ө з ә й ә н ә. Кара моны. Кара әле боларны. Элек, бөтен авыллары белән олы капкаларын ачып, кулларын сузып, авыз суларын киптереп, Мәүлихан Ханович, Мәүлихан Ханович, безгә сугылыгыз, чәйләп алырбыз, дип торган кешеләр, председательләре җүләрләнгәч, берсенә дә кирәкми. Минем белән, 83 яшьлек кортка белән нишләсен ул? Минем өемә 25 ел ир-атның аяк басканы юк. Минем белән җенләнү генә түгел, котырып үлә ул.

Ф ә с х е т д и н. Соң, алайса, җәмәгать, бергәләп үзен озатып куйыйк.

Г ө л д а н и я. Ерак ара түгел, озатыйк.

З а һ и д ә. Ни генә әйтсәгез дә, үз сөягебез.

Ф ә с х е т д и н. Урам уртасында калдырып булмый бит инде. Әйдәгез, җәмәгать. *(Тезелешеп чыга башлыйлар. Иң элек Мәүлихан Ханович баса.)* Кара әле, кем, Мәүлихан?! Син минем арттанрак бар әле.

Н у р г а л и *(Мәүлиханны артка этә)*. Артка, артка! Иң артка.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Нигә?

Н у р г а л и. Нигә, нигә? Күрмисеңмени, җил каршыга исә.

Тезелешеп чыгып китәләр.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачылганда, караңгылык. Тик сәхнәнең уң порталдагы Мәүлиханның өенә керә торган бизәкле баскыч кына яктыртылган. Ә сәхнәнең калган өлешендә, караңгылыкта, Мәүлихан Хановичның бик иркен һәм бай җиһазландырылган өй эче. Өскә киң баскыч менеп киткән, ә ишек төбендә мич. Уртада өстәл. Алгы пландарак күпереп торган диван. Шомлы музыкага Н у р г а л и, М ө з ә й ә н ә, Ф ә с х е т д и н һәм к а л г а н н а р, тезелешеп, баскыч янына чыгалар.

Ф ә с х е т д и н. Менә, кем, энем Мәүлихан, кайтып та җиттек. Бар инде, бисмилланы әйтеп, уң аягың белән кереп кит.

Мәүлихан Ханович. Юк, мулла абзый, үзем генә кермим. Куркам мин.

Нургали. Синең өеңә мин кермәм бит инде.

Заһидә. Мулла абзый, ни генә әйтсәң дә, син Ходай илчесе, Алла кешесе, җеннәрнең телен беләсең, булмаса, үзең генә кер!

Фәсхетдин. Бик керер идем дә, тәһарәтем бозылып китте шул.

Мөзәйнә. Җен янына кергәндә, тәһарәт нигә?

Фәсхетдин. Каршы сугылыр димен, кем, кортка, тәһарәтсез йөрү кичләрен ярамый, ди китап. Керсәң, син керерсең инде, Мөзәйнә карчык. Безнең арабызда бердәнбер тәһарәтле кеше син.

Мөзәйнә. Килешмәгәнне сөйләп торма әле, кем, мулла Фәсхетдин. Синнән узып керәмме соң, Алла сакласын. Гөнаһысын кая куярмын.

Фәсхетдин. Юк, син ашын ашаган, яшен яшәгән, җылап калырлык яшь балаларың юк. Бар, бар, кер. Мин сиңа фатихамны бирәм.

Мөзәйнә. Юк, хәзрәт, анда барырга ашыкмыйм әле. Синең фатихасыз да бу дөньяда калдырмаслар үземне. Аннары минем икеле-микеле күзләрем белән ул йортка кереп адашыргамы?!

Мәүлихан Ханович. Нургали иптәш, безнең авылда синнән дә зирәк, синнән дә тәвәккәл кеше юк, куркак булсаң, каравылда торалмас идең, бар, егетлегеңне күрсәт.

Заһидә. Мирвәлинең авылда иң якын иткән кешесе син идең, Нургали.

Нургали. Анысы шулай. Ул үзе дә мине көтеп арыгандыр инде.

Фәсхетдин. Шулай булгач.

Нургали *(тамашачыга)*.Үләсе килми карт ишәкнең! *(Фәсхетдингә.)* Миңа гына риза булыр микән? Мин бит әле яшь. Аңа картрак кеше кирәктер инде ул.

Мөзәйнә. Карт кеше?.. Як-ягыңа төкер, энем.

Фәсхетдин *(тамашачыга)*. Тәһарәтсез иблис, мине кертеп котыласы килә боларның. *(Кесәсеннән кукиш күрсәтеп.)* Менә сезгә!

Гөлдания. Бар инде, бар, Нургали. Синнән дә кулай кеше юк.

Нургали. Мине зурлап, чиратсыз кертәсез инде.

Фәсхетдин. Синең кайда, кайчан, нәрсәгә чират торганың бар? Син бит безнең авылда гел беренче.

Нургали. Беренче дисез инде. Бик керер идем дә, шүрлә-

тә бит. Дус дус инде ул. Дус, җенгә әйләнгәч, дуслыкны онытып муен тамырына тартмас микән?

Мәүлихан Ханович. Бар инде, катып үләм бит.

Нургали. Хәзер берәр стакан булсын иде, ике дә уйламас идем.

Мәүлихан Ханович. Өйгә кергәч, бер литр итеп бирермен.

Нургали. Бер литр? Алдамыйсыңмы? Сүзеңдә торасыңмы?!

Мәүлихан Ханович. Торам инде, торам!

Нургали. Ярый инде алайса, керәм!

Фәсхетдин. Җылап калырга бала-чагаң юк.

Нургали. Анысы дөрес, Фәсхетдин абзый, менә шушы өстемдәге кыршылып беткән телогрейкадан гайре бернәрсәм дә юк.

Фәсхетдин. Шулай булгач...

Нургали. Синең кебек байлык кала дип куркасы юк. Бар тапканымны дуслар белән уртага салып яшәдем. Алай-болай булсам, җирләрсез инде?!

Мәүлихан Ханович. Борчылма, колхоз чутыннан җирләрбез. *(Нургали баскычка менеп китә.)*

Фәсхетдин. Бисмиллаһир-рахманир ир-рахим! Вәссәламә галәй...

Нургали *(менгән җиреннән туктап)*. Кирәкми, мулла абзый, кирәкми. Безнең Мирвәли белән генә бeлә торган үз догабыз бар. *(Аягын бөкләп, намазлыктагы кебек, ике кулын аяк астына куеп, баскычка утыра.)* Син — Мирвәли, мин — Нургали, сак бул, аң бул. Син — Мирвәли, мин — Нургали, синең хозурыңа мин керәм. Аң бул, сак бул! Бер метрлы, галәфиле фәкыйреңне кабул ит! Йа Алла, үземнең язмышымны җан ахирәт дустым, кордашым Муллагали углы Мирвәли кулына тапшырам. Шушы догам кабул булып, Мәүлиханның 1 литрын кабул итеп, сиңа да, миңа да төннәр буе җәннәттә яшәргә насыйп ит. Амин.

Барысы да. Амин.

Нургали. Тәвәккәллим. *(Кереп китә. Бераздан чыга да.)* Керегез!

Барысы бергә. Ә Мирвәли?

Нургали. Мәрхүм Мирвәлигә Мәүлихан өендә шытрым калсын димени?

Фәсхетдин. Ха-ха-ха. Әйттем бит, күзенә күренгән, диеп. Әйдәгез, җәмәгать, керегез. *(Барысы да өйгә керәләр. Мирвәли, мич артыннан кулын чыгарып, Мөзәйәнә әбинең арт санын чеметеп ала.)*

Мөзәйәнә. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, нишләвең бу, кем, мулла Фәсхетдин?

Фәсхетдин. Нигә? Ни булды, Мөзәйәнә?

Мөзәйәнә. Ни булды, ни булды, җен булды! Минем арт санымны чеметкәнче, әнә яшьрәкләрнекен чемет! Гомер буе хатын-кыз капшаудан туймасаң да туймассың икән, иблис!

Фәсхетдин (*алга китә башлый. Мирвәли мич арасыннан чыга да аны төртеп җибәрә. Фәсхетдин мулла баштa алга сөрлегә, аннары, борылып, таягы белән Нургалинең сыртына менеп төшә*). Төртермен мин сиңа, алкаш. Ипи шүрлегеңә менеп төшкәнне сизми дә калырсың.

Нургали. Нишлисең, мулла абзый? Минмени ул? Ул бит Мирвәли!

Фәсхетдин. Каравылда ята-ята җенләнеп беткәнсең. Нәрсә, эчә-эчә күзеңә Мирвәли күренә башладымыни? Мә, тагын берәрне. (*Таягы белән кизәнә.*)

Нургали. Җитте сиңа, Мирвәй, башны тиштерәсең бит.

Барысы бергә. Мирвәй? Ха-ха-ха. Мирвәй, диме?

Фәсхетдин. Авылыгыз белән җенләнеп беткәнсез инде.

Заһидә. Җитте инде сезгә. Уеныгыз уен түгел. Син йокларга яттым дигән идең, кая соң ул синең яткан урының?

Мәүлихан Ханович. Менә, әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, кемдер җыештырган...

Нургали. Мирвәли-җен җыештырып чыгып киткәндер.

Мөзәйәнә. Җыештырыр бар җен. Җен өермәсен күргәнегез юкмыни? Юлындагы бар нәрсәне туздырып бетерә. Җенле өй болай булмый ул.

Фәсхетдин. Дөрес, җен юлындагы бөтен нәрсәне туздырып үтә, ди китап.

Мәүлихан Ханович. Туктагыз әле, җәмәгать! (*Дивандагы юрган астына кулын тыгып карый.*) Юеш! Менә юешме — юеш! Тотып кара, мулла абзый.

Фәсхетдин. Юеш, дип инде, энем, кем, Мәүлихан, синең, бәлки, электән үк юешли торган гадәтең бардыр?

Заһидә. Юк, юк, аның андый гадәте юк.

Нургали. Кит аннан, син каян беләсең?

Заһидә. Юк, теге ни... Хатынының, Сылуның сөйләгәне бар иде.

Мәүлихан Ханович. Мин бит исерек түгел идем, Алла бәндәләре.

Фәсхетдин. Ә, шулаймыни? Аек идеңмени?

Нургали. Шулайдыр. Син бит аның хатыны Сылу белән бик дуслар идегез. Күптән түгел генә кибет буенда, чәчкә чәч ябышып, сабан туе үткәреп ята идегез бугай.

Фәсхетдин. Эчүеңне киметергә кирәк, энем Мәүлихан, эчүеңне. Мирвәлине җирләгәндә үк шикләнгән идем мин син-

нән. Тик торганда үзеңнең атаңнан да өлкән кешенең арт санына китереп типтең бит син.

Мәүлихан Ханович. Синең генә арт саныңа тибәләр дә, сине генә төртәләр. Мәчет салырга килгән үзбәкләрдән алып калган анашаңны азрак тартырга кирәк.

Фәсхетдин. Син иблисне җәлләп, кызганып килгән булам. Алкоголик несчастный. Котырып үл шушы клуб кадәрле өеңдә. Юньле булсаң, хатының ташлап качмас иде сине. Колхоз малын сатып эчә-эчә, тилерә башлагансың. Сез диваналар белән, олы башымны кече итеп, вакытымны әрәм иткән мин дивана. Йөрим карт ишәк төсле, тәмле йокымны калдырып. Берсенә иллегә җитеп акыл кермәгән, ә икенчесенең кергән акылы да чыга башлаган. Чәнчелеп китегезсәнә! *(Чыгарга дип, өстәл янына якыная, арттарак басып торган Мәүлихан Ханович, куркып, кинәт мулла өстенә сикерә.)* Нишлисең, нишлисең, дивана! Тотыгыз, тотыгыз үзен. Үтерә! Үтерә! Коткарыгыз! Ычкына башлады бит. *(Икесе дә идәнгә егылалар. Фәсхетдин таягы белән Мәүлихан Хановичны кыйный башлый.)*

Мәүлихан Ханович. Мулла абзый, мулла абзый, гафу ит! Куркудан. *(Елап җибәрә.)* Мулла абзый, Фәсхетдин абзыкай, өстәлгә кара әле?! Нәрсә ул? *(Барысы да өстәлгә карыйлар, өстәл өстендә мөгез күрәләр, катып калалар.)*

Фәсхетдин *(саклык белән өстәлгә якыная. Таягы белән мөгезне әйләндереп карый. Гаҗәпләнеп.)* Мөгез?!

Барысы бергә. Мөгез?!

Фәсхетдин. Әйе, мөгез!

Барысы бергә. Нәрсә мөгезе?!

Мөзәйәнә *(курка-курка гына мөгезгә якыная да озак кына гаҗәпләнеп карап торганнан соң)*. Тфү-тфү! Бисмиллаһир-рахманир ир-рахим. Бәрәкалла, бәрәкалла, бу мөгез, бу мөгез, ягъни мәсәлән, минем узган ел көтүдә югалган кәҗәмнең мөгезенә охшаган, фаразан!

Барысы бергә. Кәҗә мөгезе?!

Нургали. Кәҗә мөгезе?! *(Кулына алып әйләндереп карап тора да мөгезне Мәүлиханның маңгаена куеп карый.)* Юк, җәмәгать, бу кәҗә мөгезенә охшамаган. Кәҗәнең мөгезе икәү була. Ә бу берәү. Бу мөгезнең астында, ягъни мәсәлән, нинди дә булса хикмәт ята.

Фәсхетдин *(тамашачыга)*. Исән чакта кайтып котылырга кирәк. Минем чормадагы кәҗә мөгезләре дә чыга башлады.

Мәүлихан. Әйтеп торам бит мин сезгә. Мирвәлине күрдем, дип. Нишләп кайттың, дигәч, сиңа мөгез куярга, диде.

Ф ә с х е т д и н. Ярый, авылдашлар, мин кайтыйм әле. Карчыгым бик сырхау, үзе генә курка торгандыр.

М ө з ә й ә н ә. Фәсхетдин, тукта, бергә кайтабыз. *(Мәулиханга.)* Әй, оятсыз, оятсыз, җир бит! Кәҗәмне суеп ашагансың да, мыскыл итәр өчен, бөтен авылны җыеп, мине мәсхәрә итәргә чакыргансың. Тамагыңа тыгылсын, бирән!

Ф ә с х е т д и н. Шаштың син, егет! Карт-корының арт санына тибеп, колхоз малын сатуың гына җитмәгән, хәзер авыл халкының малларына кул сала башладыңмы?! Үлгәч, авыл зиратына да күмдермибез без сине, иблисне!

Фәсхетдин белән Мөзәйәнә чыгып китәләр.

З а һ и д ә *(тамашачыга карап)*. Бу диваналар белән йөреп, күзгә мөгезләр күренә башлады. Исән чакта таярга кирәк.

Г ө л д а н и я. Әйдә, ахир, кайтыйк. Авыл халкы болай да үзебезгә әллә нинди нахак бәлаләр тагып бетерде, уйламасыннар дүртәүләшеп уйнаш итеп яталар, дип.

Гөлдания белән Заһидә чыгып китәләр.

Н у р г а л и. Ярый, Мәүлихан Ханович, мин дә кузгалыйм инде.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Китмә, китмә, Нургали туган. Бу авылда синнән дә яхшы күңелле кеше юк.

Н у р г а л и. Эш бит, Мәүлихан әфәнде, эш! Каравыл! Болай да бик озакладым.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Чукынып кына китсен каравылың.

Н у р г а л и. Алай димә, председатель усал, прямо зверь! Күрмәгәнемне күрсәтер.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Китмә, җаным?! Зинһар, мине үземне генә ташлама!

Н у р г а л и. Булдыра алмыйм, Мәүлихан Ханович, намусым кушмый. Эш! Ничего не поделаешь, эш! Кая, теге бер литрыңны менә монда тык та галифе киеп, военныйлар кебек, ике корчаңгы тайны сакларга постка китим. Ә син курыкма. Җен җен инде ул, шушы бер литрга ияреп, минем белән китәр ул.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Әнә теге диван астыннан ал.

Н у р г а л и *(диван астыннан бер литрны алып, чалбар кесәсенә тыга да)*. Менә галифиле дә булдык. Чин арта. Ә син курыкма. Җеннәр алар тимер-томырдан курка. Яныңа пычак сал, балта кертеп куй. Мин үзем баш очына арба күчәре, яныма кендек салам. Аннары җеннәр сүгенгәннән куркалар. Аты-юлы белән сүгенеп менеп ят, иртәнгә кадәр рәхәтләнеп изрәп йокларсың. Мин каравылда гел шулай эшлим.

Мәүлихан Ханович. Тукта, алайса, бераз гына сабыр ит. *(Баскычтан өскә менеп китә.)*

Мирвәли *(мич арасыннан чыга да)*. Ярый, мин кәнүшнигә элдертәм. *(Чыгып китә.)*

Мәүлихан Ханович *(баскычтан төшә. Башына кәстрүл кигән. Бер кулында пычак, икенчесендә балта, күкрәгенә кәстрүл капкачы аскан)*. Ярыймы?

Нургали. Настоящий рыцарь! Кәнүшнигә килсәң, ат та бирәм. Хәзер йокла!

Мәүлихан Ханович. Юк, йокларга куркам. Йә төнлә белән, йоклап киткәч, матчага асар.

Нургали. Ярый, иптәш председатель, мин теге флангны саклыйм, ә син бу флангны сакла. *(Кесәсендәге шешәгә төртеп)*. Хәзер шартлатабыз җеннәрне!

Чыгып китә. Мәүлихан Ханович бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлый.
Музыка. Ут сүнә.
Ут янганда, таң сызылып килә. Мәүлихан Ханович үзенең өске бүлмәсенә менә торган баскычында балтасын кочаклап йоклап утыра. Башында кәстрүл. Мирвәли килеп керә дә, йомшак кына басып, Мәүлихан Хановичның кулындагы балтасын ала, кулы белән кәстрүлгә шакый.

Мирвәли. Можнамы?

Мәүлихан Ханович *(сискәнеп уянып китә, торып утыра)*. Җен! Үтерәләр! Җен, җен! Коткарыгыз!

Мирвәли. Акырма! Балта түтәсе белән маңгаеңа бер генә тартырмын, җелегең атылып чыгар!

Мәүлихан Ханович. Кем син?

Мирвәли. Күрмисеңмени, Мирвәли ич.

Мәүлихан Ханович. Юк, син Мирвәли түгел, Мирвәлине күмдек. Син — җен!

Мирвәли. Мин — Мирвәли, теге дөньядан командировкага кайттым.

Мәүлихан Ханович. Командировкага?!

Мирвәли. Әйе, командировкага! Аллаһы Тәгаләнең приказы белән сиңа мөгез кайтардым.

Мәүлихан Ханович. Миңа мөгез?!

Мирвәли. Әйе, сезнең ике күз арасына, менә монда, маңгай уртасына *(Бармагы белән төртеп.)* мөгез куярбыз!

Мәүлихан Ханович. Ни өчен именно миңа?

Мирвәли. Аллаһы Тәгалә галиҗәнапларының әмере шундый. Бу адәмгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бары бер мөгез бирелеп, һәм дә ки ул мөгез анабыз Һава, атабыз Адәмнән яралып, җиргә сыену шарты белән җибәрелгән мөэмин-мөселман Миңлехан, мөэмин-мөслимә Бибигайшә углы мөэмин-мөселман Миңлемәүлиханга җир йөзендә кылган гөнаһларын кичерү шар-

ты белән, ул аны сезгә — ике аяклы хайвани затка җибәрә. Һәм дә ки ул аны шушы елның 15 гыйнварында, шомырт чәчәк атканда, 3 сәгать 15 минут 13 секундта үз янына, оҗмахка кабул итә.

Мәүлихан Ханович. Бөтенләйгәме?

Мирвәли. Сәвсимгә!

Мәүлихан Ханович. Мөгез?! Кызык?.. Нәрсә, мин теге дөньяда, оҗмахта кәҗә тәкәсе буламмыни?

Мирвәли. Юк! Кәҗә тәкәсе Ходай Тәгалә тарафыннан ике мөгезле итеп яратылган. Ә син бер мөгезле! Син урман сарыгы буласың!

Мәүлихан Ханович. Нигә сине җибәрде соң ул, юньлерәк кеше тапмадымыни?

Мирвәли. Мөгезне мөгезле кеше генә куярга тиеш.

Мәүлихан Ханович (*тамашачыга*). Кызык, мин бу бәндәдә мөгез күрмим! (*Мирвәлигә.*) Мин аңлап бетермәдем, сезнең исемегез һаман да Мирвәлиме соң? Сез анда нindirәк урын алып торасыз?

Мирвәли. Юк, миңа оҗмахта Аллаһы Тәгалә яңа исем кушты. Мин хәзер Әбугали-Салимали-Миңлегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали, Аллаһы Тәгаләнең уң кулы, ягъни илчесе, мөгез министры булам!

Мәүлихан Ханович. Ә... Али... Мали... Гали... Сали... Кем әле?

Мирвәли. Әбугали-Салимали-Миңлегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали!

Мәүлихан Ханович. Минем дә исемне үзгәртерләр микән?

Мирвәли. Үзгәртербез! Син Миңлемөгезлехаммәүлихан булырсың!

Мәүлихан Ханович. Шәп! Үзе озын, үзе матур, тагын кабатлагыз әле.

Мирвәли. Миңлемөгезлехаммәүлихан!

Мәүлихан Ханович. Хам... Мәүлихан... Менә шул хам дигәнен үзгәртеп булмасмы?

Мирвәли. Булмас! Хан теге дөньяда хам!

Мәүлихан Ханович. Мин аңлап җиткермәдем, Ходай илчесе. Ничегрәк инде ул мөгез? Шул сез өстәлдә калдырган мөгезме?

Мирвәли. Юк! Ул сиңа куеласы мөгезнең макеты!

Мәүлихан Ханович. Ә, шулаймыни? Аны ничегрәк куялар?

Мирвәли. Мөгезне куяр өчен, сезнең хәзерге вакытта дөньялыкта никахлы хәләл җефетегез булып саналган хаты-

ныгыз, мөэмин-мөселман Миңлесадрый кызы Миңсылуның ярдәме кирәк булачак.

Мәүлихан Ханович. Анысы начаррак икән. Заһидә белән генә куеп булмасмы?

Мирвәли. Булмас! Мөгезне бит сезгә куябыз!

Мәүлихан Ханович. Карышып маташкан булыр әле ул, Сылу тәре!

Мирвәли. Анысы синең эш! Үзең өчен кирәк!

Мәүлихан Ханович. Кайчанрак ясый башларсыз микән ул мөгезне?

Мирвәли. Ашыкмагыз, Аллаһы Тәгаләбез тарафыннан җиргә ике күзле, ике аяклы итеп яратылган хайвани зат — Миңлемөгезлехаммәүлихан, мөгезсез калдырмам!

Мәүлихан Ханович. Ходайның рәхмәте яусын үзеңә, олуг вә киң күңелле Ходай илчесе! Куйганда бик авыртмас микән?

Мирвәли. Авыртмас! Куйганын белгәч, караңгы төндә, ай-йолдызларга карап, җир тырматып җылатыр.

Мәүлихан Ханович. Җәннәт дигәндә, анысына гына түзәрбез. Аннары мөгез дигәнегез күренеп, маңгайны ямьсезләп тормасмы?

Мирвәли. Менә минем мөгез ничегрәк соң?

Мәүлихан Ханович. Ә мин сезнең маңгаегызда мөгез күрмим.

Мирвәли. Минем мөгез менә монда, йөрәктә!

Мәүлихан Ханович. Кызык, йөрәккә дә мөгез куялар, диген.

Мирвәли. Куялар! Үзеңә куйгач, күрерсең. Мөгезне теләсә кем күрә алмый! Куйган кеше дә, сам Аллаһы Тәгалә генә күрә. Аннары миннән әмер шул! Бу киемнәреңне салып, иске-москы киемнәр табып ки!

Мәүлихан Ханович. Нигә?

Мирвәли (*пышылдап, өскә, түшәмгә төртеп күрсәтеп*). Байларны яратмый.

Мәүлихан Ханович. Байларны яратмый, диген, ә? Яндырам, бөтен шифониры белән өеп яндырам.

Мирвәли. Яндырма! Авылыгыздагы берәр сәрхушкә бир! Кисен! Ул барыбер оҗмахка эләкмәячәк! Аның өчен бу дөнья оҗмах.

Мәүлихан Ханович. Ха-ха-ха-ха! Нургали исерекбашка бирәм. Рәхәтләнсен киеп, дивана баш, исерек тәре!

Мирвәли. Хәерчеме?

Мәүлихан Ханович. Кигән ыштаныннан, каткан телогрейкасыннан гайре бернәрсәсе дә юк.

Мирвәли. Бик дөрес эшлисең!

Мәүлихан Ханович. Шулай итим әле. Яхшы киенеп, тәмугта янсын, мәлгунь!

Мирвәли. Кара әле, мөгез дигәннән, бал, май, тәм-том кирәк булыр. Синең йөз илле мең акчаң бармы? Булса, бүген төнгә кибеттән шуларны алып куй!

Мәүлихан Ханович. Булмаган кая, менә моннан! Муеннан! Хәзер йөгерәм.

Мирвәли. Юк, сиңа өеңнән чыгарга ярамый. Берәрсен җибәр!

Мәүлихан Ханович. Кемне җибәрим икән? Заһидәне җибәрсәм генә инде.

Мирвәли. Хатын-кыз алган әйберләр мөгез ясарга ярамый! Мөгез ясар алдыннан сый-хөрмәтне ир кеше, ир-ат ала!

Мәүлихан Ханович. Кемне җибәрим икән?

Мирвәли. Нургалине җибәр!

Мәүлихан Ханович. Кит, дивана, кайтмый ул. Кулына акча керсә, көтмә Нургалине!

Мирвәли. Кайта. Аңа мин боерачакмын, Ходай илчесе!

Мәүлихан Ханович. Ярый алайса, Нургалине җибәрәм.

Мирвәли. Бик дөрес эшлисең! Шуны җибәр! Онытканчы шуны әйтәм, берәр коньяк белән шампунь да алсын!

Мәүлихан Ханович. Нигә, мөгезгә шампунь да кушасызмыни? Сабын гына ярамыймыни?

Мирвәли. Шампуньның исе тәмле була.

Мәүлихан Ханович. Әнә, әнә үзе үтеп бара Нургали. Чакырыйммы?

Мирвәли. Чакыр.

Мәүлихан Ханович. Син кач!

Мирвәли. Ул мине күрми!

Мәүлихан Ханович. Ничек күрми?

Мирвәли. Мин синең генә күзеңә күренәм.

Мәүлихан Ханович. Тавышыңны да ишетмиме?

Мирвәли. Ишетми.

Мәүлихан Ханович. Кызык... *(Тәрәзә форточкасын ача да.)* Әй, Нургали, Нургали, кер әле!

Нургалинең тыштан тавышы ишетелә: «Әллә бармы?»

Мәүлихан Ханович. Кер әле, кер тизрәк!

Нургали килеп керә.

Нургали. Нәрсә булды, әллә салып бирәсеңме?

Мәүлихан Ханович. Кибеткә барып кайт әле!

Нургали. Нигә?

Мәүлихан Ханович. Мөгез ясарга бал белән май алып кайт! Берәр коньяк белән шампунь да алырсың!

Нургали. Нинди мөгез?

Мәүлихан Ханович. Әнә күрәсеңме? (*Мирвәлине төртеп күрсәтә.*)

Нургали. Нәрсәне?

Мәүлихан Ханович. Диванда утырган кешене.

Нургали. Диванда мендәрдән гайре бернәрсә дә, беркем дә юк лабаса!

Мәүлихан Ханович. Алла илчесен, миңа мөгез куярга килгән Әбугали-Салимали-Миңлегали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргалине күрмисеңме?

Нургали. Кичә әллә артыграк салган идеңме?

Мәүлихан Ханович. Нәрсә сөйләгән була, тәмуг кисәве.

Мирвәли. Әйтеп торам бит мин сиңа, ул мине күрми дә, ишетми дә, диеп.

Нургали. Юк, мин диванда утырган кешене күрмим.

Мәүлихан Ханович. Сиңа тагын Алла илчесен күрергә. Мә өч йөз мең, сдачасы не надо!

Нургали (*акчаны ала*). Карале, бер шампунь белән бер коньяк кына җитәр микән, уйлат ул башыңны, кичә дә җитми калды, Мирвәй!

Мәүлихан Ханович. Кем белән сөйләшәсең син?

Нургали. Синең белән.

Мәүлихан Ханович. Мин Мирвәй түгел, надан!

Нургали. Беләм, син Мәүлихан.

Мәүлихан Ханович. Ничек кичә дә җитми калды?

Нургали. Колагыма ишетелде, әле дә колагым чыңлап тора.

Мәүлихан Ханович. Ха-ха-ха. (*Бармагы белән түшәмгә күрсәтеп.*) Тегеннән минем өчен әмер бирәләр.

Нургали. Шулайдыр, өстәндер! (*Тамашачыга.*) Диваннан түгел микән, ахмак! (*Мәүлиханга.*) Ярый, мин киттем, Мәүлихан.

Мәүлихан Ханович. Исемемне кыскартма! Мин хәзер, Миңлемөгезлехаммәүлихан.

Нургали. Кит аннан. Кайчан яңа исем куштың?

Мәүлихан Ханович. Бүген.

Нургали. Элек хан идең, хәзер хаммыни?

Мәүлихан Ханович. Син нәрсә аңлыйсың, надан! Салып ташла бу иске-москы киемнәреңне! Мә, минем яңа киемнәремне ки. (*Шифоньердан өр-яңа костюм, яңа бүрек, паль-*

*то чыгара.)* Әле бер тапкыр да кигәнем юк боларны. Әнә биркалары да үзендә.

Нургали. Юк, алмыйм. Оят. Ничек инде алыйм, кеше киемен. Дивана дигәч тә, үзеңә кирәк булыр әле.

Мәүлихан Ханович. Кем дивана?

Нургали. Мин — дивана, син — акыллы.

Мәүлихан Ханович. Каян беләсең?

Нургали. Беләм. Юк, мин кеше киеме кимим!

Мирвәли. Ал, ал, Нургали. Үз гомереңдә бер генә булса да кеше төсле кием киеп кара.

Нургали. Шулай дисеңме?

Мирвәли. Шулай димен.

Мәүлихан Ханович. Кем белән сөйләшәсең син?

Нургали. Синең белән ич.

Мирвәли. Минем тавышны синеке дип уйлый ул. Миңлемөгезлехаммәүлихан.

Нургали. Ярый алайса, Мәүлихан туган, бик кыстагач, алырмын инде.

Төенчеккә бәйләп киемнәрен ала да чыгып китә.

Мәүлихан Ханович. Озак йөрмә!

Ут сүнә, музыка. Ут янганда, Мәүлихан, аякларын бөкләп, сәләмә киемнән диванда утыра. Үзе маңгаен уа. Бүлмәгә Заһидә белән Гөлдания килеп керәләр. Озак кына кызганулы караштан соң.

Заһидә. Ни хәлләрең бар, Мәүлихан?

Мәүлихан Ханович *(кулы белән маңгаен ышкып)*. Алланың биргәненә шөкер!

Гөлдания. Терелдәсеңме инде?

Мәүлихан Ханович. Мин бит чирләмим.

Заһидә *(елап)*. Белми инде мескен. Үзенең алмашынганын белми.

Мәүлихан Ханович. Беләм!

Заһидә. Нинди ир идең бит син, Мәүлиханкаем, нинди ир идең!

Гөлдания. Сөйлисе юк, ахир. Типсә тимер өзәрдәй иде.

Заһидә. Авыртмыйм, дигән була, мескенем.

Гөлдания. Кара син аның өс-башын гына. Каян табып бетергән бу иске-москыны?

Заһидә. Мәүлиханкаем, әйдә, өс-башыңны алыштырыйк! Синең бит әйбәт киемнәрең дә күп. Кая, тәти күлмәгеңне кидерәм.

Мәүлихан Ханович. Ярамый! Тәти күлмәкләр ярамый!

Заһидә. Нигә?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч *(өскә күрсәтеп)*. Тегеләр кушмый!

З а һ и д ә. Кемнәр?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали!

Г ө л д а н и я. Күзенә күренә. Бозганнар моны, ахир, бозганнар!

З а һ и д ә. Кем бозсын аны?

Г ө л д а н и я. Кем булсын. Аның шаярган хатыннары буа буарлык. Син генә түгел.

З а һ и д ә. Шулай дисеңме?

Г ө л д а н и я. Бәлки, Сылуы бозгандыр.

З а һ и д ә. Нишләп инде Сылу үз ирен үзе бозсын?!

Г ө л д а н и я. Ышанасың икән. Миңа да, үзенә дә булмасын дип.

З а һ и д ә. Нигә ышкыйсың ул маңгаеңны, Мәүлихан!

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Йомшартырга?

Г ө л д а н и я. Кызартып бетергәнсең бит.

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Кызарсын! Йомшартырга кирәк!

З а һ и д ә. Йомшартырга?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Тегеләр, өстәгеләр әйтте. Йомшак җиргә мөгез куярга җиңел була, диделәр.

Бүлмәгә М ө з ә й ә н ә килеп керә.

М ө з ә й ә н ә. Исәнмесез, оланнар!

З а һ и д ә, Г ө л д а н и я *(икесе бергә)*. Безнең хәлләр үзегез күргәнегезчә инде, Мөзәйәнә әби.

Г ө л д а н и я. Менә Мәүлиханыбыз нинди хәлгә төште.

З а һ и д ә. Күзгә күренеп бетә, күзгә күренеп. *(Елый.)*

М ө з ә й ә н ә. Әйдәгез, бер дога. *(Өчесе дә утырып дога кылалар.)* Амин! Хәлләрең ничек, Мәүлихан энем?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Ат мөгезе кебек. *(Маңгаен ышкудан туктый.)*

М ө з ә й ә н ә. Әстәгъфирулла. Минем көнбагышларым арасына карачкы иттереп бастырып куйган иске жакетым югалган иде. Бу мескен алган икән. Хәерлегә булсын.

З а һ и д ә. Кичә көндез бакча уртасында бөтен яхшы киемнәрен өеп яндырган бит. Бөтен авылның бала-чагалары карап торган.

Г ө л д а н и я. Алла сакласын, өенә генә ут төртмәсен инде.

М ө з ә й ә н ә. Башың шауламыймы?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Юк! Алланың биргәненә шөкер!

М ө з ә й ә н ә. Менә бит, җен нишләтми адәм баласын.

Мәүлихан Ханович. Көнләшмәгез миннән! Үзегезгә мөгез эләкмәдемени?

Гөлдания. Бозганнар аны.

Мөзәйнә. Үзем дә юл буена шуны уйлап килдем. Хатыны кайтмаганмы?

Гөлдания. Кайтыр?! Ул бит аңа таза чагында гына, мал тапканда гына кирәк иде.

Мөзәйнә. Тау хәтле дөнья бит, тау хәтле...

Заһидә. Чукынып китсен дөньясы, нигезе каһәрле, аның белән торганчы, исерек Нургали белән торам мин, дип әйтә, ди Сылуы.

Гөлдания. Беренче очраган иргә тотам да кияүгә чыгам, дип әйтә, ди.

Булмәгә Фәсхетдин керә.

Фәсхетдин. Әссәламегаләйкем, авылдашлар!

Барысы бергә. Вәгаләйкем әссәлам, мулла абзый!

Фәсхетдин. Ягез, бер дога. (*Барысы да кулларын йөзләренә күтәрәләр.*) Әгузе биллаһи мина шайтан бисмиллаһи ир-рахма-ан ир-рахи-им. (*Пышылдап укыганнан соң.*) Амин!

Барысы бергә. Амин!

Мәүлихан Ханович. Фәсхетдин абзый, укыма. Синең догаң барыбер Ходайга барып ирешми!

Фәсхетдин. Нигә ирешми?

Мәүлихан Ханович. Патаму што, син иблис, кяфер, тәмуг кисәве!

Фәсхетдин (*тамашачыга*). Җүләр, җүләр каян сизә диген. Бер йөз грамм гына тотып килгән идем. (*Мәүлиханга.*) Нишләп алай дисең, кем, энем Мәүлихан?

Мәүлихан Ханович. Кая маңгаеңдагы мөгезең?

Мөзәйнә. Игътибар итмә, кем, мулла Фәсхетдин. Саташа.

Гөлдания. Күзенә күренмә.

Мәүлихан Ханович. Кәҗә урлап кына мөгезле булып булмый ул, мулла абзый. Мөгезне тегеннән, өстән җибәрәләр аны.

Заһидә. Мулла абзый, әллә өшкереп карыйсыңмы соң?

Фәсхетдин. Игътибар итмәгез, җәмәгать, аның бер сүзе дә дөрес түгел, аны җеннәр сөйләштерә. Бөтен курыкканым, өенә ут төртеп, мине генә яндырмасын инде. Бигрәк терәлеп торабыз.

Мәүлихан Ханович. Борчылма, Фәсхетдин абзый. Озакламый мин бөтенләйгә китәм. Курыкмыйча, рәхәтләнеп бакча артында кәҗә суярсың.

Фәсхетдин (*тамашачыга*). Очлы күз! (*Мәүлиханга.*) Кая китәсең, Мәүлихан энем?

Мәүлихан Ханович. Теге дөньяга, оҗмахка!

Мөзәйәнә. Китмисең әле, Мәүлихан энем, яшисең әле, яшисең.

Мәүлихан Ханович. Китәм. Хәбәр китерделәр. Быелның 15 гыйнварында, шомырт чәчәк атканда, 3 сәгать 15 минут 13 секундта бөтенләйгә сезнең арагыздан китәм.

Гөлдания. Шомырт гыйнварда чәчәк атмый бит, Мәүлихан!

Мәүлихан Ханович. Ата! Оҗмахта 15 гыйнварда ата.

Мөзәйәнә. Ходай сиздерә торгандыр.

Заһидә. Мәүлиханкаем, безне, мине ташлап китәсеңмени? (*Елый.*)

Мәүлихан Ханович. Кит, тәмуг кисәве, җылап утырма. Юньле булсаң, Ходай илчесе Мирвәли өстеннән минем белән гулять итмәс идең син, себерке! Ярый әле вакытында Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали, кайтып, үземне кисәтте. Синең белән тәмугта янасыларым булган икән.

Фәсхетдин (*тамашачыга*). Да, берәүгә дә көн калмады. Асылын да үл! (*Җыелган халыкка.*) Нинди егет иде бит. Тирә-якта тиңнәр юк иде үзенә. Әле монда килгәндә, Нургали кибеттән чыгып килә. Өстендә өр-яңа киемнәр, кулында тулы ризык белән сумка. Үземә 25 мең хәер бирде.

Мөзәйәнә. Сөйлисе юк. Көнаралаш миңа 10 мең дә, 15 мең хәер кертә. Каян ала диген?

Гөлдания, Заһидә (*икесе бергә*). Айныган көне дә юк!

Мөзәйәнә. Әллә, мин әйтәм, кем... ни, мулла Фәсхетдин, кыйнап карыйбызмы? Җеннәрен кыйнап чыгарып булмас микән?

Мәүлихан Ханович. Кыйнатырмын мин сезгә. Мөгез генә куйсыннар, озакламый күрмәгәнегезне күрсәтәм әле мин сезнең. Мин сезгә элеккеге председатель Мәүлихан түгел, мин озакламый мөгезле — Миңлемөгезлехаммәүлихан булырмын!

Фәсхетдин. Үзем дә шуны уйлап утырам. Нургалине чакырырга кирәк. Үзебезнең генә көч җитмәс. Җенле кешедә җен көче була, ди китап.

Мәүлихан Ханович. Кагылып кына карагыз. Хәзер үк Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали фәрештәне чакырам!

Мөзәйәнә. Кызым Заһидә, әллә соң Нургалине чакырып киләсеңме?

З а һ и д ә *(елый)*. Ничек җәлләмичә кыйныйсың инде аны.

Г ө л д а н и я. Кеше ясыйм, җенен куыйм дисәң, җәлләп торып булмый инде, ахир! *(Кызу гына чыгып китә.)*

Ф ә с х е т д и н. Карале, энем Мәүлихан, күзеңә бирәр нәрсә күренәме?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Күренә! Ә синекенә күренми? Нургалинекенә дә күренми.

Ф ә с х е т д и н. Нәрсә күренә?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали күренә!

Ф ә с х е т д и н. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, дилбегә буйлы исем. Ятлап бетерерлек түгел.

М ө з ә й ә н ә. Тагын нәрсәләр күренә?

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Үзе күренә — мөгезе күренми!

Бүлмәгә Г ө л д а н и я белән купшы киенгән Н у р г а л и килеп керәләр.

Н у р г а л и. Исәнмесез, авылдашлар! Заһидә, урындыкка өреп җибәр әле, тузаны булмасын. *(Бармагы белән урындыкны сыпырып карый.)* Сайдет! Әйдәгез, бер дога! *(Барысы да дога укыйлар.)*

Ф ә с х е т д и н. Амин!

Б а р ы с ы б е р г ә. Амин!

Н у р г а л и. Мәүлихан чирлегә атап хәер өләшим әле. *(Фәсхетдингә акча суза.)*

Ф ә с х е т д и н. Әле генә 25 мең хәер биргән идең бит, Миңленургали.

Н у р г а л и. Алыгыз, ал! Әтекәйнеке мал түгел, дусларныкы җәл түгел. *(Мөзәйәнәгә, аннары Заһидәгә, Мәүлихан Хановичка суза.)*

М ә ү л и х а н Х а н о в и ч. Миңа кирәкми!

Н у р г а л и. Ал, ал! Үз күчтәнәчеңне ашасаң, озын гомерле булырсың! *(Мәүлихан Ханович ала. Аннары Гөлданиягә бирә.)*

Г ө л д а н и я. Кара әле, Нургали, тәмам күзгә күренеп баедың, малай. Каян табасың шулкадәр акчаны?

Н у р г а л и. Эшләп торам бит, күрше.

Г ө л д а н и я. Элек тә эшли идең инде.

Н у р г а л и. Элек йоклый идем мин. Менә Мирвәли үлгәч, ике кешелек кооператив ачып җибәрдек. Акча агып керә, күрше.

Г ө л д а н и я. Бүген кич кереп чык әле, үтүгем янган иде.

Н у р г а л и. Үтүк ремонтлый белмим шул мин, Гөлдания. Үтүкләрне Мәүлихан әйбәт чинить итә торган иде.

Г ө л д а н и я. Әй, тиле-милегә ничек курыкмыйча үтүк ремонтлатасың инде.

Ф ә с х е т д и н. Ярый, җәмәгать, үтүк-мүтүкләрегезне калдырып торыгыз. Менә бу баланы нишләтәбез? Әллә, мин әйтәм, Нургали энем, кыйнап карыйбызмы?

Н у р г а л и. Тик торганда кешене кыйнарга мин палач түгел, миңа бер зыяны да тигәне юк, файдадан башка.

М ө з ә й ә н ә. Юк, кыйнап җеннәрен куып булмас микән, дибез.

Н у р г а л и. Җен?! Җен бар микән соң ул?

Ф ә с х е т д и н. Аптыраганнан әйтәм инде.

М ө з ә й ә н ә. Нигә булмасын.

Н у р г а л и. Синең үзеңнең җен күргәнең бармы соң, кем, Мөзәйәнә әби?

М ө з ә й ә н ә. Күрмәсәм соң?

Н у р г а л и. Ә синең, мулла абзый?

Ф ә с х е т д и н. Юк, күргәнем юк.

Н у р г а л и. Күрмәгәч, без үзебез җен түгел микән соң?

Ф ә с х е т д и н. Як-ягыңа төкер, энем, син нәрсә?

Н у р г а л и. Әйтегез, кайсыгызның җен күргәне бар?

Б а р ы с ы  б е р г ә. Юк, юк, күргән юк.

Н у р г а л и. Ә менә минем бар.

Ф ә с х е т д и н. Ха-ха-ха! Нургали энем, алдарга сиңа куш инде.

Н у р г а л и. Алайса тыңлагыз. Сөйлим. Җен күргәннеме әле.

Г ө л д а н и я. Йә, сөйләп кара.

Н у р г а л и. Шулай бер тапкыр каравыл өендә ятам. Караңгы төшкән иде. Шыгырдап колхозның тегермән капкасы ачылып китмәсенме?! Капкадан, бер олы гына шәүлә дисәң, шәүлә түгел, гәүдә дисәң, гәүдә түгел, бер өрәк килеп чыкмасынмы!

М ө з ә й ә н ә. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла. Шуннан, шуннан, кем, энем Нургали?

Н у р г а л и. Аркасына бик зур, олы капчык аскан. Аптырашта калдым. Кем булыр бу, мин әйтәм? Күзәтә башладым. Ныклабрак карасам...

З а һ и д ә. Йә шуннан, шуннан ныклабрак карасаң?..

Н у р г а л и. Мулла абзый кыяфәтендәге җен!

Ф ә с х е т д и н. Тукта әле, кем, ни, энем... Нургали, чама белән тәүлекнең кайсы вакыты инде бу?

Н у р г а л и. Чама белән кичке сигезләр тирәсе булгандыр. Нәрәт вакыты иде. Шунысын төгәл итеп әйтә алам, бөтен начальство нәрәттә иде.

Ф ә с х е т д и н. Булыр, булыр, энем. Әйтеп торам бит мин сезгә, җен — төрле кеше кыяфәтенә керер, дип. Минем нәкъ азан әйткән вакытыма туры килә, каһәр.

Н у р г а л и. Аның иң кызыгы да шунда шул, җәмәгать. Мулла абзый дисәм, мулла абзый азан сала, җендер бу, мин әйтәм. Сызгырып җибәрүем булды — җен капчыгын ыргытты да кире якка йөгерә башлады. Капчык янына барсам...

Г ө л д а н и я. Шуннан, шуннан?

Н у р г а л и. Капчык янына барсам...

З а һ и д ә. Капчык юкка чыкканмы?

Н у р г а л и. Чыкмаган шул! Капчыкның тышында олы ике хәреф ярылып ята. Х һәм Ф!

Г ө л д а н и я. Ханнанов...

З а һ и д ә. Фәсхетдин...

Ф ә с х е т д и н. Күрәсезме, җен адәм баласын ничек буталчыклыкка кертә. Караңгы төшкәч, ферма тирәләрендә дә бик йөрергә тырышмагыз, китап шулай ди. Хәтта капчыкка да хәйлә, тамга салырга өлгергән.

М ө з ә й ә н ә. Йә, шуннан нәрсә булып бетте?

Н у р г а л и. Җен артыннан йөгердем. Бераз барсам, сыңар галош аунап ята. Аның да эчендә Ф һәм Х тамгасы салынган. Менә шуннан җен юк дип кара.

М ө з ә й ә н ә. Ә ул капчык белән галошны нишләттең?

Н у р г а л и. Күтәрдем дә туп-туры мулла абзый янына йөгердем.

Ф ә с х е т д и н. Туктагыз әле, туктагыз! Мәүлихан җеннәрен куыйк!

Г ө л д а н и я. Тукта әле, мулла абзый, тыңлап бетерик.

З а һ и д ә. Капчык дигәннән, Мирвәликәем үлгән көнне минем дә мич арасыннан бер капчык шикәрем югалды.

Н у р г а л и. Мәчеткә барсам, мәчет ишегендә ат башы кадәр йозак! Ә мөнбәрдән мулла абзыйның азан әйткән тавышы ишетелә.

М ә ү л и х а н  Х а н о в и ч. Йә, шуннан?

Н у р г а л и. Шуннан шул, мәчетнең баскычына утырдым. Мулла абзыйның азанын әйтеп бетерүе булды...

З а һ и д ә. Йә инде, йә, шуннан нәрсә булды?

Н у р г а л и. Илһам Шакировның «Сарман» көенә җырлап җибәрүе булды. Әле дә бүгенгедәй хәтерлим. *(Җырлап җибәрә.)*

Сарман буйкайлары, ай, киң ялан,
Печәннәре җитәр берзаман шул,
Печәннәре җитәр берзаман.
Каушулары, иркәм, бик күңелле,
Әмма айрылышу бик яман.

*(Фәсхетдин мулладан башкалар шаркылдап көләләр.)* Шушы хәлне авыл яшьләренә сөйләгән идем, чукынмышлар, яңа җыр чыгарганнар. *(Җырлый.)*

Сарман буйларында ике күл бар:
Берсе — Андыз, берсе — Кондызлы.
Бу дөньяда ике кыенлык бар:
Берсе — картлык, берсе — ялгызлык.
Ферма буйларыннан кайткан чакта,
Очраттым мин авыл мулласын.
Авыл мулласы да шуны әйтте:
«Чәлдереп кал фани дөньясын».

Фәсхетдин. Аның бит әле шунысы да бар, җәмәгать. Күп эчкән кешенең күзенә дә җеннәр күренүчән була. Ягъни мәсәлән, медицина теле белән әйтсәк, белогорячка! Вәт шулай, энем Нургали. Әзрәк эчәргә өйрән!

Мәүлихан Ханович. Белмим, белмим. Ул мөнбәрдән кемнәр генә җырламады инде.

Заһидә. Беттеме, Нургали?

Нургали. Юк шул әле, бетмәде шул әле, Заһидә! Баскычтан тордым да, озак кына уйланып торгач, саташам, ахрысы, дип, сезнең очтан эшкә, кәнүшнигә менеп киттем. Карасам, тагын бер җен! Валлаһи, җен! Мәүлиханнарның арт капкаларыннан чыкты да туп-туры, ап-ак ыштаннан, ак күлмәктән сезгә кереп китте. Аптырадым! Кем дип уйларга да белмәдем. Мәүлихан Ханович дисәм, төнлә сездә аңа ни калган? Җеннәр бу дип уйлап, каравыл өенә менеп киттем. Каршыма синең мәрхүм ирең, кордаш Мирвәли очрады. Күзләре яшьле, үзе ямансу иде. Күзләрен үз өенең тәрәзәсенә баккан да, дәшми-тынмый, янып бетә язган тәмәкесен еш-еш суыра иде. Хәтта минем терәлеп узганымны да сизмәде. Шул төнне кордаш Мирвәлине теге җен мәңгелеккә амбар келәтенә асып китмәде микән, дигән шик яши башлады үземдә.

Мәүлихан Ханович. Әй, сез! *(Сикереп тора.)* Тәмуг кисәүләре! Минем өемнән, Миңлемөгезлехаммәүлихан өеннән, олтаннарыгызны күтәрегез! *(Кулына урындык алып кизәнмәкче була.)*

Фәсхетдин. Тотыгыз, тотыгыз үзен! Тизрәк бәйләп салыгыз. Кыйнарга кирәк аны, кыйнарга! Җеннәре котырта аны. Җеннәр җен турында сөйләгәнне яратмый, ди китап. *(Төрлесе төрле яктан килеп, Мәүлиханны кыйный башлыйлар.)*

Нургали *(китереп тибә)*. Монысы — Мирвәли кордаш өчен! Монысы — мине рәнҗеткәнең өчен!

Фәсхетдин *(йодрыгы белән корсагын төя)*. Вакытсыз эштән куганың өчен. Очлы күз, күпне күргәнең өчен!

Мөзәйәнә. Кәҗәм, бәгырь кисәгем өчен! *(Чәчен йолкый.)* Пас парву!

Заһидә *(битенә суга)*. Тереләсең, бәгърем, мә берне! Тереләсең, алтыным, мә икене!

Гөлдания. Миңа карамый, Санияне яратканың өчен! *(Яңаклый.)* Миңа карамый, Заһидәне сөйгәнең өчен! *(Яңаклый.)*

Мәүлихан Ханович. Үтерәләр, үтерәләр, коткарыгыз! Каравыл, үтерәләр! Син кая, Мирвәли туган, коткар, үтерәләр!

Заһидә. Җәмәгать! Туктагыз, туктагыз, чыкты! *(Тынып калалар.)*

Гөлдания. Нәрсәсе чыкты?

Заһидә. Җене чыкты!

Гөлдания. Кая?

Заһидә. Әнә, мич авызыннан кереп китте дә морҗадан чыгып очты!

Мөзәйәнә. Әле дә мич авызы ачык иде.

Нургали. Чыкты, чыкты, җәмәгать! Үз күзләрем белән күрдем, ап-ак ыштаннан. Ыштаны юеш иде. Чыкты да мичкә кереп китте.

Фәсхетдин. Рәхмәт, авылдашлар, булдырдык! Хәзер үзен генә калдырыйк. *(Барысы да чыгып китәләр.)*

Мәүлихан Ханович. Уф, ах, үләм... *(Өстерәлә-өстерәлә диванга менмәкче була, менә алмый.)* Мине җенле, дигән булалар. Үзләре авыллары белән котырганнар! Тик торганда бер гөнаһсыз кешене кыйнап чыгып киттеләр. Уф, үләм! Алла, Алла, кабыргаларымны сындырдылар бугай. *(Музыка. Ут сүнә. Мәүлихан Ханович аунап идәндә кала. Ут янганда, Мәүлихан башын марля белән бәйләгән, күз төпләре күгәргән. Ыңгыраша-ыңгыраша арлы-бирле бүлмә буйлап йөри.)* Кайчан тизрәк мөгезле булам да кайчан гыйнварның 15 е җитеп, шомырт чәчәк ата инде. Котылыр идем бу дөньялыктан. Юкса шомырт чәчәге урынына үземне чәчәк аттыралар болар! Тегесе дә кайтса кайтмады. Мөгез кую бик катлаулы булды, ахрысы. Сылу, кире тәре карышып ятадыр әле.

Нургали *(килеп керә)*. Нишләп йокламыйсың, сәгать иртәнге 4 кенә бит әле? Синең урында булсам, мин рәхәтләнеп йоклар идем.

Мәүлихан Ханович. Йокларсың, бар! Бөтен тәнем ут яна.

Нургали. Янса! Өстеңә ябынып ятасы юк. Йокла, дивана.

Мәүлихан Ханович. Үзең йокла. Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргалине көтәм.

Нургали. Кемне?

Мәүлихан Ханович. Алла илчесен!

Нургали. Нигә?

Мәүлихан Ханович. Мөгез куярга киткән иде.

Нургали. Аңгыра!

Мәүлихан Ханович. Син үзең аңгыра, надан, мөгезсез шайтан!

Нургали. Мөгезле шайтан!

Мәүлихан Ханович. Аллага шөкер! Тсс! Әнә үзе кайтты!

Нургали. Кем?

Мәүлихан Ханович. Күзең чыкканмыни? Әнә бит үзе, Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали! *(Мирвәли килеп керә.)*

Нургали. Мин бит синең кебек тилермәгән. Минем күземә бернинди дә Сали-малилар күренми.

Мәүлихан Ханович. Әнә ич ишектән керде. Ишек ачылганны да күрмисеңмени, дивана?

Нургали. Җил ачты ич аны.

Мәүлихан Ханович. Әссәламегаләйкем, Алла илчесе, Әбугали-Салимали-Гаптелкадый-Җаббарый-Шыттыргали! Ничегрәк, мөгез барып чыктымы?

Мирвәли. Таң алдыннан көч-хәл белән!

Мәүлихан Ханович. Шулайдыр. Төне буе утыгыз булмады. Ике авыл арасын таптап, аякларым суелып бетте, табан асларым уттай яна. Барам да тәрәзәгезне карыйм, барам да карыйм. Ишегегезне тартып карыйм, ишегегез эчтән бикле.

Нургали. Ишекләре эчтән бикле булгач, сөенеп кайтып китәсеңме?

Мәүлихан Ханович. Сөенмичә. Синең өчен караңгыда, тирләп-пешеп, Алла илчесе эшләп ятсын инде, сөенмәс җиреңнән сөенерсең.

Мирвәли. Хатыныгыз килерәк икән.

Мәүлихан Ханович. Гомергә кире булды, бәдбәхет. Бер юньле эше булмады. Менә Заһидә булса...

Мирвәли. Кич белән үк кайта идем. Инде булды дигәндә, чәлпәрәмә китерә язды.

Мәүлихан Ханович. Сылумы? Сукыр бит ул! Көн яктысында да күзлек белән көчкә күрә. Ут яндырып эшлисегез калган.

Нургали. Мөгез ясарга күз кирәкми, хис кирәк.

Мәүлихан Ханович. Тик кенә утыр! Мөгез ясаган кеше кебек утырма, ахыр заман кисәве! Кара, минем мөгез үземә килешеп торамы?

Нургали. Бераз кыеграк булган.

Мәүлихан Ханович. Кыек! Караңгыда үзең эшләп кара, алай бик оста булсаң! Рәхмәт сиңа, Алла илчесе! Меңмең рәхмәт!

Мирвәли. Бераз гына кыеграк чыкты инде. Мөгез электр яктысыннан курка шул ул.

Мәүлихан Ханович. Борчылма! Үзем гаепле! Үзем барып керосин лампасы тотып яктыртып торасым калган.

Мирвәли. Анысы ук миннән булмый инде, анысын син генә булдырасың! Ярый, әйберләремне җыйыйм да китим.

Мәүлихан Ханович. Кая? Аллаһы Тәгалә янынамы?

Мирвәли. Юк, синең хатының Сылу янына. Ошады ул миңа.

Мәүлихан Ханович. Ә тегендә, җәннәткә кайчан кайтасың?

Мирвәли. Миңа мондагы җәннәт, Сылу җәннәте ныграк ошады.

Нургали. Нәрсә, Мирвәли, өйләнәсеңмени?

Мирвәли. Өйләнәм! Свидетелем булырсың!

Нургали. Ха-ха-ха! Димәк, туй!

Мәүлихан Ханович. Нинди туй?

Нургали. Күрмисеңмени, Мирвәли Сылуга өйләнәм, ди бит.

Мәүлихан Ханович. Нинди Мирвәли?

Нургали. Каршыңда басып торган Мирвәли!

Мәүлихан Ханович. Син аны күрәсеңме?

Нургали. Күрмичә, мин бит сукыр түгел.

Мәүлихан Ханович (*Мирвәлигә*). Син Сылу белән, миңа...

Мирвәли. Синңа!

Мәүлихан Ханович. Мөгез... Син бит мәет!

Мирвәли. Юк, мин тере!

Мәүлихан Ханович. Син кабердә!

Мирвәли. Юк, мин биредә!

Мәүлихан Ханович. Ә кабердә?

Мирвәли. Капчык белән шикәр.

Мәүлихан Ханович. Мич артындагымы?

Мирвәли. Мич артындагы.

Мәүлихан Ханович. Бүген ничәсе?

Мирвәли. Гыйнварның 15 е.

Мәүлихан Ханович. Вакыт күпме?

Мирвәли. 3 сәгать 15 минут, 13 секунд.

Мәүлихан Ханович. Хушыгыз. (*Шапылдап егыла.*)

Музыка.

Пәрдә

# Бәхетеңне кайда сөзсә

*Комедия ике пәрдәдә*

КАТНАШАЛАР:

Шульдери — ликер-аракы заводының клубында сәнгать җитәкчесе.
Бәйрәмгали — «Коммунизмга» колхозының алдынгы тракторчысы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Музыка астында сәхнәгә нечкә генә озын гәүдәле, аягына кроссовки, өстенә ике размерга кечкенә шакмаклы аксыл костюм, олы якалы, бизәкле чигән күлмәге, муенына «бабочка» таккан, кулына чемодан күтәргән Шульдери керә.

Шульдери (*сәхнәне җентекләп карый-карый*). Да... Америка дигәннәре чыннан да җәннәт икән. Кара син бу отельне генә...

Шул вакыт түше орден-медальләр белән чуарланып беткән, ике размерга зуррак СПТУ костюмы, аягына башы кәкрәеп, кыршылып беткән кирза итек, башына фуражка, муенына төерләнгән зур бизәкле галстук, аркасына рюкзак аскан Бәйрәмгали килеп керә дә, ул да сәхнәне күзәтә башлый.

Шульдери (*Бәйрәмгалигә җирәнүле караш белән*). Иптәш! Сезнең үзегезгә генә берәр бүлмәгә урнашып булмый идеме?

Бәйрәмгали (*каравын дәвам итеп, масаеп кына*). Утырыгыз, утыр! Нигә бастың, син миңа комачауламыйсың!

Шульдери (*халыкка*). Нәрсә сөйләгән була ул? (*Бәйрәмгалигә.*) Ярый инде алайса, нишлисең бит, безнең илдә бу кадәр орден-медальләр таккан кешегә һәрвакыт почет!

Бәйрәмгали. Дөрес сөйлисең, абзый кеше. Безнең илдә орден-медаль тагу модага кергән.

Шульдери. Энем, каян табып бетердең бу кадәр тимер-томырны?

Б ә й р ә м г а л и (*күкрәгенә карап, горурланып*). Биредә безнең авылның бөтен орден-медальләре. Поближе приходи. Менә болары — Сәгъди бабайныкылар. Ул аны Октябрь революциясендә немеч кушмаштатлары белән сугышкан өчен алган. Теге... коли-коли бар бит әле, шытык белән шытык, туесть, штык белән. Ә менә болары аның атасы Гыйльфан картныкылар. Ул инде үзе давно пумер. Ул аларны бишенче елда япун самурайларына каршы сугышта алган. Заебавал!

Ш у л ь д е р и. Завоевал...

Б ә й р ә м г а л и. Әйе, әйе, шулай. Уруччам чамалы. Шулар, тегеләр белән кысык күзләр, япуннар белән. Ә инде болары... Гыйльмулла бабайныкылар. Ул аларны икенче бөтендөнья сугышында Гитлер акупантларына каршы, фашизмга каршы күкрәк куеп сугышкан өчен алган. Теге бар бит әле... Кәтүшә-кәтүшә... Тоф... тюф... тыф... Хәзер. (*Урындыкны идәнгә, тамашачыга каратып яткыра да үзе сузылып урындык артына ята.*) Абзый, абзыкай, читкәрәк кит, скулькасы тимәсен. (*Сикереп тора да Шульдериның иңсәсеннән сәхнә читенә эткәли-төрткәли.*) Кит, абзый кеше. Бетәсең бит, бетәсең бит. Кеше булдым дигәндә генә, харап булуың бар. Атаңа нәрсә дип җавап бирермен.

Ш у л ь д е р и (*халыкка карап*). Бала акылы чыкмаган... Әллә диванарак та инде. (*Бәйрәмгалигә.*) Кәтүшә түгелдер инде, энем, Катюшадыр.

Б ә й р ә м г а л и. Шул инде, шул. (*Җырлап җибәрә.*)

Вихадилә нәбири Кәтүшә,
Пәплени тумане под рекой.
Вихадилә нәбири Кәтүшә,
Пәплени тумане под рекой.

Ә менә бу дүрт орден безнең предсидәтелебез иптәш Карабаш Шалканбашевич Өрекбашевныкылар. Ул аларны үзен жәлләмичә көне-төне колхозын үстергәне, аякка бастырганы өчен алган.

Ш у л ь д е р и. Ә менә монысы?

Б ә й р ә м г а л и (*шатланып*). Ә, монысы — Сәгыйдә әбинеке. Күп бала тапкан өчен алган. Мать-геройня!

Ш у л ь д е р и. Мин синең өчен кайгыра башладым әле, энекәш.

Б ә й р ә м г а л и. Нигә?

Ш у л ь д е р и. Сине теге йортка — җүләрләр йортына япмасалар ярый. Бу тимерләреңне күрсәләр, синең эшләр харап.

Б ә й р ә м г а л и. Ә ни булган?!

Ш у л ь д е р и. Үзеңә 30–35 яшь. Күкрәгеңдә бишенче елгы тәре. Боларны син алганга дивана да ышанмаячак бит!

Б ә й р ә м г а л и. Син үзең дивана! Нигә ышанмасыннар?!

Әмирикәнистләр үз гомерләрендә сугыш күргән халык түгел, энем, эшләп алдым, дип әйтерсең, диде авылыбызның рәисе Карабаш Шалканбашевич.

Шульдери. Син... ни... Болай булмый бит, энекәш. Оят бит. Кара ул кыяфәтеңә. Син үзеңә аерым бүлмә сорар идең, ә?!

Бәйрәмгали *(халыкка)*. Минем орден-медальләрдән көнләште. Тот кишеремне! *(Шульдеригә.)* Юк инде, абзый кеше, рәхмәт. Бу бүлмә миңа да бик ошый. Баш бухгалтер авыл капкасыннан чыкканчы тукып барды: «Аерым гына бүлмәгә урнашма, бер койкалы бүлмә кыйммәт була, отчеттан үткәреп булмый»,— диде.

Шульдери. Соң, юньлерәк, заманчарак киенеп килергә булмый идемени соң?! Менә син миңа кара, кай җирем американистлардан ким?!

Бәйрәмгали. Шулайрак шул, Карабаш Шалканбашевич сүзенә карап харап булдым. Генераллар кебек бар, энем, генераллар кебек, кием бизи кешене, кием, касманавт дип уйласыннар, диде бит.

Шульдери. Ярый, кигәнсең дә ди инде, черт с тобой! Кигәч-кигәч, үз размерыңны кияргә иде инде. Соң, энем, үз размерың юк идемени соң?!

Бәйрәмгали. Мин укып бетергән СПТУда тәртип шундый: кем яхшы укый — шуңа ике размерга зурракны, кем начар укый — аңа ике размерга кечкенә форма бирәләр. Чтобы ты каз боты, әйбәт укучы, начар укучыдан аерылып торсын. Бәтәч! *(Костюмына карап.)* Башкортлар әйтмешли, кыек каптырганмын. Менә монда кәчтүнемнең бер төймәсе төшкән иде, бер дә аптырап тормадым, хатынның лифтчигыннан алдым да тагып куйдым. Монда килгәндә, бөтен кешенең күзе гел миндә булды. Брушка дип уйладылар, ахрысы.

Шульдери *(халыкка)*. Җитми егеткә... Бик аздан калган. Аллаһы Тәгалә бер-ике шарикны кызганган бу баладан. *(Бәйрәмгалигә.)* Менә, энем, җәннәт кая ул. Америка!.. Цивилизация!

Бәйрәмгали. Әйтмә инде, абзыкай. Генераллар кебек яшибез.

Шульдери *(җырлый)*.

Җәннәт, диләр, җәннәт, диләр,
Җәннәт күрми үләләр.
Теге дөнья җәннәт, диеп,
Диваналар китәләр.

Бәйрәмгали *(җырлый)*.

Син акыллы, мин акыллы,
Икебезгә икәү без.
Бу якларга килер өчен,
Сайланганнар икәү без.

Шульдери } *(икесе бергә).*
Бәйрәмгали }

Сынатмадык илдә дә без,
Сынатмабыз монда да.
Сынатырдай егетләрне
Җибәрмиләр бу якка!

Шульдери. Энем, өйләнденңме соң, җәмәгатең бармы?

Бәйрәмгали. Хатынмы? Бар. Бер убырлы карчык. Безнең яратыша башлау да кызык кына килеп чыкты бит, абзый кеше.

Шульдери. Кит аннан?!

Бәйрәмгали. Минем хатын яшь вакыттан ук зерә дә шустрый нәмәстә иде.

Шульдери. Шулаймы?

Бәйрәмгали. Соң, бервакыт шулай ындыр капкасы янында кулыма көрәк алып сыер тизәкләре җыештырып йөри идем, минем булачак кәләшем Мәфтуха килеп чыкты. Карыйм, ул су буена бәрәңге юарга төшеп бара. Минем яннан үтеп барганда, чабатасының үкчәсе белән шалт минем артка менеп төшмәсенме?! Мин, тизәкле көрәк белән урам әйләндереп, гөрс тегенең сыртына! Мәфтухам көлә-көлә китеп барды. Ул көлгәч, мин дә көлдем инде. Ха-ха-ха... Кызык бит.

Шульдери. Бик кызык шаяру. Искитмәле. *(Халыкка карап.)* Дурдом!

Бәйрәмгали. Беркөнне Мәфтуханың атасын, Хисмәтулла абзыйны ашка чакырырга дип кергән идем дә, Мәфтухам килеп чыкты. Кулында олы чиләк белән кер юган су. Мин тоттым да аның беләген чеметтем.

Шульдери. Ә ул аптырап тормады, шалт теге суны синең өскә!

Бәйрәмгали. Юк! Башка каплады. Ха-ха-ха!.. Кызык бит, ә?!

Шульдери. Искитмәле. Бигрәк кызык. Диваналарча.

Бәйрәмгали. Юешләттең бит, марҗа, мин әйтәм. «Авырттырдың бит, карт урыс»,— ди бу миңа. Беркөнне матур гына хикмәтле төш күргән идем. Шуны сөйләргә дип, аларга таба киттем. Мәфтуха лапасларында утын алып маташа. Мин якягыма карандым да выжт лапаска. Башка утын пүләне белән генә бирмәсә ярар иде, гүзәлем, мин әйтәм. «Әллә мине сихерләдең инде,— ди бу миңа.— Синең белән төне буе саташып чыктым»,— ди. Шуннан соң без мунчага киттек, утын күтәреп. Каршыбызга апасы килеп чыкмасынмы: «Нишләп йөрисең печтергән кәҗә тәкәсе кебек»,— ди. Әй көлешәләр, абзый, тәгәритәгәри көлешәләр.

Ш у л ь д е р и. Шуннан-шуннан?

Б ә й р ә м г а л и. Шуннан шул — алар көлгәч, мин дә көлдем инде. Кызык бит. Шуннан Мәфтуха әйтә: «Көпә-көндез кызлар янына йөрмиләр аны, төнлә килерсең»,— ди. Соң кем белгән инде аны төнлә кызлар янына барасын. Ха-ха!

Ш у л ь д е р и. Бардыңмы соң?

Б ә й р ә м г а л и. Бардым инде үзе чакыргач. Лапаска!

Ш у л ь д е р и. Лапаска?! Чыктымы соң?

Б ә й р ә м г а л и. Чыкты.

Ш у л ь д е р и. Үбештегезме соң?

Б ә й р ә м г а л и. Юк, чыгуы булды... чыгуы булды...

Ш у л ь д е р и *(уч төпләрен уа-уа)*. Йә, шуннан, шуннан?..

Б ә й р ә м г а л и. Чыгуы булды...

Ш у л ь д е р и. Йә, йә?!

Б ә й р ә м г а л и. Җилкәгә менеп атлануы булды.

Ш у л ь д е р и. Әй, пешмәгән.

Б ә й р ә м г а л и. Әле хәзер дә төшереп булмый каһәр суккан хатынны. Менә көчәй-көчәй кәртечкәсен куен кесәмә тыгып җибәрде. *(Шульдеригә карточканы суза.)*

Ш у л ь д е р и. Да... моны җилкәдә йөртсәң дә ярый. Курчак! Хатыныңны бал кашыгына сал да йот! Менә мин ул гомер буе убырлы карчык белән яшим.

Б ә й р ә м г а л и. Сөйләмә инде, абзый кеше. Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә, ди.

Ш у л ь д е р и. Минеке түгел инде. Минекеннән не молока, не шерсть!

Б ә й р ә м г а л и. Шулай инде. Син минекен чишендереп карасаң иде. Куркуыңнан йөз чакрымга качарсың. Аның гәүдәсен күз алдына китерәсең килсә, болайрак: шырпы кабына ике бөртек шырпыдан ике аяк, ике кул, баш урынына борчак төртеп куйсаң, нәкъ аның фигурасы.

Ш у л ь д е р и. Син хатын-кызда ни аңлыйсың соң?! Ябыклар алар темпераментный булалар. Ә менә минеке... Су эчеп күбенгән йомранга охшаган. Аяклар нечкә, корсак чыккан, муен юк, күкрәк турында сөйлисе дә юк. Нәкъ егерме беренче елгы хәерченең аркасына аскан капчык төсле асылынып төшкән.

Б ә й р ә м г а л и. Күкрәккә килгәндә минеке дә инде... Үтүкләп куйганнармыни! Ярый әле сыер булып тумаган. Ул имчәкләре аркасында үзен әллә кайчан мясокомбинатка озаткан булырлар иде.

Ш у л ь д е р и. Ашарга да пешерә белми бит.

Б ә й р ә м г а л и. Сөйлисе юк инде, бәрәңге дә токмач, токмач та бәрәңге... лыгыр-лыгыр! Ашасаң, аша, ашамасаң, тыгыл!

Ш у л ь д е р и. Ә минеке соң, минем маржушка?!

Б э й р э м г а л и. Маржалар әле алар тозларга хирыс булалар. Кыярын, гөмбәсен, кәбестәсен тозлап җибәрәләр, телеңне йотарсың.

Ш у л ь д е р и. Син, слушай, космонавт, нервада уйнап утырма. Сөйләшсәң, адәм рәтле сөйләш. Син монда минем хатынны мактарга килдеңме, әллә Америка карарргамы?! Әнә, ошаса, кайт та шул маржа белән яшәп кара. Бер айда үзеңнән скелет ясаячак ул. Кер бавына элеп киптерә ул сине. Менә кара! *(Күлмәген күтәреп, халыкка кабыргаларын күрсәтә.)* Миңа хәзер рентген та кирәкми. Ике тәрәзә арасына бастырсаң, бөтен эчке әгъзаларым күренә.

Б э й р э м г а л и. Да, абзый кеше, синең эшләр тугы икән шул. Сине шул паровой топления батареясе урынына стенага гына элеп куясы бар.

Ш у л ь д е р и. Әйтмә инде. Кәҗә пылавы ашатып тәмам җелегемә төште. Витамин кирәк ирләргә, витамин, дигән була. Кирәк, ананңны...

Б э й р э м г а л и. Сабыр, сабыр, абзый кеше. Акыллы бул.

Ш у л ь д е р и. Витамин белән генә ерак китәрсең — бар! Ир-атка аңа ит кирәк, мясо! Һәм хушбуй исе аңкып торган, ирне иркәли белә торган хатын кирәк.

Б э й р э м г а л и. Ә безнекеләр?! Син яткач, юк эшен бар итеп, ярты төн уздыралар. Син ятасың инде аны көтеп, тешеңне кысып, уңга-сулга боргаланып. Тфү! Гарьлегеңнән үләрсең.

Ш у л ь д е р и. Андый вакытта мин үзем дә югалып калмыйм. Килеп ятуы була, тегене иркәлим, иркәлим дә, кызгач кына аркамны куеп борылам да ятам. Төне буе уңга-сулга боргаланып чыга. Күршеләрне сүгә, машиналарны тетә, хәтта өй өстеннән очып киткән самолетка да өрә. Шулай, энекәш, булмаса булмый икән ул.

Б э й р э м г а л и. Сөйлисе юк.

Ш у л ь д е р и. Инде нинди генә журналлар укымадым да, нинди генә лекцияләр тыңламадым. Юк, хатыннан кеше ясап булмый.

Б э й р э м г а л и. Ха! Әйттең әле син, абзый. Кайчан ишәктән ат ясаганнарын күргәнең бар?

Ш у л ь д е р и. Әле монда килер алдыннан гына, күптән түгел, безгә эштә «Гаилә» дигән темага фәнни лекция укырга шундый әйбәт лектор килгән иде. Тукта, мин әйтәм, көчле лектор, диләр, җиде хатын аерган, практикасы да зурдыр, гаиләне рәткә салып булмасмы дип, кердем мин моңа. Күренеп тора, үз эшенең остасы, кандидат наук. Хәтта профессорларның башы җитми торган сорауларга да җавапсыз калмады. «Хатын-кызлар гомер буе изеләләр,— ди.— Революциягә кадәр дә изелгәннәр,

революциядән соң да изеләләр, мескеннәр,— ди.— Революциягә кадәр дә алар аста, революциядән соң да аста. Демократиягә кергәч тә аста,— ди.— Кайчан аларны өскә чыгарабыз»,— ди.

Бәйрәмгали. Сволочь! Җиде хатын белән яшәп бозылып беткән.

Шульдери. «Хатыннарыгызга комплимент сүзләр әйтәсезме?» — ди. — Күз алдыгызда сөеклегезнең чәчәк атканын күрәсегез килсә, сез аның чәчен яисә күлмәген мактагыз. Менә сез, иптәш, хатыныгызны еш мактыйсызмы? — ди бухгалтер Шамгуновка. «Кайсысын?» — дип сорап куймасынмы арткы рәтләрнең берсендә утырган шофер Федоров. «Кайсысын, кайсысын, мин аның хатыннарын санап бармаган, соңгысын, әлбәттә»,— дип ярсынды лектор. «Ә менә сез,— диде ул миңа,— соңгы вакытларда хатыныгыз белән кайчан театрга бардыгыз?»

Мин телсез калдым, лекция беткәч, мин байтак вакыт үземне — үзем хатынга әһәмият бирмәгәнем өчен сүгеп утырдым.

Бәйрәмгали. Шуннан, Чүлдери абзый?

Шульдери. Өйгә кайттым. Керсәм, ишек ачык. Хатын...

Бәйрәмгали (*шатланып*). Балалар өйдә юк.

Шульдери. Хатын мескен кер юып азаплана.

Бәйрәмгали. Ә мин керне гел үзем юам.

Шульдери. Кайтып керү белән хатынның алдына килдем дә тезләндем. (*Бәйрәмгалинең алдына килеп тезләнә.*)

Бәйрәмгали. Кит әле, чүпрәк. Мин синең хатының түгел ләбаса! Тор, ишәк!

Шульдери. «Сөеклем, мин әйтәм, мин бит сине үлеп яратам». «Тагын лыкынганчы эчтеңме», — ди хатын. Аның өчен әллә мин бар, әллә юк. Күтәрелеп тә карамады. «Шул пивнушкаңны ремонтка да япмадылар, ичмасам». «Кадерлем минем, эш пивнушкада түгел, үзем дә бүген генә аңладым, мин бит сине үлеп яратам икән ләбаса».— Хатын сагаеп кына миңа карады да, һаваны иснәштерде, бераз уйланып торганнан соң: «Акча сорап юхаланма, барыбер бирмим! — ди. «Тормышымның чәчкәсе син минем. Кирәкми акча. Мин бит сине изге күңелең өчен яратам». Хатын башта катып калды, аннан ап-ак булып ванна кырыена утырды: «Акчаңны югалттыңмы, Ходаем!» «Карлыгачым минем, син бит яхшы беләсең, акчаны безгә егермеләрендә генә бирәләр. Ә бүген уникесе генә. Әйдәле, бүген күңелле генә итеп сөйләшик әле. Аһ! Күрми дә торам икән, чәчең нинди матур бүген!» «Нахал син, башка беркем дә түгел,— диде хатын.— Чәч тарарга минем вакытым булмады». Үземнең ялгышлык җибәргәнемне аңладым, шулай да тәмле сүзләрне яудырдым гына моңа. «Таралмаган чәчеңә исең китмәсен, сиңа болай килешәрәк тә төшә, аның каравы күлмәгең си-

нең нинди затлы! «Хатынның йөзен кан басты: «Үзеңне бел! Карачкы! Пинжәгеңнең карар җире калмаган». Хатын, үкси-үкси, күлмәген алыштырырга чыгып китте. Бер генә мизгелем дә мин исәпләгәнчә килеп чыкмады. Ләкин минем тагын бер саклап тоткан сүзем бар иде. «Урман фәрештәм минем, дип, башымны аска идем, син миңа үпкәләмә. Әйдә, иң әйбәте театрга яисә консерваториягә барабыз». Хатын, үкси-үкси, чемоданга әйберләрен тутырды да әнкәсенә кайтып китте. Менә шуннан соң тыңла син фәнни лекция. Юк, энекәш, лекция түгел, хатын-кыз өлкәсендә университет бетер, аларны рәткә салып булмый. *(Елап утырган Бәйрәмгалигә.)* Нигә җылыйсың, энекәш?

Бәйрәмгали. Кызганыч бит.

Шульдери. Булыр кызганыч! Кичке якта анасын ияртеп кайтты да, миңа шәпләп кенә домашний арест, өстәвенә бер ай голодовкада тотты.

Бәйрәмгали. Балаларыгыз бармы соң?

Шульдери. Булмаган кая... Унике штук! Коеп кына тора! Пачти ел саен хәерче арттырабыз. Ә синеке?

Бәйрәмгали. Юк. Кысыр.

Шульдери. Кысыр?! Аер! Кысыр сыерны да ике генә ел асрыйлар.

Бәйрәмгали. Аерып кара, түщә әби — зверь! Синекеннән ким түгел. Иртә дә бездә, кич тә бездә, әбәттә дә бездә. Кызык иттем үзен дә. Ну, мин әйтәм, убырлы карчык, кызык итәм әле мин сине. Нишләттем дип уйлыйсың?

Шульдери. Нишләттең?

Бәйрәмгали. Тегенең тәһарәт ала торган комганына бер пачка кызыл борыч тондырдым. Шуннан бирле күренгәне юк.

Шульдери. Ха-ха-ха!..

Бәйрәмгали. Нигә көләсең? Әйе, менә хатын белән уналты ел яшибез, әбидән, түщәдән җилләр исте. Ни ответ, ни привет...

Шульдери. Сезнең халыкка рәхәт, сезнекеләр комган белән, тәһарәт белән, безгә нишләргә?

Бәйрәмгали. Нишләргә, нишләргә?! Туалеттагы кәгазь ящигына стекловата салырга.

Шульдери. Чыннан да, кайту белән эшлим!

Бәйрәмгали. Түщәңне үлгәнче күрмәячәксең.

Шульдери. Молодец, энем, бераз гына булса да акылың бар икән.

Бәйрәмгали *(бүлмә буйлап йөренә дә сәхнә уртасында аптырап кала)*. Да-а... бар әйберләрен җиренә җиткереп эшләгәннәр, итек үкчәсен эләктереп салырга тупса гына куймаганнар.

Ш у л ь д е р и. Бу синҗа әбиеннең комганы түгел шул. Американистлар итек кими.

Б ә й р ә м г а л и. Кими кая барсыннар, коеп яңгыр ява башласа. *(Итеген сәхнә алдында эләктереп сала да портянкаларын урындык башына элеп куя.)*

Ш у л ь д е р и. Нишләвең бу, энем?

Б ә й р ә м г а л и. Киптерергә элеп куйдым.

Ш у л ь д е р и. Бу бит синҗа каравыл өе түгел.

Б ә й р ә м г а л и. Ә ни булган?

Ш у л ь д е р и. Атаңның баш сөяге булган. Ул портянкаларыңны итегең эчендә калдырсаң да ярыйдыр.

Б ә й р ә м г а л и. Исең китмәсен, чиста ич алар. *(Битен сөртеп ала.)* Килер алдыннан гына колхоз складыннан алдым.

Ш у л ь д е р и. Фу, энем, энем, зинһар, аякларыңны кире итегеңә тыгып куй. Исенә исереп егылабыз бит.

Б ә й р ә м г а л и. Син нәрсә?! Бәлки, син йоклаганда да итегеңне салма диярсең. Мин бит урманда агач аударып ятмыйм. Ял итәргә, Әмрикә күрергә килдем. Бер атна буе итек салмасаң, болай да бик тиз тирли минем аяклар.

Ш у л ь д е р и. Иртәгә салырсың, энем, иртәгә. Юк, бүген үк берәр пот тоз алып кайтырмын, ул аякларыңа тоз сипмәсәң, синең эшләр харап.

Б ә й р ә м г а л и. Хитрый. Минем аяктан каклаган каз ясамакчы була. Извини, старик! Бу аяклар колхозга бик кирәк әле.

Ш у л ь д е р и. Ай Аллам, каян килеп чыктың син минем башыма?!

Б ә й р ә м г а л и. Каян дип, Татарстаннан, суверенитный государстводан, «Коммунизмга» колхозыннан. Мин бит хөкүмәт кешесе. Хөкүмәтебез кушуы буенча килдем. Карале, абзый кеше, болар кыш көне ничек яшиләр икән, итек, портянка киптерергә дә урыннары юк. *(Рюкзагыннан бау чыгарып, сәхнәнең бер ягыннан икенче ягына бау суза да портянкаларын элеп куя.)*

Ш у л ь д е р и. Кая укыдың син, энекәш? Кем укытты сине?

Б ә й р ә м г а л и. Муллагали абзый укытты. Үзе мәрхүм инде. Аракы дип, уксус эчеп үлде. Аннары СПТУ бетердем, отличнога. Минем бит кызыл диплум.

Ш у л ь д е р и. Атаң кем синең? Анаң...

Б ә й р ә м г а л и. Этем белсен. Аны мин түгел, әнкәй үзе дә белми. Вәт шулай, абзый кеше.

Ш у л ь д е р и. Нишләп мин синең абзаң булыйм ди?!

Б ә й р ә м г а л и. Абзый булмый, атам булмассың инде, безнең якта йөрмәгәнсеңдер.

Шульдери. Аллам сакласын.

Бәйрәмгали. Шулай булгач. Күреп торасың, пин пит чуаш түгел. Пин пит татар малай.

Шульдери. Син һәрвакыт начальство белән «син, абзый, абзыкай» дип сөйләшәсеңме?

Бәйрәмгали. Төрле чак була: җиде катлап та сөйләшкән чаклар була. Кәефкә карап.

Шульдери. Минем исемем, отчеством бар, энем. Мин Шульдери Михайлин.

Бәйрәмгали. Ә мин Бәйрәмгали булам. Әйткәнемчә, «Коммунизмга» колхозы, Алга авылының алдынгы трактористы-комбайнеры! *(Кулын Шульдерига суза.)*

Шульдери *(кулын бирми)*. Энем, бу портянкаларыңны яшереп куй. Йә американистлар урлар.

Бәйрәмгали. Чыннан да, носки табалмый йөргән кеше булса, ике дә уйламый ала да тыгып куя. *(Портянкаларын кире төреп, рюкзагына салып куя.)*

Шульдери. Ну, юморный да син, ә, энекәш!

Бәйрәмгали. Сөйлисе юк. Шуннан бирле, шул җуморной булганым аркасында гел үземне авылда кагып йөрттеләр дә. Участковый 3 нче класстан үземне учетка алып теңкәмне корытты. Үлгәч тә мин ул участковойның төшенә кереп азапლармын әле.

Шульдери. Шунда үзеңне ябып куйган булса, менә хәзер мин синең белән иза чикмәгән булыр идем.

Бәйрәмгали. Надан ул безнең участковый. Җумор аңламый. Элек авылда мунчалар сирәк иде бит. Безнең авылда мунча минем мәрхүм бабайда гына иде. Бөтен авыл кешесе шунда мунча керә иде. Шулай бервакыт безнең мунчага Акай күз Әхмәдиләр мунча яктылар. Тегеләр мунчасының өлгергәнен генә көтеп алдым да мунча ләүкәсендәге тасны җепкә бәйләдем. Җепнең икенче башын төнлектән чыгардым. Берзаман Акай күз Әхмәт, култык астына себеркесен, икенче ягына хатынын култыклаган да урам буйлап, парлашып, пар күгәрченнәрдәй гөрләшә-гөрләшә мунчага килделәр дә, мунча алачыгына үттеләр. Анадан тума, шәп-шәрә чишенеп мунчага керделәр. Ә мин шул вакыт җепне тартуым булды, ләүкәдән тасның сикерүе булды. Ай, диде Акай күз Әхми, һай, диде хатыны... тагын бер җепне тарткан идем, җен бар монда, дип кычкырдылар да шәп-шәрә килеш урамга чыгып йөгерделәр. Алар урам буйлап шәп-шәрә чабалар, алар артыннан урам тутырып этләр өрә-өрә чаба. Вәт, мин әйтәм, җүләр, вәт, мин әйтәм, кәмит. Шушы җуморымнан соң участковый үземне учетка алды. Надан, җумор аңламый, тинтәк!

Ш у л ь д е р и. Малай чакта андый гына шуклыклар була инде ул, энекәш. Мин үзем дә мунча мастеры идем. Естәгнәй картны тоже тәмләп мунча керткән малай мин. Кыяр урлаган өчен арт саныма кычыткан белән менеп төшкән иде. Әткәйләрнең Естәгнәй картны мунчага чакырганнарын көтеп кенә йөрдем дә, ул килер алдыннан мунча себеркесенә йодрык кадәрле шөрепләр бәйләп куйдым. Себеркене кайнар суга батырдым. Бераздан бабай килеп җитмәсенме?! Чишенеп мунча эченә килеп керде дә ләүкәгә менеп кунаклады. Кулына себеркесен алды. Ә мин шул вакыт ишекне келәгә эләктереп куйдым. Янәсе, эссе салгач, ачылып китмәсен. Улым, Шульдери, Естәгнәй бабаңа сәламәтлек теләп, эссе җибәр әле, диюе булды, минем алагаем тулы чүмечтәге кайнар суны ташка китереп ямавым булды, ул селтәнеп торып, себеркесе белән кизәнеп, сыртына китереп салуы булды, ләүкәдән очып төшүе булды. Ул башта тәрәзәдән чыкмакчы иде. Тәрәзәгә сыймагач, ишеккә атылды, ишек келәсе шартлап өзелде, Естәгнәй карт урамга чыгып атылды. Мунчаны шәп-шәрә килеш өч тапкыр әйләнде дә бакча артыннан гына өенә сызды. Култык астына ишекне дә кыстырган иде.

Б ә й р ә м г а л и *(шаркылдап көлеп)*. Ха-ха-ха!..

Ш у л ь д е р и. Ышанмыйсың?! Мунча ишеген бер атнадан соң, Естәгнәй карт үлгәч, эти белән барып алдык.

Б ә й р ә м г а л и. Ха-ха-ха!.. Вәт ичмасам җумор! Вәт эта интересно! Үзе үлгәч, диген, ә? Ә безнең участковый җуморны аңламый. Патамушто надан!

Ш у л ь д е р и. Ярый, энем, мин Нью-Йорк урамнарын карап керим әле.

Б ә й р ә м г а л и. Авыздан тартып алдың. Мин дә синең белән.

Ш у л ь д е р и *(халыкка, пышылдап)*. Аллам сакласын, син дивана белән! *(Бәйрәмгалигә.)* Ә, юк-юк, энем, мин, ни...теге... Соңрак чыгарбыз. Минем капкаларга берәр ризык кына алып керергә иде исәп. Аннары шунысы да бар бит әле аның, энекәш. Бу сиңа безнең ил түгел, Америка! Шпионнар оясы. Менә мин үзем өченче ел Мәскәүгә генә бардым. Күрмәгәнемне күрсәтеп кайтардылар.

Б ә й р ә м г а л и. Зинһар, абзый, Мәскәү турында исемә төшермә. Үземне бизгәк тота башлый. Син син әле ул, урычча беләсең. Ә минем белән узган ел Мәскәү астына санаториягә барганда ни булды. Минем бәхеткә каршы, пуезд Мәскәүгә туктады. Озак кына, 3—4 сәгать тора, диделәр. Ә мин, тинтәк, Мәскәү карамакчы булдым. Кирәк бит, ә? Чыгып киттем шәһәргә. Һәр кешенең хыялы була бит. Кемдер машина алырга,

кемдер гитарада уйнарга, кемнеңдер хыялы начальник булырга, ә минем хыял — метрода кататься итәргә.

Шульдери *(көлә)*. Ха-ха-ха!..

Бәйрәмгали. Син көләсең, сиңа кызык. Син дивана! Безнең авылда метро юк. Метро түгел, трамвай-троллейбуска да утырып караганым юк минем. Ә менә минем дустым Әһлетдин, ышанасызмы-юкмы, ике мәртәбә метрода булган. Шаккатмалы итеп сөйли. Бөтен җирдә мрамор, хрустальный люстралар, бинаның өстендә матур итеп «М» хәрефе янып тора, ди. Мин дә киттем «М» хәрефен эзләп. Озак та бармадым, «М» хәрефен күреп алдым. Эченә керсәм, нәкъ әкияттәге кебек ул «М» эчендә. Кая карама көзге, кафель, чип-чиста сөлгеләр эленеп тора. Шунысы гаҗәп, пассажирлар гел ирләр.

Шульдери. Да, кирәк бит, ә?

Бәйрәмгали. Әйе, бер генә хатын-кыз да юк. Мин бер кабинага кереп утырдым да ишеген бикләп куйдым. Утырам поезд көтеп. Ярты сәгать көттем, бер сәгать, поезд юк. Ә пассажирлар фөлләмиләр*. Кайсы кырына, кайсы юына, кайсы ислемай сибенә. Шул вакыт ишегемне дөбердәтә башладылар. Гражданин , чык! Монда чират! Ишегемне ачтым да: «Чего? Куда, мин әйтәм, чыгарга?! Мин бит поезд көтәм. Әгәр теләсәң, минем янга утыр, бергә будем көтәргә». Алар аңлыймыни кеше хәлен?

Шульдери. Әй, бичара. *(Халыкка.)* Тинтәк! Дурдом!

Бәйрәмгали. Сүз артыннан сүз китте, кычкырышып-сугышып кемнеңдер күлмәген ерттым.

Шульдери. Шуннан!

Бәйрәмгали. Урамга чыгарып ыргыттылар.

Шульдери. Тәки поездга утыртмадылармы?

Бәйрәмгали. Кая утырту, үз поездыма да өлгермәдем. Санаториягә дә барып торасым булмады. Туп-туры психушкага озаттылар.

Шульдери. Ә мин «Москва» гостиницасыннан урамга чыктым һава суларга. Карыйм, каршыма джинсадан бер чибәр егет килә. Күренеп тора «фирменный» американист. Мин аңа итагатьле генә итеп сүз куштым: «Дустым, мин сиңа ике йөзне бирәм, джинсаңны сатмассыңмы», — дим.

Бәйрәмгали. Интересно, әмирикәнский, диген!

Шульдери. Урамда салып бирмәм бит инде, өйгә ничек кайтырмын, ди. Мин сиңа үземнекен бирәм, дим. Сөйләштек, аңлаштык, киттек подъездга чалбар алыштырырга.

Бәйрәмгали. Әмирикәнский джинсаны?

---

* *Фөлләмиләр* — уйламыйлар мәгънәсендә.

Ш у л ь д е р и. Мин аңа ике йөз меңне бирдем, чалбарны салып тоттырдым, ул бөтенесен алды да, лифтка кереп, югарыга менеп качты.

Б ә й р ә м г а л и. Чукынды маржа калачка! Имәндә икән чиклəвек! Шуннан, шуннан...

Ш у л ь д е р и. Ә мин аның артыннан баскыч буйлап тәпи-тәпи өскә, алтмыш сигезле трусикларымны җилфердәтә-җилфердәтә. Мин өскә менеп җиттем, ул аска төшеп китте.

Б ә й р ә м г а л и. Син аска, ә ул өскә...

Ш у л ь д е р и. Юк шул, ул арада аннан җилләр искән инде.

Б ә й р ә м г а л и. Аферист! Каһәр суккыры! Кабахәт!

Ш у л ь д е р и. Бу килеш урамга чыгып булмый бит иде.

Б ә й р ә м г а л и. Шул бер квартирага кереп ярдәм сорасаң гына инде.

Ш у л ь д е р и. Шулай эшләдем дә. Бер ишеккә шалтыраттым, хатын-кыз килеп чыкты.

Б ә й р ә м г а л и. Шуннан, шуннан, хатын-кыз, диген, ә?

Ш у л ь д е р и. Мин әйтәм, кадерлем, синең ирең бармы? Ул әйтә, бар, ә нәрсә? Ул хәзер өйдәме, дим. Юк, эштә, ә нәрсә булды, ди. Мин әйтәм, бәхетсезлек булды. Аның беләнме, ди хатын. Минем белән. Мине сезнең подъездыгызда таладылар, дим. Ул әйтә, нинди ярдәм күрсәтим? Мин әйтәм, кадерлем, чалбар биреп тор. Мин аны иртәгә үк китерермен, дим. Ул әйтә, миңа чалбар жәл түгел, ләкин сиңа ул ярамас. Шул вакыт ире кайтып керде.

Б ә й р ә м г а л и *(шатлыгыннан кулларын чәбәкләп)*. Кирәк бит, ә?!

Ш у л ь д е р и. Аның чалбарының миңа ярамаслыгын шунда ук аңладым.

Б ә й р ә м г а л и. Кызганыч.

Ш у л ь д е р и. Кызганыч... аның бер йодрыгы минем баш кадәрле. Ул башта хатынына, аннары минем кыяфәткә карап торды да, алай, бик күңелле булып китте, ди ире. Мин әйтәм, миңа да бик күңелле булып китте, әйдә, танышыйк. Ул әйтә, дәшмә, юкса бәреп үтерәм, ди. Ни өчен, дим. Мине ыштансыз каршы алганың өчен, ди бу. Кем сине каршылый, дим.

Б ә й р ә м г а л и. Да, кем сине каршылый, грубиян!

Ш у л ь д е р и. Без хатының белән сине бөтенләй көтмәдек.

Б ә й р ә м г а л и. Да!

Ш у л ь д е р и. Ул сине эштә, диде. Хатыны әйтә, Коля, тыңлама, хәзер барысын да аңлатам, ди. Ул кычкыра башлады, ишетәсем дә килми, әйберләреңне җый да ычкын моннан! Мин әйтәм, кадерлем, әйберләреңне җыйганда, миңа да бер-ике чалбар алырга онытма, дим. Ул әйтә, сиңа хатын гына җитми, әле

чалбар да кирәкмени, ди ачуланып. Билгеле, кирәк, мин бит бу килеш урамга чыга алмыйм, дим.

Б ә й р ә м г а л и *(ярсып)*. Да!

Ш у л ь д е р и. Син чыкмассың, сине алып чыгарлар!

Б ә й р ә м г а л и. Нәрсә белән? Ничек?

Ш у л ь д е р и. Аягыңнан өстерәп! Менә сиңа, бандит, ди. Каһәр суккан, шул вакыт йодрыгы белән китереп торып мордама берне тартмасынмы?!

Б ә й р ә м г а л и. Каравыл! Үтерәләр! Көпә-көндез кеше үтерәләр!

Ш у л ь д е р и. Нигә акырасың, дивана!

Б ә й р ә м г а л и *(үксеп елап җибәрә)*. Соң, кыйныйлар бит. Чалбар сораган өчен шулай сугарга ярыймы?

Ш у л ь д е р и. Шуннан нәрсә булганын тыңла.

Б ә й р ә м г а л и. Тыңлыйм, тыңлыйм, кая, йөзеңә юеш чүпрәк кенә куйыйк та...

Ш у л ь д е р и. Нигә?

Б ә й р ә м г а л и. Шешмәсен өчен.

Ш у л ь д е р и. Тинтәк! Шуннан очып чыктым урамга, Аллага шөкер, исән-сау. Торам такси көтеп. Астан җил өрә.

Б ә й р ә м г а л и. Алтмыш сигезле трусик балагыннан.

Ш у л ь д е р и. Тышта минус алты.

Б ә й р ә м г а л и. Кесәдә минус ике йөз мең.

Ш у л ь д е р и. Такси тоттым. Кадерлем, мин әйтәм, зинһар, гостиницага илтеп куй. Ул әйтә, сине илтмим мин, исерек, ди. Кем, нәрсә? Ничек исерек, дим. Соңгы ыштаныңны сатып эчкәнсең, ди бу миңа. Мин эчмәдем, мине таладылар, дим. Ул әйтә, алайса, бигрәк тә синең акчаң юк, ди. Акча бар, чалбар юк. Зинһар, коткар, дим ялварып. Егерме биш мең бирсәң, коткарам, ди. Синдә намус бармы, монда ике генә адым, дим ачуланып. Дөрес, һәрбер адым ун мең, ди бу миңа каршы. Тагын биш мең ни өчен, дим кызыксынып. Туктаган өчен, ди бу.

Б ә й р ә м г а л и. Имансыз, взяточник!

Ш у л ь д е р и. Кеше талаучы!

Б ә й р ә м г а л и. Канечкеч, вәхши! Хәшәрәт!

Ш у л ь д е р и. Риза булды. Гостиницага килеп җиттек. Ничек гостиницага керергә икәнен белмим. Күрәм, автобустан делегация чыга. Бөтенесе каралар, үзләре ап-ак ыштаннан. Мин дә аларның койрыгына бастым. Швейцар тотты, кабахәт! Кая барасың кара трусигың белән, ди. Нәрсә, мин әйтәм, кара трусиктан ярамый, ак ыштаннан ярыймы, дим. Аларга ярый, алар интуристлар, ди бу.

Б ә й р ә м г а л и *(чалбар төймәсен ычкындырып, эчтәге киемен карый)*. Ярый әле, әнкәйнең башы эшләгән, ретусын

кидереп җибәргән. Әниләр сиземле була шул ул. Андый-мондый хәлдә калсаң, Алла сакласын. Шуннан?

Ш у л ь д е р и. Шуннан шул, каһәр суккан швейцарга, вышебалга егерме мең биреп, көч-хәл белән интурист булып бүлмәмә кердем.

Б ә й р ә м г а л и. Күпне күргәнсең икән шул, абзый кеше. Капкаларга, дигән идең бугай. Чыгып, буталып урамда йөрмик, Алла сакласын. Мин запассыз йөрмим. Минем ризык һәрвакыт үзем белән. Басуга киткәндә дә хатын әбизәтелне бер егерме биш, утыз йомырка, берәр буханка икмәк, өч литр сөтне дыңгычлап сумкага тутырып, трактор кабинасына куя. Хәзер мин сине сыйлыйм.

Ш у л ь д е р и. Егерме биш, утызлап, дисеңме, энекәш?

Б ә й р ә м г а л и. Егерме биш тавык коеп тора, ә мин җилгәреп торам. Житешмиләр мескен, бичара тавыклар.

Ш у л ь д е р и. Әтәчегезне кызганам.

Б ә й р ә м г а л и. Әтәч үземә охшаган, күршеләрне дә читкә куймый. *(Рюкзагын ала да актара башлый.)* Бу каһәр төшкән рюкзакның бер җирендә ниндидер төере бар. Шул, юл буена аркама кадап, бөкремне чыгара язды. *(Шашып көлә башлый.)* Ну бу әнкәйне, ну бу әнкәйне, сыерыбызның тышавын алырга оныткан. *(Тышауны болгап читкә ыргыта.)* Ярый, кайткач, яңасын ясармын әле.

Ш у л ь д е р и. Нишләвең бу, энекәш? Оятлы итмә, зинһар, кире капчыгыңа тыгып куй.

Б ә й р ә м г а л и. Син нәрсә, абзый кеше. Нишләп мин тизәккә каткан тышау күтәреп йөрим ди! Ятсын шунда, кирәк кеше алыр.

Ш у л ь д е р и. Монда алай эшләргә ярамый, энем. Ни генә әйтсәң дә, без илебез горурлыгынакларга килгән кешеләр.

Б ә й р ә м г а л и. Менә кызык. Мин аны кая куйыйм. Колхоз склатында аркан бетмәгән. Кайткач, яңасын ясармын әле.

Ш у л ь д е р и. Теләсә кая куй! Телисең икән, муеныңа галстук итеп так! Минем эшем юк. Тик монда гына калдырма.

Б ә й р ә м г а л и. Моны элмә, тегене атма, син бигрәк! Беләсең килсә, без икебез дә тигез кешеләр. Әллә кем булып утырма, абзый кеше. *(Тышауны болгап, кулиса артына ыргыта.)* Ха-ха-ха!.. Тәрәзәдән ыргыткан идем, бер квартираның форточкасына эленеп калды. Ха-ха-ха!.. Вәт сезгә, Әмрикә дуслар, Рәсәйдән бүләк! Ха-ха-ха!.. Твикс-секс-микс! Ха-ха-ха!..

Музыка.

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Музыка астында пәрдә ачыла. Б ә й р ә м г а л и өстәлгә йомыркаларын тезә. Ш у л ь д е р и шаккатып карап тора.

Ш у л ь д е р и. Җитәр, энем, җитәр! Ул кадәр йомыркаларны кем ашасын?!

Б ә й р ә м г а л и. Юрында әле бу, мин аны кырыкка кадәр ашаганым бар.

Ш у л ь д е р и *(халыкка)*. Сасы көзән! Син ашарсың ул, йөзне дә. Синең белән бер бүлмәдә йоклыйсы да бар бит әле.

Б ә й р ә м г а л и *(авызын чәпелдәтеп, бик тәмләп кенә ит кимерә башлый)*. М-м-м... Шәп! Бигрәк тәмле.

Ш у л ь д е р и. Энем, син американистлар янында да шушылай авызыңны чәпелдәтеп ашарсыңмы? Культураң кая?

Б ә й р ә м г а л и. Авылда, бакча артында сине көтеп калды.

Ш у л ь д е р и. Чәнечкең, пычагың кая?

Б ә й р ә м г а л и. Авыл кешесенең чәнечкеләп торырга вакыты юк. Ә пычакка килгәндә, минем тавык суясым юк. Ул менә минем алда, суелган. Ашыйсы гына калган.

Ш у л ь д е р и. Ә салфетка?

Б ә й р ә м г а л и. Анысын табарбыз. *(Портянкасын алып, кулларын сөртә башлый.)*

Ш у л ь д е р и. Энем, җаным...

Б ә й р ә м г а л и. Пардон! Мирси, абзый! Хинди хох! Кинода күргәнем бар. Ауфизерзиен. *(Портянкасын муенына кыстыра.)*

Ш у л ь д е р и *(халыкка)*. Рәхәттер бу! *(Бәйрәмгалигә.)* Энем, эшләр болай бармый. Сабыр ит. *(Чемоданыннан пычак, чәнечке, китап чыгара да Бәйрәмгали янына килеп баса, китапны укый-укый.)* Сул кулыңа чәнечке тот әле. Әйтер идем инде китап язучыларын да, кәгазь әрәм итеп утыралар. Шушында адәм рәтле итеп, аңлаешлы итеп сурәт төшерсәләр, булмагандыр. Буталып беттем. Ә, юк, юк, уң кулыңа тот сәнәгеңне, то есть, вилкәңне. *(Бәйрәмгали кулына чәнечке ала.)* Энем, алай тотмыйлар. Китапта язылганча тот. Соң бит син кулыңа чәнечке түгел, ә сәнәк как будто тоткансың.

Б ә й р ә м г а л и. Как бутто, как бутто, то сәнәк, то вилкә, яхшылап аңлат.

Ш у л ь д е р и. Син бит ризык янында утырасың лабаса.

Б ә й р ә м г а л и. Юк, ризык минем янда утыра. Беләсең килсә, мин үстердем аны.

Ш у л ь д е р и. Энем, син бит силос базында, йә булмаса, тиреслектә казынмыйсыңдыр...

Б э й р э м г а л и (*чэнечкене өстэлгэ ыргыта*). Булмый миннэн! Булмый! Инде күпме азаплыйсың!

Ш у л ь д е р и. Соң, Алла бэндэсе. Америка ул культура ягыннан алга киткэн ил! Бездэге кебек авызыңны чэпелдэтеп, ботка ашаган ата дуңгызны хэтерлэтеп утырмассың бит инде.

Б э й р э м г а л и. Абзый, азаплама мине. Тракторны төн чыкканчы өч тапкыр сүтеп-җыярга ризамын, ну, бу эшне булдыра алмыйм.

Ш у л ь д е р и. Нинди эш?! Ашау эш була димени?!

Б э й р э м г а л и. Эшнең дэ нинди эле бу! Бөкрелэрем чыгып бетте, муен сөяклэремне көзэн җыера башлады.

Ш у л ь д е р и. Эhэ, төшендем. Левый рука — нож, правый рука — вилкэ. Болай була икэн бу, энем. Так... Левый кул кайсы кул була эле ул безнең?..

Б э й р э м г а л и. Надан! (*Чүгэлэп утырып.*) Кэгазь тота торган кул.

Ш у л ь д е р и. Так-так, по-моему, правы белэн язабыз... язган кул уң кул булгач, болайрак була бу, энем. Сул кулыңа пычак ал эле. (*Бэйрэмгали кулына пычак ала.*)

Б э й р э м г а л и. Абзый, авызга да кашык кабыйммы?

Ш у л ь д е р и. Энем, пычагыңны җайлабрак тот инде, дуңгыз суярга чыкмагансыңдыр бит. Ай, энем, соң кара инде ул кыяфэтеңэ, уң кулыңа кара, боз ватарга лом тоткан кешегэ охшагансың лабаса!

Б э й р э м г а л и. Чүлдери абзый, ныклабрак кара эле китабыңа, нуж түгел, икмэктер ул.

Ш у л ь д е р и. Менэ бит, энем, акка кара белэн язылган. Правый рука — вилкэ, левый рука — хлеб түгел, э нож диелгэн. Эй, энем, монда баш бетмэле. Менэ тыңла эле: лезвие ножа должна лежать параллельно с локотью руки.

Б э й р э м г а л и. Нэрсэ, эмирикэнистлэр ризыкны кырып ашыйлар микэнни?

Ш у л ь д е р и. Этем белсен. Минем ресторанда чэнечке, пычак тоткан кешене күргэнем бар, э менэ лезвия нэрсэ өчен икэн, анысына баш җитми.

Б э й р э м г а л и. Нэрсэ, эмирикэнистлэр итне чи килеш ашыйлар микэнни? Хараплар гына буласым бар икэн. Болай да ашказаным чамалы. Төне буе бэдрэф юлын таптыйм икэн.

Ш у л ь д е р и. Нэрсэ сөйлисең син, энекэш? Нинди чи ит ашасыннар ди алар. Алар бит мэче яисэ эт түгел. Безнең кебек кешелэр.

Б э й р э м г а л и. Э пычак ни өчен соң, алайса?

Ш у л ь д е р и. Ит кисэр өчен.

Бәйрәмгали. Нәрсә, алар минем алдыма тере сыер китереп салалармыни? Итне бит аны, өстәлгә турап, бәрәңге белән бирәләр. Минем сыер түгел, тавык та суйганым юк. Кызганам мин аларны.

Шульдери. Юк, буталып беттем. Моны язган кеше исерек булгандыр. Вилкә, нож, лезвия! Юк, юк, бу парикмахер эше белән бутап язган булырга тиеш. Моны язган кеше, мөгаен, чәчтараш, үзе парикмахердыр. Киредән башлыйбыз.

Бәйрәмгали (*халыкка*). Үҗәт! Рюкзактагы самогонны күреп калды, ахрысы. Эчмичә тынгы бирмәячәк бу миңа, карт тәре, мөртәт! (*Шульдерига рюкзагыннан самогонны чыгарып, шап иттереп өстәлгә куя да халыкка.*) Мә, эч! Бирәнең тыгылсын! Тончыкмассыңмы?!

Шульдери. Шулай дисеңме, энекәш. Америкага килүне юыйк, дисеңме? Ярый алайса. (*Стаканнарга самогон сала. Үз стаканын кулына ала да бер сулышта эчеп куя. Озак кына бер ноктага карап торганнан соң.*) Ох!

Бәйрәмгали (*куркуыннан читкә сикерә. Халыкка карап, алгы планнан*). Нишли ул?! Әллә ычкынды инде?

Шульдери. Шәп ясагансыз, энекәш. Бераз слабыйрак кына.

Бәйрәмгали. Слабый?.. Син нәрсә, тинтәк! Нинди слабый булсын. Чирек стакан эчеп, күзең атылып чыга язды лабаса! Акырмаган булсаң, астыңа җибәрә идең бит.

Шульдери. Юк, слабыйрак, слабыйрак, энекәш.

Бәйрәмгали. Бумы слабый?! Бу, беләсең килсә, настоящий көмешкә! Иң кимендә 70 градус. Мә, күрмәсәң, күр! (*Авызына каба да шырпы сызып өреп җибәрә, ут көлтәсе күтәрелә, Шульдери тамаша залына сикерә.*) Күрдеңме?!

Шульдери. Күрдем.

Бәйрәмгали. Мен монда, арт саныңа сибеп, ут төртәм. Әмирикәдән Чувашияңә космик корабль тизлегендә кайтканыңны сизми дә калырсың.

Шульдери. Кирәкми, энекәш, ашыкма, энекәш. Американы күрик инде. Ышанам. Тик барыбер точно рецебына туры китереп ясый алмагансың, энекәш, рәнҗемә. Тавык тизәге кушарга оныткансың, ахрысы.

Бәйрәмгали. Мин пит татар рецепты белән ясадым.

Шульдери (*тагын стаканнарга самогон сала да берсен Бәйрәмгалигә тоттыра, икенчесен үзенә ала*). Әйдә, энекәш, безнең дуслык өчен. Татар-чуаш дуслыгы өчен. (*Чәкештерәләр.*)

Бәйрәмгали. Түлке, абзый кеше, зинһар, эчкәч, акырма гына. Зинһар! Эчәм, акырма гына. (*Икесе дә эчәләр, исерешеп китәләр.*)

Шульдери. Менә син мине, энекәш, эчә дип уйлыйсың инде. Мин эчәммени, мин бит лечиться итәм. Миндә бит хәшәрәт аллергия.

Бәйрәмгали. Әйтәм җирле, эчкәч, калтырана-калтырана акырасың.

Шульдери. Бернинди дару да ярдәм итми. Бер стакан барматуханың бер килограмм димедролга караганда тәэсире әйбәтрәк икәнне син беләсеңме?

Бәйрәмгали. Юк, белмим.

Шульдери. Белмисең.

Бәйрәмгали. Не представляю.

Шульдери. Кешедә аллергия нәрсәдән була: кайсының җиләктән, кайсының чәчәктән, ә минем любой нәрсәдән килеп чыгарга может. Менә ни өчен мин этне тешләдем дә. Мин бит юри түгел, ә аллергиядән. Әле ярый, аның алдыннан гына ике стакан портвейн тондырган идем. Юкса эттән мине аерып алалмыйлар иде. Ә хәзер бераз лечиться итсен дә, инвалидность алып, тик рәхәтләнеп өреп ятсын. Ятам шулай чәчәкләр арасында, клумбада, беркемдә дә эшем юк. Ә бульдогларны җенем сөйми. Минем борын төбенә килде дә иснәнә, арткы ботын күтәрә, чыраен сыткан була, нәкъ минем бабайның, тестьның мине беренче күргәндәге кыяфәте.

Бәйрәмгали. Сволочь, диген.

Шульдери. Бабайга карата минем хранический аллергия. Аны күрүем була, аллергиям кузгала, кулларым кычыта башлый. Әгәр вакытында аларны бабайның аркасында кашый алмасам, кычыту аякларга да төшә. Мине мясокомбинаттан да аллергия аркасында кудылар. Ну бөтен дөньям кычыта. Әгәр күлмәк астына бер-ике, өч кило чи ит кыстырмасам, култык астына бавыр, охотничий колбаса белән чорналмасам... Аннары ике стаканны тондырасың да, и пошел. Проходнойдагыларның бит медицинский образованиеләре юк. Алар аллергиянең нәрсә икәнен белми.

Бәйрәмгали. Тупойлар!

Шульдери. Имеш, мин ни өчен сарык ите алып чыгам?

Бәйрәмгали. Сыер ите булмаганга.

Шульдери. Ничего подобного. Чөнки дуңгыз итеннән миндә аллергия. Әгәр наганы булмаса, мин аңардан отбивной ясаган булыр идем. Хатынга карата минем аллергия бик острый формада. Җитмәсә, көннән-көн көчәя бара. Ишектән кайтып керүгә, йөзенә карый алмыйм. Күзләр яшьләнә, тавышын ишетә алмыйм. «Акчаны кая куйдың?» — дип чырылдавы була, биткә кызыл тимгелләр бәреп чыга, куллар калтырый, баш тартыла башлый.

Бәйрәмгали. Их, бичара.

Ш у л ь д е р и. Эш мәсьәләсендә дә шулай ук. Бу эшемә кадәр эшләгән урыным культура паркында — карусель әйләндердем. Иртә белән карый гына алмыйм бит шул карусель-гә — күңел болгана. Ул тик тора, ә баш әйләнә.

Б ә й р ә м г а л и. Муен тирәли баш әйләнә...

Ш у л ь д е р и. Лечиться итә башладым. Өченче стаканнан соң аллергия тынычланды. Җиң сызганып эшләү теләге туды. Кем белгән, бәлки, башка напряжение биргәнмендер, бәлки, тизлеген арттырганмындыр, аны соң хәзер ничек тикшерәсең, карусель бит юк. Ишәккә атланган әбине Норильск янындагы кардан табып алдылар. Бер кыз утырган самолет әле дә булса Молдавия өстендә әйләнеп очып йөри, ди. Үзбәкләр утырган машинаны шәһәр читендәге ГАИ тоткан, тизлеген арттырган өчен. Әгәр дүртенче стаканны эчкән булсам, аллергия туктар, кешеләр бәлагә тарымаслар иде. Бәлки әле мин рубильникка да сузылып җитмәгән булыр идем.

Б ә й р ә м г а л и. Правильно! Совершенно верно!

Ш у л ь д е р и. Менә шуңа күрә дә, энекәш, мине, аллергиядән җәфа чигүче авыру буларак, мәҗбүри дәвалану шарты белән ликеро-водочный заводның клубына художественный руководитель итеп куйдылар да. Ә син миңа үзеңнең утиль самогоныңны мактап маташасың.

Б ә й р ә м г а л и. Әйдәле, Шульдери-Мөлдери абзый, тотыйк әле, шәп самогон бу. Брашкасына икмәкне колхоз амбарыннан юнәткән идем. *(Стаканны Шульдерига суза.)* Җирәнәсең?! Тавык тизәге салмаганга җирәнәсең. Шәп самогон бу, известь аркылы сөзелгән. Эчмисең, да?! Эчмисең?! Җырлап биргәнне кетә, чурты-матыр.

Алым жәл түгел сиңа, Шульдери абзый,
Гөлем жәл түгел сиңа, Мөлдери абзый.
Алым түгел, Чүлдери абзый, гөлем түгел, Мөлдери абзый,
Көмешкәм жәл түгел сиңа, Шульдери абзый!

*(Шульдерины кочаклап, алгы планга алып чыга.)* Без синең белән туганнар түгел микән, Чүлдери абзый.

Ш у л ь д е р и. Кит моннан, аллергиямне кузгатма, нинди туган булыйм ди мин сиңа!

Б ә й р ә м г а л и. Юк, мин синең күзләреңнән күреп торам, без синең белән туганнар. Синең әбиеңнең атасының баеның улы белән минем бабайның атасының ике туган малае туганнар булганнар. Без синең белән троераднуйлар!

Ш у л ь д е р и. Бик якыннар икән...

Б ә й р ә м г а л и. Әйе, син бит минем атамнан да кадерлерәк туганым. Батько бит син! Батько!

Туган авылым минем, куенында синең
Гөрләп үтте үсмер елларым.
Суларың хуш исле, урманың да тәмле,
Яратам мин туган авылымны.

Шульдери
Бәйрәмгали } *(икесе бергә).*

Суларың хуш исле, урманың да тәмле,
Яратам мин туган авылымны.

Шульдери. Кыздырма мине. Аллергия кузгалса, соң була.

Бәйрәмгали. Телисеңме, мин сине лечить итәм. Миндә бит биотоклар көчле.

Шульдери. Токлар...

Бәйрәмгали. Биотоклар! Кара минем учка. Ну, кара инде, их, Алла бәндәсе! Кыздырамы? *(Кулларын йомарлый.)*

Шульдери. Көйдерә. Чишенәсем килә башлады. *(Сугышырга җайлап, җиңен сызгана, түшен ычкындыра башлый.)*

Бәйрәмгали. Хап! Эләктең биотокларыма. Әнә чайкала ук башладың.

Шульдери *(йодрыгын йомарлап Бәйрәмгалинең борын астына китерә)*. Мин сине селкетеп кенә калмам, мин синең азау тешеңне суырырмын!..

Бәйрәмгали. Ышанмыйсың. Мин, беләсең килсә, авылда әллә ничә кешене лечить иткән экстрасеанс. Менә безнең күрше... Гөлсем җиде иргә чыкты, берсеннән дә авырга узмады. Ә мин бер генә кич кереп лечить иттем, шунда ук корсакка узды.

Шульдери. Бар, имгәк, утны сүндер, мин йоклыйм. *(Чыгып китә.)*

Бәйрәмгали. Хәшәрәт, бичара.

Музыка, ут сүнә. Талгын гына музыкага Шульдериның магнитофон тасмасыннан пышылдап кына тавышы ишетелә.

Шульдери. Нишләп йөрисең син?
Бәйрәмгали. Синең янга ятам.
Шульдери. Үз караватыңа ят.
Бәйрәмгали. Анда юеш.
Шульдери. Ничек юеш?
Бәйрәмгали. Аска пес-пес иттем.
Шульдери. Аңламыйм.
Бәйрәмгали. Балык тоттым.
Шульдери. Җәтмәңне әйләндереп сал.

Б ә й р ә м г а л и. Әйләндерерсең, бар, күтәреп кара син аны. Ярый инде, чукынма. Бер кичкә кер мичкә, ди. (*Шул ук музыка астында ут яна. Бәйрәмгали хатын-кыз рейтузыннан, шәп-шәрә, чалбар үтүкләп йөри, үзе җырлый.*)

Рукой замахнула у ворот,
Моя любимая.
Рукой замахнула у ворот,
Моя любимая.

Ш у л ь д е р и (*уяна, киерелә*). Нишлисең син? Әстәгъфирулла, нәрсә кидең син, энекәш?

Б ә й р ә м г а л и. Күзең чыккан мәллә, ыштан ич.

Ш у л ь д е р и. Кит, адәм тәганәсе, тизрәк чалбарыңны ки. Кеше-фәлән күреп калмасын!

Б ә й р ә м г а л и. Күрсә ни булган! Җылы ич ул, бумазый. Элеккеге патшалар шушыңа охшаш ыштан кигәннәр бит әле, оялмаганнар. Балагына бәби итәк куйсаң, аларныкыннан кай җире ким.

Ш у л ь д е р и. Зинһар, чалбарыңны ки, энекәш! Мине адәм мәсхәрәсенә калдырма.

Б ә й р ә м г а л и. Тукта, чалбарны үтүклим әле. Чалбарны аны теләсә кем үтүкли алмый. Әнә минем хатын 180 сыр салып бирә. Чалбар үтүкләргә көч-куәт, дәрт кирәк аңа.

Ш у л ь д е р и. Чалбар түгел, уха пешерәсең ләбаса. Бүлмәдә чыдар хәл юк, сидек-моча исе...

Б ә й р ә м г а л и. Анысы да ярый инде син йокыдан торышка.

Ш у л ь д е р и (*кинәт сикереп тора, өстендә сиксән алтынчы размерлы трусик*). Вәт сволочь! Вәт дуңгыз! Бөтен дөньямны юешләгән. Вәт сасы көзән, ондатра, дуңгыз ясап качкан.

Б ә й р ә м г а л и. Борчылма, абзый кеше, батып үлмәссең, астыңдагы трусигың бик мул күренә, караватыңа менеп бас та, трусигыңнан җилкән ясап, дөнья буйлап сәяхәт яса. (*Шульдери караватка сикереп менә дә трусигының ике балагын ике кулы белән читкә тарта, үзе халыкка.*) Бәреп үтерәм мин бу мөртәтне. (*Простыня күтәреп сәхнәдән чыгып китә, бераздан, индуслар шикелле җырлый-җырлый, сәхнәгә килеп керә.*)

Ш у л ь д е р и. Шәп җырлыйммы?

Б ә й р ә м г а л и. Шәп!

Ш у л ь д е р и. Шәп булмыйча, мин бит ликеро-водочный заводның клубында ун кешедән дуэт, сигез кешедән трио ясаган кеше.

Б ә й р ә м г а л и. Исең китмәсен. Мин өч кешедән һәрвакыт колхоз ясап торам.

Ш у л ь д е р и. Миндә бит абсолютный дар, абсолютный ритм,

абсолютный слух! Ә менә синнән американистлар художество ягыннан сездә ничегрәк, дип сорасалар, син нишлисең инде, имгәк?

Бәйрәмгали. Җырлыйм, биим, декламация сөйлим. «Кәҗә белән Гали»не.

Шульдери. Постой, киенеп чыгыйм әле. Тыңлап карарга туры килер. Йә үземне оятлы итәрсең.

Бәйрәмгали *(чалбарын кия-кия)*. И хәсрәт! Мине Карабаш Шалканбашевич өйрәтеп җибәрде шул.

Шульдери чыгып китә. Бәйрәмгали идән буйлап мүкәләп, учы белән идәнгә суга-суга, таракан куа. Сәхнәгә, киенеп, Шульдери килеп керә.

Шульдери. Нишләвең бу, энекәш?!

Бәйрәмгали. Нишлим, нишлим, таракан үтерәм!

Шульдери. Үзең белән ияртеп алып килгәнсеңдер әле.

Бәйрәмгали. Килгән. *(Һаман эзләнә. Тагын куа башлый. Аңа Шульдери кушыла.)* Качты, сволочь. Күралмыйм шуларны. Авылда да туйган алардан.

Шульдери. Бездә дә күп алар.

Бәйрәмгали. Үтереп бетерегез.

Шульдери. Үтерерсең, бар! Әллә нинди агулар сибеп карадым. Уйлап та бирми!!!

Бәйрәмгали. Агу белән таракан бетереп була димени? Син тараканны тот та әйләндереп сал. Күзенә көл яисә тоз сип. Үлә ул.

Шульдери. Бигрәк полоумный син.

Бәйрәмгали. Йә тотып ал да, корсагын кытыкла. Көлә-көлә дә егылып үлә ул.

Шульдери. Синең кебек бер дивана картның сүзен тыңлап, күрше-тирәнең тараканнарын үземнең фатирга җыйдым да инде...

Бәйрәмгали. Ничек алай?

Шульдери. Күршедәге Николай картка: «Өйне тараканнар басты», — дигән идем. «Син, энем Шульдери, аларны хәйлә белән бетер. Бездән бер-ике шырпы кабы тараканнар алып чык та үзеңнең фатирыңа җибәр. Алар безнекеләр белән сугышып, берсен-берсе үтереп бетерерләр»,— ди. Шулай эшләдем дә. Алып чыктым мин болардан биш шырпы кабы таракан. Иртән торсам, иртән торсам...

Бәйрәмгали. Йә шуннан, торсаң...

Шульдери. Бөтен өйне таракан баскан. Араларыннан берсе — озын мыеклысы: «Әй, хуҗам, Шульдери иптәш, күрше Николайларның тараканнары безгә бәреп кергәннәр иде, яртысын кырып, яртысын пленга алып кайттык әле»,— ди. Шуннан күрше картка, Николайга йөгердем.

Б ә й р ә м г а л и. Ә ул нәрсә ди?

Ш у л ь д е р и. Главарьларын үтерәсең калган, командирлары үлгәч, таралган булырлар иде әле, ди. Төне буе сакладым теге озын мыеклы сары командирны. Иртә белән, таң беленгәндә генә, тапочка белән бәреп үтердем. Иртән җиделәр тирәсендә уянып китсәм, өйдәге тараканнарның чиге юк. Хатынның елап җибәрүе булды, бер тараканның сөйләп җибәрүе булды: «Алай бик бетерешмәгез әле,— ди.— Нишлисең бит, үлгән артыннан үлеп булмый. Безгә дә бик авыр, түзәбез. Менә шул мәрхүмнең поминкасына бөтен авылның тараканнарын җыйдык. Озакламый күрше авыллардан да килеп җитәрләр»,— ди.

Б ә й р ә м г а л и. Алла боерса, син моннан әйләнеп кайтканчы, тирә-як республиканың бөтен тараканнары синдә була икән.

Ш у л ь д е р и. Ярый, телеңә салынма. Тозсыз! Мин ликероводочный заводның клубында художество җитәкчесе буларак, сине җырлатып карарга телим. Йә, нәрсә җырлыйсың?

Б ә й р ә м г а л и. Минем шул инде, колхоз тормышы, комбайн турында.

Ш у л ь д е р и. Яхшы. Комбайн турында бата.

Б ә й р ә м г а л и *(җырлый башлый)*. Комбайн ура икмәкне... Кам...

Ш у л ь д е р и *(кулы белән ишарәләп, Бәйрәмгалине туктата)*. «Си», энекәш, «си»!

Б ә й р ә м г а л и *(аптырап)*. Мондамы? Кит аннан, көпәкөндез шыр аек килеш... урамга чыгам.

Ш у л ь д е р и. Юк инде, энекәш. «Си» — минор, мажордан башла.

Б ә й р ә м г а л и. Абзый кеше, мин силәрне, миләрне белмим, минеке туп-турыга туп пошел. *(Җырлый.)*

Комбайн ура икмәкне, комбайн ура икмәкне...
Өйләнергә уйлаган идем, кызым булды корсаклы...

Ш у л ь д е р и. Батмый, энекәш. Менә син миннән, профсуиналдан кара. *(Җырлап җибәрә.)*

Тагын ямьле язлар килде,
Урман, сулар уянды.
Кыр үрдәкләре кайттылар,
Бәбкә үстерергә туган ояларына.

К у ш ы м т а:

Кыр үрдәге кача камышка ла,
Сине сагынып җырлаган тавышка.

Кыр үрдәкләрен санадым
Зәңгәр күл өсләреннән.
Бер минутка, бер секундка
Чыкмыйсың исләремнән.

Кушымта.

Йә, ничек?

Бәйрәмгали. Шәп... Чыннан да сибәсең син.

Шульдери. Теге җырың батмый. Тагын нинди җыр беләсең?

Бәйрәмгали. Менә мондый җырым бар. Бәйрәмгали Бәдруллин музыкасы һәм сүзләре. «Дим-дим».

Шульдери. Туктале, энекәш, син көйләр дә язасыңмыни?

Бәйрәмгали. Халык яза, халык ул — мин! *(Җырлый.)*

Җилфер-җилфер, дим-дим,
Йөргән чакта, дим-дим,
Җилләр ача куенымны.
Янып-көеп, дим-дим.
Йөргән чакта, дим-дим,
Дуслар ача күңелемне.

Җилфер-җилфер, дим-дим,
Ука-чуклар, дим-дим,
Ник җилферди, җил дә юк?
Синең кебек, дим-дим,
Матур ярлар, дим-дим,
Авылда түгел, илдә юк.

Җилфер-җилфер, дим-дим...

Шульдери *(бүлдереп)*. Слушай, тукта! Тынычлан, шартлыйсың бит, дивана. Муеныңдагы кан тамырың өзелә бит. Син нәрсә, Габдулла әкә Рәхимкулов булып эшләдеңме әллә?

Бәйрәмгали. Юк, Карабаш Шалканбашевичның яраткан җырчысы ул.

Шульдери. Менә сездә, татарларда, кем әле ул, единственный шәп җырчы?

Бәйрәмгали. Азат Аббасовмы?

Шульдери. Юк...

Бәйрәмгали. Эмиль Җәләлетдиновмы?

Шульдери. Юк ла инде, теге...

Бәйрәмгали. Ә-ә, Мөнирә Булатовамы?

Шульдери. Теге-теге, кем соң әле, урысча җырлый.

Бәйрәмгали. Ә-ә-ә... *(Җырлап күрсәтә.)*

Нигә күк көн саен зәп-зәңгәр, гел зәңгәр?
Сагышлы зәңгәрлек сибелә күзләрдән.

Кушымта:

Сөйсәң син әгәр дә —
Сагыш бар зәңгәрдә.
Зәңгәр күк, зәңгәр күк,
Зәңгәр моң, мәхәббәт
Сагыштан тора ул.

Нигә таң көн саен гел алсу, гел алсу,
Таңнарда нигә соң һәрвакыт ямансу?

Кушымта:

Сөйсәң син әгәр дә —
Таң — алтын мәгарә,
Алсу таң, алсу йөз,
Алсу моң, мәхәббәт
Шатлыктан тора ул.

Әйе, әйе, нәкъ үзе, Ибраһимов.

Шульдери. Менә, ичмасам, бу җыр! Күңелләр тулып китте. Зәңгәр диме? Менә шушыны җырларсың. Түлке, энем, сәхнәдә үзеңне артистичный тота белмисең. Менә миннән өйрән. *(Сәхнәдә вак-вак адымнар белән арт санын уйнатып, «зәңгәрләр»чә чыга да җырның кушымтасын җырлый. Ике сүз саен «зәңгәрләр»гә ишарә ясый.)*

Зәңгәр күк *(ишарәләп)*, зәңгәр күз *(ишарәләп)*,
Зәңгәр моң...

Энекәш, менә бу ишарәне калдырма. Бик күп артистлар шушы жест аркасында зур уңышларга ирештеләр, зур-зур исемнәр алып бетерделәр. Ну-ка, повтори!

Бәйрәмгали *(аныңча алгы планга чыга да ым ясый)*. Булмый миннән.

Шульдери. Менә, кара. *(Тагын чыгып күрсәтә.)* Ну-ка, кабатла.

Бәйрәмгали *(тагын чыгып карый)*. Юк, булмый.

Шульдери. Тиз генә булмый ул, энекәш. Аның өчен шулай пластичный булып туарга кирәк. Ничего, мин сине өйрәтермен әле. Мин бит сезнең халыкны үлеп яратам. Сезнең гореф-гадәтләрегезне, бәйрәмнәрегезне яратам. Сезнең сабан туйларыгыз да ни тора! Аркан тартышу дисеңме, чүлмәк вату дисеңме, ә ул капчык киеп узышуга ни җитә?! Әйдә, булмаса, капчык киеп бер дөнья әйләнәбез, әмирикәнистләрнең күзе шар булсын.

Б ә й р ә м г а л и. Шәп булыр иде дә, капчыклар каян аласың?

Ш у л ь д е р и. Юкка башыңны ватма. Мин алдан ук хәстәрен күреп, әзерләнеп килдем. *(Чемоданыннан дүрт капчык ала да берсен Бәйрәмгалигә ыргыта.)* Мә! Әйдә минем белән. *(Тамаша залына чыгып, ике тамашачыга капчык кидертәләр.)* Болар әмирикәнистләр булыр.

Б ә й р ә м г а л и. Буржуйлар! *(Шульдери үзенә төбе тишек капчыкны кия, дүртесе дә тезелеп басалар. Шульдери муенына асылган свистокны кычкыртып җибәрә, тегеләр сәхнәгә таба чабалар.)*

Ш у л ь д е р и *(сәхнәгә беренче булып менә, халыкка)*. Берсе дә күренмиме? Барысы да калганнар! Красота! Эх, яратам да соң капчык киеп узышлы уйнарга. Шту син, канат тартуны исәпләмәгәндә, иң акыллы эш. Кызганычка каршы, монда коры. Яңгыр яуганда тагы да кызыграк. Син пычрактан элдертәсең генә, ә арттагы кешенең йөзенә балчык чәчри. Ул, күзен йомган килеш, гөрс башы белән әтәч баганасына. Бух! Тәгәри-тәгәри эчеңне тотып көләсең. Кызык бит, ә? Шундый кызык...

Б ә й р ә м г а л и *(сәхнәгә артыннан менеп)*. Кызык түгел, син капчык түгел, киндер итәк киеп чаптың. Хәрәмләштең син.

Ш у л ь д е р и. Менә син кызык түгел, дисең. Синең, кулларыңны артка куеп, торт ашаганың бармы? Мин аны ял йортында күрдем. Менә, ичмасам, уен! Ышанасыңмы, бер-ике килолы торт.

Б ә й р ә м г а л и. Ун килолысы булсын, кирәге юк.

Ш у л ь д е р и. Бисквитный, кырыйларында роза чәчәкләре...

Б ә й р ә м г а л и. Гөлҗимеш чәчәкләре булсын, ә, иркәм.

Ш у л ь д е р и. Кайберләре башлары белән бух, тортка! Авызда — бисквит, күзләрдә — крем, колакларда — роза чәчәкләре! Бернәрсә дә күрмим, бернәрсә дә ишетмим, бернәрсә дә әйтмим. Вот, ичмасам, көлке. Тәгәри-тәгәри көләсең...

Б ә й р ә м г а л и. Шуның ни кызыгы бар?

Ш у л ь д е р и. Җенем сөйми синең кебек җитдиләнеп маташкан кешеләрне. Нәрсәдер уйлаган булып кыланасыз! Ә нәрсәгә уйланырга?! Нәрсә уйларга?! Күптән бит инде бөтенесен дә уйлап тапканнар.

Б ә й р ә м г а л и. Тапканнар, тот кишеремне...

Ш у л ь д е р и. Күңел ачасың килә икән, энекәш, рәхәтлән! Теләсәң, пиво эч, теләсәң, кәҗә уйна, шалбанга! *(Шалт итеп Бәйрәмгалинең башына чиртә, халыкка.)* Туң баш! Теләсәң, энекәш, приемникны бөтен көченә акырт, күңел ач, рәхәтлән. Инде тагын нәрсә дә булса эшлисең килсә, нәрсәгә булса да бәхәсләш.

Б ә й р ә м г а л и. Нәрсәгә?

Шульдери. Нәрсәгә бәхәсләшсәң дә ярый. Вакыт кына күңелле үтсен. Менә мин үземнең дус белән көн дә бәхәсләшәм, шундый күңелле бәхәсләр килеп чыга, шаккаткыч. Беркөн шулай дус белән ишегалдында сөйләшеп утырабыз. Дөньяда ирләр күбрәкме, әллә хатын-кызлармы?

Бәйрәмгали. Кәнишне, хатын-кызлар. Безнең авылда бер бабайга унике әби.

Шульдери. Ә ул, ирләр күбрәк, ди. Ә мин үзем синең фикердә. Хатыннар күбрәк, дим. Әйдә, мин әйтәм, бер меңнән бәхәсләшәбез. Ишегалдына беренче булып кем керә, ир кешеме, хатын-кызмы? Көтәбез. Кич буе көтеп утырдык.

Бәйрәмгали. Шуннан?

Шульдери. Беркем дә юк, инде караңгылана башлады. Кинәт бер шәүлә килеп керде.

Бәйрәмгали. Тәк-тәк, шуннан, шуннан?..

Шульдери. Ныклабрак карасак, ныклабрак карасак... Эт булып чыкты. Без ул этне ике сәгать буе куып йөрттек.

Бәйрәмгали. Нигә?

Шульдери. Хатынмы, ирме икәнен белергә. Ул кич искиткеч күңелле үтте. Ике сәгать йөгердек. Вәт ичмасам ял дисәң дә ял! Энекәш, минем табигатем шундый. Уен-көлкесез яши алмыйм. Бер тапкыр эштә утырып торам шулай, бик күңелсез булып китте. Юк, мин әйтәм, болай булмый. Срочно нәрсә булса да уйлап табарга кирәк. Өскә күтәрелдем дә главбухка кердем. Начар, мусорный кеше, язвенный, кырыс. Ишеттеңме, мин әйтәм, слесарь Терехин акылдан язган. Кувалда күтәреп, кешеләр кыйнап йөри. Бухгалтерның коты очты. «Скорый»га шалтыратырга кирәк, алып китсеннәр тегендә», — ди. Мин әйтәм, миңа нәрсә, мин кисәттем, теләсәң нишлә. Аска төштем дә слесарьны эзләп таптым. Бар, мин әйтәм, сине бухгалтериягә тишек тишәргә чакырдылар. Слесарь кувалда алды да менеп китте тегендә. Бухгалтерның тегене күрүе булган: «Каравыл, үтерәләр!» — дип чыгып сызуы булган. Эх, көлдек тә соң туйганчы. Бухгалтерны аңына китерү өчен хәтта врач та чакырдылар. Аңламый ул шаяртуны, арифмометр! Шул хәлләрдән соң директор мине эштән куды. Надан! Жулик! Юмор аңламый!

Бәйрәмгали. Дундук, диген.

Шульдери. Эх, энекәш, үз гомеремдә никадәр креслолар алмаштырдым мин. Барлык урында да шул үземнең юморный булуым аркасында янам.

Бәйрәмгали. Аңлыйм, абзыкай, минем үземнең дә баштан күп узды.

Шульдери. Мин, энекәш, юморный гына түгел, өстәвенә

артык инициативный да. Натурам шундый. Әле дә исемдә, обойлар фабрикасында директор булып эшләдем. Обойларның кыяфәтләрен үзең беләсең.

Бәйрәмгали. Шакмаклы да чәчәкле...

Шульдери. Адәм баласына нинди шатлык бирә инде ул обойлар. Мин яңа обой уйлап таптым.

Бәйрәмгали. Ниндине?

Шульдери. Акча рәсеме төшерелгәнне.

Бәйрәмгали. Кит аннан?!

Шульдери. Күз алдына китерәсеңме? Стенада биш меңлекләр, ун меңлекләр: кешенең күзгә карап кәефе күтәрелә. Кесәдә шалтырап торган сукыр бер тиен юк, ә өй эче тулы акча... Барысын да халык өчен эшләдем.

Бәйрәмгали. Киләчәк өчен.

Шульдери. Бер диванасы кибеттә ун меңлекне ертып алган. Кассир әйтә икән: «Бу нинди яңа акча? Бер ягы ак, икенче ягы кызыл?» Теге әйтә ди: «Миңа как рас бер ак белән бер кызыл ликер кирәк»,— дип... «Сиңа кирәктер дә, акчаң әллә нинди, беренче күрәм мондыйны». Винога чират торучылар арасында яңа акча чыккан икән дигән хәбәр таралган. Күбесе куркуга төшкән. Берсе алып килгән буш шешәләрен кире алып кайтып киткән. «Акчаның нинди буласы билгесез, ә шешә ул мал, недвижимость»,— ди икән. Бер әби әйтә ди: «Мин точно беләм, акча алмашыначак. Өч йөз меңнән артык булса, алалар икән, ә ким булса, өстәп бирәләр». Милиция килеп җиткән. «Каян алдың бу акчаны? Үзең ясадыңмы, әллә ярдәм итүчеләр булдымы?» Теге әйткән: «Мин түгел, обойлар фабрикасында ясыйлар»,— дигән. Шуннан мине, пальшивый манетчик дип, ел ярымга ирегемнән мәхрүм иттеләр.

Бәйрәмгали. Әй, бичара. Аннан кайткач нишләдең?

Шульдери. Төшеп калмадым. Мунчага директор булып урнаштым. Дөресен әйткәндә, халык мунчага начар йөри, һәрберсенең өендә ванна. Мин мунчага капитальный ремонт ясаттым. Хәзер бит безнең промышленность яңа пыялалар чыгара. Бер ягыннан карыйсың, күренә, ә икенче ягыннан күренми. Мунчаның иске стенасын җимертеп, шундый пыялаларга алыштырттым. Эчтән күренә, ә тыштан юк. Минем бәхетсезлеккә, исерек строительләр пыялаларын киресенчә куйганнар. Бер карауга барысы да әйбәт кебек. Мунча эчендә юыналар, чабыналар, алар бернәрсә дә белмиләр дә, күрмиләр дә. Ә тыштан аермачык. Шәһәргә «комната смеха» да кирәкми. Мунчадан юынып урамга чыккач, тегеләрне таныйлар. Браво! Афәрин! дип, кул чабалар. Аны-моны аңлаганчы, мине мунчадан яфраксыз мунча себеркесе белән кудылар. Хәзер менә ликеро-во-

дочный заводның клубында художественный руководитель булып эшлим. Җиде кешедән — дуэт, унике кешедән трио ясадым. Алда планнар зурдан. Белмим, күпме тотарлар.

Б ә й р ә м г а л и. Сезгә, шәһәр кешесенә җиңел, атна саен эш алыштырып була. Менә безгә, авылдагыларга нишләргә? Мин үзем дә завферма булып эшләгән идем бит. Карыйм, сыерлар ничектер эленке-салынкы, кыяфәтсезләр. Аларны көн саен җиде чакрым көтүлеккә куалар икән. Янында гына колхоз бакчасы була торып, ә анда менә дигән сусыл колмак үсә. Кудырттым сыерларны бакчага... Ашаганнар туйганчы колмак. Тегеләрне танып булмый. Абзарга килеп керсәм, сыерларның кәефе шәп, дояркалар белән бер өстәл артында. Берәүләре җырлый, икенчеләре мөгри, ә көтүче ни Аллага, ни муллага... Ветеринар үгезне кочаклаган да: «Вася, безнең колхозда ике генә чын ир бар, берсе — син, икенчесе — мин»,— ди. Безнең сыерларның сөтенә кибетләрдә чират башланды. Күрше авыллар килеп тулды. Район хуҗалары бездән китмәс булдылар.

Ш у л ь д е р и. Кирәк бит, ә?!

Б ә й р ә м г а л и. Хәтта элек сөткә әйләнеп тә карамаган кешеләр өч борынга бер шешә ала башладылар. Трактористлар иртән берәр кружка парной сөтне җибәрәләр, әбәт җиткәнче бөтен кырны сукалап, чәчеп, өстенә асфальт җәеп куйганнар. Шуннан мине председатель чакыртып алды да: «Син лутче тракторга утыр да фермадан тирес ташы»,— дип чыгарып җибәрде.

Ш у л ь д е р и. Карале, энекәш, минем нигәдер карын ачып китте. Бар, булмаса, кибеткә чыгып кер.

Б ә й р ә м г а л и. Минем бит әле авылдан килгән йомыркаларым бар.

Ш у л ь д е р и. Кирәкмәс, энем. Кирәкмәс, Алла сакласын! Биредә атнага якын ятабыз, ул күкәйләреңнән әллә нинди исләр киләдер.

Б ә й р ә м г а л и. Исең китмәсен, абзый, монда килер алдыннан гына мунча кердем. Ярый, синеңчә булсын. Мин хәзер. *(Чыгып китә.)*

Ш у л ь д е р и. Вәт дуңгыз, ишеген дә япмады. Үз авылы дип уйлагандыр. Моны бирегә җибәргән хуҗа Америкада пленда булгандыр. Юкса адәм рәтле кеше җибәргән булыр иде. Каян башларына килгән дә, каян эзләп тапканнар бу маймылны?! Чыгып адашса гына ярар иде. *(Алгы планга килә дә тамаша залына карап.)* Америка, диләр, Америка! Бер карасаң, табигатьләре өч тиенгә дә тормый. Безнең Чувашстанга җитәме соң! Табигатьне сакларга кирәк, дип, тел чайкаган бу-

лалар, буржуйлар! Табигатьне сакларга — кемнән? Кешене табигатьтән сакларга кирәк! Ә урманнарда күпме зверь үрчеде. Алар инде урманга гына сыймыйлар, асфальтка чыга башладылар. Шосседагы знакларны гына кара. «Сак бул — лось!» Ул лосьлар хәзер бөтенләй хайванга әйләнделәр. Безнең начальник үзенең дачасына барганда, служебный «Волга»да бара. Лось тегенең «Волга»сына таран ясаган. Үзенең мөгезе төшкән, ә начальникка үскән. Күптән түгел, монда килер алдыннан, барам шулай урманнан, күке кычкыра. Мин әйтәм, күке, күке, әйт әле, Шульдери абзаңа күпме гомер калган? Алты сәгать, илле ике минут, ди. Хәзер бит аның охотасы да мылтык белән түгел, фотоаппарат белән. Әнә минем брат охотага чыккан фотоаппарат белән. Фотоохотник! Тегенең каршына аю килеп баскан. Ба-бах, тегенең ике күз уртасына фотоаппарат белән. Аю аны үтерүен үтермәгән, ә фотокарточкасын бозган... Хәзер минем братның башы алтыга тугыз сантиметр, паспорттагы кебек. Кая карама табличка. «Охота тыела, боланнарны саклагыз!»; «Кабан дуңгызы синең дустың!» Дус... Күптән түгел мин ул дустан көчкә котылдым. Әле хәзер дә вакыт-вакыт тотлыгам. Ярар, мин кабанның дус икәнен белдем дә ди. Ә ул кабан аны беләме соң? Аңа хәтта пуля да керми. Ул бит броневик кебек. Шулай бервакыт ямадым тегенең күзенә таш белән. Дөмекте бу, мин әйтәм. Юк, сикереп торды да мине урманнан шәһәргә куып алып китмәсенме?! Әле ярый тегенең борын төбендә лифт ябылып өлгерде. Күз алдына китерәсезме, ул мине күпме куып алып килде? Мин лифт белән, ә ул баскыч буйлап, арымый да бит, сабакы! Мин квартирама кереп бикләндем, ә теге ишекне дөбердәтә. Хәзер, мин әйтәм, ишекне җимереп керсә, квартирамны тетеп бетерәчәк. Чуен табаны алдым да, ишекне ачып, бах-бах!.. Ә ул минем хатын булып чыкты. Куллары буш булмагач, аяк белән ишекне дөбердәткән. Су сибеп, көчкә аңына китердем. Маша, Машенька, мин әйтәм. Гафу ит, мин сине кыргый кабан дип торам. Мин түгел ул кыргый кабан, син ул кыргый хайван! ди. Аның балыгы да шулай ук. Искә аласы да килми. Бер тапкыр балыкка кармакны салдым гына, ә ул төпкә зләкте. Нишлисең, анадан тума чишендем дә кереп киттем суга. Чыксам, киемнәрдән җилләр искән! Проездной гына калган. Тиз генә урманга кереп, яфраклардан пояс ясадым. Киттем папуас кебек станциягә. Электричкадан чыккан халык миннән читкә тайпыла, ә үзләре сер бирмәгән була. Бәлки, артисттыр, кинога төшүче, йә булмаса, иностранец, бәлки, Миклухо Маклайдыр дип уйлыйлар, күрәсең. Минем бәхетсезлегемә каршы, бер карчык кәҗә алып бара икән. Мин тәрәзәдән карап барган арада,

минем поясны кәҗә ашаган да бетергән. Басып калдым шәпшәрә. Электричкадан чыгуым булды, метеор кебек өйгә кайтып керүем булды, проездной белән капланып... Табигатьне кулдан ычкындырырга ярамый, нык тотарга кирәк.

Бәйрәмгали (*кайтып керә. Өстендә яңа костюм, кулында сетка тулы консервалар*). Абзыкай, хатамны төзәттем. Менә яңа кәчтүм алып кидем. Шалкан бәясе генә.

Шульдери. Нинди кибеттән алдың син бу костюмны?

Бәйрәмгали. «Ритуальный услуг» дигән кибеттән.

Шульдери. Тинтәк! Долларларыңны бетердеңме?

Бәйрәмгали. Бетсә, син биреп торырсың әле, кайткач түләрмен.

Шульдери. Ахмак, бу бит үлгән кешеләр өчен.

Бәйрәмгали. Булыр инде, үлгән кешегә кәчтүм нәрсәгә? Аның Әмирикә урамында йөрисе юк!

Шульдери (*күзе сеткадагы консерваларга төшә*). Энем, син нәрсәләр алдың?

Бәйрәмгали. Нәрсә булсын, консерва ич. Әллә күзең чыкканмы?

Шульдери. Нигә боларны алдың, тинтәк?

Бәйрәмгали. Арзан... шалкан бәясе торганга!

Шульдери. Бәхетеңне кәҗә сөзсә... соң бит бу консервалар этләр, мәчеләр өчен.

Бәйрәмгали. Булыр инде, этләр, мәчеләр өчен ит консервасы чыгарырлар. Итнеке ич алар. Безнең авылда кильки консервасын да сугыш ветераннарына гына бирәләр.

Шульдери. Әнә, күзеңне ныклабрак ачып кара, мәче, эт сурәте төшергәннәр. Үләм, ашказаным килеп чыга. Духтыр чакырт. Уф, үләм! (*Укшый-укшый идәнгә тезләнә.*)

Бәйрәмгали. Үлә күрмә, хәзер чакырам. (*Йөгереп чыгып китә. Ут сүнә. Музыка. Ут янганда, Шульдери идәндә, Бәйрәмгали өстәл өстендә утыра.*)

Шульдери. Каһәр суккан духтыр, долларларымны кырыпсыпырып алып чыгып китте. Инде нишлибез? Синең бераз булса да калмадымы, ачка үләм.

Бәйрәмгали. Каян калсын, үзең беләсең, минем өстә мәетләр кәчтүме ич, кесәсез.

Шульдери. Безгә бер генә юл калды: урамга чыгып хәер сорашырга.

Бәйрәмгали. Ә кем сорый?

Шульдери. Син! Теге орденлы киемеңне киясең дә, авызыңны күккә элеп, тешләреңне ыржайтып, урам почмагына чыгып утырасың. Иманым камил, сине кызганып хәер бирәчәкләр.

Б ә й р ә м г а л и. Юк инде, үзең сора, миннән булмый.

Ш у л ь д е р и. Соң, энем, акылың булса, уйлап кара, бу киемнәрем белән кем миңа хәер бирсен. Мине капиталист, миллионер дип уйлаячаклар. Ә менә син нәкъ үзе, диванага охшагансың.

Б ә й р ә м г а л и. Син үзең дивана!

Ш у л ь д е р и. Туган илгә кайтасың килсә, сорарсың. Минем Әмирикәдә иммигрант бабам яши, ничек тә үзен эзләп табармын. Ә син, энем, үз ягыңны үзең кара. Дүрт ягың кыйбла.

Б ә й р ә м г а л и. Абый җаным, зинһар, ташлама! Сорыйм, син ни кушсаң, шуны үтим, зинһар, ташлама!

Ш у л ь д е р и *(халыкка)*. Тинтәк, ничек ташлыйм, коткарсаң, син генә коткарасың инде мине.

Б ә й р ә м г а л и *(җырлый)*.

Эләкте безнең башлар,
Терәлде безнең эшләр.
Эләкте безнең башлар,
Терәлде безнең эшләр.
Хәер эстәп, хәер сорап,
Яшәргә калды көннәр.

Ш у л ь д е р и *(җырлый)*.

Ал кулыңа капчыгың,
Туган илнең янчыгын.
Ал кулыңа капчыгың,
Туган илнең янчыгын.
Син акыллы, бул дивана!
Хәерне син табучы!
Син акыллы, бул дивана!
Хәерне син табучы!

*(Бәйрәмгали аркасына рюкзагын аса, аны Шульдери култыклый.)*

Ш у л ь д е р и. Борчылма, энекәш, җәяүләп булса да, берничә елдан, дөньялар үзгәргәч, туган илгә кайтырбыз әле. Ул илдә безгә барыбер әлегә рәт юк.

Музыка. Икесе дә, сөйрәлеп, авыр адымнар белән сәхнәдән чыгып китәләр.

П ә р д ә

## Эчтәлек


Ак күгәрчен. *Драма* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Гыйләҗ тәрәзәләре. *Драма* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Өзелгән йөзем. *Драма* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Язмыш. *Драма* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Узып барышлый. *Моңсу драма* . . . . . . . . . . . . . . 114
Күтәреп килгән яңгыр. *Публицистик драма* . . . . . . . . 146
Кызлар капкыны. *Комедия* . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Мөгез. *Комедия* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Бәхетеңне кәҗә сөзсә. *Комедия* . . . . . . . . . . . . . 253

Литературно-художественное издание

*Салихов Данил Хабибрахманович*

**Окна Гиляза**

(Пьесы)

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы *Р.Р.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.07.2004. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 15,12 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 16,38.
Нәшер-хисап табагы 16,91 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Э-518.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.